# КАЗАН УТЛАРЫ

3
МАРТ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**3**

МАРТ
1979

## Бу санда

Ә. ЕНИКИ. Тынычлану. Хикәя . . . . . . . . . 3
К. БУЛАТОВА. Апрель керде җиргә. Шигырьләр. 23
Л. ШАКИРҖАНОВА. Без — хатын-кызлар ич. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 26
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Гөлбадран. Повесть . . . 30

ОЧЕРКЛАР

Л. ИХСАНОВА. Стелла — йолдыз дигән сүз . . . 82

И. ҖӘЛИМУЛЛИНГА 50 ЯШЬ

И. ҖӘЛИМУЛЛИН. Бунтарь портреты янында. Поэмадан өзек . . . . . . . . . . . . 90

ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Ә. МИРЗАҺИТОВ. Бөек Октябрь һәм Башкортстан әдәбияты . . . . . . . . . . . . . 93
М. КӘРИМ. Туган илем! Шигырь . . . . . . 96
С. КУДАШ. Гомер сәрәсем килә. Шигырь . . . 97
Н. НӘҖМИ. Башкортстан. Шигырь . . . . . . 98
Х. ГЫЙЛӘҖЕВ. Әҗәл белән айкашканда. Шигырь 99
М. ГАЛИ. Ышанам. Шигырь . . . . . . . . 100
Ш. БИККОЛ. Озата кил. Шигырь . . . . . . 101
Г. РАМАЗАНОВ. Дүрт мәхәббәт. Шигырь . . . 101
Ә. АТНАБАЕВ. Горурлык. Шигырь . . . . . . 102
Р. БИКБАЕВ. Башкортстан моңда башлана. Шигырь . . . . . . . . . . . . . . . . 103
Р. НАЗАРОВ. Башкорт. Шигырь . . . . . . . 104
Р. ХИСАМЕТДИНОВА. Буранбай. Шигырь . . . 105
Ф. ИСӘНГОЛОВ. Агыйделнең аръягында... Хикәя 106

СӘНГАТЬ

Т. ӘЙДИ. Тылсымлы сурәтче . . . . . . . . 114

Ә. ЕНИКИГӘ 70 ЯШЬ

Ф. САФИУЛЛИНА. Рухи матурлык җырчысы . . 122

КПССның ТАТАРСТАН өлкә КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Ә. ДАВЫДОВНЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

**Ә. БАЯНОВ.** Вакыт сурәтләре . . . . . . . . . 128

Г. СӘГЪДИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

**Э. БАРИЕВА.** Галим һәм тәнкыйтьче . . . . . . 135

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Р. ШӘРИПОВ.** Мөхәммәдьяр иҗатында бәхет мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . 141

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**З. МАНСУРОВ.** Йөрәк уйлый да белсен . . . . 146
Укучылардан хатлар . . . . . . . . . . . . 152

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Х. ЗАРИПОВ.** Бу — безнең туган халкыбыз . . . 156
**Р. МӨХӘММӘДИЕВ.** Якутлар табыладыр вакыт белән . . . . . . . . . . . . . . . . 160

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Ш. ГАЛИЕВ.** Хикмәтле сүзләр . . . . . . . . 166

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**Р. МИҢНУЛЛИН.** Мияулый торган ишек. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 182

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Лафонтен мәсәлләре . . . . . . . . . . . . 184

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**ФӘТТАХ.** Эшчән һәм турылыклы дустыбыз . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-63, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 21/XI-1978 ел. Басарга кул куелды 6/II-1979 ел. ПФ 07013. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83 549 экз. Заказ В-391. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

Әмирхан Еники

# ТЫНЫЧЛАНУ

хикәя

## I



Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә дә башлар икән? Гаҗәп! Хәттә төне дә җиңеллек китермәде — суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан, асфальт исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да, йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең, мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!..

Гасыйм Сәләхович та шәрә килеш диярлек киң караватының читенә таянып, күзләрен дә ачарга иренеп, тик кенә утыра. Әллә ялкаулыктан, әллә хәлсезлектән? Икесе дә бардыр, ахрысы. Шулай да ялкаулыгы хәлсезлектән иде. Хәлсез булганга күрә, аның кыл да кыймылдатасы килми. Чөнки ул бик начар йоклады, тирләде-пеште, әйләнде-тулганды — һаман да шул әшәке эсселек аркасында. Әмма сәбәп бер аңарда гына түгел иде шикелле... Төп сәбәп йөрәгендә булса кирәк — йөрәге таза түгел иде Гасыйм Сәләховичның...

Менә хәзер дә ул, караватыннан кузгалырга кыймыйча, гүя йөрәгенә колак салып утыра. Нишли, ничегрәк «тота» үзен — ул тәндәге тере җан? Көйсезләнмиме, ялгышмыймы, хәрәкәт итүе ничегрәк? Шуны әйтергә кирәк, соңгы вакытларда йөрәге аның нәкъ менә йоклаганда яки уянгач үзен ныграк сиздерә башлады. Нидән, ни өчен?.. Бүгенгесен бөркү һава, начар йокыдан да күрергә мөмкин, ә башка көннәрдә? Бу хәл, билгеле, Гасыйм Сәләховичны борчый, кәефен боза, куркытып та куя иде. Ярамый бит болай, ди ул үз-үзенә, бер җитди хәтәрне сизгәндәй, һәм, бөтен эшен ташлап, бүген үк врачка күренергә кирәк дигән карарга килә. Ләкин шулай дисә дә ул бармый, күренми. Чөнки эшеннән аерыла алмый, ә врачка бару үзе бер мәшәкать, аннары — иң гаҗәбе — йөрәк үзе дә тынычлана, «хуҗасын»

бер дә диярлек борчымый башлый. Гүя «хуҗасының» эше, хәрәкәте, кайгысы аңа да күчә, ул да шуларга көйләнә, җайлаша, гүя үзен юри оныттырып тора. Кыскасы, яраклаша белә йөрәк кешегә!

Тик менә кеше үзе еш кына йөрәге белән хисаплашмый. Борчый, җәберли, оныта бичараны еш кына! Сәбәпләре моның кырык төрле — санап кына чыгарлык та түгел. Гадәттә кешенең үзен гаеплиләр, «саклый белмәде йөрәгенң», диләр. Әмма кеше үзе генә саклый ала микән соң аны? Иң элек кешенең үзен сакларга кирәк түгелме икән?

...Икенче атна инде Гасыйм Сәләхович өч бүлмәле квартирасында япа-ялгыз яши. Хатыны больницада, улы Кырымга китте. Ирексездән төрлесен уйларга туры килә аңа ялгызлыкта. Бигрәк тә бүгенге шикелле иртәдән үк йөрәгенең хәлсезлеген сизеп торган чакта. Ул бит бала түгел, үз хәленең җитдилеген аңлый торган кеше. Ярый, әллә ни булмасын да ди, ләкин шулай да... Һәм мондый минутларда Гасыйм Сәләховичның күңелендә хатыны белән улына карата ирексездән рәнҗү хисе уяна. Дөрес, сирәк уяна, әмма ялгызлыгын тирәнрәк сизгән һәм күңеленә төрле шомнар килгән чакта уянмыйча калмый иде. Белергә теләмиләр, тиешенчә игътибар итмиләр аның хәленә хатыны да, улы да... Эше шундый күп, киеренке, тыгыз бер вакытта аны ташладылар да ялгыз калдырдылар; хатыны Рәмзия ханым, юк авыруын бар итеп дигәндәй (белештермичә ашаса, кайчагында бавыры авырткалый иде), тикшерүләр ясау өчен спецклиникага кереп ятты, ә малае Радик, икенче курс студенты, имтиханнарын ашык-пошык биреп бетерде дә, ниндидер хәр егетләр һәм кызларга ияреп, Кырымга китеп барды. Гасыйм Сәләхович фикеренчә, клиникага кереп яту да, Кырымга китеп бару да һич зарури, кичектермәс эш түгел иде. Ә менә аның өчен хәзер, чынлап та, бик тыгыз вакыт. Уку елы тәгәлләнеп килә, студентлардан имтиханнар кабул итү башланды, һәртөрле отчетлар язасы бар — бу вакытны кафедра мөдиренең урак өсте диярге ярый. Иртәдән кичкә кадәр ул хәзер бушамаячак, ашау-эчү, яту-торуның да рәте-юне булмаячак, кыскасы, авырга киләчәк аңа. Шуны уйлап, ул хатынына әйтеп тә карады:

— Җаный, әллә бераз сабыр итеп торасыңмы?.. Нинди вакыт икәнен беләсең...

— Урын барында кереп ятарга кирәк,— диде Рәмзия ханым үзен кенә.

— Урын булыр иде әле...

— Ә минем көтәсем килми.

— Миңа авыр булачак бит, аңлыйсыңмы?.. Эшемнең иң тыгыз чагы.

— Син гел үзеңне генә кайгыртасың, минем сәламәтлегем турында уйлап та карамыйсың, эгоист син! — диде Рәмзия ханым, кинәт кыза ук башлап.

— Һич тә алай түгел, әнкәсе! — диде Гасыйм Сәләхович, хатынын тынычландырырга ашыгып.— Синең сәламәтлегең минем өчен дә бик кадерле. Сүз бит клиникага керүне беразга кичектерү турында гына бара. Тикшерүләр үтәр өчен генә булганда ашыкмаска да ярыйдыр инде.

— Ярыйдыр!.. Аны син беләсеңме, әллә минме?.. Аннары синең эштән бушаган чагыңны көтсәң, кабергә кергәнеңне дә сизми калырсың!.. Юк инде, җан кисәгем, клиникада урын бар чагында керәм дә ятам. Бала түгелсең, үз-үзеңне генә карый алырсың әле.

Билгеле, мондый сүзләрдән соң бәхәсләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Бигрәк тә авыру мәсьәләсендә, бигрәк тә хатының белән. Гомумән, хатынны сүз белән җиңеп булмый, юк, мөмкин түгел. Бөтен дәлилләрең аның корыч «логикасына» бәрелә дә чәлпәрәмә килә. Иң

яхшысы чигенү, нервны бозмас өчен, йөрәкне саклар өчен бары тик чигенү,— калганы ник шунда чәнчелеп китми!..

Беренче мәртәбә генә түгел инде. Зуррак, җитдирәк мәсьәләләрдә дә аңа еш кына чигенергә туры килде. Гадәтенә керде дияргә ярый. Чигенсә, семьяда азмы-күпме татулык һәм тынычлык урнаша. Ә бу Гасыйм Сәләхович өчен иң зур ганимәт... Аннары ул мондый татулык урнашкан чакларда үзеннән шактый яшь, чибәр, әмма еш кына кәҗәләнергә ярата торган Рәмзиясен иркәли дә, сөя дә ала. Сирәк кенә булса да... Я, аңа тагын ни кирәк?!.

Тик шулай да әлеге рәнҗү тойгысы аның күңелендә бер вакытта да бетми диярлек. Яки бетеп торган төсле генә була да, берәр сәбәп чыгу белән яңадан көчәеп китә. Чөнки күп вакытта ул тынычлык хакына дәреслекне, гаделлекне корбан итеп чигенергә мәҗбүр була. Чөнки эгоизм җиңә, ә эгоизм белән килешүе бик-бик читен... Нәкъ менә бу очрактагы шикелле: Рәмзия керәм диде һәм керде дә ятты. Һич нигә карамастан. Урынсыз, мәгънәсез эгоизм түгелмени бу?! Инде хәзер Гасыйм абзаңа ике көннең берендә клиникага барып йөрү мәшәкате дә өстәлде. Рәнҗемәс җиреңнән рәнҗерсең! Ичмасам, куркуга салырлык берәр җитди авыруы булса иде! Юк, анысы да юк, үзе уйлап чыгарган шик кенә бар. Остарды кеше врачларның башын әйләндерергә!

Хатыны клиникага кереп ятканда, улы Радик өйдә иде әле. Бик кызу имтиханнарын биреп йөри иде. Гасыйм Сәләхович та тынычлана төшкән иде, бөтенләй үк ялгыз түгел, өйдә сүз кушарга кеше бар, имтиханнарыннан бушагач, әнисе янына да баргалар дип ышанып тора иде.Ләкин Радик имтиханнарын биреп бетерү белән, әтисенә бер сүз әйтмәстән, каядыр китәргә җыена да башлады. Билгеле, ата кеше аптырый калды: «Кая син болай?» дип сорады ул улыннан: «Кырымга!» диде малае бик гади генә итеп. Моны ишеткәч, Гасыйм Сәләхович бик гаҗәпләнде, хәтта ышанып бетмәгәндәй күпмедер ара сүз әйтә алмыйча торды, аннары сабырлыгын җуймаска тырышып, тагын иплән кенә сорады:

— Син, улым, әзрәк уйлап эшлисеңме моны?

— А в чем дело? — диде Радик тыныч кына.

— Әниең больницада, минем эшем баштан ашкан. Ниткән Кырым ди ул шушындый чакта?

— Ә миңа отдыхать итәргә кирәкме-юкмы?

— Җәй озын, өлгерерсең... Ә хәзергә менә өйдә ял итәрсең.

— Ха! — диде егет, башын чөя биреп.— Көлке!.. Өйдә пенсионерлар да ял итми хәзер.

— Әниең чыккач, син дә китәрсең.

— Кая?

— Кая да булса... Әнә үзебезнең Идел буендагы студентлар лагерена.

— Юк, булмый! Мин Кырымны күрмәгән, только — Кырымга!

— Кырымны мин кырыктан узгач кына күрдем,— диде Гасыйм Сәләхович тыелып кына.

Егет әтисенең бу минуттагы хәлен әллә сизми, әллә сизәргә теләми иде, шактый дорфа гына:

— Таптың чем гордиться!— диде дә бөтенләй аркасы белән үк борылды.

Гасыйм Сәләховичның эчендә кинәт дөрләп ачу кабынды. Малаеның җилкәсенә төшеп торган озын чәчләреннән урап алып, яңадан үзенә таба борасы килде. Ләкин ул тыелып калырга мәҗбүр булды — һәр төрле кискен хәрәкәт аның йөрәге өчен хәтәр иде. Шулай да ачуын сиздерерлек итеп, әкрен генә әйтте:

— Әгәр дә мин рөхсәт итмәсәм?

— Поздно, — диде егет игътибарсыз гына. — Безнең билетлар уже кесәдә!

Радик күптән инде әтисеннән курыкмый иде. Нишләп курыксын, нишләтә ала ул аны? Берни дә эшләтә алмый, билгеле! Һәм берни дә эшләтә алмавын Гасыйм Сәләхович үзе дә бик яхшы белә иде. Кул күтәреп суга алмый ул студент егеткә, хәленнән, дә килми, табигате дә сыйдырмый андый кыргыйлыкны. Үз гомерендә бер тапкыр, Радикка унберме-уникеме яшь чагында, бик ачуы килгәч, аның яңагына шәп кенә бер чәлтерәткән иде, анда да әнисе малаен кочаклап ярты көн үкерде, ә ул үзе шул эше өчен үкенеп бетә алмыйча күпме газапланып йөрде. Юк, ата-бабалардан калган тәрбия «ысулы» бетте, онытылды, күптән юкка чыкты. Әлбәттә, Гасыйм Сәләхович, хәзерге заман педагогы буларак, андый «ысулларның» бетүе белән һичшиксез килешә... Тик шулай да, үз малаең өчен генә булса да, берәр төрлесен саклау зарар да итмәс иде бәлки. Менә Гасыймның үз атасы, мәрхүм, кыска саплы каеш чыбыркысын ишек яңагында гына элеп тота иде; әйткәнен тыңламасаң яки берәр әшәкелек эшләсәң, хәзер үк шул чыбыркысын чөйдән ала торган иде. «Әлә-лә-лә»не әйттерә иде ул зәһәр чыбыркы! Ләкин сыртка бик сирәк төшә иде бит, күп вакытта әтисе аны худка җибәрмичә кире элеп тә куя иде. Әмма чыбыркы бар, чыбыркыны онытырга ярамый! Нишләргә генә уйласаң да, кылт итеп ул искә төшә торган иде.

Әлбәттә, хәзер чыбыркыны сагыну, Радик әйтмешли, үзе бер «көлке»!.. Сатып алыйм дисәң дә юк ул хәзер. Тик менә аның урыны буш калды, шунысы кызганыч! Яхшы сүз, үгет-нәсихәт белән генә максатка ирешүе бик читен икән шул. «Тегенең» кебек үтемле түгел берсе дә.

Әмма... сүздән башка чара юк. Искерсә дә, үтмәсләнсә дә, бердәнбер «ысул» шул гына... Гасыйм Сәләхович үзалдына озак кына уйланып торганнан соң, авыр гына сулап, малаеннан янә сорады:

— «Без» дигәнең кемнәр инде алар?

— Ну, Вовка Бобров, Гена Соловьев, Рита Козлова, Эмма Булатова, Марсель Ганеев... Вообщем, компания менә дигән!

— Студентлармы?

— В основном.

— Кем балалары соң алар болай ансат кына Кырымга очып китәргә?

— Это не имеет значения.

— Шулай да?.. Кем акчасына йөрмәкче буласыз?

— Мин синнән акча сорамыйм.

— Рәхмәт монысы өчен... Ә башкаларыгыз?

Радик аз гына икеләнеп торды, шулай да кыюланып әйтте:

— Башкаларның родительләре сорамасаң да бирәләр. Без унижения.

— Алай икән,— диде Гасыйм Сәләхович кызара төшеп.— Күрәсең, бик байлардыр инде.

— Причем байлык! Просто понимают.

— Нәрсәне?

— Понимают наши потребности.

— Ах, шулаймени?! Алар аңлый, мин аңламыйм икән!.. Хуш, шулай да булсын ди, ләкин бит сезнең ихтыяҗны үтәр өчен бер аңлау гына җитми, аның өчен, хочешь не хочешь, 300—400 тәңкәне кесәдән чыгарып та бирергә кирәк. Ә аны кайдан алырга? Ярый, минем хәлемнән килә, аңламасам да, мин бирә алам. Ә башка кеше, мәсәлән, уборщица булып эшләүче берәр апа кадерле малаеның пот-

ребностен бик аңлый да, тик менә сезнең белән Кырымга җибәргә хәленнән килми. Ул чагында нишли?

— Ялгышасың, па! Рита Козлова, биофак студенткасы, тоже уборщица кызы, ә безнең белән барачак. Вот так!

Гасыйм Сәләхович бер мәлгә аптырый калды, күңеленә шунда ук ямьсез уй да килде: «Берәр акчалы кешенең яшерен сөяркәседер әле ул юньсез кызый!» — Ләкин бу уен тизрәк үзеннән куарга тырышты. Дөрес, булмый торган хәл түгел, ишеткәне дә бар андыйларны, тик бу очракта бик сак булырга кирәк иде. Онытырга ярамый, малае белән сөйләшә ул. Шулай да әйтмичә түзә алмады:

— Әгәр дә сезнең ул Ритагыз әнисе җилкәсендә шулай кылана икән, бу бик кызганыч! Бичара хатын аның өчен муеныннан бурычка баткандыр, үзе ипи белән суда гына утыра торгандыр. Юк, жестокый ул сезнең мактаулы кызыгыз! Миһербансыз!

Радик әтисенә нәфрәт белән диярлек карады.

— Син, па, абсолютно бер нәрсә белмисең, син страшно артта калган кеше... Син просто невежда!

— Җитәр, малай актыгы! — диде Гасыйм Сәләхович буыла язып. — Күземә күренмә, эзең булмасын монда!

— Яхшы, мин күренмәм, — диде егет һич исе дә китмичә һәм юри ашыкмыйча гына ишеккә таба юнәлде.

— Ләкин бел, — дип кычкырды әтисе аның артыннан. — Әниең белән сөйләшмичә торып, мин сине Кырымга түгел, Арчага да җибәрмим.

Егет, ишетмәгән дә шикелле, артына да борылып карамыйча чыкты да китте. Гасыйм Сәләхович хәлсезләнеп, креслосына барып утырды. Сул кулын йөрәге өстенә куеп торды — йөрәк шактый каты тибә, ләкин авырту-чәнчү кебек нәрсә сиздерми иде. Шуңа күрә дарумазар да кабып тормады.

Бераздан тынычлана төшкәч, Гасыйм Сәләхович уйлана башлады. Кызганычка каршы, улының «бер нәрсә белмисең» дигән сүзләрендә дөреслек юк түгел иде. Бигрәк тә тормыш мәсьәләсендә һәм хәзерге яшьләрне аңлауда... Нигә ул алай, тормыштан бөтенләй үк аерылган кеше дә түгел ләбаса!.. Бөтен үзгәрешләрне, яңалыкларны күреп тә тора шикелле... Ләкин үзе дә сизә, нәрсәнедер белеп җиткерми, аңлап җиткерми... Әйтик, кешеләрнең көнкүрешләрен... Сүз дә юк, кешеләр хәзер җиңелрәк тә, яхшырак та торалар, әмма шуның белән бергә аларның килерләре тигезләнеп беткәне юк бит әле. Аерма шактый зур, мәсәлән, профессор алган 450—500 сум айлыкны бик күпләр алмыйлар ич әле. Ә шулай да 70—80 сум ала торган вахтерның яки уборщицаның кызы 70—80 сумлык импортный сапожкиларны киеп йөри... Ничек итеп моны эшләргә мөмкин? Дөньяның чыгымы күп — ничек кенә арттыра алалар?.. Баш җитәрлек түгел. Әйтәләр инде, кеше хәзер яшәргә остарды дип... Ни дигән сүз бу? Ничек аңларга ул «остаруны?» Берничә җирдә эшләүме? Хаклы һәм хаксыз премияләр алумы? Спекуляция белән шөгыльләнүме? Ниһаять, дәүләт милкен әкрен генә ташумы? Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, «остару» дигән төшенчәгә бу «ысулларның» барысы да керә, имеш. Тик кеше кайда, кем булып эшләвенә карап, шул «ысулларның» берәрсен оста гына куллана икән.

Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк, анысы синең эш. Гасыйм Сәләхович ул ысулларның берсен дә белми иде, әлбәттә. Бер вакытта да бер тиен харам акча кермәде аңа. Хезмәт хакы аның һәр вакытта зур булды, иркен-мул гына яшәр өчен җитеп торды. Кайчандыр фән әһелләре халык арасында иң яхшы тәэмин ителгән катлаудан саналa иде. Ә хәзер дөнья тигезләнеп бара шикелле... Һәрхәлдә, Гасыйм абзаң ашаган-эчкәнне, Гасыйм абзаң кигәнне һәркем диярлек ашый-эчә

дә, кия да. Хәтта уздырып та җибәрәләр: белеме юк, квалификациясе юк, ә машинасы бар. Әнә кая китте эшләр!

Хәерле булсын. Халыкның тормышы елдан-ел яхшыра икән, бу бик әйбәт, ул шулай булырга тиеш тә, тик әлеге харам «ысуллар» гына тамыр җәя күрмәсен иде. Гаять зарарлы нәрсә, кешене тәмам боза, җәмгыятьне имгәтә торган хәтәр нәрсә. Бигрәк тә яшьләргә күчә башласа, бик начарга әйләнеп китүе мөмкин. Ә аның симптомнары юк түгел. Акча ератучы, акча артыннан куучы яшьләр студентлар арасында да бар, кызганычка каршы. Менә шушы нәрсә Гасыйм Сәләховичны аеруча борчый да инде. Чөнки, аның белүенчә, яшьләрдәге акчага, малга комсызлык һич тә нуждан түгел (иске мәгънәсендәге нужа юк та ул), ә бик иртә, бик яшьли, әле кеше булып җитәргә дә өлгермәс борын, рәхәт, иркен яшәргә омтылудан гына килә. Менә үз улы белән бәхәс-талаш шуның бик ачык бер мисалы түгелмени?!

Әйе, улы аңа «син бер нәрсә дә белмисең, па!» дигән гаеп ташлады. Ә ул бит менә утыз ел инде шул яшьләр арасында яши, шуларны укыта, тәрбияли. Нәрсәне белми соң ул? Яшьләрнең уйларын, хыялларын, теләкләрен, кыскасы, эчке рухи дөньяларынмы — шуны күздә тотып әйтәме Радик?.. Әйе, кырык ата баласының эчке дөньясын белеп бетерү гаять читен, мөмкин дә түгел диярлек. Дүрт-биш ел саен алар алмашынып тора, берәүләре китә, икенчеләре килә (һәм гел генә үзгәреп килә), ә син һаман искечә каласың, һаман олыгая барасың, һәм, табигый хәл, яшьләр гүя синнән ераклаша, син инде аларны томанлырак, ятрак итеп күрә башлыйсың. Әйе, белүләре бик читен. Әмма белмим дип әйтергә дә аның хакы юк. (Бу үз-үзенә каты һәм гаделсез хөкем чыгару булыр иде.) Иң элек аның өчен көн кебек ачык бер хакыйкать шуннан гыйбарәт ки, сугыш артыннан ук укырга килгән яшьләр белән хәзерге абитуриентлар арасында искиткеч зур аерма бар. Бөтен җәһәттән. Сугыштан соң килгәннәрнең күпчелеге буйга кечкенә, арык, өс-башлары өтек, үзләре бик күндәм, тыйнак булса, хәзер килүчеләр барысы да диярлек озын буйлы, тук чырайлы, зәвык белән киенгән, үз-үзләренә нык ышанган таза, чибәр егетләр һәм кызлар. Тегеләрдә белем чамалы, ә дәрт, теләк бик көчле булса, боларда инде белем бик күп, шунлыктан, ахры, кыюлык та, әрсезлек тә җитәрлек. Тегеләр университет бинасына, изге бер җиргә аяк баскандай, эчләреннән дулкынланып һәм чын күңелдән шатланып керсәләр, хәзергеләр исә хис-хыялларга артык бирелмичә, бары үтеп китү турында гына борчылып, бик эшлекле кыяфәттә килеп керәләр. Дөрес, университетка керү сугыштан соңгы елларга караганда шактый авырлашты, каты конкурс аша үтәргә кирәк, әмма үтә алганнар инде үзләрен судагы балык кебек хис итә башлыйлар. Алар арасында бик сәләтле яшьләр дә бар — киләчәктә алардан чын фән эшлеклеләре дә, зур белгечләр дә, һичшиксез, чыгачак. Ихтимал, үзләрендә шундый көч-куәт барын сизгәнгә күрәдер дә, алар бик хөр кыланалар. Фикердә, сүздә хөр — менә хикмәт нәрсәдә. Гүя аларның үз башлары эшли, үз хакыйкатьләре бар. Гүя алар бөтен кыланышлары белән сиңа: «Әнә үз предметыңны бел, башкасында эшең булмасын», дип әйтергә телиләр. Әлбәттә, мондый чакларда Гасыйм Сәләховичка бик ямансу булып китә торган иде. Ераклашу, ераклашу... шулай ук котылгысыз бер күренеш микәнни?! Хәтта үз балаңнан да!

Билгеле инде, ул Радикны Кырымга китүдән дә туктата алмады. Шул ук көнне клиникага барып, бу хакта сүз башлагач, Рәмзия ханым, гадәтенчә уйлап-нитеп тормыйча гына:

— Ник тыясың, китсен!— диде.— Аңа да ял кирәк ич.

— Ләкин вакыты ул түгел бит! Син монда, мин анда ялгыз башым...

Рәмзия ханым шунда ук аның сүзен бүлде:
— Радикның ни гаебе бар соң, ул бит инде синең эшеңне эшләп йөрмәс.
— Эш андамыни,— диде Гасыйм Сәләхович үртәлеп.— Үзем өчен әйтмим мин... Менә синең яныңа да кемдер килеп йөрергә тиеш бит әле.
— Ә мин эгоистка түгел, миңа кирәк булыр дип кенә Радикны иптәшләреннән аерырга һич тә теләмим.
— Ләкин моның авырлыгы миңа төшәчәк.
— Авыр булса, син дә килмәссең... Ятармын әле шунда тол хатын кебек.
— Я хода! — дип куйды Гасыйм Сәләхович ирексездән.— Ник син минем һәр сүземне кирегә тырныйсың да торасың? Менә килгәм ич, тик миңа барысына да өлгерүе читен, аңлыйсыңмы шуны?
— Бик яхшы аңлыйм. Ләкин Радикны барыбер җибәрергә кирәк. Иптәшләреннән яхшы түгел, аның кай җире ким? Юк, барсын... Инде расходыннан курыксаң, акчасын да үзем рәтләп бирермен.
— Бусы тагын ни дигән сүз?
— Нигә, әллә мин белмимме?
— Нәрсәне?
— Синең саранлыгыңны... Шуңа күрә җибәрәсең килмидер әле.
— Их, Рәмзия, Рәмзия, ничек телең әйләнә!— диде Гасыйм Сәләхович тирән әрнү белән.— Аңлый алмыйм мин сине, җаный, әллә ни булды сиңа!
— Миңа берни дә булганы юк,— диде Рәмзия, гаепсез баладай елмаеп кына.— Ә менә син, дускай, чынлап та, үзгәрдең... Картаясың, ахры...
— Ярый, шифаханә — сүз көрәштерү урыны түгел, китим булмаса,— диде Гасыйм Сәләхович, урыныннан авыр гына кузгалып.— Нәрсә китерим?
— Апельсин согы тапмассыңмы? Монда берәү хатынына китерде. Импортный икән... Аннары минем челтәрле бюстгалтерымны онытма әле, бик эссе була башлады. Шифоньерның уң тартмасында, естә генә, күрерсең...
Гасыйм Сәләхович ярый-фәлән дип тормады, бары чарасыздан башын гына каккандай итте. Урамга чыккач, тел астына валидолын салды һәм иләсрәк бер хәлдә университетка таба атлады. Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде. Шунда ук йөрәккә суга, башына каба, җитмәсә, хәтере дә кинәт кенә югалып торгалый. Кеше сүзен тиз генә аңламый, алдында яткан әйберне дә күрми башлый. Иртәрәк килә түгелме соң әле бу зәхмәтләр?! Аңа бит әле илле тугыз яшь кенә — безнең заман өчен әллә ни күп тә түгел шикелле... Дөрес, өч елга якын ул фронтта йөрде, шуның михнәт-газапларын кичерде, берничә тапкыр бик хәтәр хәлләргә дә юлыккалады, ләкин шулай да, бер авыр контузияне исәпләмәгәндә, кул-аягы бөтен килеш әйләнеп кайтты. Баш та ярыйсы, йөрәк тә тап-таза иде әле ул чакларда. Тик соңгы дүрт-биш ел эчендә генә бирешә башлады. Күрәсең, еллар үзенекен итә, какшата әкрен генә кешене... Аннары безнең бу тынгысыз, киеренке заман кеше өчен шактый куркыныч бер нәрсә китереп чыгарды — стресс дип атыйлар аны. Кинәт башка төшкән зур хәсрәттән яки һич көтелмәгән берәр күңелсез эштән була диләр ул явызны. Хәтта көтелмәгән зур шатлыктан да була, имеш; хәер, анысын инде, шат, татырга туры да килмәс. Ә менә һәр төрле ямьсез эштән туганын Гасыйм абзаңа татырга туры килгәне бар. Дөрес, алар вак стресслар иде, көчек кебекләре генә, ләкин барыбер каты «тешлиләр», каһәрләр!
Рәмзия белән бүгенге сөйләшү дә әнә шундый көчектәй кечкенә

стресс иде, ә шулай да Гасыйм Сәләховичның кәефен чынлап торып бозар өчен җитә калды. Һәм бик авыр уйлар да кузгатты. Күпме бергә гомер иткән ир белән хатын бер-берсен аңламасыннар әле — гаҗәп бит бу... Гүя икесе ике телдә сөйләшәләр! Бигрәк тә соңгы ике-өч елда алар арасындагы каршылык, аңлаша алмау ни сәбәптәндер аеруча ешаеп китте. Гасыйм Сәләхович торып-торып аптырый: әллә бу хатыннар, кырык биштән узгач, психический үзгәрә башлыйлар микән? Менә аның Рәмзиясе кебек... Ни әйтсәң, шуңа каршы төшә, һәр сүзеңне гел кирегә бора, бернинди дәлилең аңа үтми дә, кермн дә, юньләп тыңламый да әле ул сине! Шуның өстенә Рәмзия аңардан унбер яшькә кечерәк, табигый инде, ул көйсезләнергә ярата, ул аны үзенең ходай биргән хокукы дип саный, ә ир дигән кемсә, үзен яшь хатыннан яраттырасы килсә, һәр вакытта аның көенә торырга, аңа юл куярга тиеш. Гаделлекне, дөреслекне аяк астына салып булса да!

Иң аянычы тагын шул, Рәмзия ханым бөтен мәсьәләдә диярлек гел генә малае ягына каера, гел аны гына яклый. Дөресме, кирәкме, урынлымы — анда аның эше юк. Ул ана кеше, ул гына малаен аңлый, кызгана, ә син — деспот, син бары кысу, тыюны гына беләсең. Өстәвенә, җитмәсә, малае алдында еш кына көлеп тә, чынлап та, синең әтиең инде шундыйрак та мондыйрак дип әйткәләп тә тора. (Әпә саранлыкны аңа таккан шикелле.) Ә малай яшь, кемнең хаклыхаксыз булуын уйларлык акыл юк әле аңарда. Кем аның яклы, кем аңа файдалы — ул бары шуны гына белә. Табигый инде, ул күбрәк әнисенә елыша, үзенә кирәкне аның аша алырга тырыша. Ә әтине тыңламаска да була, әтидән курку юк. Әнә шулай бер-берсеннән читләшә, ераклаша ата белән бала.

Аптырый иде Гасыйм Сәләхович бу хәлгә, төрлечә уйлап карый иде: әллә Рәмзиядә җиткән улын әтисеннән әзрәк көнләшү дә бар микән? Үзенеке генә итәргә тырышу, үзенә генә карату?.. Буламы шундый нәрсә хатыннарда?.. Ә бәлки аның үзендә дә берәр гаеп бардыр, берәр төрле хаталык эшләгәндер дә, тик ул аны эш-мәшәкать аркасында сизмичә калгандыр. Хәзер инде әйтүе читен, ләкин шулай да бер эпизодны яхшы хәтерли, чөнки аңа әле күп вакыт та узмады. Радик унынчыны бетергән елны әнисе белән шундый сүз булып алды. Дөресрәге, Рәмзия үзе башлап аңардан сорады:

— Син Радикның кем булуын теләр идең?

Гасыйм Сәләхович үзенең язу өстәлендә нидер эшләп утырган җиреннән генә бары:

— Кеше булуын,— диде.

Менә шушы сүзгә Рәмзия ханым бөтенләй күтәрелеп бәрелә язды. Яман кызып, иренә:

— Ахмак, идиот!— диде.— Мин синнән аны сорыйммыни?! Ул болай да кеше, дүрт аяклы хайван түгел!

«Хайванның ике аяклысы да була» димәкче иде дә Гасыйм Сәләхович, ярый, тыелып кала белде. Рәмзия бит, асылда, улыбызны кайсы ВУЗга кертәбез, кем итәбез дип сорамакчы иде, ә ул акыллы башланып, әнә нәрсә әйтеп ташлады. Ә соңыннан Рәмзия ханым улы алдында ничә тапкыр «әтиең сине кешегә дә санамый» дип кабатлады. Яхшы сүз дә кайчан баш казыгына әйләнә икән!

Әйе, сәер халык бу хатыннар җенесе, ике төпле, юк, өч төпле чемодан кебек, ниләр генә ятмыйдыр аның төпләрендә. Кайчагында шундый көтелмәгән берәр әкәмәт китереп чыгара, шаккатудан тәмам гелсез каласың. Әнә бит Радикка акчаны да үзем табып бирермен ди! Күзен дә йоммый. Менә бу, ичмасам, көлке! Әйтерсең акчаны ул үзе таба!

Ярый, хәерле булсын! Барыбер хатын бик кирәк кеше, алардан башка күңелсез, кызыксыз, әйләнәңдә шыксыз бушлык. Гаилә тор-

мышына бер өйрәнгәч, башкача яшәү мөмкин дә түгел. Тик җайлаша, яраклаша белергә кирәк. Яраклаша белсәң, яшәп була дилэр күпне күргән агайлар!

Шул ук кичне Гасыйм Сәләхович малае алдына 250 сумны чыгарып салды да әйтте: «Мин сиңа акча, шуны җиткерергә тырыш, әйбәт кенә йөр, бәла-казага тарма, кайда икәнеңне хәбәр итәрсең», диде. Егет бер сүз дә дәшмәде, тик аның йөзеннән: «То-то, старик!» дигән сыман елмаю гына чагылып узды. Икенче көнне үк ул рюкзагын аркасына киеп, фотоаппаратын муенына асып, үзе кебек хөр, горур егетләр һәм аларны иңнәренә таяндырып йөртүче чалбарлы кызлар белән бергә Кырымга — диңгез буендагы ташлар арасында кызынып ятарга китеп тә барды. Исән-сау гына йөри күрсеннәр инде, балакайлар! Исән йөрсәләр, башта акча сорап телеграммалары килер, аннары үзләре дә кояшта кара янган бәхетле кыяфәтләре белән кайтып төшәрләр.

## II

...Көне... Булыр икән бу хәтле дә теңкәгә тигән эсселек! Өченче атнага китте бит инде, зур бер афәткә әйләнмәсә ярар иде. Игеннәр ни хәлдә икән, ялан-кырлар, болыннар? Терлекләр дә интегә торгандыр... Чакырып кына китерәсеңмени шифалы яңгырларны... Юк шул әле, юк кешедә андый кодрәт!

Ә шулай да кузгалырга вакыт, күптән вакыт. Хатыны белән малае өйдә булса, уянгач болай карават читендә изрәп, иренеп утырыр идемени?! Ә ялгыз булгач менә утыра, берәүдән дә тартынмый, уңайсызланмый — үзенә күрә бәләкәй генә бер хөрлек! Дөресен генә әйткәндә, ялгызлык ул кадәр начар нәрсә дә түгел. Күпмегәдер семья ыгы-зыгысыннан котылып торасың, әзрәк җан тынычлана, үә алдыңа уйланып була, тып-тын бүлмәдә доньясын онытып эшләп яки укып утырып та була. Йә, начармыни ул?! Тик менә хәлсезлек кенә борчымасын иде.

Гасыйм Сәләхович ике карават арасындагы тумбочка өстендә яткан сәгатенә үрелеп карады. Сәгать тугыз иде инде. Мәлҗеп озаграк та утырылган икән, хәерсез. Унда инде аңа кафедрада булырга кирәк.

Карават башыннан зәңгәр буйлы киң пижама чалбарын алып киде, аякларына артсыз чүәкләрен эләктереп кенә кухняга чыкты да, газ плитасына ут кабызып, чәй кайнатырга куйды. Ванна бүлмәсенә кергәч, башта кулы белән ияген, яңагын ышкып карады, ләкин, бүгенгә ярар әле дип, кырынып тормады. Аннары краннан суны шактый гына агызып торып, битен-күзен юарга керешге. Су барыбер көткәнчә салкын ук булып килмәде, шулай да әйбәтләп юынгач, бераз хәл кереп, җиңеләеп калды. Шуннан соң янадан кухняга кереп, тиз генә ашый-эчә башлады. Билгеле, ашау ягы аның хәзер мактанырлык түгел иде. Кичтән калган бер кукәй, искерәк булки белән ак май, бер чәшкә куе гына сөтле чәй — завтрак дигәне әлегә менә шул. Аннары, ачыга төшкәч, сәгать 12 ләрдә, университет буфетында ул тагын җиңелчә генә бер тамак ялгап алачак әле. Инде эш беткәч, кайтышлый, сәгать 3—4 ләрдә «Татар ашлары»на кереп, татарча токмач белән татарча пешерелгән ит кисәге ашап чыгачак. Тик кай көннәрдә токмач та, ит тә беткән була — ашап бетерә халык. Шуңа бераз кәефсезләнә, мыгырдана Гасыйм абзаң, ләкин башка җирдә аңа ярарлык ризыгы юк та диярлек (хек белән дуңгызны, гафу итсеннәр, аның нәфсе кабул итми)... Кайтышлый юл өстендәге магазиннан сөт, эремчек, каймак кебек азыклар сатып ала да өендә үзе бик әйбәтләп кенә сөтле токмач белән берәр төрле ботка пешереп ашый. Дөрес, карын кана-

гатьлэнеп бетми бетүен, лэкин, аның каравы, йөрэгенэ җиңел була. Аз ашасаң, күп яшэрсең дигэннэр, имеш, безнең ерак бабайлар.

Гасыйм Сэлэхович кыска җиңле саргылт күлмэген, яньчелэ төшкэн капрон эшлэпэсен киеп һэм бигe бозык иске зур портфелен күтэреп өеннэн чыкканда, сэгать ун тулып килэ иде инде. Урамга чыгып, кояшка элэккэч тэ ул аның агарган тимердэй кыздыруын тойды. Тизрэк күлэгэ якка күчте һэм ашыкмыйча гына урам буйлап атлады.

Бу урамнар буйлап Гасыйм Сэлэхович менэ утыз ел атлый инде. Шуның егерме елын кафедра мөдире буларак. Шулай уза гомер. Эмма ул үз эшеннэн бик канэгать. Бөтен илгэ исеме билгеле мэшһүр университет аның туган йортына эверелде дияргэ дэ ярый. Шунда үсте ул, шунда шактый зур дэрэҗэгэ иреште һэм тормышын тээмин итэрлек матди җирлекне дэ, үзенэ кирэк мэгънэви азыкны да шунда тапты. Билгеле, төрле чаклар булды, төрле авырлыкны кичерергэ, төрле кыенлыкларны җиңэргэ дэ туры килде аңа — шунсыз бер генэ хезмэт тэ булмый торгандыр инде безнең заманда. Шулай ук кайбер максатына да ирешэ алмады: мэсэлэн, күпме генэ уйланса-борчылса да, докторлык диссертациясен, ахры, яза алмыйча калды. Ул бит тарихчы, тарихчының эше гадэттэ зур күлэмле, тарих өлкэсендэ чын фэнни хезмэт тудырыр һэм нинди дер яңа сүз эйтер өчен бик күп эзлэнергэ, тикшеренергэ, уйланырга кирэк. Тарихчыдан күп нэрсэ талэп ителэ хэзер. Э ул яшьрэк, җегэрлерэк чакта, аңа нидер көтү, тыелып тору, саклык күрсэтү хас иде. Менэ ни өчен ул эзер программа нигезендэ, тэкъдим ителгэн дэреслеклэр буенча студентларга лекциялэр укуны артыграк күрэ иде. Җиңелрэк тэ һэм хэвефсезрэк тэ... Инде гыйльми дэрэҗэ алыр өчен берэр хезмэт язарга уйласа, бу очракта ул теманың отышлырагын, үтемлерэген сайларга тиеш. Э андый өстэ генэ яткан темалар һэр вакытта табыла, бар алар. (Фэн эһеллэре арасында «дежур тема» дигэн төшенчэ дэ бар хэтта.)

Кыскасы, безнең Гасыйм Сэлэхович асылда энэ шул юл белэн китте. Аспирантураны бетереп, университетта калгач, ул бик җигелеп һэм бик бирелеп студентлар белэн шөгыльлэнэ башлады. Э тора-бара кандидатлыгын яклап, ниһаять, кафедра мөдире булып алгач инде, укыту-тэрбия эшлэре аның өчен төп хезмэт, төп йөк булып калды. Вакытын, көчен, акылын, хэтта сэламэтлеген дэ беткэнче шуңа бирде. Үзе эйтмешли, университет белемле кадрлар эзерлэп чыгаруга багышлады ул бар гомерен!

Эмма лэкин университет эчендэ, шуның бер кешесе була торып, фэнни эшлэрдэн бөтенлэй ваз кичү һич тэ мөмкин түгел иде. Фэнни эшлэр буенча кафедраның махсус планы бар, шунда кемнең нэрсэ эшлэргэ тиешлеге ачык язылган, һэм бу планны үтэүне тээмин итү Гасыйм абзаң җилкэсендэ, беренче нэүбэттэ аңардан сорыйлар. Шул сэбэпле аңа бу очракта да, үзе утырып язуга караганда, башкаларны эшлэтергэ, башкалардан талэп итэргэ туры килэ иде. Иң мөһиме — кафедра үтэсен, кафедра үтэсэ, аның да йөзе ак — мөдир җитэкчелек итэ белгэн диярчэклэр.

Хэер, ул үзе дэ калэм тибрэтмичэ тормады торуын. Редакциялэрнең заказлары буенча төрле даталарга карата мэкалэлэр, теге яки бу темага багышланган брошюралар, чыккан китапларга рецензиялэр, кыскасы, шуның кебек вак нэрсэлэр шактый күп язылды. Билгеле, болар да хезмэт, эмма алар гына җитми, канэгатьлэндерэ алмый иде Гасыйм Сэлэховичны. «Галим» дигэн исемне акларлык, горурланып кулга тотарлык җитди зур хезмэте (калын китабы) юк иде аның... Һэм бу «юклык» аның җанын гел иги дэ тора иде. Бигрэк тэ соңгы елларда, чөнки соңгы 10—15 ел эчендэ яңа хезмэтлэр чыга башлады, һэм аеруча күзгэ ташланганы—яңа яшь галимнэр үсеп, калкып чыкты. Өлгер һэм кыю галимнэр! Менэ шуларның барысын да уйласаң,

чынлап торып борчылмыйча хәлең юк. Артта калу дигән нәрсә бик хәтәр, иртәме-соңмы исемеңә дә, дәрәҗәңә дә китереп суга ул!

Ә бит аның күптән уйлап йөргән теләк-хыялы да бар иде. «Татарларда эшче сыйныфының тууы һәм формалашуы» дигән темага зур бер хезмәт язмакчы иде. Шуңа дип ничәмә еллар буенча, Петр патша заманыннан алып дигәндәй, күпме материал җыйнады ул!.. Әнә, калын папкаларга тутырып бәйләгән килеш, ярты шкаф белән яталар... Әмма, ни кызганыч, шуны утырып тәртипкә салырга, эшкә кертергә, бөтен бер язма хәленә китерергә вакыт та, мөмкинлек тә таба алмады. Мөдирлек йотты аны. Хәер... бу үзеңне юатыр өчен генә әйтелгән сылтау түгелме? Кешеләр икесен дә сыйдыра лабаса! Ихтимал, аңа җитди хезмәт өчен кайбер сыйфатлар, әйтик, көчле теләк, тәвәккәллек, ниһаять, үзеңне мәҗбүр итә белү җитмәгәндер. Шуның өстенә тагын фикерне эшләтү, хыялны җигү, сәләтеңне сынау — иҗатны шулар кабындыра бит инде. Ничек кенә булмасын, ул һаман сузды да сузды һәм суза торгач, иң ганимәт вакытны уздырып та җибәрде. Дәртле һәм җегәрле чагын!

...Үтте инде, булмады дип бәлки тынычланырга да ярагандыр, болай да эше начар түгел иде, ләкин ул һич тә тынычлана алмады. Үкенү, кимсенү, хәтта оялу аның җанын борчыды да торды. Ә борчылу бик кирәк нәрсә икән, борчылу ахыр чиктә кешене кузгата да ала икән. Башкаларга да гыйбрәт бу!.. Кыскасы, моннан өч ел элек Гасыйм Сәләхович үзенең ял айларында бер кая да китмичә, тотты да шул папкаларын сүтеп, актара-карый башлады. Материал бик күп, бик кызыклы иде, борынгы лашманчылардан алып, Уралдагы чуен коючылар, Каспийда балык тотучылар, Апшеронда нефть чыгаручылар, Донбасста күмер чабучыларга кадәр барысы да монда тупланган иде. Әмма бу хәтле материалны ничек кенә эшкәртеп чыгасы да, ничек итеп бер кульязма хәленә китерәсе? Каян көч аласы да каян гына вакытын җиткерәсе? Мөмкин эшме бу?! Бер мәлгә яңадан күңеле сүрелеп, әллә ташларга микән дип тә уйлады Гасыйм Сәләхович, ләкин шулай да бер тотынгач аерыласы килмәде, кызганыч иде аерылуы, һич югы, өлешчә файдаланып булмасмы дип, баш күтәрмичә утыра бирде. Һәм утыруның бер нәтиҗәсе булмыйча калмый ул. Менә Гасыйм абзаң да казына, уйлана торгач, шул тау чаклы материалдан йолкып алып, «Донбасста татар шахтерлары» дигән йөз кырык битлек монография сыман нәрсә дә язып ташлады. Өч ай эчендә! Соңыннан үзе дә гаҗәпләнә калды, шундый авыр башланган нәрсәне ничектер җиңел генә язды да чыкты. Донбасс бит татар кешесенә якын җир, йөргән-таптаган, җырларына кергән җир — бәлки шул да ярдәм иткәндер. Нәтиҗәдә менә өч нөсхә итеп машинкада бастырылган, яңа таза папкага пөхтәләп салынган кульязма аның өстәлендә ята! Бер дә икеләнмичә нәшриятка илт тә бир!

Әмма ләкин Гасыйм Сәләхович кульязмасын йөгертеп илтергә ашыкмады. Нигә ашыгырга, бераз ятсын әле, күз алдында торсын, караштырыр, уйлаштырыр — кадерле, тансык бит әле ул аның үзенә дә! Ләкин анысыннан да битәр, кульязманы кемнәндер укытып та алырга кирәк иде. Газетадагы шикелле «свежий головадан» һәм бик ышанычлы кешедән. Ягъни киңәш-күрсәтүләрен әйтерлек тә, шуның белән бергә автор теләгән аңларлык та булсын иде ул кеше!

Кем бар, кемгә ышанып бирергә мөмкин? Үз кафедрасындагы кешеләрнең берсе дә, билгеле, аның үтенечен кире какмаячак. Ләкин чынлап аны хөрмәт иткәне һәм чын сүзен әйтердәе кем булыр икән? Шактый уйланганнан соң, ул ахырда Идеал Ибәтович Шәйхиевне сайларга булды. Бу — кафедра профессоры, тарих фәннәре докторы, арада иң яшь галим. Һәм иң мөһиме — кайчандыр Гасыйм Сәләхович кул астында аспирантураны бетергән егет... Хәер, бу кадәресе бер

яктан уңайсызрак та кебек, ләкин чынлабрак уйлаганда, моның һичбер гаебе дә юк шикелле... Шәйхиев аңа шәкерт булудан күптән узган инде, үзен бик бәйсез тота торган кеше, Гасыйм абзасына алай бик баш иеп, бил бөгеп тә тормый ул. Әмма күңелендә аның элеккеге хәлфәсенә карата билгеле бер хөрмәт сакланган булырга тиеш. Димәк, хәерхаһлык күрсәтүенә дә ышанырга мөмкин.

Идеал Шәйхиев гомумән бик оригиналь шәхес. Искиткеч тырыш, басылып утыручы, бер генә минутын да бушка әрәм итмәс (университет китапханәсеннән, хезмәткәрләр утларны сүндереп куймыйча, ул чыкмый да торган иде). Коточкыч хәтер үзендә, тарихчы белергә тиешле йөзләрчә исемнәрне һәм даталарны ул күңелдән генә әйтә дә бирә. Башка ягы ничектер, әмма башы аның, чынлап та, идеальный корылган диярлгә була. Уйлап карагыз, бүтәннәр утыз елда да үтә алмаган юлны Идеал Шәйхиев ун-унике ел эчендә үтте дә китте; аспирантураны кандидатлык диссертациясен яклап бетерде, ә алты-җиде ел узуга докторлыгын яклап, әнә профессор да булды. Һәм үзенең моңа һич тә исе китмәде, киресенчә, шулай булырга тиеш ул дигән шикелле генә карады. Күпләр аны артык һавалы булуда гаеплиләр, хәлбуки, бу аның үз-үзенә бик нык ышанудан килгән гадәти тотышы иде. Гомумән, ул аз сүзле кеше, тигез, тыныч холыклы, сүз көрәштерергә, шаулап бәхәсләшергә яратмый, әмма инде сөйләргә туры килсә, бик тәмләп, дәлилләп, сеңдерерлек итеп үзенекен әйтә дә белә. Логика гаҗәп! Аның өчен фән бар, ул фәндә яши, өзлексез казына, эзләнә, өйрәнә һәм яза, күп яза. Үзәк журналларда аның мәкаләләре әледән-әле чыгып тора. (Тарихтагы тикшерәнә торган төп өлкәсе — XVIII һәм XIX гасырларда Рус самодержавиесенең колониаль сәясәте, шул нигездә капитализмның үсү-җәелүе һәм бу процесска Россия эчендәге төрле халыкларның тартылуы.) Хәзер инде тугандаш республикаларда да профессор Идеал Шәйхиев дигән исемне яхшы ук беләләр. Әйе, һаваланырга хакы да бар егетнең!

Яшь галимнең бу уңышлары Гасыйм Сәләховичта ирексездән беркадәр көнчелек уятса да, ул, шуңа карамастан, аның өчен куана иде. Ярый, ул үзе кандидат кына булсын, фәндә зур казанышларга да ирешмәсен, ди, ләкин дә бит Идеал аның шәкерте, аның кул астында шәп галим булып өлгерде бит әле Яңа Бистә малае! (Шәйхиев үзе бу хакта ничегрәк уйлый торгандыр, ул кадәресен Гасыйм Сәләхович белми иде, әлбәттә.) Алай гына да түгел, Гасыйм абзаң нәкъ менә хәлфәләрчә Шәйхиевне үз урынына кафедра мөдире булып калачак бердәнбер лаек кеше итеп тә саный иде. Тик Шәйхиев үзе генә ни өчендер моңарчы мөдирлеккә бер дә омтылыш сиздермәде. Ихтимал, аңа, мәшәкатьле эшкә башын тыкканчы, фән белән шөгыльләнү һәм лекцияләр укып кына йөрү файдалырактыр, шуны артыграк күрәдер, әмма Гасыйм абзый тагын үзенең беркатлылыгы белән моны шәкертнең хәлфәсенә конкурент булырга теләмәве дип кенә карый иде. Һәм, дөресен генә әйткәндә, яшь галимнең мөдирлеккә ашкынып тормавы Гасыйм Сәләхович өчен бик тә әйбәт иде. Һич югы, тагын бер дүрт ел мөдирлектән төшмичә утырырга кирәк иде әле аңа!

Озын сүзнең кыскасы, Гасыйм Сәләхович үзенең кульъязмасын Идеал Шәйхиевтән укытырга булды. Иң кулай кеше шул, әгәр баш тартмаса. Хәер, ни өчен баш тартырга тиеш?.. Юк, тартмас, күрсәтмәс ул андый сансызлыкны кафедра мөдире Гасыйм абзасына! Тик җаен-форсатын туры китереп, дәрәҗәңне төшермичә генә сөйләшергә кирәк үзе белән. Һәм Шәйхиев аның янына кереп, бер сөйләшеп утырганда, Гасыйм Сәләхович сүз ахырында гына сорады аңардан:

— Идеал Ибәтович, әгәр мин сезгә бер эшемне карап чыгарга бирсәм, ничек, вакытыгыз булырмы?

Һәр вакыттагыча яхшы кара костюм, чиста ак күлмәк кигән, арык

какча битле, әмма калку маңгайлы Шәйхиев үз нәүбәтендә тыныч кына сорады:

— Нәрсә ул?

— Донбасс турында... Дөресрәге, татарларның Донбасс шахталарына кай заманда бара башлаулары турында, ничек дим, тарихи бер күзәтү... Исеме дә «Донбасста татар шахтерлары» дип атала. Күләме зур түгел, вакытыгызны күп алмас дип уйлыйм.

Шәйхиев дәшми торыбрак тагын сорады:

— Минем бурыч нидән гыйбарәт?

— Сездән мин, Идеал туган, бер генә нәрсә ишетәсем килә: кульязма шушы хәлендә нәшриятка тәкъдим итәрлекме, түгелме?

Шәйхиев көлемсерәп куйды:

— Нәшрият үзенчә хөкем итәчәк.

— Әлбәттә... Сүз бары тәкъдим итеп карау турында гына бара. Мин моны үзем дә эшли алам, билгеле, ләкин сез бит нәшрият белән күбрәк эш иткән кеше, аларның таләпләрен яхшырак беләсез!

Шәйхиев бераз гына уйланып торды. Аннары:

— Яхшы,— диде һәм папканы кулына алды.— Карап чыгармын.

— Рәхмәт, туган! — диде Гасыйм Сәләхович, һәм шуның белән сүз дә бетте. Шактый ук коры килеп чыкты бу сөйләшү, шул сәбәпле киңәшегез-фәләнегез булса дип тә сүз озынайтып тормады. Тик Шәйхиев чыгып киткәч тә артыннан көрсенеп: «Үзенә күрә түгел, егет!» дип калды.

Ә өч көннән соң яшь профессор кульязманы китереп тә бирде. (Эшне тиз тотарга ярата иде.) Папканы «Дипломат» дип йөртелгән өр-яңа сай гына тартмадан чыгарып:

— Укыдым,— диде.— Минемчә, бу хезмәтегезне нәшриятка тәкъдим итәргә ярый, Гасыйм Сәләхович!

— Рәхмәт, туган!.. Биреп карыйм, алайса...

— Бирегез....

Гасыйм Сәләхович әз генә сүз табалмыйчарак торды.

— Бәлки замечаниеләрегез бардыр, Идеал Ибәтович? Мин, рәхәтләнеп дигәндәй, әзер...

Шәйхиев бик мәгънәле генә итеп елмайды.

— Сез бит миннән бер генә нәрсәне ишетергә теләдегез, Гасыйм Сәләхович! Шулай түгелме?

— Анысы шулай инде... Мин канәгать, тагын бер мәртәбә рәхмәт сезгә!

Аннары әзрәк вакытны сузар өчен генә аны-моны сөйләшкәләп утырдылар. Ә бер биш-алты минуттан Шәйхиев каядыр ашыккандай сәгатенә карап алды да, торып, баш кагып кына чыгып китте. Күрәсез, бу сөйләшү дә Гасыйм Сәләхович көткәнчә булып чыкмады. Янәсе ул бер генә нәрсә ишетергә теләгән! Бу кадәр коры, рәсми булыр икән кеше! Бигрәк тә аның мәгънәле генә елмаюы Гасыйм Сәләховичка бер дә ошамады. Хәтта билгесез бер борчылу да тудырды.

Әмма соңыннан Шәйхиевнең «тәкъдим итәргә ярый» диюе бушка булып чыкмады. Кульязманы нәшриятта кабул иттеләр, бик озакка сузмыйча укыдылар, ошаттылар, кемнәндер рецензия дә яздырып алдылар. Гүя кульязма тышындагы исеме белән үк үзенә юл ачты һәм менә бер ел үтүгә, күптән түгел, дөньяга басылып та чыкты. Йөз егерме битлек, катыргы тышлы, кулга тотарлык бер китап — һәм бу китап Гасыйм Сәләховичка чын канәгатьләнү белән бергә рухи бер җиңеллек тә китерде. Ниһаять, җаны тынычланып, үзенә ышанычы артып, өметләре яңадан кабынгандай булды. Ә бит аның яшенә җиткән һәм кафедра мөдире булып торган кеше өчен моның әһәмияте кечкенә түгел — баскан урыныңда әле селкенмичә нык торырга була дигән сүз!

Билгеле, Идеал Шәйхиевкә дә аның ышанычы яңадан артты, яңадан ныгыды. Теге вакытта егетнең сәер елмаюына әһәмият биргән булып, юкка гына борчылган икән. Просто балалык! Асылда дөрес бәяли белгән яшь галим аның хезмәтен, тәкъдим итәргә ярый дип бик дөрес, бик урынлы әйткән. Кыскасы, Гасыйм Сәләховичның рәхмәте зур аңа!

Ул эчке кичерешләрен тышка чыгармаска өйрәнгән кеше. Шулай да бу юлы аңа куанычын яшерү җиңел булмады. Сүзләреннән сизелмәсә дә, моны аның йөзеннән күрергә мөмкин иде, гадәттә сытыграк чырайлы шешенке бите ничектер язылa һәм яктыра төшкәндәй булды. Аннары китап магазинга чыккач та, берьюлы утыз данә сатып алып, шуларны кыска гына автограф белән кафедра кешеләренә һәм якын танышларына өләште. Бу да үзенә күрә шатлыгы белән уртаклашу иде. Барысы да рәхмәтләрен әйттеләр, кулын кыстылар. Ә соңрак аларның кайберләреннән ул: «Бик кызыксынып укыдым», яки «Китабыгыз миңа бик ошады», яки «Бик кирәкле нәрсә язгансыз, Гасыйм Сәләхович» дигән кебек сүзләр дә ишеткәләде. Автор кеше бу мактау сүзләрен шактый ук ышанып кабул итте, чөнки, аның фикеренчә, бер дә ошамаган китап турында берәү дә алай ялганлап әйтмәс,— хәтта комплимент итеп тә!

...Тик иң теләгән кешесе Идеал Шәйхиевкә китабын тапшыра алганы юк әле. Китап сатуга чыккан көннәрдә генә яшь галим персональ чакыру буенча Болгариягә китеп барды. Шуннан соң өч атна чамасы вакыт үтеп китте, күптән кайткан да булырга тиеш, ә менә Гасыйм абзасына ни сәбәптер килеп күренгәне юк. Бу хәл Гасыйм Сәләховичны беркадәр гаҗәпләндерә дә, уйландыра да, ләкин үзе башлап аның өенә шалтыратырга уңайсызлана да иде. Шәйхиев берәр ерак җирдән кайтса, кафедрага кереп, исәнләшеп, күргәннәрен кыскача гына сөйләп чыга торган иде. Бу юлы ни үзе, ни хәбәре — гаҗәп! Теләсәң ни уйла!.. Шулай итеп, Гасыйм Сәләхович үзенең зур рәхмәтен һәм хөрмәтен титул битенә язып, махсус әзерләп куйган китабын аңа тапшыра алмыйча менә күпме вакыт портфелендә саклап йөртергә мәҗбүр... Кызыксызрак килеп чыкты әле бу, хәерсез!.. Хәзер инде аның шатлыгы да, дәрте дә шактый сүрелде. Кәефе дә шәп түгел... Ләкин ул китабын барыбер тапшырачак, бүген булмаса— иртәгә!.

*III*

Университетның таш идәнле караңгырак вестибюленә килеп кергәч тә Гасыйм Сәләхович җиңеләеп бер сулап куйды. Тыштагы эсселек монда юк, һава монда салкынчарак иде. Тәненнән бигрәк йөрәге белән тизрәк сизде ул моны.

Имтиханнар бетеп, студентларның таралыр вакыты җитсә дә, университет коридорларында шаулашып, ашыгып йөрүче яшьләр күп иде әле. Билгеле, аларның барысында да хәзер йә эшкә, йә ялга китү кайгысы — шуның белән мәш килеп йөриләр. Ә гомумән исә бу коридорларның бушап торган чаклары булмый да диярлек. Менә озаклямый читтән торып укучылар киләчәк, аннары университетка керергә теләүче яшь кенә егетләр һәм кызлар монда әйләнә-тулгана башлаячак, инде күпмедер вакыт үткәч тә йөзләренә өмет, шик, каушау чыккан шул яшь абитуриентлар аудитория ишек төпләренә җыелачак. Елдан-ел кабатлана бу хәрәкәт, университет күпме яшәсә шул чаклы дәвам итә ул! Кайберәүләр яшь кенә студент булып керәләр дә ап-ак сакаллы галим булып чыгып китәләр моннан — вакыт һәм язмышлар әнә шулай өзлексез агып һәм алмашынып тормакта бу таш бина эчендә!

...Кояшлы көн яктысыннан килеп кергәч, аеруча караңгырак булып күренгән озын коридор буйлап Гасыйм Сәләхович үзенең кафедрасына таба атлады. Очраган танышлары белән баш кагып кына исәнләшеп узды. Инде үз бүлмәсенә кереп, капрон эшләпәсен чөйгә элеп, өстәле янына килгәч, ул башта таза, иркен креслосында җәелә биреп, бераз хәл алып тик кенә утырды. Бер-ике генә минут шулай тугарылып утыруга ул соңгы вакытларда гына ничектер гадәтләнеп киткән иде. Күрәсең, бу аның йөрәге белән бәйләнгәндер инде. Аннары гына ул эшкә күчә, уйлый һәм хәрәкәт итә башлый. Һәм тиз арада йөрәк тә, хәлсезлек тә — барысы да онытыла. Бары тик эш кенә кала, ә эш сыналган дәва, яшәтә ул кешене!

Алгы бүлмәдә утыручы лаборант кыз көндәге тәртип буенча бүген дә яңа газеталарны аның өстәленә кертеп куйган иде. Гасыйм Сәләхович, эше бик тыгыз булмаса, аларны шунда ук караштырып чыга, инде вакыты юк икән, барысын бөкләп портфеленә тыга да, өенә кайткач, ашыкмыйча иркенләп карый.

Бүген исә ул газеталарны хәзер үк ачып, күздән бер кичерергә булды. Башта, билгеле, Мәскәү газеталарын карап чыкты. Алардагы кыскарак хәбәрләрне тиз генә укыштырды да үзе өчен әһәмияте булган җитдирәк мәкаләләрне кайткач укырга дип калдырды. Шуннан соң үзебезнең газеталарга күчте. Гадәтенчә ул аларны ахыргы битеннән карый башлый — төрле яңалыклар, кызыклы хәбәрләр күбрәк шушы биттә табыла. Шулай ук бу биттә ара-тирә булгалап торган кара сызыклар эчендәге кайгылы белдерү дә аның игътибарын җәлеп итмичә калмый—кайчагында күз күргән яки колак ишеткән кешеләр дә очрап куя бу кара сызыклар эчендә. Әмма Гасыйм Сәләхович үзе үлем турында уйларга да, сөйләргә дә бер дә яратмый.

...Инде менә «Татарстан»ның икенче, өченче битләре. Чит ил хәбәрләре, хуҗалыкка караган мәкаләләр, алдынгыларга багышланган язмалар... Тукта, ә бусы нәрсә?.. «Донбасста татарлар». Гаҗәп таныш исем ич бу!.. Ә исемнән өстәрәк, ваграк хәрефләр белән бер читтә «Тәнкыйть-библиография» диеп тә куелган. Димәк, рецензия, аның китабы турында рецензия бу!.. Ә кем язган?.. Гасыйм Сәләхович тиз генә мәкаләнең ахырына күз төшерде: профессор Идеал Шәйхиев! Алай-й икән, хөрмәтле Идеал Шәйхиев аның китабы турында рецензия язып чыккан икән ләбаса! Рәхмәт төшкере!

Гасыйм Сәләхович газетаны урталай бөкләп, алдына салып, кечерәк подвал итеп басылган мәкаләне бик игътибар белән ашыкмыйча гына укырга кереште. Баш күтәрмичә һәр җөмләсен, һәр сүзен, хәтта юллар арасында әйтелмичә калганын да аңларга тырышып укыды. Кайбер төшләрен кайтадан укып карады. Ниһаять, укып бетерде һәм бик нык уйга калды Гасыйм абзаң! Хуш, ничегрәк аңларга бу мәкаләне? Китапка ниндирәк бәя бирә хөрмәтле рецензент? Мактыймы, яманлыймы?.. Хәер, монда артык юрап маташыр нәрсә юк та шикелле... Әгәр аның катлаулы җөмләләр белән бик фәнчә итәргә тырышып язганнарын гадиләштереп, кеше аңларлык телгә күчерсәң, түбәндәге төп нәтиҗә үзеннән-үзе диярлек килә дә чыга: ягъни «Донбасста татар шахтерлары» дигән бу әсәр чын мәгънәсендә фәнни хезмәт түгел, имеш! Менә шул. Дөрес, Шәйхиев китапны яманламый. Киресенчә, укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле китап ди. Тик хикмәт шунда ки, бу китап, башлыча, җирсезлектән интеккән ярлы татар агайларының Донбасска отхожий эшкә китәргә мәҗбүр булуларын бик тәфсилләп язган бер беллетристика сыман нәрсә булып чыккан, янәсе — чын фәнни хезмәт булыр өчен аңа тege җитми, бу җитми, имеш, анысы онытылган, монысы ачылмаган, анализ йомшак, гомумиләштерү зәгыйфь — кыскасы, китапка карата рецензиядән әнә шуның кебек тәнкыйть сүзләрен күп чүпләргә була. Дөрес, фәннәр

докторы үзенең каты хөкемен мөмкин кадәр такт саклап, аябрак әйтергә тырыша, моның өчен еш кына «хәлбуки», «безгә калса», «кызганычка каршы» кебек буфер ролен үтәрдәй сүзләр дә куллана, әмма ләкин күпме генә йомшартып маташмасын, төп нәтиҗә һаман шул бер нәрсәгә кайтып кала. Гасыйм абзаңның бу хезмәте хәзерге фән таләпләренә җавап бирүдән ерак тора икән әле... Менә шулай ул, кем, автор иптәш!

...Озак утырды Гасыйм Сәләхович алдында яткан газетага текәлеп. Һәм ул бу минуттагы хәлен ничек кенә дип атарга да белми иде. Әллә авыр аңа, әллә түгел, әллә инде барыбер?! Хәер, барыбер булуы һич мөмкин түгел, чөнки рецензияне иң ышанган кешесе язган, һәм шик тә юк ки, аның зарарына язган. Әмма шул ук вакытта ул Идеал Шәйхиевкә бер төрле дә гаеп ташлый алмый иде. Менә нәрсә аны тирән бер аптырауга төшерде. Я, ничек итеп, нәрсәдә гаепли ала ул аны?.. Икейөзлелектәме?.. Әйе, Шәйхиев кульязманы укыганнан соң менә монда язып чыккан фикерләренең берсен дә аңа әйтмәгән иде. Ләкин бит ул үзенең шул чакта биргән киңәшенә каршы да килми ич! Кульязманы нәшриятка тапшырырга да, бастырып чыгарырга да яраган, хәтта әнә китапның укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле булуын да әйткән! Кайда монда икейөзлелек?.. Юк, тагын булмый аңа бу гаепне! Тик шул гына, теге вакытта үзенең чын, асыл фикерләрен әйтеп торуны кирәк дип тапмаган. Ни өчен? Әйе, ни өчен, нигә яшергән? Бәлки ул кульязманы сүтеп ташларга теләмәгәндер (кызганган Гасыйм абзасын!), ә бәлки әйтеп торудан файда юк, бу карттан шуннан да артыгын көтеп булмый дип тә уйлагандыр. Бик мөмкин моның шулай булуы... Теге вакытта аның йөзендә чагылган мәгънәле елмаю дә нәкъ менә шуны раслый түгелме?!

Кинәт күңеленә килгән бу уйдан Гасыйм Сәләхович үзен ничектер бик кечерәеп калган шикелле хис итте. Ниндидер мескенлек, нәүмизлек аның җанын биләп алды. Күңелендә ирексездән яшь галимгә рәнҗү хисе уянды. Ни әйтсәң дә, Гасыйм абзасы аны кайчандыр укыткан кеше бит әле, остазы, хәлфә хакы бар бит әле, аңардан башка бүтән тәнкыйть итүче табылмас идемени? Ә ул, профессор, яшь галим бик югарыдан торып: «Җитте сиңа, абзый, иярдән төшәргә вакыт!» дип әйтә кебек.

Хәер, ник әйтмәсен?.. Хәлфә-шәкерт төшенчәсе хәзер инде бер анахронизмга әйләнеп бара. Алар, Шәйхиевләр килә, хәтәр килә, юл бирмәсәң, күрәләтә таптап та узарлар. Нәрсә ул, аерым кеше язмышы! Алар өчен иң югары максат — фән, ә фән ул һәр төрле исәп-хисаплардан өстен торырга тиеш. Я, алар хаклы түгелме?! Юк, картайдың син, картайдың, хөрмәтле мөдир!

Гасыйм Сәләховичның хәзерге минуттагы рухи хәлен бер генә сүз белән билгеләргә була, бу — апатия. Дөньясына, эшенә, үзенә, ниндидер Шәйхиевләргә — барысына да салкын битарафлык. Кызыксыз, мәгънәсез, кирәксез... Шушы минутта, шушы сәгатьтә... Аннары үтәр, иншалла, үтәр! Тик болай бөкрәеп утырмаска, торырга, хәрәкәтләнергә кирәк. Йөрәгенә дә хәрәкәт кирәк... Иң яхшысы, чыгып китеп, бераз йөреп кайту — монда хәзергә әле ашыгыч эше дә юк. Кешеләр килеп кергәләгәнче — югыйсә, тегесе яки бусы килеп керер дә хәләхвәл сорашкан булыр, газетаны укыганнары гаҗәпләнүләрен, хөрмәтле Шәйхиев белән килешеп бетмәүләрен белдергән булырлар... Юк, юк, кирәкми, алла хакы өчен икейөзлеләнмәсеннәр! Берсенеке дә бик җиткән!

Гасыйм Сәләхович сәгатенә карап алды — унике тулган икән инде. Халыкның нәкъ мыжгыган чагы... Ул алдында яткан газетаны бөкләп, башкалары өстенә куйды, ләкин, кеше күрмәсен дип, ахры, кире алып, өстәл тартмасына салды. Аннары барып, чөйдәге калай

шикелле яньчелеп каткан эшләпәсен алып киде. Ах, белсәгез иде аның бу капроннан туйганын! Юк бит электәге башка сихәтле салам эшләпә!..

Портфелен алып, кабинетыннан чыккач, алгы бүлмәдә утыручы лаборант кызга узышлый гына: «Мин клиникага киттем, бер-ике сәгатьтән кайтырмын», диде. Кыз аның хәлен аңлагандай башын кагып: «Ярый, Гасыйм абый, ярый!» дип калды. Ә Гасыйм абзасы инде шунда ук үкенеп тә куйды: «Нигә әле мин кая баруымны әйтеп торам?.. Сораган бер кешегә клиникага китте дияр, ә сораучы эченнән генә «эһә, Шәйхиев тәнкыйтен күтәрә алмаган икән» дип уйлар... Минем кебек тә хәйлә белмәс кеше бар микән?!». Ләкин шуның артыннан ук ул үзен тиргәргә дә тотынды: «Нишләп әле мин җыен чепухага игътибар итә башладым? Хатынның клиникада ятканын белмиләрме соң... Юк белән баш ватасың, карт тиле!».

Дөрес, хатын янына барырга бик иртә иде әле. Анда сәгать дүрттән соң гына кертә башлыйлар. Хәер, Рәмзия аяк өстендәге авыру, чакырткач, үзе дә чыгар. Бүген барыбер аның янына барасы көн. Аннары, кеше күп булмаса, бәлки ул үзе дә врачка күренер. Йөрәгенең әледән-әле борчып торуыннан бер кереп зарланырга кирәктер бит инде, кешеләр энә, эчләре катса да, тизрәк врачка йөгерәләр.

Гасыйм Сәләхович як-ягына каранмыйча гына озын коридор буйлап узды, кемнәрдер аңа баш иде, ул да таныса-танымаса да баш иде, ахырда менә яп-якты урамга да килеп чыкты... Ну көне... Пешерә генә. Тынны куыра... Яктысыннан күзләр камаша... Һава эретеп агызган кургашындай тик тора. Ник бер генә яфрак селкенсен! Яңгырга гына булса ярар иде! Алай дисәң, төпсез күк йөзе чат аяз... Килеп чыкмый бит шул Ослан таулары артыннан кәҗә тиресе хәтле бер генә кара болыт!.. Ә барырга, әлсерәп булса да барырга кирәк... Ул трамвайга утырыр өчен университет урамы буйлап түбән төшеп китте. Тротуарның кояшка караган җирләре йомшарган, аяк батып киткәли хәтта.

Шәһәр урамында бик сакланып йөрергә кирәклеген Гасыйм Сәләхович һәр вакытта исендә тота торган иде. Бу юлы исә ул һәр төрле куркынычны онытып, бары өйрәнелгән гадәт буенча гына башын уңга-сулга борды да, ашыкмыйча гына киң, хәтәр урам аша чыга башлады. Алдыннан һәм артыннан выжлап машиналар узды, әмма ул аларга юньләп игътибар да итмәде. Тукталышка килде, трамвайга утырды, ә трамвай аны үргә таба алып менеп китте. Бер кыз бала торып аңа урын бирде (рәхмәт төшкере!), Гасыйм Сәләхович утырып, вагон тәрәзәсеннән урамга карады. Ул тыныч иде, ул һич ни уйламый иде, ул урамданиләр барын да күрми иде шикелле. Күзгедә чагылгандай күзләреннән йортлар, агачлар, кешеләр үтә, әгәр шуларның берәрсе таныш кеше булса, ул аны да ихтимал күрми-танымый узар иде. Ләкин шулай да бу әле аның чын хәле түгел, чын хәле аның үз эчендә, каядыр тирәндә. Иң элек ул бер генә минутка да Идеал Шәйхиевне оныта алмый. Идеал Шәйхиев гүя бер адым калмыйча аңа ияреп бара, һәм Гасыйм Сәләхович теләсә-теләмәсә дә аның турында уйланырга мәҗбүр иде. Уйланып гаҗәпләнергә һәм ирексездән рәнҗергә мәҗбүр иде. Ничек кенә булмасын, башта чын фикереңне әйтмичә яшерү, соңыннан шуны язып чыгу бу егетлек түгел. Бу куркаклык һәм түбәнлек! Аннары ни өчен ул, Шәйхиев, менә өч атна инде кафедрага килмичә, күренмичә йөри? Намусы кушмыймы әллә?.. Юк, ул андый кеше түгел, салкын, рационалист кеше ул, намус аның өчен абстракт төшенчә генә... Хәер, килеп күренмәве яхшы да булган икән. Югыйсә Гасыйм абзасы аңа дип саклап йөрткән китабын түбәнчелек белән тапшырган да булыр иде. Ярый, ходай сакласын! Әмма барыбер аларга очрашырга туры киләчәк. Тик шул

чакта бәхәскә кермәскә (керүдән ни мәгънә?), сер сынатмаска, бәйсезлек, тынычлык сакларга иде. Тик шуңа көче җитсен иде аның!

...Трамвай урам чатына җитеп, туктады, халык төшә башлады, ул да агымга ияреп төште. Чехов базары аша үткән чакта хатынына дип бакчачылардан бер кило виктория җиләге сатып алды. Шуны үзе белән йөртә торган целофан капка салдырды да урам ашасындагы клиникага таба атлады. Башта ул үзен кабул итә торган врачка кермәкче булды, ләкин аның врачы бүген сәгать икедән генә кабул итә башлаячак икән. Шуннан соң ул ишегалды аша гына авырулар ята торган стационарга узды һәм түбәндә утыручы сестрадан хатынын дәшеп чыгаруны үтенде. Сестра аны таный иде, шуңа күрә, вакытсызрак килгән булса да, сүзен тыңлады.

Гасыйм Сәләхович бер читтәрәк торган дермантин тышлы киң генә йомшак эскәмиягә барып утырды, эшләпәсен салып, янына куйды, шактый керләнгән кульяулыгын чыгарып, маңгаен, муенын сөрткәләде. Монда, таш бина эчендә, аз гына салкынчарак иде, тын алуы да җиңелрәк иде... Озак та үтми, соры халаттан гына Рәмзия ханым да килеп чыкты. Больница киеме кешене гадәттә авыру итеп кенә түгел, килбәтсез итеп тә күрсәтә. Авыру ирләр бу хәл белән ничектер килешсәләр дә, хатын-кызлар, бигрәк тә яшьрәкләре, бер дә килешергә теләмиләр, күрәсең. Менә Рәмзия ханым да өстендәге котсыз халатын гәүдәсенә сыланганчы урап, билен фланель билбавы белән шундый кысып бәйләгән — озын аяклары да, җәелә төшкән янбашлары да, тулы күкрәкләре дә йомры-калку булып, бик ачык беленеп тора. Кыскасы, эссе дип тормаган, сакларга тырышкан фигурасын... Шулай ук бакыр төсенә кертеп буяган чәчләренең прическасы да һаман шул килеш, матур килеш тора икән әле... Озынчарак куллары да әнә нинди ак, йомшак — төче генә бер ис тә аңкый үзләреннән. Әлбәттә, хатынының шушылай пөхтә, чиста, чибәр булуына һәрбер җаны бар ир сокланмыйча, хәтта дәртләнмичә калмас иде, әмма Гасыйм Сәләхович Рәмзия ханымның бу котыртып торырлык килеш-килбәтенә гүя бөтенләй игътибар да итмәде. Хәер, игътибар итте итүен, ләкин гаҗәеп бер салкынлык һәм битарафлык белән генә... Гүя хатынының бу байлыклары бер дә аның өчен түгел кебек иде. Хәтта көнләшү дә кузгалмады аңарда — кузгалырга иренде, ахрысы.

Янәшә утырышкач, Гасыйм Сәләхович, күрешергә килгән ир буларак, башлап үзе сүлпән генә сорады:

— Я, ничек соң... хәлең?

Рәмзия ханым да гадәтенчә туры гына «яхшы» яки «начар» дип әйтмичә, башта әзрәк зарланып алды. Үткән төнне начар йоклаган икән, шуңардан бүген менә башы авырткан. Ә хәзер?.. Ә хәзер үтте кебек. Әлбәттә, үткән булырга тиеш...

— Кайчан чыгасың? — дип сорады ире тезләренә таянган килеш кенә.

— Ахрысы, озак тотмаслар, — дип зарланды Рәмзия ханым. — Урын бушатырга кирәк, диләр. Үзләренең берәр дус-ишләренәдер инде. Бөтен җирдә блат, җаным!

— Нигә, үзеңнең чыгасың килмимени?

— Килсә дә бит, бер кергәч, барысын да белеп чыгасы иде. Каткат кереп булмый монда.

— Врачлар белеп чыгара торганнардыр инде.

— Сиңа шул врач сүзе генә сүз, — диде Рәмзия ханым турсая биреп, — ә минем хәлемдә кайгың юк синең...

Гасыйм Сәләхович дәшмәде. Сүз көрәштерергә аның һич кенә дә теләге юк иде. Врачлар турында әйтү дә кирәк булмаган. Ни пычагыма?!

Менә ул көн аралаш диярлек килә, китә, ә Рәмзиянең бер генә

һапкыр да аның үз хәле турында сорашканы юк. Ничек яши ул ялгызы, үзен ничек хис итә, эшендәниләр бар? — ник бер юри генә сорап карасын! Бәлки зарланганны көтә торгандыр. Ә Гасыйм Сәләхович зарлана алмый, һәм иң гаҗәбе — нәкъ менә хатынына зарлана алмый ул. Сәбәп?.. Моны аңлатуы да читен. Кыскасы, үзеннән күп яшь һәм шактый ваемсыз хатынын борчымаска теләп, ә бәлки аның алдында дәрәҗәсен төшерүдән куркып та, ул Рәмзиягә эше-хезмәте, бигрәк тә сәламәтлеге турында тыелып килде. Һәм шушы нәрсә ничектер ирексездән аның гадәтенә дә кереп калды. Куанычын уртаклаша ала, әмма кайгысын — юк, сөйли алмый. Ләкин бит сөйләмәсә дә сизәргә, күрергә мөмкиндер инде, кешенең йөзенә карап та! Сукыр булмаса... Хәер, күрсә дә бәлки әһәмият бирми торгандыр. Кем ул ир дигән кемсә? Эш аты. Аттан да бит кәефең ничек, берәр җирең авыртмыймы дип сорамыйлар. Селкенәме — селкенә, тартамы — тарта, тагын ни кирәк?!

Рәмзия ханым малае турында сорады:

— Радиктан хат юкмы?

— Юк.

— Бу ни эш, киткәннән бирле бер хаты юк. Син шул бала өчен борчыласыңмы әзрәк?

— Бала түгел, җиткән егет, — диде Гасыйм Сәләхович.

— Ата диген инде... Бу хәтле дә таш йөрәк булырсың икән!

— Мин аның исән-сау кайтуына ышанам, — диде Гасыйм Сәләхович, ничектер бик кистереп.

Рәмзия ханым иреннәрен кысарга мәҗбүр булды, тик бераздан гына үзалдына хафалангандай:

— Акчасы да җитмәс инде балакаемның, — дип куйды.

— Җитмәсә, телеграммасы килер, борчылма!.. Акчадамыни эш! Менә көннәр бик кызуга китте әле... — Гасыйм Сәләхович эшләпәсен алып җилпенә башлады. Бите аның тимгел-тимгел кызарып һәм бүртенеп тә киткән төсле иде. Аннары кинәт кенә сүнгән хәлсез тавыш белән: — Мин кайтыйм инде булмаса! — диде.

— Нигә, миңа бер нәрсә дә алып килмәдеңмени? — диде Рәмзия ханым, аз гына көлемсерәп.

— Да... бөтенләй онытып җибәргәнмен. — Гасыйм Сәләхович артындарак торган целофан капны алып, хатынына сузды. — Виктория. Әле генә базардан алдым.

— Рәхмәт инде... Ә мин кушканны китердеңме соң?

— Нәрсә иде ул?

— Минем челтәрле бюстгалтерымны?

— Нәрсә-ә?

— Бюстгалтерны дим... Челтәрлесе...

Гасыйм Сәләхович һич нәрсә аңламыйча, кашларын җыерып, хатынына карап тора башлады. Бюстгалтер!.. Бик мәгънәсез бер әйбер турында сүз бара түгелме?.. Каян белсен, хәтерләсен ул аны?!. Шундый бер чүпне!

Рәмзия ханымның кинәт аңа ачуы килеп китте:

— Нәрсә син, аңгыра сарык шикелле, миңа карап торасың. Нәрсә икәнен белмисеңме әллә?

— Белмим! — диде Гасыйм Сәләхович, хатыныннан күзләрен ала алмыйча.

— Нигә, студенткалар түшендә бер дә күргәнең юкмыни? — диде Рәмзия ханым, юри шаркылдап.

Гасыйм Сәләховичның йөзе, каны качкандай, кинәт агарынып китте. Әллә һава җитмәгәннән, әллә нидер әйтмәкче булып авызын ачты, нигәдер бик кызганыч итеп бер елмаеп та алды, әмма ни дә булса әйтә алудан узган бер хәлдә авыр гына торып, бәкрәеп ишеккә

таба атлады. Аяк атлаулары бик сәер, бик кыюсыз иде аның,— хәтта Рәмзия ханым да моңа игътибар итте. Ләкин, ирексездән борчылып куйса да, ирен шулай да туктатып тормады.

Урамга чыккач, Гасыйм Сәләхович бик аз гына вакытка туктарга мәҗбүр булды. Ашыгырга ярамый иде аңа. Йөрәк менә тире астында гына тибә кебек, бер авырттырып кыса, бер җибәрә, бер кыса, бер җибәрә... Хәтәр иде бу... Тизрәк валидол кабарга теләп кесәсенә тыгылды, ләкин анысы да онытылып калган булып чыкты. «Өйгә, тизрәк өйгә!» диде ул үз-үзенә һәм әкрен-сак кына атлап китте. Башы да бераз әйләнә кебек, шунлыктан ара-тирә чайкалып та киткәли иде.

Үз хәленең бөтен җитдилеген яхшы аңласа да, ул ни өчендер шушында ук врачка күренергә кирәк дип уйлый белмәде. Күңеле аны нигәдер өенә тартты. Ә бит аның кәефе иртәдән үк начар иде, эшенә баргач, Шәйхиев мәкаләсе кәефен тагы да ныграк бозды — бозу гына түгел, бәгырен тирән яралады. Шулар өстенә тагын Рәмзия белән менә бу мәгънәсез сөйләшү! Җиткән иде аңа, бик җиткән иде, кирәкми иде аңа агудай кечкенә, әмма бик хәтәр бу соңгы тамчы!

...Көн әүвәлгечә аяусыз эссе иде. Эссе булу гына түгел, гаять бөркү-тынчу да иде. Һава һич селкенмичә, шылт та итмичә бөтен нәрсәне басып, изеп тик тора. Моның кебек авыр, тын, хәрәкәтсез һава бары яшенле яңгыр яки көчле давыл алдыннан гына булырга мөмкин. Һәм ныграк игътибар итсәң, көн, чынлап та, үзгәрмәкче иде шикелле... Әнә еракта, Иделдән дә ары, тауларга охшап тик кенә торган ак читле кара-зәңгәр болытлар күренә. Юк, алар, чынлабрак баксаң, тик кенә тормыйлар икән, алар һаман кабара баргандай үсәләр, куералар һәм бик әкрен генә болай таба авышалар да иде... Әмма Гасыйм Сәләхович боларның берсен дә күрми иде, эсселеккә дә, сәер тынлыкка да бөтенләй игътибар итми иде, аның бөтен кайгысы — тизрәк өенә кайтып җитү иде.

Үз йортларына җитеп, өченче катка туктый-туктый менгәнче ул тәмам тиргә батты, калтыранган кулы белән ишекнең ике бигеп азаплана-азаплана ачты, эчкә узды, шулай да кире борылып, чылбыр бикне генә булса да эләктереп куярга онытмады. Аннары үз бүлмәсенә узып, эшләпәсен һәм портфелен диванга ыргытты да, сөйрәлеп кенә өстәле янындагы күн төпле креслосына барып утырды. Аңа хәзер үк берәр дару кабу кирәк иде, ул үзе дә моны бик яхшы белә иде, ләкин ни өчендер ашыкмады — чак кына хәл аласы, бер-ике генә тапкыр булса да тирән итеп һава сулыйсы килде. Нәкъ шул чакта каядыр бик еракта кинәт тау ишелгәндәй дәһшәтле гөрселдәп, көчәя барып, озак итеп күк күкрәде һәм нәкъ шул ук мизгелдә Гасыйм Сәләховичның йөрәгенә әйтерсең уттай кызган пычак китереп тыктылар. Кискен, көйдергеч авыртудан яман коты алынып, авызын зур ачып, ул креслосына чатыр ябышты, көзән тарткандай киерелеп артка каерылды, бугазыннан гыжлап әллә тавыш, әллә һава чыккандай булды, ләкин шул секундта ук гәүдәсе капчыктай бушап, күзләре сүнеп, туктап калды. Тик бераздан гына башы үзеннән-үзе күкрәгенә кире салынып төште. Тагын еракта отыры дәһшәтләрәк, катырак итеп күк күкрәде, якынлашып килгән давыллы яңгырның беренче кискен җиле урам агачларын сыгып, шаулатып узды, ләкин Гасыйм Сәләхович өчен дөнья тып-тын, дөнья юкка чыккан иде инде.

Ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр тәүлек буена бер әкренләп, бер шәбәеп туры гына яуды да яуды. Көчле җилдән бүлмәнең урам тәрәзәсе ачылып калган иде, өйгә яңгыр шавы белән бергә дымлы салкынча һава тулды. Гасыйм Сәләхович шул рәхәт җиләстә тынычланып ял иткәндәй үзенең креслосында, башын игән килеш, бер ялгызы тып-тын гына утыра бирде.

Әле беркем дә бер нәрсә дә белми иде.

1978 ел.

## Клара Булатова

### Апрель керде җиргә

Син: «Язмый тор, укытмый тор, — дисең, —
Шигырьләрне, — дисең, — куеп тор».
«Эшләми тор, уйламый тор»,— дисең...
«Яшәми тор», — дисең бит, доктор!

«Урамнарда, — дисең, — күбрәк йөр син,
Ял итеп йөр, — уйлап ялыкма».
Синең сүзне тыңлау бик кирәктер,
Хөрмәтем зур сезнең халыкка.

Хөрмәтем зур... Үзем гомер буе
Хыялландым — әмма булмадым.
Хәзер инде доктор була алмам...
Ә сүзеңне барыбер тыңламыйм.

Син бит миңа: «Эшләми тор, — дисең, —
Шигырьләрне, — дисең, — куеп тор».
Эшләми дә, уйламый да йөрсәң,
Яшәү буламыни ул, доктор!

Киңәшеңне тотып, урамнарда
Саф һавада йөргән чагымда
Ничек язмый торыйм
Тәүге язын күргән Әлмәтемнең
Егерме бишенче язында?

Син ул язда, доктор, кайда идең?
Урта мәктәп яки вузыңда?
Ә мин монда, нәкъ шушында идем —
Шушы иркен, якты шифаханәң,
Кабинетың булган урында.

«Әлмәтнефть төзү тресты»ннан
Бер участок иде бирелә.
Һәм мин, доктор, шунда эшли идем,
Шушы больницаны төзүдә.

Төзелештә төрле кеше иде —
Төрле якның төрле яшьләре.

Житәкчебез Азат Дияровның
Кара иде әле чәчләре.

Ут уйнатып торган инженерга
Кем сокланмас иде ул чакта.
Бүген менә тагын аның белән
Очраштык без сиңа чиратта.

Ул — ак чәчле... Бер дә гаҗәп түгел
Безнекеләр инде агаргач.
Әмма, доктор, Әлмәт төзелеп калды
Безнең яшьлек белән аралаш.

Шул Әлмәткә тагын язлар килде,
Апрель керде җиргә нур бөркеп.
Кыш буенча кар астында яткан
Үләннәрне төптән терелтеп.

Ә син миңа: «Эшләми тор, — дисең, —
Шигырьләрне, — дисең, — куеп тор»...
Яз көнендә җыр да язма, имеш.
Шул буламы яшәү соң, доктор?!

Киңәшеңне тотып, саф һавада
Җәяү генә кайтып китим әле,
Йөзем куеп Әлмәт язына.
Бу көннәрдә никтер күп языла,
Күп языла доктор, языла!

## Севан

Тарих беләдер дә — без белмибез
Сиңа тыңдәш күлне тауларда.
Севан, Севан! Күпме сагыш сыйган
Өмет тулган синең ярларга.

Булган еллар — йөзең җыерылган...
Үзең тулы сулыш алмастан,
Суларыңны утка күчергәнсең
Үссен өчен улың Аястан [1].

Яшәвеңне хәзер саклар өчен
Туннель ярып тау-таш аркылы
Оныкларың сиңа борып кертә
Тау елгасын — уйнап Арпыны [2].

Севан, Севан, сиңа нурын сузган
Октябрьда туган аяз таң.
Таң балкышы хәзер, тау балкышы —
Утлы-сулы булган Аястан.

---

[1] Әрмәнстан.
[2] Язмада: Арпа.

●

Урартудан калган тау ташларын
Тишеп гөлләр үсеп чыкканнар.
Әрмәннәрнең зәңгәр күзле чагын
Хәтерләтә кебек сусамбар [1].

●

Таңнар яңа җыр өйрәтте —
Тау чишмәсе көйләрен.
Ул җырларның ни кыйммәте?
Ах, җырларның юк кыйммәте,
Тыңламаса сөйгәнең...

Бер карашың ут дөрләтте —
Тоташ яна йөрәгем.
Ул януның ни хикмәте?
Януларның юк кыйммәте,
Аңламаса сөйгәнең,
Аңламаса сөйгәнең...

≈≈≈≈≈≈

[1] Сусамбар — тау гөле.

## Лена Шакирҗанова

# БЕЗ ХАТЫН-КЫЗЛАР ИЧ

●

Буйсынам мин буйсынырлык законнарга.
Әмма менә катып калган кануннарга,
Коеп куйган җыен юк-бар гадәтләргә
Ничек итеп
Баш ияргә,
Бил бөгәргә?!
Шул түгелме күңелләрне буып алган,
Чын хисләргә богау салган
Һәм, әгәр дә
Табынып ятсаң барчасына —
Йотып алган...
Шул түгелме җанга киртә,
Чылбыр — тәнгә,
Иреклене ирегеннән мәхрүм иткән,
Якты нурын томалаган кара пәрдә?..
Мин җыенмыйм ата-бабалардан калган
Изге йола, гадәтләрне гаепләргә.
Җаным сыймый әмма кысан кысаларга.
Җенем сөйми,
Буйсынасым юк аларга!..

## Кайтып киләм

Кайтып киләм.
Юл читләре яшел келәм.
Йөгерә-йөгерә бер кыз миңа каршы килә,
Менә-менә кочагыма атылып керә.
Туктамады, узып китте көлә-көлә.
Күбәләкләр куныл калган күлмәгенә...
Толымыннан эләктереп алсаң икән,
Ефәк тасмаларын урлап калсаң икән...

Кайтып киләм.
Болыннарның хәтфә чагы.
Кыймый гына каршы килә бер кыз тагы...
Иңнәренә чәчелеп киткән чәчкәйләре,
Кулларында күк кыңгырау чәчкәләре.
Йөгереп барып үзен кочып алыйм микән,
Танытмыйча әллә качып калыйм микән?..

Кайтып киләм.
Печәннәрнең җиткән чагы,
Җиләкләрнең янып-янып пешкән чагы,
Шук җилләрнең итәкләрдән үпкән чагы...
Ә хисләрнең гөлләрдән дә нечкә чагы.
Яшел юллар буйлап кына барсаң икән,
Я шул еллар уртасында калсаң икән...

Кайтып киләм.
Болыннарда эскерт-кибән.
Эңгер-меңгер,
Каршы килә тагын кемдер...
Арып-талып, уйга калып кайтып бару.
Басуларда җитеп килә иген-тару...

## Без хатын-кызлар ич...

Без хатын-кызлар ич...
Яшьлектә генә ул
Кычкырып көләсең,
Үкереп елыйсың —
Беркемнән яшереп тормыйсың.
Күңелең шар ачык —
Чаршау да, пәрдә дә кормыйсың...
Яшь чакта тормышың
Төп-төгәл, түгәрәк.
Ә үзең —
Гөлләрдән яралган
Бер гамьсез күбәләк...

Без хатын-кызлар ич...
Яшьлектә генә ул
Өлеш юк, бүлеш юк,
Шобага салыш юк,
Жирәбә тотыш юк,
Үлчәүләр тип-тигез —
Отылу, отыш юк...

Без хатын-кызлар ич...
Бүгенге нәрсә ул —
Без алга, иртәгә
Йөз тотып яшибез.
Бүгенгә дәшмибез.
Кайвакыт сагаеп,
Саргаеп китсәк тә,
Яисә өметләр
Киселсә кисәктән,
Юк әле бирешү,
Бөрешү эшмени!
Без кабат дөрлибез,
Янәдән яшьнибез.

Без хатын-кызлар ич,
Көтәбез,
Ышанып яшибез!..

## Яшереп тормыйм

Син мине кабат яшәрттең,
Син мине кышын яшьнәттең,
Син мине әллә нишләттең,
Мин башым җуйдым бугай.

Син миңа канат ялгадың,
Яңарып китте як-ягым,
Сәбәбен хәзер аңладым,
Мин гашыйк булдым бугай...

Яшереп тормыйм оялып,
Син — минем яшьлек хыялым, —
Соң гына шулай уянып,
Гел чынга аштың бугай.

Күңелнең күгәргән кылын
Тибрәтеп җибәрде моңың,
Бүленеп калган бер җырның
Син юлын ачтың бугай...

## Хуш, сихерле бакча

Хуш, сихерле бакча, — исергәндә
Хуш исеннән чәчәкләреңнең,
Белмәгәнмен икән — кырда үскән
Кырыс, әче исен әремнең...

Туфрагыңа синең калды иңеп,
Эч серләрем, яшьлек эзләрем.
Ядкарь итеп зәңгәр гөлләреңнең
Төсен алып китә күзләрем.

Хуш, сихерле бакча, бөтенләйгә,
Кабат сиңа кереп йөрмәмен.
Кайтмам инде, бер кат сахраларда,
Далаларда тойгач җир ямен.

Еллар узгач, яннарыңнан синең
Бер үтәрмен әле әйләнеп.
Син калырсың яшьнәп, яшьлегемнең
Яшел аты төсле бәйдәге...

## Төнге шигырь

Бүген төнлә шигырь язып чыктым,
Ә урамда буран уйнады.
Мин үземчә зур эш кырдым, дидем,
Кыш бабай да шулай уйлады.

Мин кәгазьгә яңа юллар тездем,
Тышта исә юллар күмелде.
Кар бураны шашып биеп йөрде,
Мин бушаттым ярсу күңелне...

Төн күзәтте мине тәрәзәдән,
Мин аңарга бармак янадым:
Таң атканчы китү ягын кара,
Соңга калма, димен, ярамый.

Кар ява да ява бөтерелеп,
Мин язам да язам: төн уза...
Ак урамнар буйлап, хәйран калып,
Иң беренче бүген кем узар?..

## Көзләргә кереп барыш

Ваемсыз чакларым узды,
Талымсыз чакларым да...
Уйланып калдым бер мәлгә
Көзге юл чатларында...

Бу юлдан күпләр үткәндер,
Алар бәхетле микән?
Язларым килә озатып,
Кайларга хәтле икән?..

Ак-караны аермаган
Гамьсез көннәр бар иде,
Миңа калса, төн кап-кара,
Ә иң агы кар иде...

Сүз кадерен белми торып,
Җыр кадерен кем белгән.
Туфрак түмен белгәнгәдер,
Таллар җиргә иелгән...

Гел алдыңда торса бар да,
Буйлар ерак үрелми.
Кеше кадерен аңламыйча,
Үз кадерең күрелми...

Еллар өс-баш алыштыра,
Дөнья көн дә яңара...
Каршымда, алга чакырып,
Утлы усаклар яна.

Серләрен төйнәп язларның
Көзләргә китеп барыш.
Орлык серләрен саклый күк,
Өлгереп җиткән арыш...

Җиләген җыеп җәйләрнең,
Көзләргә кереп барам.
Ачырак төсле шул әле
Кызарып пешкән балан...

Йөрәгемдә — җәйге җырым,
Яз нуры — күзләремдә.
Шуңадыр керәм ашкынып
Алкышлы көзләремә...

≈≈≈≈≈≈

## Саҗидә Сөләйманова

# ГӨЛБАДРАН

ПОВЕСТЬ

4



Тикшерү берничә атнага сузылды. Прокурор эшкә белгечләр советын җәлеп итте. Алар инде һәр кан тамырының нәрсәгә хезмәт иткәнен, кайсын нинди җеп белән, ничә минут, ничә секундта төенләргә тиешлеген беләләр һәм хирургның җинаяте ни дәрәҗәдә икәнлеген төгәл әйтеп бирәчәкләр.

«Эш» хирург файдасына борыла башлаган иде инде, мәрхүмәнең командировкадан кайткан ире торып-торып җинаятьчене таптыра башлады.

Операция барышын җентекләп, кабат-кабат күздән кичергәч, ул өлкәдә гаеп таба алмадылар. Белгечләр фикеренчә, хирургның гаебе алдарак булган: авыруны ул илтифатсыз караган, башта ук дөрес диагноз куя алмаган. Диагноз билгеле булгач та әле операция ясауны сузган. Диагноз куелгач, ашыгыч операция ясамау — бу инде күренеп торган җинаять. Операциягә гинекология буенча белгеч чакырмау факты да хирург файдасына түгел: Аллаяров үз мөмкинлекләрен артыграк бәяли, белгечләр белән киңәшми. Шартлатып статья бирергә була. Хөкем ителүчеләр эскәмиясендә утыру, рәшәткә эченә ябып куймаган сурәттә дә, хирургның абруена каты сугачак. Бу фикерне аяк терәп яклаучыларның берсе Алкина иде.

Аллаяров хирургия бүлегендәге күп санлы авыру тарихларын актарып, тикшерелгән очракка охшаш хәлләрне тапты, җиде сәгать кенә түгел, озаграк вакыт операция ясалмый торып та, исән калган авыруларны дәлил итеп китерде. Бу юлы исә фаҗигале финалның сәбәпләре берничә. Очракның типик булмавы. Авыруның артык симез, шуның нәтиҗәсендә йөрәгенең ялкау булуы. Диагноз буенча докторның шикләрен авыруның катгый кире кагуы да эшне катлауландырган. Гади кешегә бу төп сәбәпләрнең берсе булып күренсә дә, врачлар аны исәпкә алмый. Авыру ни сөйләмәс? Сүзгә түгел, фактка таянып эш итәргә кирәк иде...

Тикшерүнең ахыры күренми сыман, бер-ике көн чакырмый торсалар да, тагын кайчан башларлар дип, Аллаяров һаман көтеп йөрде.

Ахыры. Башы 2 санда.

Үлгән хатын өчен аның болай да җаны талкына, тулысынча аклану көтми. Кулы эшкә бармый шулай тинтерәп йөргәндә, Аллаяровны хирурглар советына чакырттылар, «Эш»нең прокуратурадан алар кулына күчүе турында әйттеләр. Гинеколог чакырмаган өчен Аллаяровка каты кисәтү ясадылар.

Алкина кужытып торган килеш хәлнең болай кинәт үзгәреп китүенә Аллаяров гаҗәпләнебрәк йөрде. Өстән берәрсе Аллаяров файдасына сүз әйткәнме әллә? Алай дисәң, ул үзе беркемгә дә мөрәҗәгать итмәде. Яңа күңелсезлекләр чыкмауның сәбәбен хирург соңыннан гына белде. Фәрханә мәрхүмәнең ире янына барган, аның операция өстәленә ни сәбәпле барып эләккәнен сөйләгән. Әгәр хирургка суд була калса, медицина заключениесе укылачагын, хатынның ире юкта кылган гөнаһысы бөтен шәһәр алдында фаш ителәчәген аңлаткан. Алданган ир шәфкать туташының сүзләренә болай ышангандырмы, прокуратурага барып тикшергәндерме, һәрхәлдә, эшне судка чыгармауларын сорап, гариза илтеп биргән. Фәрханә, әлбәттә, медицина серләрен ир кешегә ачмаска тиеш иде, әмма моның өчен аны җавапка тартучы булмады.

## Бибиса

### I

Бибиса ел буе, көн саен ике рольнең берсе белән сәхнәгә чыкты. Беренчесе — актрисага дан, Бибисага күңел канәгатьләнүе биргән разведчица. Икенчесе — йөз еллар буе тамашачының күңелен суытмаган классик әсәр героинясы. Бибисаның иң бәхетле елы. Иң яратып уйнаган рольләре. Үсмер чагыннан татарның Галиябануы, Мәйсәрәсе белән хыялланды. Күңел кичерешләрен татар кызлары моң аша аңлаталар. Кысанлыкка, чикләнгәнлеккә каршы җыр белән көрәшәләр. Бибисага алар шуның белән якын. Ләкин театрда төп милли героиня Сәйарә. Карлыган күзле, карлыгач кашлы дигәндәй. Бибисага көнбатыш классикасын һәм заман геройларын теләбрәк бирәләр. Быелгы бәхетле рольләре дә шулардан.

Училищега керә алмыйча, беренче тапкыр театрга килгәч, Бибисаны Сакмарова бик куркыткан иде. «Үзеңне онытырга, гаилә бәхетеннән баш тартырга. Эт итеп сүксәләр дә, баш иеп тор. «Мин», «үзем» дигән сүзләр юк. Режиссер дигән кеше синең аллаң, ул ни боерса, шуны эшлә. Ул ничек әйтсә, шулай дөрес. Булдыра алырсыңмы?» — Кызның ризалык биреп, баш кагуын күргәч, Сакмарова бераз тынып тора. Текәлеп карый. Аннары тагын да куркынычрак сүзләр сөйли башлый: «Сәхнә данына ирешим дисәң, кайбер шәхесләр алдында юхаланырга туры килер. Бусы ничек?» Бибиса, үз колакларына ышанмаган төсле, режиссерга рәнҗүле караш ташлап ала, аның өттергеч күз карашын күтәрә алмый, башын түбән ия. Режиссер карарга куркыныч чибәр ханым. Аның матурлыгын Бибиса тел белән сөйләп аңлата алмас иде. Шомырт кара күзләре кешенең аңын томалый торган нурлар бөрки. Баш түбәсенә өелгән дулкын-дулкын кара чәче арасында әллә нинди сихерләр бар сыман.

— Тырышырмын, — ди кызый, пышылдап. Сакмарова, сигарет көлен озын, нечкә бармагы белән кага-кага, кычкырып көлә.

— Бер мәгънә чыгар синнән, кызый.

Бу сөйләшү җырлап, биеп, шигырь сөйләп күрсәткәч булды. Тәрҗемәи хәлен дә Бибиса тәгәл сөйләп бирде.

— Сөйгән ярың белән үпкәләштегезмени? Ул ташладымы, синме?

Режиссерның сүзен раслап, Бибиса дәшми генә баш какты, сорауның икенче өлешен гүя ишетмәде. Сакмарова сигаретын көл савытына басып сүндерде.

— Ташлаштыгыз, димәк. Күрәм, син аны үзең ташлагансың... (Кыз бу юлы күтәрелеп карамады, җавап та бирмәде.) Шулай итеп, Бибиса үзенең хыял дөньясына килеп керде. Ул чакта әле Сакмарова режиссер түгел, гади артист, дөрес, атказанган артист булган. Бер режиссер киткән, икенчесе килеп өлгермәгән чакта, әлеге вазифаны вакытлыча үтәгән вакыты булган икән. Ә режиссерларның ниндиләрен генә күрмәде Бибиса. «Авыл мужигы! Агач тел!» дип кычкырганнары да яшь талантларны тәрбияләде. «Үскәнем, сине егет кочканы бармы? Әйт, бармы? Мин синең яраткан егетең ди, сине кочаклап үбәргә телим ди. Син нишлисең шул чакта? Я, күрсәт әле, нишлисең?» — дип, җанны кыерсытучылары да булды. Шәһәрнең бер очыннан икенче очына сажень адымнары белән җәяү йөреп, спектакльдәге һәр рольне үзе уйнарга сәләтлесе дә очрады. Соңгысыннан Бибиса сәхнә осталыгына ныклап өйрәнде. Аңарчы ул сол беләнрәк уйный иде. Ул режиссерлар Казаннан килделәр дә, Яшьләрне иҗат лабораториясе урынына файдаланып, кабат киттеләр. Бибиса сүз тыңлаучан булды, шулай да һәрберсенә яраклашырга тырышмады. Нигездә үз сиземенә таянып, роль артыннан роль эшли торды. Аны артык пафосланууда, артык хисләнүдә гаепләделәр, табигыйлек җитми диделәр. Сәхнәгә менгәч, Бибисаның бөтен дөньяны үзенчә әйләндереп куясы килә. Тыныч кына, гади генә яшәргә ярамый дигән уй аның күңеленә нык кереп урнашкан. Шул уй аны сәхнәгә алып килде дә. Медеяләр, Жанна д'Арклар биләде Бибисаның күңелен. Тиенкы хисләрне ул көчлеләр сыйфаты итеп таный алмый азапланды. Җәйге гастрольләрдә артистканың яңа рольләре турында Казан тамашачысы, республика газеталары җылы гына сүзләр әйттеләр. «Темпераментлы. Тавыш диапазоны киң» дигән югары бәяләрне дә кызганмадылар.

Быелгы ялын Бибиса Әскәр мәшәкатьләре белән уздырды.

Күчмә театр артистының теңкәсенә тигән нәрсә — кышкы бураннар, көзге пычраклар, ягылмаган клублардан бигрәк — бала тәрбияләү. Мәктәпкә кергәнче ул нарасыйлар әти-әниләре белән авылдан-авылга, өйдән-өйгә йөреп, бер йончыйлар. Әнисе сәхнәдә Шәмсекамәрне уйнаса, ят ир аны кыйнаганда, сабыйкай залда сулыгып-сулыгып елап утыра. Әнисе партизанка булып, әтисен пистолеттан атса, гәрчә ул фашист офицеры формасыннан булса да, спектакльдән соң бала әнисенә борылып та карамый, ә әтисен кызгана, кочаклый, үбә. Я булмаса: «Нигә син Әхияр абый белән чишендең?» — дип, әнисенә бәйләнә. Үстереп кара шуннан инде бала. Мәктәпкә кергәч, иң бәхетләләре — әби-бабай тәрбиясендә. Бүтәннәре — якын-ерак туганнары кулында. Шулай иза чигә торгач, Бибисаның Әскәре дә уналты яшен тутырды. Утызга якынлашып та, актрисаның кияүгә чыкмавы дөньяның кайбер четерекле якларына бәйле. Әтисенең бердәнбер сеңлесе икенче бәбиен таба алмый үлгәч, ятим калган Әскәрне Бибиса авылга, әнисе янына кайтарып куйган иде. Башта вакытлыча, җизнәсе башкүз алганчы дип. Бераздан кечкенә малай Бибисада торып калды, чөнки Гөлчирә түти дә бу дөньяга мәңгелеккә килмәгән икән... Театрда бу хакта белгәне белә, белмәгәне юк, Бибисаның Әскәре — вәссәлам. Әнә, бер артистканың кызы әтисе булып та, әнисенә исеме белән эндәшә, чөнки ана «әни» дигән кеше юк. Күңелендәге назын кеше кемгәдер бирергә тиеш, табигать аны шулай яраткан. Мәхәббәте бәгланышсыз калган кеше сөйкемсез, ахыр чиктә киреәксез булып чыга. Авылда кияүгә барып кайткан дигән исеме чыккач, Бибисада бала тудыру теләге туды. Әскәрне ул үзенеке итеп тәрбияләде.

Урта мәктәп тәмамлаган Әскәрнең ул соңгы көнгә чаклы нинди

һөнәр сайларын белмәде. Егет исә Казандагы хәрби мәктәпкә документларын җибәрде. Башта медицина комиссиясен үтте, аннары имтиханнар биреп кайтты. Бибиса хәрби эшкә күңеле белән риза түгел иде, әмма бер каршы сүз дә әйтмәде. Үзе дә бит әнисен тыңламый артистлыкка киткән иде. Кеше үз юлын үзе сайларга тиеш. Малайның спорт белән шөгыльләнүе дә, пионер лагеренда эшләп уңай характеристика алуы да файдага булды. Әзерлекнең бу якларын хәстәрләүдә малай төшеп калганнардан түгел икән. Ә менә Бибиса сынатты, Әскәр имтиханнар тапшырган чакта бөтенләй бөгелеп төште. Керә алмаса? Беренче омтылышлары челпәрәмә килеп сибеләчәк. Ярый, эшкә дә урнашыр. Хезмәт хакы да килеп торыр. Һәр получканы юа башласалар? Мәктәптә чакта укытучылар, тәрбиячеләр бар иде, баланың һәр адымын күзәтеп торалар иде. Ә хәзер? Унҗиде яше тулмаган үсмер нинди юлга кермәс? Шундый уйлар белән үзен кая куярга белмәде Бибиса. Егет имтиханнарны уңышлы тапшырып кайткач та тынычлана алмады. Чакыру кәгазе килеп, курсантны Казанга илтешеп кайткач, кинәт хәле беткәндәй булды. Киеренке булды Бибиса өчен бу ел. Ирешелгән уңышларны күтәрүе дә җиңел түгел икән.

Яна сезонда баш режиссер Бибисага сугышта улларын, ирен югалткан көчле ихтыярлы ана ролен бирде. Режиссер карт булса, бу роль өчен Бибиса аңа артык яшь күренер иде. Артистка башта куркып калгандай булды. Хыялында йөрткән Медеясе түгелме соң бу? Хыялга ирешер көн дә була микәнни? Артистканың элекке рольләрендә үк режиссер иҗтимагый аһәң ишеткән иде.

Җир шары һәм Ана. Балаларына килгән хәсрәт һәр икесенең күкрәгенә китереп суга. Җир һәм Ана. Алар кешегә гомер бирәләр һәм ул гомернең тереклеккә хезмәт итүен телиләр, кешелекне шуңа чакыралар. Сыгылып торган нәфис гәүдәсе белән Бибиса Сабанаева бу юлы йөкне күтәрә алырмы?

Гастрольдә йөргәндә рольдән чыкмас өчен Бибиса квартирага да ялгыз төшә торган булды. Бүтәннәр белән бергә төшсә, чит нәрсәләр турында сөйләшергә туры килә. Авыл өенә урнашып, чәй эчкәч, бераз ял итәм, янсә башым авыртып тора дип, сөйләшүдән читләште, һич булмаса, диванга баш төртте. Шулай йөри торгач, әллә, чыннан да, рольгә кереп китте, кич җиттеме, тәне кызыша.

— Градуснигыгыз юкмы, апа?

— Үзем дә карап торам аны, бит алмаларың ут кебек яна.

Бераз югалып торганнан соң хуҗабикә градусник табып кайтты.

— Йөрмәскә иде, үзегездә булмагач...

— Һи, нәрсәсе бар аның?

Терекөмеш утыз сигездән узып китте. Салкын тидергән, күрәсең. Спектакльне өзеп булмый, алыштырыр кеше юк. Сәхнәдә Бибиса төшендә йөргәндәй йөрде. Соңгы пәрдә ябылгач, Сәйарәнең сүзләре дә төштәге сыман ишетелде:

— Уйнавы шул чаклы авыр булды бүген. Борһан абый сәхнә артында кама бүреген таба алмый. Зөфәрнең сыңар итеген кемдер алыштырып кигән дә, чолгавын өстерәп, итек таптырып йөри... Бибисаның шуларга ачуы килде бугай, сәхнәгә чыга да, тамак төбе белән кычкыра...

Утырган урынында гына калыр иде Бибиса, кузгалып кайтырлык хәле юк. Кешеләрне болай газапларга ярамас. Сакмарованы чакырып алсаң... Бу рольне ул уйный ала. Иртәгә үк дирекциягә телеграмма бирергә, яки шалтыратырга...

Сакмарова Мәскәүгә, иҗат командировкасына киткән, кайту белән җибәрербез, спектакльләрне өзмәгез, финанс планын үтәгез, дип хәбәр иткәннәр театрдан. Авыл саен иртәле-кичле стрептомицин, пенициллин уколлары ала-ала, тагын ун көнләп йөрделәр. Сакмарова, мө-

гаен, юри килмәгән. Теге вакытта Бибиса сәхнәгә үз белдеге белән ялан аяк чыккач, Хөснә аны танымый ук башлады. Сәламен ала, әмма ят кешедән алган кебек. Ни тели ул Бибисадан? Хөснә Сакмарованың Бибиса Сабанаевада кабатлануынмы? Режиссер өчен ачыш булмый бит бу, үткәнне кабатлау була. Үзе өчен күп нәрсә эшләгән режиссерның салкын карашын Бибиса авыр кичерә. Ләкин араны ничек якынайтырга белми. Гафу үтенергәме? Нәрсә өчен? Хәзер инде теләсә дә, Хөснә туфлиен киеп бии алмый ул.

Бибиса уттан суга, судан кыяга бәрелеп, чыныгасы урында йомшара башлады бугай. Артистка өчен иң куркыныч нәрсә — тавышы өзелеп-өзелеп куя. Бу юлы спектакльләрне өзми йөреп кайта алса, докторга күренергә кирәк. Әлегә чи йомырка эчеп, тамагын сода белән чайкатып йөри бирә. Үз урынына дублер әзерләргә кирәк. Миннән яхшы башкаручы юк дип йөрү ярамас, Бибиса, үзеңнең беренче елларыңны хәтерлә. Яшьләрне күтәрү мәсьәләсендә Сакмаровадан өйрәнергә кирәк. Авылда уйнаганда бит ул костюмерша булып эшләүче Сәйарәне үз урынына, яшь кыз роленә кертеп җибәргән. Әлеге дә баягы, авыл халкы өстендә сынау уздыралар. Бәлки бу яхшыдыр да: беренче самими хисләр, беренче дулкынлану... Яз көне яшь үлән баш төртүен, яңа ай тууын күргән сыман, яшь артистның җан тетрәнүен авыл тамашачысы беренче булып күрә.

2

Бибисаны тын юллары ялкынсынудан дәваладылар, өч көн саен канын алып тикшерделәр, гәүдәсен рентген нурлары белән яктыртып карадылар. Өч атна чамасы шифаханә юлын таптагач, кулына язу тоттырдылар. Бүген ук стационарга кереп ятарга куштылар. Бибиса язуның диагноз турысын карады: «Острый лейкоз». Юл уңаеннан, китапханәгә кереп, медицина сүзлеге алды, үзенә куелган диагнозны табып укырга тотынды. «Авыруның башлангыч чоры аз гына күтәренке температура бирә, баш әйләнү, хәлсезлек, сөякләр сызлау — атналар, хәтта айлар буе дәвам итәргә мөмкин. Кеше, гадәттә, шул хәлдә үз хезмәтен башкарып йөри. Күпмедер вакыт узгач, югарыда әйтелгән билгеләр кинәт кискенләшә, температура күтәрелә, борын, теш уртлары каный. Тамак ялкынсына, үпкә шешә». Барысы да миңа туры килә дип уйлый Бибиса. Артабан ничек дәвалау турында язылган. Белешмәнең ахыргы җөмләсенә җиткәч, Бибисаның өстенә бозлы су койгандай булды: «Прогноз өметсез, авыруның хәлен вакытлыча гына яхшыртырга мөмкин».

Бибиса ул көнне больницага кереп ятмады. Аннан тиз генә чыга алмаячак. Бая телгә алынган чир белән кеше ике елдан биш елга чаклы яши диелгән... Исәпләсәң, Бибиса күтәренке температура белән ике ел яши инде. Гел ангинага юрап йөрде. Еш кына больницага бармый үзе генә дәваланды. Димәк, ике елы үтеп киткән... Тагын күпме яшисе калган? Бер елмы? Бер аймы? Бибиса урындыкта хәрәкәтсез утыра. Башына бер уй да килми. Кинәт аның мие кызу-кызу эшли башлады. Ашыгырга кирәк. Театрга барырга. Урынына кеше әзерләсеннәр. Бусын Бибисаның үзенә кушачаклар, чөнки баш режиссер командировкада, ә Сакмарова авырый. Хатлар, көндәлекләр, китапханәдән алган китаплар... Һәммәсен тәртипкә китерергә, ягасын утка ягарга. Юылмаган кер җыелган, аларны сабынлап суга салырга, иләнне сөртеп алырга, бар да чиста калсын... Хәзер инде дүрт-биш көн берни дә хәл итми. «Ике елдан биш елга чаклы яши...»

Бибиса бөтен көчен бер йодрыкка туплады. Күңеленнән барлаган эшләрен ул сабырлык белән башкарырга тотынды. «Кабалансаң, гаса-

билансаң, берсен дә үти алмый калуың бар», дип уйлады ул. Врач биргән сөйкемсез сары кәгазьне яңадан алып карады. Диагноз сүзләреннән соң зур сорау билгесе күрде. Башта ничек искә алмаган? Диагноз бит әле сорау астында! Бөтенләй бүтән чир булуы мөмкин. Аннары, дәваламаган очракта гына авыру кешенең гомере 2—5 ел белән чикләнәдер, дәвалансаң, нәтиҗә, мөгаен, башкача буладыр. Шул фикерләрдән куәт алып, Бибиса атна буе үзен чыбыркылады, өлгерергә тырышты. Әле анда, әле монда өзелеп яткан җеп очларын ялгагач, теге шомлы кәгазьне тотып, шифаханәгә китте.

Күккә баккан дини кешедәй, Бибиса аның соры күзләренә сөзелеп карый. Күк уртасында нәни кояш сыман күз каралары яна, анда шомлы күләгәләр уйный.

— Элегрәк күренгәнегез булмадымыни?

Сорау бирүче җавап көтми, бары үкенечле бер хәлне хәбәр итә. Нәни кояштагы шәүләләр гаҗиз калгандай чайкалып торалар. Авыруның анатомиясе белән шөгыльләнгән хәлдә, хирург үзенең карарын әйтә:

— Операция кирәк. Һич кичектермичә.

Бер мизгелгә шәүләләр ут артына посалар, әмма шунда ук ак җәймәле сәкедә ятучы өстенә сикереп төшәргә теләгәндәй, дәррәү калкыналар:

— Элегрәк кирәк иде...

Элегрәк... Ләкин бит элегрәк Бибисага беркем дә мондый тәкъдим ясамады. Күпме гомер күтәренке температура белән йөрде, шул килеш эшләде, врачларга күренде. Организмыгыз йомшак, чыныктырырга кирәк, диделәр. Тимераякка басып, боз күлләрен әйләнде Бибиса. Тәне ут янып, урын өстенә ауды, үз йомшаклыгына үч итеп, чаңгыда җилләр кочагына ыргылды. Бугазыннан буып, ютәл җиргә бөкте. Күл буеның бәрхет җилләреннән йөзләрен сыйпатты, зәңгәр дулкыннарында тирбәлде. Файдасы тимәде. Шулай йөри торгач, әкренләп сулды, йөзенә яңа янып беткән учакның кайнар көлен хәтерләткән төс иңде. Житди чир һаман табылмады. Ниһаять, үткен карашлы хирург бер сыйпап карауга бар да ачыкланды. Зәгыйфьләнә барган яшәү теләген гүя өргетеп җибәрделәр. Бибисаның хәле ничек кенә аяныч булмасын, хәзер нишләргә кирәклеге билгеле.

Күкрәгенә чаклы өскә кайтарылган ак күлмәк итәген ул түбән сыдырып, тезләрен каплаштырды, «смотровой» дип аталган бүлмәдәге биек сәкедән җиңел генә шуып төште. Аягы белән капшап, чүәкләрен эләдерде, күтәрелеп карамый гына, ишектәге кадактан чәчәкле халатын алып киде. Ак халатлылар аңар тамчы да игътибар итмәделәр, әле генә игълан ителгән карар турында да авыруның фикерен сорамадылар. Чөнки аның житди мәсьәләләр тикшерерлек көче дә, ихтыяры да юклыгы врачларга мәгълүм булса кирәк. Бибиса хәзер тулысынча алар кулында, нишләтсәләр дә риза. Әйтерсең ул җилдә җилфердәп торган шәүлә, шым гына, ишек ярыгыннан гына диярлек чыкты да, терапия бүлегендәге үз палатасына кереп, ятагына сеңде. Ике атнадан артык инде, ул монда төрле яклап тикшерелү-күзәтү астында.

Бибиса алдында тагын бер житди сынау. Бәлки соңгысыдыр. Шыбыр тиргә батып уянган шомлы төннәрдә ул үткәннәре хакында күп уйланды. Шатлыклар белән борчулар бәрелеште, уңышлар белән аянычлар чәкәләште. Соңгы айда ул килачәгенә үрелеп карарга базмый башлады, әйтерсең аяк очлары белән төпсез упкын ярына килеп терәлде. Бүген исә Бибисаның сөремле төтен эчендә калган тормышында бер ачыклык пәйда булды. Ул ачыклык — болытлар арасыннан күренгән күк сыман якты күзләр. Хирург күзләре. Бибисаның аны моңарчы

якыннан очратканы юк иде. Халык телендә Аллаяровның исеме еш кабатлана. Ныклап кызыксынганы булмады, эше төшмәде. Аллаяровка бер күз салуга Бибиса аның гадәти кеше булмавын сизде. Күзләрендәге илһам чаткысы аны бүтән табиблардан аерып тора. Кулы белән ул йомшак кына сыйпый, ә күзләре белән гүя дошман яшеренгән кара урманга разведкага кереп бара, һәр куак, һәр түмгәк аны сагайта. Һәр мизгелдә ул куркыныч өстенә ташланырга әзер һәм җиңүче булып чыгачагына шик тотмый. Хирург күзләрендәге әнә шул чаткы Бибисаның сүнеп барган өметен уятты. Гүя хирургның ихтыяр көче аны да үз артыннан ияртте.

Гомере буена кеше идеалга омтыла, үзе табынырдай көчле затка тартыла. Очрата алмаса, андый затны үзе уйлап чыгара. Мондый омтылыш бигрәк тә хатын-кызга хас. Күңелендә йөрткән илаһи сыйфатларны ул сайлаган кешесенә бирә. Хирургның очкынлы күзләрендәге утлы шәүләләргә карап, көчле затка тап булганын сиземләде Бибиса. Яшәү белән үлемне хәл итүче буларак, хирург үзенең күңелен хәзер Бибиса гомере белән бәйләде. Утлы шәүләләр арасындагы якты ачыклык актрисаның күз алдыннан китмәде. Бибиса яшәсә генә хирург сәнгатьтә яшәячәк. Мондый фикер Бибисада минуты белән тулаем өлгерде дию ялгыш булыр иде. Тәүдә тынгысыз бер теләк һавада йөзеп йөрде: яшәргә! Исән калырга!

Терапиядә яткан килеш, Бибисага операция көне билгеләнде, әзерлек башланды. Яңа анализлар, рентген нурлары белән яктырту... Бер көнне бүлек мөдире Динис Сәлимович авыруны үз бүлмәсенә чакырып алды. Бибисага өстәл каршысындагы урындыкны тәкъдим итте.

— Ничек хәл кылдыгыз, операциягә монда каласыңмы, әллә Казанга барасыңмы?

Докторның кырыслыгыннан Бибиса югалып калды. Нишләп әле ул Казан турында сөйли? Бибиса бит ул турыда сүз чыгарганы юк.

Бибиса, үзенең йомшаклыгын җиңәргә тырышып, докторның соравына кыска җавап бирде.

— Сөйләшкән идек бит инде, Динис Сәлимович.

— Монда калырга булдыңмы?

— Минем башкача уйлаганым да юк.

— Ә менә сезнең хезмәт урынында бүтәнчәрәк уйлыйлар, — диде Динис, кырыслана барып. — Шәһәр советы председателе баш врачка шалтыраткан, авыру тарихыгызны баш врач сорап алды.

Доктор, Бибисага шелтәле караш ташлап, бераз тынып торды да дәвам итте:

— Безнең эшкә администрация кысыла башласа, бик кыенга туры килә. Алар бит эшнең асылын белмиләр. Авыруның язмышын ахыр чиктә без хәл итәбез. — Динис Сәлимович өстәл янында түрдә, күз явын алырлык ак башлык, ак халаттан, Бибиса ишек катындагы артлы урындыкта, кат-кат юылудан төсе китә башлаган ситсы халаттан, мескен кыяфәттә утыра. Бәхәсләшер-әрләшер өчен көчләр тигез түгел. Доктор электән таныш, театрал, сау-сәламәт чагында Бибиса аңа Динис дип кенә дәшә. Актриса сәламәт чаклары дәрәҗәсендә калырга тырышып, тамагына килгән яшь төерен йотты да үз сүзен әйтте.

— Казанга барырга бер теләгем дә юк. Хәснә апа да («кысылып йөрүче»нең Сакмарова икәнлегенә Бибиса шикләнми) махсус бу мәсьәлә буенча шәһәр советына кермәгәндер, очраклы сөйләшү булгандыр. Аннары ул нишләп әле миннән башка хәл итәргә тиеш?

— Кәгазьләрегез баш врачта, ул ни кушса, шулай булачак.

Бибисаның тамагына тагын каһәр төшкән төер тыгылды. Бу юлы ул аны авырлык белән йотты, тавышы да калтырап чыкты.

— Операцияне мин монда ясатам. — Аның хәтеренә хирургның раз-

ведчикныкы кебек тәвәккәл күз карашы килде. Тынычлана төште, Диниснең дә йомшара башлавын тоеп, өстәде:

— Борчылмагыз, Динис Сәлимович, бар да яхшы булыр.

Соңгы сүзләрне докторның мин-минлегенә суктырып әйтте Бибиса. Динис Сәлимовичның ирен читенә елмаю эсәре кунды.

— Режиссерыгыз килсә, мине күрсен әле.

Бибиса борылып карамый гына чыгып китте. Бу сөйләшүдән соң ул үзенең бөтенләй төшеп калган бәндә түгеллеген сизде. Аңа үпкә сүзләре әйтәләр, аны орышалар, димәк, каршы торырлык көч күрәләр. Димәк, көрәшергә мөмкин әле.

Ай башына билгеләнгән операция 8 нче Марттан соңга кичектерелде. Авыруга өенә кайтып, юынып килергә рөхсәт иттеләр. Атакага кергәндәге сыман бар да чиста булырга тиеш.

Әледән-әле телефон шалтырап бимазалады. Хезмәттәшләре, дуслары Бибисаның хәлен сорашалар, бәйрәм белән котлыйлар, кыстап-кыстап кунакка дәшәләр, телефоннан булса да әңгәмә коралар. Булачак операция турында алар ишетеп өлгергәннәр, юатырга, киңәшләр бирергә телиләр, күрәсең. Бибисаның исә кемнәр беләндер әңгәмә корырга хәле дә, теләге дә юк. Аның гәүдәсе генә монда, күңеле тормыш белән үлем арасында, әле бер якка, әле икенче якка бәрелеп очып йөри. Телефон артында бәйрәмле, мәҗлесле тормыш барлыгын белү үз хәленең аянычлыгын тагын да ныграк сиздерә. Хирург күзендәге кара шәүләләр аңын томалагандай итә. Элегрәк кирәк иде... хәзер соң инде, соң... Тизрәк үз ятагыма китәргә кирәк, дип уйлый Бибиса. Анда барысы да тулы канлы тормыштан өзелеп киткән халык. Ул дөнья белән уртак тел табу хәзер җиңелрәк.

Китәр алдыннан Бибисаның күңеленә: «Бу өйгә кире әйләнеп кайтмавым да бар», дигән уй килде. «Декабрина» дип аталган көньяк гөле беренче тапкыр чәчкәгә йомарланган. Ул декабрь аенда чәчәк атарга тиеш булган да, вакытын саташтырып, март аенда ачылырга әзерләнә. Ничә ел көтеп алган чәчкә бөресе дә Бибисаны хисләндермәде, бу сөенечләрнең берсе дә минем өчен түгел, дип уйлады ул. Үзенең гамьсезләнә баруына да ул читтән карап торган кебек. Шулай да: «Әйләнеп кайтмавым бар», дигән уй күңелен кузгатып куйды. Юк, юк, ничек кенә булса да кайтырга кирәк. Кире кайтырга сәбәп калсын өчен беркем белән дә хушлашмады, васыятьләр язмады. Әскәргә дә хәбәр итмәде. Хисләнергә, җебергә ярамый. Көчне операция өчен сакларга кирәк. Өзелгән эшләрне кире әйләнеп кайткач дәвам итәргә язсын дигән уй белән Бибиса өеннән чыгып китте.

Иртәгә операция буласы көнне авылдан энесе Әсаф килде. Бибиса аңа йомыш кушып җибәрде. Җәрәхәт төзәлә төшеп, аякка баскач, теккән җөйләр сүтелеп китмәсен өчен, эчне кысып бәйләргә яулык рәвешендәрәк ситсы кисәге кирәк булачак иде, шул турыда Әсафка әйтте. Аңлаешлырак сөйләргә тырышты, чөнки чүпрәк турында сүз чыкса, ирләр берни аңламаска әвереләләр. Өендә искедән дә, яңадан да ситсылар күп күбен, ләкин алар арасында Әсаф адашып калачак. Кибеттән бер метр ситсы аның өчен җиңелрәк булыр. Ашыкмый гына карап, үз җае белән ала торсын, бер атнадан аякка басачакмын, дип уй йөртте Бибиса. Боларның түбәнге ишек катында сөйләшеп торуларын күргән хирург Әсафның кабинетына кереп чыгуын үтенде. Бибиса үз палатасына күтәрелде, Әсафка батист ише югарак ситсы ал дип әйтеп калды. Өч-дүрт сәгать үтүгә, Әсаф яңадан шифаханәгә килеп җиткән, апасын чакыртып чыгарды. Сораган әйберенне китердем дип, Бибисага зур гына төргәк сузды. Апасы төргәкне алып, сүтеп караса, баштанаяк уранып ятарлык ак ситсы. Бер чите сүтелгән, җеп кисәкләре тырпаеп тора, икенче чите чачакланып ертылган. Апасының гаҗәпләнүен күргәч, Әсаф акланганай итте:

— Кибеттә юка ситсы юк, пододеяльник алып сүттем...

И ходаем, бу ир-атка ни әйтсәң инде дигән мәгънә белән, Бибиса энесенә карап озак кына баш чайкап торды. Кайнатып юудан юкарып беткән җәймәләр өйдә дә аз түгел, югыйсә. Бүген үк алмаса, бөтән көн беткәнмени? Уйлаганын Бибиса әйтеп тормады, кафенлеккә җитәрлек төргәкне кире биреп җибәрде. Әсаф җилкәсен бөгеп кайтып китте. Бибисага ул кызганыч булып калды.

Операция буласы көнне Әсаф иртүк килде. Бибисаның беркемне дә күрәсе килми иде, энесе килүгә шатланмады. Аның хәзер һәр кылы киерелгән, ул кылларны бушатып, яңадан киерү өчен өстәмә көчләр таләп ителәчәк. Дөресрәге, ул үзе бер нечкә кыл сыман өзелер дә яңадан ялгана алмас сыман.

— Йөрмә инде, кайтып китап укы... — Бибиса бу сүзләрне ниндидер ризасызлык белән әйтте. Әсафның йөзенә рәнҗү билгеләре чыккандай булды. Моны күргән Бибиса үзен йомшартырга, елмаерга мәҗбүр итте:

— Беткәч килерсең...

Тәгәрмәчле биек ятакка салып, Сабанаеваны операция бүлмәсенә алып киттеләр. Шундый ук биек (операция ясаучының биленнән булыр) икенче ятакка очыртып кына күчереп куйдылар. Озын буйлы, куе кашлы анестезиолог килде. Ул инде Бибисага бераз таныш, кичә кереп авыруның пенициллин, стрептомицин ише антибиотикларны кабул итә алу-алмавы хакында сорашып чыккан иде.

— Курку хисе юкмы? — дип сорады авыру янына килү белән. Сорау Бибисага урынсыз кебек тоелды. «Юк» дип җавап бирде катгый гына, нәкъ докторны кызыксындырган хисне куарга тырышып.

— Бераз кислород иснәгез әле, — диде Варис Русланович (анестезиологның исеме шулай икән), микрофонга охшаган кара нәрсәне авыруның авызына китереп.

Андый-мондый ят ис юк, Бибиса сулый бирә. Онытылыбрак киткәндәй булды. Варис авыруның сул беләгендә нидер кисте, кан юлына озаклап резин көпшә кертеп маташты. Даруларны һәм кирәк очракта өстәмә канны шуннан гына җибәрәбез дип, Бибисаны никтер кисәтеп куйган иде. Веносекция дип аталган бу җайланманы урнаштыру гадәттәгедән озаккарак сузылды, ахрысы, шәфкать туташы ризасыз уфтану авазлары чыгаргалап куйды. Бибисаның да күңеле сабырсызлана башлады. Ниһаять, монысыннан котылдылар. Авыруның бугазына кара пластмасса көпшә керттеләр, авызның буш калган урыннарына марля кисәкләре тутырдылар. Боларны Бибиса төшендәге кебегрәк сизеп ятты. Вак-төяк әзерлекләр Бибисаның сабырлыгын шактый какшатты. Ул, түземсезләнеп, хирургны көтә башлады. Янында ул торса, куркыныч кимер төсле. Ниһаять, шәфкать туташы кемгәдер боерды:

— Баязит Алмасовичка әйтегез, наркоз бирә башлыйбыз!

Бибиса бер заман җанны кимерә торган сабырсызлык белән айнып китте. Беренче ишеткән сүзе:

— Яман шеш.

Бу сүзне Аллаяров әйтте. Һич кызганусыз, үкенүсез, салкын тавыш белән әйтте. Бибиса шушы коточкыч сүздән уянды бугай, чөнки «мин кайда, нишлим?» дигән сораулар башына килмәде. Операция барышында уянуын аңлады. Хирург, кемдә дә булса шик калмагае дигәндәй, тагын теге коточкыч сүзне кабатлады.

— Әйе, рак.

Хирургка карата рәнҗү хисе Бибисаның бөтен барлыгын ачыттырып үтте. Тавышының битарафлыгына, шул сүзне игълан итүенә рән-

жеде. Хирургка, аның янәшәсендә торган бөтен ярдәмчеләренә ачу итеп, күңеленнән ни өчендер русчалап кычкырды: «Юк, юк, мин яшим!.. Күрерсез менә, яшәячәкмен!»

Әйтерсең ул кылыч болгап, җан ачуы белән дошман өстенә ташланды, утлы шәүләләр эченә кереп, һушын югалтты.

Хирург тавышыннан Бибиса тагын бер уянды, нәрсәнедер кисә башлавы турында хәбәр итте теге. Хатын-кыз тавышы:

— Бәлки калдырырсыз... — Үтә ягымлы, бик шәфкатьле булып ишетелде ул тавыш Бибисага, тәненә җылы йөгергәндәй булды.

— Юк! — диде пычаклы кеше, — кире әйләнеп кайтырлык булмасын. — Хирург нәрсәнедер кисте, берьюлы Бибисаның аңын да суырып алды...

Бибиса өченче тапкыр уянганда да операция тәмамланмаган иде әле. Әйләнәсендә кемнәрдер кайнашалар, сөйләшәләр. Уянганын белдерергә теләп, Бибиса күзен ачарга, кулын күтәрергә тырыша, ләкин керфеген дә күтәрә алмый, бармагы да селкенми. Исән икәнлеген күрсәтергә тырыша торгач, ниһаять, башын чайкап алды. Тагын баягы хатын-кыз тавышы:

— Уянды! Башын чайкый...

Куркып та, кызганып та әйткән бу сүзгә каршы берәү гади генә җавап бирде:

— Ятып арыгандыр, шуңа башын чайкый.

Аллаяров сүзгә кушылды:

— Арырлык та булды, биш сәгать буе...

Бу юлы хирургның тавышы йомшак, Бибисаның хәленә кергән кебек.

— Баязит Алмасович, сезгә анда чәй китерделәр, эчәсезме?

Шул ук ягымлы хатын-кыз тавышы. Ул, җаныем, хирургның да хәленә керә, дип уйлый Бибиса.

Ул арада сулышына кабына язып, икенче хатын килеп керде, ашыгып сорады:

— Ничек, Баязит Алмасович?

Хирург эшеннән канәгать кеше кебек әйтеп куйды:

— Менә чистарттык.

— Нәрсә иде соң?

— Яман шеш.

Әйтерсең башкача булуын хирург көтмәгән дә, хәзер үзенең фикере раслануга канәгатьтер. Аллаяровның сүзләре Бибисага шулай ишетелде. Авыруның хәлен белергә кергән хатын өстәл янында бик авыр итеп, көрсенеп куйды. Бибиса аны тавышыннан танып алды: рентгенолог, бер йортта яшиләр. Туктап сөйләшкәннәре булмаса да, исәнләшеп йөриләр. Бибисаны рентген аша тикшергәндә, борчылуын яшерә алмыйча, йөзенә карамаска тырышты. Бер нәтиҗәгә риза булмыйча, кабат-кабат тикшерде. Аллаяров ул чакта ук рентгенсыз да диагнозны белүенә ишарә ясаган иде. Күрәсең, сүзенең раслануына канәгать булып чыгып китте. Операция өстәлендә яткан авыруның үтә нечкәргән күңеленә шулай тоелды. Хирург чыгып китте, ә Бибисаның эче тегелмәгән икән ләбаса! Хатын-кыз тавышы:

— Уянды бит, авыртыр, ничек тегәбез хәзер?

Бусы шәфкать туташыдыр, баягысы Бибиса янында юк иде.

— Авыртса-авыртмаса, текми калдырып булмый бит!

Рентгенологның боерулы тавышы.

Бибиса үзенең эчендә кышкы бәкедә кер чайкаган кебек нидер чайкалгансыман тойды. Мышный-мышный, берсе тегә башлады. Җан өзгеч авырту сизелмәде. Чөнки баягы коточкыч сүзләрдән дә ныграк әрнетер нәрсәнең булуы мөмкин түгел.

Аллаяровның үз практикасында мондый операция ясаганы юк иде. Мондый очракта кире ябып куялар. Шундый күрсәтмә бар. Операциягә чаклы Сабанаева турында сүз күп булды. Аллаяров куйган диагнозны якламадылар. Аныңча булса, авыруның бер ай, күп булса, ай ярым гомере калган. Операция файдасыз, тотынсаң, өстәлдә үк җан бирүе мөмкин. Шәһәрдә билгеле кеше, актриса... Аллаяров аның үз пычагы астында үлүен теләмәс иде. Терапевт Динис үтенде. Ачып кара, зинһар, бәлки ялгышасыңдыр, диде. Диагнозың дөрес булса, авыру бу чиктә аяк өсте йөри алмас иде, диде. Югыйсә, баш врач Казанга җибәрү ягында иде. Операцияне аның күзәтчелеге астында ясарга туры килде. Баштан ахырга чаклы Камилла Асадовна авыруның аяк очында торды. Хирургка киңәшләр дә биргәләде. Аллаяровның ачуы килде: бик оста булгач, ник үзе алынмый...

Операция барышында ике тапкыр туктап, ял иттеләр. Чөнки авыруның пульсы югалды, аяк-куллары суынды. Кулында гәрәбә кашлы йөзек, тырнагында маникюр... Хатын-кыз үлгәндә дә хатын-кыз булып кала. Ярый әле, маникюры сыек алсу, куе кызыл булса, сөртеп ташларга туры килә иде. Тырнакның күгәрү-күгәрмәвен хирург күреп торырга тиеш.

Наркозны Варис Русланович кызганып кына бирде бугай, чөнки операция озакка сузылды, ә авыруның наркозны күтәрә алмау куркынычы бар. Җәрәхәтнең тышкы каты тегелмәгән иде әле, авыру уянды. Актрисаның төпсез күл сыман карашын күтәрер хәле калмады Аллаяровның, тегүне ассистент төгәлләде.

### 3

Бибисаның көннәре һәм төннәре буталды. Тамак төбенә яры каплана, тыны бетеп, шыбыр суга батып уяна. Сулышын рәткә китерә алмыйча бик озак газапланып ята. Башын суга манып алган диярсең, чәч очлары тамчылап тора. «Йокламаска, йокламаска! Үлеп киткәнеңне сизми дә калырсың...» Шулай үз-үзен кабатлап, ут эчендә бәргәләнеп ятты Бибиса. Караватта тәгәрәп-тәгәрәп ауныйсы килә аның, ләкин сул беләген тешләп торкан веносекция, җан сакчысыдай, янәшәсендә басып тора, беркая җибәрми. Бибисаның бөтен тәне, җаны бөгәрләп кыскан сиртмә кебек, беләгенә сөлек булып кадалган кызыл көпшәне суырып алып, мәтәлчек атып китәсе килә. Әмма яшәү теләге бүтән теләкләрне җиңә: венага ялгыш һава керсә, кеше шундук үлә дип ишеткәне бар. Ә «җан сакчысы» үзенең нечкә көпшәләреннән Бибисага берөзлексез ниндидер дарулар тамызып тора. Аһ, шул тамчының өчесен генә иренгә тамызсалар! Нигә шулчаклы кызганалар суларын? Бибиса уң ягындагы тумбочкага үрелә. Юк, буе җитәрлек түгел. Анда, чәйник сыман борынлы савытта су. Савыт эчендә бал калагы, калакның башына марля уралган. Шәфкать туташы үзе теләгән вакытта марляле калакны судан алып, Бибисаның иреннәрен чылата, ләкин ул бәхет шул чаклы сирәк тия...

— Эчәсегез киләме?

Фәрештә бит ул актан киенгән кыз, өзелеп кирәк чакта килеп тә житкән. Бибиса мул чыланган калакны иреннәре белән кыстырып ала да, тартып алуларыннан куркып, йотлыга-йотлыга суыра башлый. Дөньяда иң шәфкатьле, иң әйбәт кеше булса, ул шушы кыздыр дип уйлый.

— Рәхмәт, акыллым, рәхмәт...

Бибисаның авыз ачып әйткән беренче сүзләре. Ул үзенең тавышын ишетмәде. Тавышы юк, бары иреннәре генә кыймылдый. Дөньядагы барлык нигъмәтләрне тезеп куеп, «сайла!» дисәләр, шушы бер йотым

суны сайлар иде. Бибисаның бөтен барлыгы утта кызган ук сыман бер нәрсәгә төбәлгән: яшәргә!

Уң як стенаны иңләп торган тәрәзәләргә сыек караңгылык төште. Тирә-якта ыгы-зыгы тукталды. Ак халатлылардан бары бер генә кыз калды. Ул баядан бирле ялгызы бөтерелә. Кинәт Бибиса аңлап алды: бу икенче кич, икенче төн. Бары бер төн, бер көн узган. Ә тамак чатный, янып-янып чатный. Бибиса тагын уң кулын сузып кармалана башлады. Шәфкать туташы килде, шифалы бал калагы иреннәрне чылатты, кипкән тамакка татлы су йөгерде.

— Тумбочканы янығызга куям, теләгән чакта үзегез үрелеп алырсыз, — диде ягымлы кыз, — тик карагыз аны, эчә күрмәгез, иренегезне генә чылатыгыз.

— Рәхмәт яусын, акыллым, рәхмәт яусын, — дип пышылдый Бибиса үз тавышын тагын ишетми. Әллә колакка зарар килгәнме? Алай дисәң, сестраның сүзләрен ишетә бит. Ярый, хәзергә тавышсыз яшәп торырга була, баш исән булсын. Тавыш турындагы мәсьәләне хәл итү киләчәккә калды. Иң мөһиме — тылсымлы бал калагы янында гына. Күпме теләсәң, шул кадәр суыр. Шәфкать туташы да күз алдында тормый, сүз әйтүче юк...

Бөтен тәнен өттереп торган хәсрәт — су хәсрәте беткәч, Бибиса әйләнә-тирәгә игътибар итә башлады. Тәрәзә янындагы уң як карават буш. Сул якта берәү ята. Аны күптән түгел кертеп салдылар, ахрысы. Бибисаның онытылып киткән чагы булгандыр. Иркен палатада бүтән беркем юк. Каршыда капка чаклы киң ишек, аның ак чаршавы ян-якка сыдырылып куелган. Алгы якта дежур сестра өстәле. Ә арырак шушындый ук киң ишекле тагын бер палата, анысының да чаршавы ачык. Ишек турысындагы караватта, Бибисаның нәкъ каршысында ир кеше өзлексез ыңгырашып ята. Кичә төнлә кычкырган тавышлар колагына кереп калган иде. Шул ир булган, күрәсең. Шәфкать туташы уртадан ике якны да күзәтеп, әле бер бүлмәгә, әле икенче бүлмәгә йөгергәләп йөри. Бибисаның әйләнә-тирәне өйрәнүе шуннан ары китә алмады, тәнен кыздырып, фикерен гүя утлы игәү белән игәүли башладылар. Бердәнбер юаныч — сулы бал калагы, аның да шифасы озакка житми. Чәчтән тир белән борынны яра торган ис чыга, наркоз шулай чыга микән, дип уйлый Бибиса. Уң кулының бармаклары белән тактаусыз чәчен тараштыра. Башында зеңләгән кыңгырауларны шулай туктатмакчы була. Күпмегә сузылыр бу төн, айгамы, елгамы?

Төннең кайсы сәгате булгандыр, бер заман кыңгырау тавышы тәрәзәгә якынлаша башлады. Ул ара булмый, ак бураннар туздырып, аты-арбасы белән Бибисаның әтисе килеп туктады. Бер кулы белән дилбегәсен тоткан килеш, икенче кулын изәп, Бибисаны чакыра. Атын көчкә тыеп тора, ашыктыра. Урманнан кайткан, хәзер яңадан китә икән. Бибисаны алырга гына сугылган. Чыгарга ярамый бит, нишләргә? Бибиса йөзен мендәр белән каплады да, караватка сеңде. Караваг буш дип уйласын. Кыңгырау тавышы ераклашты. Ә менә мендәрне һич кире алып булмый, уң кулы кыймылдамый, сул кулга сөлек кадалган. Тын бетә, тын бетә... Аһ, нигә әткәсен алдады, шуның өчен җәза бу...

Тын ала алмый җәфалана торгач, Бибиса уянып китте. Тамагына утырган төерне авырлык белән йотып җибәрде. Сулыш юлларын ярып һава керде. Һава! Яшәү өчен барыннан да элек һава кирәк. Сулавы нинди рәхәт! Ярый, урамга чыкмадым, дип уйлый Бибиса. Әткәсе бит күптән үлде. Аның белән китмәвенә кабат-кабат сөенде ул. Хәзер инде бервакытта да йокламам дип, үзенә сүз бирде. Китеп барганыңны сизми дә калырсың...

Зарыктырып кына таң беленә башлады. Кояш әле чыкмаган, ә нурлары өй кыекларына, тирәк башларына кагылып, кошларны уята.

Чыпчыклар, песнәкләр, «йоклап кала язганбыз бит!» дигәндәй, чыркылдашып бер-берсенә дәштеләр. Кошларны сайраткан таң тәрәзәләргә үрелеп карый, эчтән корылган пәрдә араларыннан бүлмәләргә үтеп керә. Эшкә иртә барасы кешеләрне барлап чыга. Табигать патшасы кояш алтын таҗын киеп, тәхетенә менеп утырганчы, бар да үз урыннарында булырга тиеш, менә шунда инде ул кешеләрнең эшләрен яктыртып, күзәтеп йөри: яхшыларын балкытып, яманнарын көйдереп күрсәтә. Өлешләренә тигән эшләрен төнлә башкарганлыктан, төн йокылары калган кешеләрне җылытып, иркәтеп йоклатып ала. Җан һәм тән газабыннан сызланганнар янына да ул төн пәрдәләрен ертып керә, шифалы нурлары белән сыйпап, аларга да бераз ял бирә.

Бибиса көн яктысын күрүенә сөенде, аргы бүлмәдәге ир кешенең ыңгырашуы басылудан бераз ял алгандай булды. Менә шәфкать туташы градусниклар куярга керер, иртәнге ыгы-зыгы башланыр. Ялгызлыкта, караңгылыкта кичергән газаплар онытыла төшәр.

Өстәлгә башын салып черем итеп алган сестра кузгалды, авыруларның хәл-әхвәлләрен белде, форточкаларын ачып, палаталарны җиләтте. Сестра янына ак халат кигән бер хатын керде, төнлә яман каты ыңгырашкан ир хакында гәпләштеләр. Бибиса боларның сүзләренә колак салды, ыңгырашкан кешенең хатыны килгәнен чамалады. Врачлар килгәнче дип, сестра аңа керергә рөхсәт иткән. Югыйсә, реанимация бүлегенә авыруларның туганнарын кертмиләр. Хатынны сестра палаталарны юып, җыештырып чыгу шарты белән кертте. Чөнки санитаркалары авырып эшкә чыкмады, эшче куллар житешми икән.

Аз гына тынып ятканнан соң, теге ир тагын ухылдый, ыңгыраша, бәргәләнә башлады, беләгендә веносекция булганлыктан, караватыннан ары китә алмады. Хатыны исә аның әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан килеп карады, ярдәме тимәде. Сестра куйган шартны үтәргә дә кулы бармады, кич килергә вәгъдә биреп, кайтып китте. Сестра янына кабаланып тагын бер кыз керде. Кызның колагына сестра нидер пышылдады, тегесе коты очып Бибисага карап алды да тиз генә чыгып китте. «Минем чирне әйтте», дип уйлап куйды Бибиса, йөрәге чәнчеп-чәнчеп сыкрый башлады.

Эш сәгате житте. Беренче булып өлкән сестра килде. Ул башта ирләр бүлеменә, аннары хатыннар бүлеменә керде. Аның артыннан ук ишектә Аллаяров күренде. Өлкән сестра, Аллаяровны күрмичә, дежур сестрага җәймәләрне алыштырырга кирәклеге турында кисәтеп маташа иде.

— Хәерле иртә, — диде Бибиса өлкән сестрага, моңарчы тавышы булмаганын онытып. Үз тавышын ишеткәч, чиксез сөенде, хәтта көлеп куйды.

— Ә-ә... исәнмесез...

Сестра уңайсызланып елмайды. Ул арада Бибиса янына Аллаяров килде.

— Хәерле иртә! Сез инде көлә дә башлагансыз, күрәм. — Бибиса янындагы урындыкка утырып, хирург сүзен дәвам итте. — Операция ясадык. Уңышлы чыкты.

— Рәхмәт...

Сезнең белән бүтән сөйләшер сүзем юк дигәндәй, Бибиса башын читкә борды. Нилектән Аллаяровка ачулы ул? Җәрәхәтен текмичә китеп баруы өченме? Әллә теге чирнең коточкыч исемен бөтенесе алдында әйткәнгәме?

Хирургның авыру белән шәхси мөнәсәбәтләрне ачыкларга вакыты юк иде, үз эшендә булды.

— Түбән төшеп беткәнсез бит, арка өлешегез югарырак торырга тиеш, — дип, сестралар ярдәменнән башка гына Бибисаны өскәрәк күтәреп салды. Авыруның аңа ачык йөз күрсәтмәгәнен сизде, әлбәттә,

нинди дарулар бирергә кирәклеген сестрага әйтеп яздырды да сул яктагы авыру янына китте. Авыруны Бибисадан җиңелчә ак ширма белән аерып куйганнар. Сирәк-мирәк зәгыйфь кенә ыңгырашып куюдан башка аның бер тавышы да чыкмый. Докторлар да аның янында акрын сөйләшәләр. «Ә мин нәрсәгә өметләнәм?» дип уйлады Бибиса үзе турында. Хирургның үз авызыннан ишетте, иртән кергән кызның куркынган карашын күрде. Ләкин Бибисада яшәү өмете ныгый барды. Аның өметләнер нигезе бар. Медицина белмәгән бер дару белә ул. Кеше аягы басмаган урман-тауларда үсә. Әбугалисина заманында ук белгәннәр икән ул шифалы дәва турында. Әбугалисинаның язмалары калган. Дөрес, ракны дәвалавы турында бер китапта да язылмаган. Ләкин Бибиса өметләнә. Бик нык ышана. Терелеп кенә чыксын, ул туган якларына кайтыр, кара урманга төнлә ялгыз барыр, таң сызылганын көтәр һәм табар ул тылсымлы үләнне. Чиргә дәва табылмавы мөмкин түгел. Мөгаен, Гыйлфан да беләдер аны. Нигә тегә вакытта Бибиса Гыйлфанның үләннәренә күлеп карады? Менә кайчан кирәге чыкты. Кешеләрне рәнҗетергә ярамый, алар һәр вакыт бер-берсенә кирәк булып торалар. Терелеп чыгу белән Бибиса Гыйлфанны эзләп табачак. Больницадан чыгу белән Бибиса урманга китәчәк. Әйдә, кемнәрдер, үлә инде бу кыз, дип уйлый бирсеннәр. Ә ул, әнә, елмаеп ята...

— Кунак егете. Исеме Гыйлфан. Сезнең концертны карарга килде... — Бибисаның кардәш абыйсы китапханә бүлмәсендәге кызларга шулай тәкъдим итмәсә, ак куян бүрекле, боек карашлы чандыр малайга бәлки игътибар бирмәсләр дә иде. Нидидер датага багышланган бу концертта Бибиса ялгыз да биеде, күмәк биюдә дә катнашты, җырлады да. Кайтканда юл уңай туры килеп, баягы куян бүрек белән бергә киттеләр. Кунак егете булгач, Бибиса аны куып җибәрергә кыенсынды. Авылныкыларга якты йөз күрсәтсәң, кич саен озата йөри башлыйлар. Күрше авыл егете бүген озатыр да, иртәгә кайтып та китәр. Бер кич озаттырудан бер җире дә кителеп калмас әле. Кара кашы астыннан сөзеп кенә карый, үзе шундый тыйнак. Авылныкылар кебек беләгеңә дә ингә салмый, кулдан да тотмый... Чана юлының ике эзе буйлап атлыйлар. Берсе бер дәшми. Әле күктәге айга карыйлар, әле җирдәге карга күз салалар.

— Минем сезнең авылга киләсем бар әле, — диде егет, Бибисаларның өй турыларына җиткәч, — тагын шулай капка төбенә чаклы килергә рөхсәт итәрсезме?

— Юл иркен, йөргән кешегә ирек, — ди кыз, аз гына кыланчыкландай итеп. Сүзне озайтырга уйлапмы, егет бүгенге концертны исенә төшерә:

— Ничек шулай бармак очында биергә өйрәндең?

Бу мәсьәлә аны бик нык кызыксындырган кебек итеп, ихлас сорады егет, хәтта «син»гә күчте.

— Телевизорда күрдем дә, үзем дә шулай аяк бармагына басып карадым, — диде Бибиса, андый вак-төяккә әһәмият бирмәгәндәй генә.

— Бер карауда өйрәндеңме?

— Башта бер минут кына тора ала идем, соңыннан озаграк тора башладым.

Бию турында сөйләшеп бетерделәр. «Инде җыр турында сөйләшәбезме?» — диясе килгән иде Бибисаның, кунакны рәнҗетүдән куркынып тыелып калды.

— Мин сезнең авылга тагын киләм әле, — диде егет. Сүзендә торды. Бер дә килде, ике дә... Алты чакрымны көн саен икешәр тапкыр узган чаклары да булды. Икенче тапкыр килгәндә рәтләп сөйләшә алмадылар. Бибиса фермадан кәефсезрәк кайткан иде, идарәгә чакы-

ралар дип, дәшеп алдылар. Идарәдә аны көткән кеше табылмады, кыз юл уңаеннан китапханәгә сугылды. Куян бүрекле кунак егетен күргәч, эшнең нидә икәнлеген сизенде. Сәлам бирде, ары-бире журнал актаргалады да, кайтырга чыкты. Кунак егете дә аның артыннан нярде. Аны-моны сөйләшеп кайттылар да, Бибиса өйләренә кереп китте. Әмәнә өченче килүендә озын кышкы кичне бергә уздырдылар. Икәүдән-икәү, генә түгел, әлбәттә. Авыл егетләреннән ул кичне Гыйлфанга бераз «өлеш» тә эләкте.

Өлкән яшьтәге савымчыны ял йортына җибәргәннәр иде, йорт-курасына күз-колак булырга Бибисага әйтеп калдырды. Көннәрнең берендә савымчы кызлар ялгыз өйдә кич утырырга җыелдылар. Кызлар булган җирдән егетләр каламы соң, аулак өй дип аталган кичә оешып китте. Нәкъ шул кичне кунак егете килгән иде. Аулак кичә аның хөрмәтенә җыйналмады микән әле? «Кул эше эшләрбез, яңа җырлар өйрәнербез»дән гайре сүз әйтелмәгән иде, югыйсә. Егетләр чакырырбыз дип булмый бит инде. Аларны атап чакырмыйлар да. Фәлән өйдә фәлән кызларның кич утырачагын берсе ялгыш кына ычкындырып ташлый да, калганын егетләр үзләре белә. Аулак кичә ничаклы яшерен җыйналмасын, күңеле тарткан кеше аны эзләп таба. Уеннары да кемнең кемгә күңеле төшкәнлеген белер өчен уйлап чыгарылган. Каешлы уенны гына ал... Ян сәкегә тезелеп утырдылар. Кунак егете Бибиса белән янәшә. Бүтәннәр дә шулай парлы-парлы. Аяк өсте калган егет белән кыз үзләренә яңа пар сайлыйлар. Егет кулында каеш. Ул туры Гыйлфан каршына килеп, Бибисаны сорый.

— Бирәсеңме?

— Бирмим.

Каешлы егет үз янында торган кабартма битле кызга мөрәҗәгать итә:

— Ничәне?

Кызның кунак егете янына утырасы килгәндер, җәзаны җәлләми бирә:

— Унны.

Гыйлфан кулын алга суза, икегә бөкләнгән каеш кунак егетнең уч төбенә ун тапкыр чатнап төшә.

— Хәзер ничек, бирәсеңме?

— Юк.

Нишләгән бу авылдаш, тагын ун каеш әйтә. Хәзер инде Гыйлфан усаллашып, үз парын бүтәнгә бирми. Кунакка егерме каеш төшергәннән соң, каешлы егет бүтән кызны сорарга китә. Ул кызның пары биш каеш алып котыла. Каешлы егет күзен бәгырәйтеп, кабат Бибисаны сорап килә. Шунда сынала егетнең кызга булган мөнәсәбәте. Авыл егете каешын селтәп-селтәп, чажлатып суга. Бибиса җәзаны бүлеп алырга тели, Гыйлфан риза түгел. Кыз аңа сыеныбрак утыра. Һәр суккан саен Гыйлфанның тәне тертләп куйганы сизелә.

Ул көнне Гыйлфан кырык каеш алды. Күңел хисләрен сүз белән белдерүнең кирәге бөтенләй калмады. Кара-каршы җырлашканда Бибиса кунак егетенә керфек сирпеп бер җыр җырлаган иде:

Чәчләремне, чәчләремне
Сибелдереп таратам.
Уйларыңны белмим әле,
Буйларыңны яратам.

Бибисаның җырына Гыйлфанның җавабы иде бу. Алты чакрым араны тәүлегенә икешәр урау күрше авыл егетенең гадәтенә кереп китте. Кичке караңгыда килә дә, иртәнге караңгыда кайтып китә. Бибиса исә, монтер егет йокысыз төннән соң электр баганасыннан башы әйләнеп, егылып төшмәсә ярар иде, дигән теләктә яши. Авылда сагаешын

калдылар. Чышы-пышы китте. «Куян бүрек» нинди әфсенен тапкандыр, кызның күзе юлда гына. Сагынышып очрашулар шул дәрәҗәгә барып җитте, кунак егет бергә булу хакында сүз кузгата башлады. Бибиса бу хакта ишетергә дә теләми. Энесен, сеңелесен аякка бастырасы бар, аннары үзенә укырга кирәк булачак. Техникумгамы, институткамы китәсе килә... Биш елсыз бергә булу турында уйларга да ярамый, ди. Гыйлфан гаҗәпләнүеннән сызгырып җибәрә:

— Һуу-уу-уу... Биш ел буе ике авыл арасын таптап, мин күпме юл узарга тиеш... Сузып салсаң, җирдән йолдызга чаклы...

— Шуңа әйтәм бит мин сиңа, көн дә килмә димен, атнага бер килсәң җитәр.

— Ә ул атна арасында сине бүтәннәр сугып алса!

«Авызыңнан җил алсын» диясе калган бит шул чакта. Алай димәде шул Бибиса, «кемгә хаҗәтем бар минем», диде. Вакыйгалар терлекчеләрнең район киңәшмәсеннән куерып китте. Башта Бибиса биек трибуна артыннан халыкка башын гына күрсәтеп, үз эшләре турында сөйләде. Без шундый да, без мондый, үтибез, арттырып үтәргә сүз бирәбез... Сөйләгән чакта үзенең бик хәтәр мактануын шәйләмирәк калды, чөнки кеше язып биргән кәгазьне укыды. Сүзләре кешенеке түгелтүгелен. Комсомолның район комитеты секретаре сорашты, савымчы кыз сөйләде, теге язгалап утырды. Шул язганнарын Бибисага тоттырды, шунын буенча чыгыш ясарсың, диде... Тәнәфес вакытында бөтен халык, урман җәнлеге күргәндәй, Бибисага борылып карый. Килеп күрешә, таныша башладылар. Бигрәк тә үзе ише кыз-кыркын. Шуннан гына савымчы кызның эченә җылы керде: гаепләп түгел, үз итеп карыйлар икән. Киңәшмәдән соң терлекчеләр көче белән концерт оештырдылар. Бибиса чыгып җырлады.

— Те-йе-лейе-гее-раам ба-а-һа-га-һа-на-һа-сын...

Күбәләктәй җиңел кыз баладан шундый тирән моң чыгуына хәйран калырсың. Моңлы бала бәхетсез була дигән сүз бар халыкта. Хак микән бу сүз? Әллә, киресенчә, хәсрәте күпкә димик инде, башында уй күпкә моңлы буламы ул? Баскан урынында очынып торучы уналтыунҗиде яшьлек кыз балада нинди хәсрәт, нинди уй дисезме? Өйләнешү хакында сүз кузгаткан Гыйлфанга да ул һәммәсен әйтеп бетермәде. Сыңар канат белән тормыш алып бару җиңел түгелдер, әнисе күз алдында сыза. Бала-чага сизмәгәнгә салышып йөрсә дә, барын да күрә, күңеленә җыя ул, тормыш авырлыгын анасының хәсрәтле күз карашыннан тоя. Исәпләрендә уен-көлке генә дип уйлый күрмәгез.

Залда утыручылар бу хакта уйландылармы-юкмы, әмма барысы бердәй күңелне күз күрмәгән якларга алып киткән моң иркенә бирелгәннәр иде.

Күз керфекләрем талганчы-ы-ый
Ка-һа-рыйсым ка-һалга-аһаан икән...

Якыннарның, дусларның кадерен белерлек. Соңыннан үкенечкә калмасын... Тыңлаучылар, мөгаен, шундый хис кичереп утырдылар.

Бибиса сәхнәдән чыккач, арткы рәттә утырган сөт ташучы ике егет арасында әңгәмә булып алды.

— Ниндәйрәк кыз бу?

— Ниндәй икәнен күреп торабыз ич, алдынгы сыер савучы дип игълан иттеләр.

— Ата-анасы кем димен.

— Атасы юк, анасы әлегә исән, бер энесе, бер сеңелесе бар. Җитмеме?

— Егете бармы?

— Авыл егетләре белән эре бәрәңге ашап чыккач кына сөйләшә ул.

— Кыз минеке булачак.

Берәүгә жирдән йолдызга чаклы тоелган ара сөт ташучы өчен икеөч көн эчендә хәл ителде.

Бер онытылып, бер уянып, тирә-юньне күзәтеп, сестраларның мәш килүләренә игътибар салып ята торгач, көн үтеп китте. Төнгелеккә зәңгәр күзле, кара кашлы чуваш кызы Лена калды. Бибисаның уң якка авыштырып кына аркасына банка салырга әзерләнгән иде, тегесе утырам ди башлады. Биш кенә минут утырып торам ди. Лената кулына тотынып, торды да утырды. Әйдә, утырып карасын. Лена авыруның аркасына банкалар тезде. Озак ятудан пневмония булырга мөмкин, банка исә канны тарата. Ул арада Ленаны кемдер чакырып алды. Бибисаның башында бер генә уй: ничек кенә булса да биш минут түзәргә. Банкалы арка белән ятып булмый бит.

— Лена, булгандыр инде...

Сестра ширма артында гына икән.

— Хәзер, хәзер, тагын бер генә минут түзегез.

Мендәргә яткач, Бибиса иркен сулап куйды. Утырып аргач, яту тансыкланган.

Утта янып, суга төшеп тагын бер тәүлек узды. Кич тагын банка салдылар. Бу юлы Бибиса ун минут утырды.

Бүген ул ярыйсы гына йоклап алды. Йокы аралаш ниндидер тавышлар ишетте. Шәфкать туташы кемнәр беләндер бәхәсләште, ниндидер авыруларны үз бүлегенә алмаска тырышты, нәрсәдер исбат итеп маташты. Яктыра төшкәч, Бибиса каршы бүлмәдә яңа авырулар барлыгын белде. Ишек каршысында башсыз биек караватта ятучы ир-атны Бибисага күренгән уң як караваттан нәни ак пәрдә белән бүлеп куйганнар. Менә бер заман пәрдә артыннан озын коңгырт чәчләрен таратып салган, ак күлмәкле, ялан аяклы кыз пәйда булды. Нәкъ су кызы. Бүлмәдә сестра күренми. Су кызы каршылыкка очрамыйча, йөзеп кенә ишектән чыгып та китте. Кичә ыңгырашкан ир гаҗәпләнүдән шар булган күзләре белән аны озатып калды. Бу күренешнең өнме-төшме икәнен аңларга тырышып, уң кулы белән йөзен сыпырып алды. Бибиса аның бернәрсә дә аңламаган кыяфәтен күрде. Теге ир тагын бер тапкыр йөзен маңгаеннан иягенә чаклы сыпырып төшерде. Ул да булмады, икенче пәрдә артыннан беренчесенә ике тамчы су кебек охшаган бүтән кыз килеп чыкты. Шундый ук озын чәчле, ак күлмәкле, ялан аяклы. «Су кызлары» урта ишек янында кара-каршы очраштылар, берберсенә баш игәндәй иттеләр дә, берсе су юлына (Бибиса хәзер аларның кая чыкканнарын аңлады), икенчесе үз караватына юнәлде. Яман ыңгырашучы ирнең исә ике күзе шар булган, әле уңга, әле сулга тәгәриләр. Бу тамашаны карап яткан Бибиса кычкырып көлеп җибәрә язды, янында каты авыру ятуын уйлап кына тыелып калды. Эх, бүлмәдә уяу җан иясе булса, рәхәтләнеп бер көләр иде. Шундый кызык хәлне кеше белән уртаклаша алмавына үкенеп куйды. Көлкеле кинода ялгызы утырган сыман хис итте үзен. Озын чәчле кызлар кереп урнашуга, Ленага иярeп, теге ирнең хатыны керде. Хатын йомшак кына итеп иренә дәште:

— Бүген хәлең әйбәтләнгәндәй булган.

Ир дәшмичәрәк ятты да, канын туктаусыз суырып торучы веносекциягә карап әйтеп куйды:

— Белмим, ахыры ни белән бетәр...

Ире янында хатын озак юана алмады, Лена кушуы буенча, Бибиса яткан палатаны җыештыра, сөртә-юа башлады. Эш арасында сестра белән алар гәпләшеп алдылар. Хатын ире ягына ымлап:

— Оҗмахка эләккән ич бу, ике ягында ике хур кызы утыра...

Лена күңелле итеп көлеп куйды.

— Әййе, оҗмах юлы нәкъ шушыннан башлана.

— Нәрсә белән кергәннәр?

— Берсе серкә эчкән, егете ташлаганмы шунда... Икенчесе тагын нидер капкан.

— Агу эчкәнгә охшамаганнар үзләре.

— Күп эләкмәгәндер. Без кеше саулыгы өчен көн-төн тырышабыз, ә алар тормышны чүпкә дә санамыйлар.

Реанимация бүлеге мөдире Варис Русланович килде.

— Хәлләр ничек? — дип сорады ул Бибисадан.

— Бик шәп!

— Шулай укмыни? Әйбәт, әйбәт. Сезне кичә утырып торды диләр. Алай да артык шәпләнеп китмәгез, өзлегү дигән нәрсә бар бит, ишеткәнегез бармы?

Варис Русланович янәшә караватк янына китте. Үзе һаман Бибисага мөрәҗәгать итә:

— Менә, күршегезгә дә җан керде бит. Терелер дип уйламаган идек.

Ике арадагы пәрдәне алганнар.

— Терелдәм мин, терелдәм, — диде хатын, иреннәрен ялый-ялый, — менә күрерсез.

Хатынның эче тау кебек. Варис Русланович исә, хәйран калгандай, әле Бибисага, әле аның күршесенә карап торды. Шул арада Аллаяров кереп, әлеге хатын янына килеп басты. Варис Русланович та шул якка борылды. Авыруның йөзенә иелеп хәлен сораштылар.

— Терелдәм мин...

Бибисаның күршесе карлыккан тавыш белән һаман шул сүзен кабатлый. Аллаяров нишләптер аңа җавап бирми. Хәтта авыруның сүзенә ышанмаган төсле. Шул кыяфәттә хирург Бибиса янына килде.

— Сез инде сират күперен кичтегез, артка юл юк сезгә, — диде ул бик ышанычлы итеп. Бибисаның уң кулын алып пульсын санады. — Йөрәк ярыйсы. Ничек йоклыйсыз? Авырткан җирегез бармы?

Бибиса зарларын сөйләп тормады. Аяклары гөбе кебек шешенгән иде, аларны да әйтмәскә булды. Әкренләп узар әле.

— Чагыштырмача яхшы, — диде ул, Аллаяровка карамыйча гына.

Хирургка ул һаман ачылып китә алмый. Шулай булмыйча, ничаклы газапларга дучар итте бит ул Бибисаны.

Хирург Варис Руслановичка карап сорады:

— Бүген бишенче тәүлекме?

Тегесе хирургның сүзен раслап, баш какты. Хәер, хирург моны үзе дә яхшы белә, болай гына сорый. Алгы бүлмәгә чыгып, авыру тарихына нидер яздылар, дарулар турында киңәштеләр.

Аллаяровны озаткач, Варис каршы як бүлмәгә керде. Докторны күргәч «хур кызлары»ның берсе кайтырга сорый башлады.

— Биш яшьлек энем өйдә берүзе, өстеннән бикләп киттем.

— Энең җәл булгач, нишләп агу эчтең соң?

— Ул югалган иде, шуңа куркып эчтем.

— Ничек югалган иде?

— Апам белән җизни кунакка китте. Мин аларның малайларын карап, өйләрендә калдым.

— Шуннан?

— Ул малай чыгып китте дә юк булды. Көне буе шуны эзләп чаптым, табылмаган кайгыдан агуланырга уйладым.
— Ә каян килеп ул хәзер бикле өйдә утыра инде?
— Мин агулануга ул үзе кайтып керде...
Варис Русланович аптырап бот чабып куйды:
— Менә бит, исәрне һәчеп үстермиләр, үзе үсә ди.
Кыз елый ук башлады.
— Кайтарыгыз инде, абый, ул хәзер уяныр да ялгызы куркыр, я тәрәзәдән чыгып качар...
Варис йомшара төште:
— Ярый, каныгызны тикшерсеннәр дә, зарарлы булмаса, кайтырсың.
Врач китәргә кузгалгач, кыз үз-үзенә сыктап алды:
— Башта кабул итми газапладылар, хәзер чыгармыйлар...
Кызның икенчесе белән ни турында сөйләшкәннәре ишетелмәде. Агуланганнар белән эшен бетергәч, Варис янадан Бибисалар бүлеменә керде. Бибисага карап сөйләнеп алды:
— Якшәмбе булса, бәйрәм булса, больница ишеге ябылмый. Кешегә эш кирәк, эшсез тәмам рәттән чыгачак ул.
Кичә якшәмбе булган икән дип искәреп алды Бибиса, врачларның озак күренми торуларын хәтеренә төшереп. Алардан башка вакыт бик акрын уза.
— Хирург сезгә башыгызны югарырак салып ятарга кушты, ә сез түбән төшеп беткәнсез.
Варис, Бибисага булышмакчы булып, ике кулын аның аркасы астына шудырып кертте. Дәрәҗәле кунакларны кабул иткәндә, ак сөлгегә салып, ак көмәч күтәргән шикелле генә күтәрергә уйлыймы? Бибиса врачның инсезлегеннән көлеп куйды:
— Юк, юк, алай түгел, сезнең сестралар менә болай күтәрәләр: Бибиса уң кулын анестезиологның иелгән җилкәсенә салды. — Хәзер үн кулыгызны өскә алыгыз, — дип өйрәтте ул врачны,—хәзер күтәрегез.
— Сестралар алар өйрәнгәннәр шул, — диде Варис, гади генә ысулны да белмәвеннән гафу үтенгән сыман.
Көндез Бибисага кан салдылар, ниндидер яңа уколлар бирделәр. Иртәдән бирле акрынлап сыкрый башлаган умыртка сөяге бер урыннан чүкеч белән төйгән сыман авырта башлады. Авырту тиз арада бөтен аркага, күкрәк читлегенә таралды. Күз аллары караңгыланды, укшыта башлады. Көндез ашаган аш шул килеш кире чыкты. Аз гына тыны җиңеләйгәндәй булды. Күз аллары караңгыланып, янадан укшыта башлады. Мең газап белән ашказанын сыекчадан бушаткач, анда йодрык чаклы таш утырып калды. Бибиса, тамагына ике бармагын тыгып, шул ташны чыгармакчы була. Шәфкать туташы моны күреп ачуланырга тотынды:
— Алай ярамый бит, сез бәләкәй баламыни?
— Лена, косарга ярдәм ит...
— Сезнең анда бер ризык та калмады инде, барысы чыгып бетте бит.
— Кичә иртән ашаганы калды әле анда...
Сестра мондый сабыйлыктан көлеп җибәрде:
— Һа-һа, уйлап та чыгаралар соң безнең авырулар!
Ләкин Бибиса берни аңларлык хәлдә түгел иде, юдырып чыгармасмы дип, бер стакан боржом салып эчте. Хикмәт, эч авыртуы шундук басылды. Ләкин үтереп аркасы сызлый башлады. Бибиса иртән үк инде сестрадан караваТ башына дилбегә сыман итеп бинт бәйләткән иде, сынар кулы белән шуңа тотынып, торып утырды. Утыруы булды, эче пычкы белән телгәләгәндәй авыртырга тотынды. Ятты — аркасына чыдар әмәл юк. Тагын торды, тагын ятты.
— Ванька-встанька булды бит бу чистый, — дип сөйләнә-сөйләнә

сестра веносекциядәге савытка дарулар китереп салды, — хәзер тынычланырсыз.

Бер-ике минут узуга, авыру, чыннан да, тынычлангандай итте. Ләкин бу тынычлану озакка сузылмады, Бибиса яр өстенә ташланган балык сыман бәргәләнә башлады.

Ашыгып Аллаяров килеп керде (чакырып алдылар, ахрысы). Ул кергәч, Бибиса тешен кысып түзәргә, тыпырчынмаска тырышты.

— Ни булды? — дип сорады хирург кырыс тавыш белән, әллә Бибисадан, әллә сестрадан.

Бибисаның сүзләре ыңгырашу булып чыкты:

— Арка авырта, эч... Кычкырырлык булып авырта...

Хирург ялт итеп сестра ягына борылды:

— Прамедол бирегез, демидрол!

— Бирдем инде, Баязит Алмасович.

— Тагын бирегез! — диде Аллаяров, ни өчендер сестрага ачуланып. Шулай кәефе кырылган хәлдә чыгып китте.

Доктор кушкан даруларны кабатладылар.

Бибиса манма су эчендә бераз онытылып ятты. Арка сызлавы басылмады. «Дилбегә»сенә тотынып, тагын торып утырды. Суга манып алгандай юеш күлмәген салырга азапланды. Китәргә җыенган өлкән сестра моны күреп, ярдәмгә ашыкты. «Сөлек»не ычкындырып, күлмәкне салдырдылар. Ләкин алмаш күлмәк юк икән. Эш сәгате бетеп, хуҗа-сестра кайтып киткән. Бибисаның җилкәсенә япма салдылар, сестра юеш күлмәкне киптерергә алып китте.

— Үлеп арка авырта, — диде Бибиса, артына каеша төшеп. — массаж ясасаң икән...

Сестра бармаклары тиюгә, Бибисаның сызлаулары басыла төшкән кебек булды. Аһ, нинди шифалы куллар... Һич үз яныннан җибәрмәс иде кызны. Ә аның күптән эш сәгате беткән, кайтырга ашыга.

— Тагын аз гына, тагын аз гына...

Үтенсәң, сестра һаман арка сылавын дәвам итәр иде, ләкин оят кирәк бит, кайтсын инде, дип уйлады Бибиса. Сызлавы да кимеде, ахрысы, бая оят турында уйларлык хәле юк иде. Бибиса чалкан ятып, күзен йомды. Еракта́н-еракта́н кыңгырау тавышы ишетелә. Менә тәрәзә каршысына кар бураннары туздырып, җигүле ат килеп туктады. Атны тыеп тотарлык түгел, бер урында тыпырдап тора. Бибисага чыгарга ярамый, аның монда аяк киеме дә, өс киеме дә юк. Күренми калырга кирәк, яшеренергә. Ләкин кая? Тәрәзәләр шундый зур, бөтен нәрсә уч төбендәгедәй. Мендәр астына качсаң, кире чыгып булмас... Әһә, җаймәне башка капларга кирәк, менә шулай... Әнә, кыңгырау тавышы ераклаша да инде. Бөтенләй тынды. Тып-тын. Әмма әтисе китмәгән икән әле, дугаларын, тәртәләрен ташлап, ап-ак ат тәрәзәдән очып керде. Бибисаның өстендә бии башлады. Караватта кеше юк дип уйлады, ахрысы. Бибиса бит җаймә астында. Сиздә, кеше барын сизде. Тоягы белән йөрәкне чокып чыгармакчы... Әнә, йөрәк чыкты да инде, ак ат аны ике тоягы белән кыстырып алып китмәкче. Шул чак палатага кемдер керде. Ат йөрәкне кире ташлады да тәрәзәдән тышка сикерде. Ә йөрәк тыпырчынды да тынды. Тып-тын...

Бибиса бик тырышып күзен ачты. Аңа хирургның соры күзләре карап тора. Соры күктә кара болытлар йөзә. Бар да таралды. Полдызлы күк кенә калды. Бибиса күзен йомып, нәрсәнедер хәтеренә төшерергә тырышты. Ә ул «нәрсәдер» баш өстендә зеңләп очып йөри.

Бибиса кабат күзен ачканда хирург юк иде инде.

Яман шеш канны агулый, кешенең бөтен барлыгын тарката торган матдә бүлеп чыгара. Күп мәйданны яулап алган шешне кисеп таш-

лагач, чирле чакта гадәтигә әйләнгән хәл кинәт үзгәрә, организмда стресс башлана. Шул тетрәүне күтәрә алмыйча, кеше тиз арада вафат була. Сабанаева хәзер шул чорны кичерә. Канны сугаручы дарулар белән фаҗигане кичектерергә тырышалар. Операциядән соң авыру икенче шокны үткәреп җибәрде. Аның торып утыруын ремиссиягә[1] юрадылар. Димәк, тәүлек эчендә гомере өзелергә мөмкин. Сабанаевадагы кебек очрак белән аякка баскан кеше юктыр да... Андый очракларда операция ясамаска дигән күрсәтмә булса да, кире ябып куярга хирургның кулы бармады. Актрисаның күзләре хирургка шундый тирән өмет белән бактылар, андый карашны хирург үз гомерендә хәтерләми. Дәрья-күлдә сәламәт, гүзәл килеш күрмәгән булса, бәлки ябып та куяр иде.

Аллаяровның ни уйлаганын Бибиса белә. «Прамедол, демидрол»! — дип, хирург бая ни өчен ачуланды? Үлә дип ачуланды. Бибиса сизмәсен өчен булса да, ачуланмаска тиеш иде. Сабырлыгы сынды, кабынып китте. Ачуландырмаска кирәк хирургны, ул үзенең көченә ышанырга тиеш. Хирург та ышанычын югалтса, йомшак табигатьле авыруларда яшәү өмете югалачак. Хирург Бибисаның яшәвен тели, авыр операция ясавының әҗерен күрәсе килә. Бибиса хакына шулай тырышканы өчен аны сөендерергә кирәк. Бибиса шундый уйларны үз-үзенә такърарлап ятты.

Сызланулары кузгалудан куркып, Бибиса хәрәкәтсез ята. Ишектән бер төркем ак халатлы халык керде. Варис Русланович Бибисалар бүлеменә узды, тегеләргә нидер аңлата: «Рәхим итегез, биредә онко авырулар да бар...» Шөкәтсез Варис, шул каһәрләнгән сүзне әйтмәсә, кеше белән сөйләшергә бүтән сүз юк микән? Бибисаның ак халатлылар белән күзгә-күз очрашасы килми. Шулай да арттарак торган зур кара күзлеклесенә карашы төшә. Килеш-килбәте... Аркылы сызык төшкән киң маңгае... Гыйлфан! Бибиса ак җәймә белән йөзен капларга уйлый, ләкин бер генә бармагын да кыймылдата алмый, ике күзен дә кара күзлектән ала алмый...

Ял итүчеләр кумәкләшеп, «Изге чишмә» дип аталган чыганакка баралар. Үзәнлек. Калкулык. Урман сукмагы. Ат юлы. Берара Гыйлфан Бибиса белән янәшә атлый. Кулында берничә төрле үлән.

— Бусы — «көтүче биштәре», бөер ише әйберләргә дәва, бусы — гөлбадран.

Хатыннар чая да соң, тыңлашып кына йөриләр, Гыйлфанны шундук уратып алдылар:

— Кая, кая, бусы нидән файдалы?

— Монысы ни исемле?..

Читкә кысрыкланып чыккан Бибиса аларны калдырып, ары китте. Бүлмәдәшләре барын да күреп торганнар икән, яшь дусларының хәленә кергәндәй, икесе ике яктан сөйләнеп баралар:

— «Үләннәреннән рәхәтен үзең күр, ускәнем» диясең калган.

— Нишләп «ускәнем» булсын, Бибисадан шактый өлкән бит ул, ике бите буйлап буразна сызылып төшкән.

— Елмайганда бит уртасындагы чокыры шулай сызылып китә аның.

Кешене алар шулай нечкәләп өйрәнәләр. Житен чәчкәй дә кем белән танышканын алдан белеп торсын:

---

[1] Ремиссия — үләр алдыннан авыруның вакытлыча хәле җиңеләю.

— Авыл малае. Сырхау карчыкның хәстә төпчегедер, үлән белән тәмам саташкан.

— Кара, кара, Бибиса, сиңа караем диеп, муены кәкрәеп кала бит анаунын...

Кримплен күлмәкленең икенчесе пырхылдап көлеп жибәрде, анын өчен кызарып, Бибиса түбән карап барды. Хатыннар мәгълүматларны бирә тордылар:

— Оясыннан егылып төшкән чәукә баласы сыман муенын кысып китте, бахыркай...

Бибиса шунда гына башын калкытып карады. Алда, каеннар арасында, якташының аклы күлмәге балкып-балкып кала.

Жәйнең соңгы ае. Табигатькә сизелеп сары инә. Кичкырын гармунга кушылып, урман буйларын яңгыраткан егетләрнең жырларында да сагыш ишетелә:

Утыр алдагысына...
Ул сиңа булыр яр түгел,
Син алданасың гына.

Ир кешеләрдә кайдан шул чаклы моң була? Авыл халкы беренче булып кызлар моңын түгел, егетләр жырын ишетә. Үсмерлектән чыгып тавыш утырткан егетләр жырлап урам әйләнәләр. Армиягә киткәндә алар яшенле-күкрәүле малай чакларын, сизелер-сизелмәс кабынган мәхәббәт чаткыларын жырга салалар.

Агыйделнең аръягында
Калды каеш дилбегәм.
Озак тормам бу илләрдә,
Калсын тавышым билгегә...

Күңелдә дулаган хисләр, әйтеләсе сүзләр, язылаcы хатлар — һәммәсе-һәммәсе жыр белән, моң белән үргылa. Әнә бит, бүген дә ничек үздерә егетләр, кемнәр беләндер аерылышалар:

Ка-һа-ралы күлмәккәен лә,
ка-һа-ралы яулыккаен шул,
та-һа-гын бер кат ныклап уйлап
ка-һа-рале, жаныкаем...

Бибисалар бүлмәсендә дә жыр тыңлыйлар. Күрәсең, жырның бер сүзе дә игътибарсыз калмый, Бибисаны шаяртып алалар:

— Тәмам үзәгенә үткәнсең бичараның...

— Ул жырлаганын каян беләсең?

— Әһә, тотылдыңмы? Кем турында әйткәнне каян белдең? Үзеннең дә бәгыреңә корт төшә башладымы әллә?

Чыннан да, бу көннәрдә Бибисаның колак төбендә таныш исем яңгырап торды:

— Гыйлфан, туп уйнарга чык!

— Гыйлфан-аанни... фан... фаанн!

Яфракларына сары ингән каеннарны аралап, тар сукмак сузыла. Сукмак буйлап икәү бер-берсенә каршы атлый. Каеннар арасыннан аларны кояш күзәтә. Бүген генә түгел, кояш аларны туган көннәреннән бирле күзәтә. Кызның толымнарын алтынсу нурга мана, күзләренә йөз төрле төс өсти. Гомерләр узу белән кояш сүрәнрәк карыймы — чәчләргә конгырт, күзләргә соры төс ингән. Бу үзгәрешне бүген генә күргәндәй, кояш каен артына посып, карап тора. Тегеләр акрын гына бер-берсенә каршы киләләр. Бер-берсенә карашып, тукталып калалар. Кыз, хәлсезләнгәндәй, янындагы каенга таяна. Егет кызның чәчләрен, битен сыйпый, керфеген, маңгаен үбә. Күз карашы белән генә, күңе-

ле белән генә үбә. Кояш үпкәнен күреп, көнләшүдән аңарда шундый теләк туа. Теләк әле ул чынбарлык түгел. Әмма чынбарлыкка бик якын. Африка ярларыдай кипкән иреннәрен кузгатырга гына куркып тора егет. Кузгата калса, чәчрәп кан чыгар төсле. Алар сихерләнгәндәй бер-беренә карашып, хәрәкәтсез торалар. Ике күзләре талганчы... Кыз карашын читкә ала. Тирә-якта алтын тәңкәдәй сары чәчәкләр. Янәшә китсәң, табигатьнең бу зиннәтләре тапталачак. Кыз кире борылырга уйлады, ахры, сындай торган җиреннән хәрәкәткә килде. Юк, борылмады, ике кулы белән егетнең яңакларына орынды. Кайнар, кызган авыл миче кебек. Кызга салкын. Куллары чак кына дерелди. Тыштан туңып кергәч, кулны, битне мич яңагына тидереп тору нинди рәхәт була...

— Мич янында эссе, китик...

— Әйдә...

— Кулың нинди көчле...

— Ә синең кулың йомшак... Мин аларны гомергә шулай нәфис килеш саклармын.

— Мин дә... Тәрәзәдән кеше күрер, китик...

— Ут сүнгән бит.

— Барыбер... Җил өрә...

Егет кызны күтәреп ала.

— Сулышың кайнар.

— Синең дә.

— Мин гомергә сине генә яратырмын...

— Мин дә...

— Безнең бәләкәй генә өебез булыр.

... Әллә кайда, бик еракта, хыялда калган сөйләшү... Хыялның үткәндә калганы да була. Киләчәкне көтеп, үткәндә яши ул. Алтынга манчылган каенлыкта очраштырган сукмак буйлап, шул хыялның бу икәүне эзләп килүе түгелме? Кояш сурәтенә кереп, читтән күзәтеп торган була.

Каенга таянган кулын кире алганда, Бибиса килгән ягына борылмакчы иде. Хуҗасын тыңламастан, кул Гыйлфанның кибеп кутшаклангап ирене тирәсендә тукталды. Гыйлфан иренен сак кына кыймылдатып, Бибисаның бармак очларын үпте. Тагын бер секунд шул рәвештә калсаң, соң булачак. Бибиса кискен борылды.

— Китик...

Гыйлфан, юлын югалткандай, аяк астындагы сукмакка карап, Бибиса артыннан атлый. Юл торак бинасы ягына борылгач, Гыйлфан читкә суклыгып[1] калды. Бибиса артына әйләнеп карамады.

Ял сезоны тәмамланып килгәндә белдерүләр тактасына зур хәрефләр белән язылган игълан элделәр: «Лекция. Медицина фәннәре кандидаты Г. С. Кылычбаев...» Темасына да, лекторның исеменә дә әллә ни игътибар бирмәделәр. Иң мөһиме: фәннәр кандидаты, сәламәтлек саклауга кагылышлы.

Кичке җидедә кино залы халык белән тулды. Тел бистәсе массовик трибуна артына басып, ни булачагы турында кабат белдерү ясады. Аннары Бибисаның якташы чыгып, микрофонга өреп карады. Бүлмәдәшләре Бибисага ым кактылар, төрткәләп тә алдылар:

— Безнең «Фан-Фан» микрофонда разбираться итә икән, монтер, мөгаен.

«Монтер» көр тавыш белән сөйләп тә китте. Бибиса аның сүзләренең мәгънәсен аңларлык хәлдә түгел иде, башы «чеңн» итеп куйды

[1] Суклыгып (диалект) — кереп, тайпылып.

да, туктаусыз зеңләп тора башлады. Ни күргәнен, ни ишеткәнен белештерми шактый утыргач, сөйләүченең сүзен-сүзгә ялгап, мәгънәсенә төшенгәндәй итте.

Гыйлфанны һәм аны иптәшләрен ерак илгә җибәрер өчен институтның икенче курсыннан ук әзерли башлаганнар. Чит телләр өйрәнү. Гарәп телен үзләштерү. Спорт. Төрле шартларга чыдарлык итеп чыныктырганнар үзләрен. Шуңа да карамастан, Африка табигатенә ярашып китә алмаганнар. Эсселек хәлне алган. Ул илнең табигать шартларына гына түгел, ашау-эчүенә дә озаклап күнегү кирәк. Пешкән икмәк, ит ризыгы турында хыялланырга гына кала. Җирле халык медицинаның көченә ышанмый, хәтта курка. Бәндәне җиргә ходай вакытлыча җибәргән, вакыты чыккач, кире чакыртып ала дип фикер йөртәләр. Аларча, авыруны терелтергә азаплану ходай кодрәтенә каршы килү була. Авыруга бүтән кешенең канын бирү олы гөнаһ исәпләнә. Бәндәләрнең каннарын буташтырырга ярамый. Кан биргән бәндәнең җаны бүлгәләнә, кан алган бәндәгә төрле кеше сыйфатлары керә, ул сыйфатлар үзара сугышып яшиләр. Ә сырхау бәндә бары тик сугыш-ызгыш мәйданы булып җан асрый...

Фәннәр кандидаты Гыйлфан Кылычбаев, өстәл янында әңгәмә коргандай, җай гына сөйли. Залдагы халык аны Бибиса кебек үк хәйран калып тыңлый. Таныш булмаган илдәге гаҗәп хәлләр турында сөйләгән өчен генә дә түгел. Сөйләүче алар өчен гүя күз алдында бүтән сурәткә кергән тылсым иясе. Туп тибеп йөрүче «Фан-Фан» менә кем булып чыкты.

Гыйлфан ерак илдән алган тәэсирләре белән бүлешүендә дәвам итә.

Кырык-илле яшьлек бай гарәпләр унбер-унике яшьлек кызларны дүртенче, бишенче хатынлыкка алалар икән ул илдә. Бу кыз балалар бик авыр бәбәйли, үлем чигендә булсалар да, аларны ир-ат врачка күрсәтмиләр. Шуны искә алып, чит илгә чыккан совет врачлары арасында хатын-кызлар да була.

Бер заман бәби көтүче гаиләдән совет врачларын чакырып килэләр. Авыр очрак булырга тиеш, анда халык юкка-барга врачка мөрәҗәгать итми. Акушерканы алып, Гыйлфан шофер сыйфатында бара. Институтны яңа тәмамлаган яшь врач ханым балчык өй эченә кереп китә, Гыйлфан машина янында кала, ир-атка анда керергә ярамый. Утыра көтеп. Ярты сәгать уза, бер сәгать — кереп киткән врач юк. Тәвәккәлләп, Гыйлфан да эчкә керә. Ни күрсен, ишек янында акушеркасы һуштан язып ята, игътибар итүче дә юк. Уколлар биреп, Гыйлфан аны көч-хәл белән һушына китерә. Исенә килгән врач түр якка, чаршау артына ымлый. Доктор чаршауны ачып караса, анда бер кыз асылынган. Көтелмәгән хәлдән доктор бер мәлгә хәрәкәтсез кала, ул арада асылынган гәүдәнең аяклары тыпырчынып ала. Тере! Гыйлфан ярдәмгә ташлана, әмма ике хатын аның юлын бүлә. Бигрәк тә берсе докторга ана арыслангай ташлана. Икенчесе асылынган кызның ике аягыннан тарта башлый. Шунда гына Гыйлфан эшнең нидә икәнлеген аңлап ала. Бәби табучыны култык астыннан асып куйганнар, аеруча авыр очракларда бәби таптыруның бер ысулы икән бу. Әкәмәт көрәшнең ахырын Гыйлфан күрә алмады, җирле халыкның ихтыярына каршы килергә ярамый, чыгарга туры килде. Ул арада акушерка да үзен кулга алып, эшкә тотынды. Гыйлфан ишек яныннан читкә китми, әледән-әле чаршау артындагыларның хәлләрен белеп тора. Эчтә яңа туган кеше зәгыйфь кенә итеп аваз бирә, бераздан аның тавышы көрәя. Доктор җиңел сулап, машинасы янына китә. Акушерканың хәлен Гыйлфан бик аңлый, үткән атнада гына коллегаларын җирләделәр. Врач ханым өчен ул коллега гына түгел, тормыш иптәше дә иде. Мәрхүмне туган туфракка кайтарып җиткерергә күпме тырышсалар

да, булмады. Үзләре яшәгән дәүләттән рөхсәт алуга нрештеләр, самолет очып утәчәк күрше дәүләт үз күгеннән уздырырга ризалык бирмәде. Баш өстеннән мәет очыру дин буенча катгый тыела икән.

Безнең ватандашлар бу илдә бигрәк тә бөер, бавыр авыруларыннан җәфа чигәләр. Яман чебен тешләсә, канда микроблар барлыкка килә, бөер эштән чыга, буыннарның тотрыгы бетә. Җирле халыкның бу чиргә азмы-күпме иммунитеты бар. Безнекеләрне көчле дарулар белән дә коткарып калып булмый...

Гыйлфанның нинди һөнәр иясе булуы турында Бибиса элек тә белә иде. Армиядән соң медицинскийга укырга китүен ишеткәч, бераз гаҗәпләнсә дә, әллә ни искитәрлек нәрсә күрмәде. Азмыни врачлар: йөрәкне тыңлыйлар, пульсны саныйлар, микстура язып бирәләр... Шуннан арысын Бибиса күз алдына китерми дә, кызыксынмый да иде. Нишләп әле ул бүген гаҗәп-гаҗиз булып утыра? Гыйлфан үзе белән булган кызыклы очрак турында сөйли.

Чит илгә чыгачак белгечләр студент чакларыннан ук үзләре барачак җирнең табигате, үсемлек дөньясы турында мәгълүмат алганнар. Ананас дигән җимешне һәркем татып карамаган, ләкин барысы да диярлек укыган, яисә ишеткән. Африкага килүенә ел тула, Гыйлфанның шул җимешне күргәне юк. Һәр очраган куактан ананас эзли, таба алмый. Кайда үсә ул дип, кешедән сорар иде, аңгыра урыс дию-ләреннән курка. Бер көн шулай ике гарәп белән елан ауларга чыгалар. Елан агуы белән сәүдә итүче гарәпләр була болар. Эре яфраклы биек үсемлекләр арасыннан баралар. Гыйлфан шунда үзе кызыксынган әйбер турында сорый. Гарәп көлә, без хәзер шул ананасны таптап барабыз, ди. Иелә дә, комда үскән үсемлекне йолкып ала. Ананас дигәннәре шикәр чөгендере төсле тамыразык икән. Доктор аны агач башыннан эзләп йөргән. Халык көлешеп алды.

Тыңлаучылар лектор белән бергә ерак Африка илләренә сәяхәт кылдылар. Ул сүзен тәмамлагач, Бибиса да, туган иленә кайтып төшкән мөсафир кебек, җиңел сулап куйды.

Уң ятакка авыру китерделәр. Шундук аның тирәсендә ыгы-зыгы башланды. Бибиса белән ике арага ак пәрдә тарттылар. Кемнедер ашыктырдылар, кемнедер таптырдылар, бүлмәдәге аппаратларны урыннан-урынга дөбердәтеп күчерделәр. Беравык барысы да хәрәкәтсез торды. Әле генә тыз-быз килүче ак халатлылар акрын гына таралышты.

Бибиса онытылып яткан җиреннән кинәт уянып китте. Караңгы. Теге бүлмәдә шыпырт кына кемнедер орышалар.

— Үз аягы белән йөргән авыруларны без монда тотмыйбыз.

Баш врач урынбасары. Урта ишек каршына басып торган сестрага дәшә:

— Хәзер үк кайтып китсен.

Егете өчен агуланган кыз тавышы:

— Минем киемнәрем юк...

— Телефоннан соратыгыз.

— Өйдә телефон юк.

— Тәрәзә янына кем килгән иде, кем белән сөйләштегез?

— Бер егет...

— Өегезне беләме?

— Белә...

— Лена! (Сестрага эндәшә.) Егете китмәгәндер әле, бар чыгып әйт, килеп алсыннар кызларын!

Врач чыгып китте. Тирә-як тынып калды.

Агуланган кызның егете тәрәзәгә килгән, димәк, татулашканнар дип, Бибиса сөенеп куйды.

Көтмәгәндә сул як күршесенең телгә килүеннән Бибиса дертләп китте:

— Шул шифалы суыгызны бер генә йотыймчы...

Хатынның стаканнан су эчкәне бар, димәк, рөхсәт итәләр.

— Эчә генә күрегез, хет шешәсе белән.

Ләкин ничек бирергә, караватлар арасы шактый ерак, Бибисаның сул кулын «җан сакчысы» тоткан. Сул кабыргасына борылып, күршесенә Бибиса сулы шешә сузды. Хатын караваттан төшәргә житешеп үрелә, әмма уңышсыз. Ярдәмгә чакырып карыйлар, сестра чыгып киткән...

— Тукта, хәзер болай итәбез...

Шешә авызын Бибиса пластмасс бөке белән ябып маташканда, күрше хатын кипшенгән иреннәрен ялап-ялап ала. Хәзер шешәнең төбеннән тотып сузарга була. Ара шактый якыная. Тагын аз гына үрелсә... Булды. Хатын шешә авызыннан голт-голт итеп шифалы су эчә.

— Аh, рәхмәт... Сез эчкәндә кулыгыздан тартып алырдай булып яттым...

Әлеге эшне башкарып чыгу Бибисаны бик арытты. Аның бер җире дә авыртмый, «җан сакчысы» сызлатмый торган даруларны туктаусыз тамыза. Бик нык арудан кан белән тәнне аеру читенләшә.

Бибиса өшеп уянды. Уң яктан чаршауны алганнар, карават буш. Ак чаршау хәзер сул якта. Салкын тынлык. Караңгы. Урта бүлемнән тоныкк кына электр яктысы төшә. Өстәлгә башын салып, сестра черем итә. Бибисаның тәне шыбыр су, күлмәге юеш, шуңа күрә туңа. Төнлә, әлбәттә, алмаш күлмәк табалмаслар, салып киптерәсе иде. Шәфкать туташы кызганыч, аз гына ял итсен инде. Кеше уянганны ишетте, ахрысы, күзен сөрткәләп, ул да кузгалды. Чакырмаган килеш, Бибиса янына килде.

— Туңасызмыни? Хәзер тагын бер юрган ябам...

Бибиса юеш күлмәк хакында сүз чыгармады. Ике кат юрган астында тән жылысы белән кибәр әле. Күлмәкне салдырыр өчен веносекцияне ычкындырырга кирәк, энәсен кабат кан юлына кадарга, мәшәкать...

— Сез тыныч кына ял итегез, мин хәзер санитарканы чакырып киләм...

Сестра чыгып югалды. Нишләп шул чаклы озак йөри? Пәрдә артындагы күршесе йоклый микән? Хәле авырайгандыр, югыйсә, арага чаршау кормаслар иде. Шулай уйлавы булды, санитарка чакыру белән пәрдә артындагы тынлык арасында бәйләнеш барлыгын абайлады. Салкын аның сөякләренә чаклы үтеп керде.

Халат өстеннән сырма кигән, башына чуклы шәл бөркәнгән санитарканы ияртеп, Лена керде. Тегесенең йокысы бүленгәндер, кәефсез.

— Кая бүтәннәр?

— Хәзер килерләр.

Санитарка белән сестра урта бүлемдә утыралар, көткән кешеләре юк. Ниһаять, шулай ук җылы киенгән тагын берсе керде. Ул да шул ук сорауны бирде. Көттереп өенче хатын керде дә, кемнедер ачулана башлады:

— Төнлә моргка барырга куркам ди, килми.

— Яктырганчырак ятсын иде, мин дә куркам...

Сестра килешми:

— Юк, калдырырга ярамый, болай да ике сәгатьтән артык ята.

Палатада ут яндырмый гына, Бибисаның сул як күршесе янына килделәр. Нәрсәдер лапылдады. Иске одеалның дүрт почмагын өч итеп тоткан килеш, санитаркалар гәүдәне кадерсез генә күтәреп чыгып киттеләр.

Бибиса таң атканчы күзен йоммады, дерелдәп, туңып чыкты.

4

Бибисаны өзеп ташлаган бәрәңге шытымы хәлендә күрү Гыйлфанны миңгерәйтеп җибәргәндәй булды. Ни өчен аның иң якын кешеләренә бәйләнде бу чир? Гыйлфан аңа каршы көрәшкә чыккан өченме? Җиңүче булып, тантана итәргәме? Рак — күзәнәкләр фетнәсе. Тыелып торган күзәнәкләр бер заман ни сәбәптәндер үзләренең хуҗаларына каршы баш күтәрәләр. Буйсынудан чыккан фетнәчеләр позиция артыннан позиция яулыйлар. Хирург аларны кисеп атса да, яшәү белән үлем арасында көрәш дәвам итә генә түгел, тагын да кискенләшә. Чөнки анда бер, монда бер фетнәче качып кала, яңабаштан көч туплый. Йомшарган организм аларга тиз бирешә. Кеше әгәр якын арада аяктан егылмаган икән, димәк, качкын фетнәчеләр көч туплый алмаган.

Гыйлфан кайда гына йөрмәсен, Бибиса аның өчен югалмаска тиеш иде. Һәм югалмаган да. Эзләп тапкач, күз алдында югалуы мөмкин дигән уй белән Гыйлфанның килешәсе килми. Хыялында алып киткән авыл кызына ул солдат походлары, диңгез арты кыйтгалары аша якынайды. Дәрья-күлдә очраткач, мәңгелеккә тапкан шикелле булды. Дөрес, элегрәк, Амур буенда сакта торган чакларын исәпләмәгәндә, Бибиса турында еш уйламаган сыман иде. Баксаң, яшьлек мәхәббәте бервакытта да аның күңеленнән чыгып тормаган икән. Фәнни эш дип тә, дәвалау практикасы дип тә түгел, «Яшьләргә» ул Бибиса янына дип килде. Фән үзәгеннән качып, фәнни эшкә киләләрме? Гистология[1] бирдә үткәрелми, авыруның зарарланган урыныннан тукыма кисәкчеге алып, Казанга җибәрәләр. Анализ әйләнеп кайтканчы кадерле вакыт уза. Шәһәрнен үзендә лаборатория эшен җайга салмыйча, мәкерле чир белән көрәштә уңышка ирешү кыен булачак.

5

Бибисаны реанимация бүлегеннән югары катка, хирургия бүлегенә мендерделәр. Операциядән соң бүген сигезенче тәүлек, авыру инде аягына басты. Аллаяров дежур сестра өстәле янында утыра иде, үз күзләренә ышанмады. Ал бумази халат кигән, ак яулык бәйләгән таныш сыман кыз яңа йөрергә өйрәнгән бала кебек бу якка атлый. Өстәл янына килеп җиткәч кенә таныды: Сабанаева бит бу! Юка гына, кечкенә генә калган. Операциягә чаклы авырлыгы кырык сигез килограмм иде, хәзер кырыктан артык түгелдер. Маңгаена, борын очына сәйлән кебек бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан, атлавы бик җиңел түгелдер. Аллаяровның беренче теләге — авыруны күтәреп, караваткаилтеп салу булды, ләкин урыныннан кузгалмады. Сорауны да җайсыз бирде сыман:

— Башыгыз бик әйләнмиме?

— Юк. Бөтенләй әйләнми.

Сабанаеваның кулында сөлге, йөзе чиксез шат, әйтерсең сабантуйда җиңеп алган. Башы, чыннан да, тамчы да әйләнми, тик аяк табанына йөзләрчә энә кадалган кебек. Аңарда хәзер бер генә теләк: урынына барып җитәргә дә, тизрәк караватка сузылып ятарга. Артын-

[1] Гистология (лат.) — тән тукымасы анализы.

нан Аллаяров карап тора. Бибисаның хирург алдында сынатасы килми, стенага тотынмый гына барып җитәсе килә. Ирешге теләгенә, караватына барып җитте. Хәзер ял итәргә була. Аягына баса алуга ышану кыйммәт аңа, калганы акрынлап яуланыр. Каршы стена ягында яткан хатын Бибисаның исән-имин йөреп кайтуына сөенде:

— Киттең дә югалдың, башы әйләнеп егылмады микән дип кайгырыплар ятам, үземнең торырга җай юк... Ялгызың киттең бит, берәрсен ияртмәдең иптәшкә...

— Палатада кеше юк бит, апа.

— Әйе шул, уч иткәндәй, әллә кая качышып беттеләр.

Нигә качышканнарын Бибиса белә. Палаталарына яман авыру кергәнгә курыкканнар. Операциягә чаклы ул шушы бүлмәдә ятты. Элекке авырулардан берәү генә калган, бүтәннәре яңа. Каталка белән кемне алып килгәннәрен, әлбәттә, теге иске таныш әйткән. Бибисаны кертеп яткырганда, күрше караватта бер кыз утыра иде. Бибиса аны үзе белән юынгычка барырга чакырып карады. Мин сиңа тотынмам, янәшә генә барырсың, диде. Кызның йөзе агарынып, бүлмәдән чыгып ук китте. Бибиса аңа рәнҗемәде. Куркыр да шул, яшь бит әле. Ә менә операциягә чаклы ук таныш хатынга рәнҗегәндәй итте. Аңа да нык ачуланмады. Тора-йөри алмас, палатаның һавасын бозып ятыр дип курыккандыр. Үзенең андый түгеллеген исбат итәргә теләп торып китте Бибиса.

Аның каравы, Аллаяров үтә игътибарлы. Баштарак Бибисаның аңа кечтек кенә үпкәсе бар иде, анысы да күптән онытылды. Аягына басу шатлыгына ирешкәч, Аллаяровны ул алла итеп күрә башлады. Бугазыннан газраил килеп буган иде бит, котылыр әмәл юк иде, шушы ак халатлы кеше аралап калды.

Дежур врач бүген Гыйлфан. Кич белән, коридорлар тынып калгач, яшь белгеч Бибисалар палатасына керде. Бер очрашырга кирәк ләбаса. Икесе дә үзләрен күптән түгел очрашкан сыман тоттылар. Бибиса Гыйлфанның биредә икәнен белә, палатаның ачык ишеге каршыннан узып йөргәнен әллә ничә күрде. Реанимация бүлегенә кергән кара күзлекле доктор, әлбәттә, ул булган.

— Терелеп буламы, Бибиса?

— Терeләм, Гыйлфан. Сезнең ярдәм белән.

Бибисаның шундый шат чагын моңарчы кем күргән икән? Булмагандыр андый хәл. Йөзе балкып, бит алмалары алсуланып киткән. Гыйлфан аңа карап, тәэсирләнеп тора.

— Кызганычка каршы, минем ярдәм тия алмады.

— Медицинаның ярдәме тиде.

— Шулай дисәң инде.

Гыйлфан Бибисаның аяк очына, караватка утыра. Болай иркенләбрәк сөйләшергә була.

— Салихҗан абзый исәнме? Синең агаең? Исән-саумы?

Гыйлфанның йөзеннән кан качкандай булды. Нигә сораша Бибиса аның турында, берәр нәрсә ишеткәнме? Гыйлфанның җавапсыз утыруын Бибиса әллә уңайга юрады, әллә күңелсезлек булганын сизде, бүтән сорашмады, үз сүзен дәвам итте:

— Ул бит мине теге вакытта Кашкар малае кебек чанага салып алып китмәкче иде. Син кулдан тоттың, ул аяктан... Чәбәләнә торгач, нык кына типкәнмен, борыны канады. — Бибиса авызын тотып кына көлеп куйды. — Миңа ачуланасын абыең синә ачуланды, кыз кирәксә, үзең алып кайт, диде дә, кулын селтәп китте...

Бибисага ияреп, Гыйлфан да елмая. Ул вакыйгалар әйтерсең күңелле сабый чак уены гына булган. Бибиса хәзер бөтен нәрсәне матур

итеп күрә. Кайчандыр ике арада булган аңлашылмаучылык та сабыйлык галәмәте генә, андый әкәмәтләр булмаса, ни турында көлеп сөйләр иден? Гыйлфан да, ачылып китеп, бер-ике мәзәк сөйләп алды. Бибисаның акрын гына сөйләвен тыңлыйсылары килепме, авырулар тынып калган иде, икесе арасында бернинди сер юклыгын сиздерер өчен, доктор һәммәсенә ишетелерлек итеп сөйләп китте:

— Авырулар кызык икән монда, операцияне чүпкә дә санамыйлар. Кичә ике авыруга операция ясарга тиеш идем, берсе белән эшне бетердем, икенчесе юк та юк. Палаталардан, коридорлардан эзлиләр, таба алмыйлар. Ә миңа ярты сәгатьтән поликлиникага приемга барырга кирәк. Чишенеп ташлар идең, авыру табылыр да, операциягә яңабаштан әзерләнәсе булыр. Аллеяләр буйлап гулять итеп йөргән җиреннән тотып китерделәр. Син аны дерелдәп караватында утырадыр дип уйлыйсың, ә ул хозурланып бакчада йөри. Ә үткән дежурствода ике көн элек кенә аппендиксын кискән авыру юкка чыкты. Дару бирергә эзлибез, таба алмыйбыз. Больница киеме белән хатыны янына кайтып киткән, төн уртасында өеннән алып килдек, мультфильм карап утыра.

Палатадагы авырулар сызланудан түгел, көлүдән җәфа чигәләр. Менә әле дә кичә генә операциядән чыккан кыз, эчен тотып, үксегән сыман итте:

— Ай, ой, уфф... Үләм, көлдермәгез зинһар!..

— Бетте, бетте! Мин алай көлке булыр дип уйламаган идем.

Доктор Бибиса янышнан китеп, бик җитди кыяфәт белән авыруларны карый башлады. Һәрберсенең җанына кереп сөйләшә. Кайсының пульсын саный, кайсының юрганын ачып, операция урынын тикшерә. «Ә минем пульсны санамады», дип уйлап куйды Бибиса, көнләшәсе килеп. Ләкин көнләшмәскә булды, докторның бу кыланышын үзе өчен яхшыга юрады: димәк, бүтәннәр белән бер рәткә куймый.

Бибиса инде фойега чыгып, кәнәфидә утыра, юынгычка барып, кул-аяклары белән гимнастика ясый. Аны хәзер әллә нинди каты авыру дип исәпләүче дә юк. Узган-барганда хәл белергә кергән Варис Руслановичның сынап һәм гаҗәпсенеп каравы гына Бибисаны сагайткандай итә. Әмма куркытмый. Гыйлфан да монда булгач, терелә дә терелә инде Бибиса. Гыйлфан бит табигатьнең әллә нинди серләрен белә. Кичә Сакмарова кереп утырган иде. Вак-төякне зурга әйләндерүче, ул да Бибисаның савыгуына шикләнүен сиздермәде. Ә артистларда сизелде. Тормышта уйный белмиләр алар. Сәхнәдә уйнаган да җиткән диләр, ахры.

Өч атна дигәндә Сабанаеваны шифаханәдән чыгарып, Казанга дәваларга җибәрергә булдылар. Анда махсус клиника, зур белгечләр... Казанга икән, Казанга, Бибиса Әскәрне күрәчәк. Операция турында ул бала әле берни белми. Бибисаның авырып больницага керүе турында гына белә.

Апрель. Урамда гөрләвекләр аккан эзләр. Нинди якты бу дөнья, нинди саф! Кайтырга ике кварталдан ары түгел, ярый әле, җәяү чыккан. Апасын барып алырга жыенган Әсаф өй баскычыннан төшеп килә иде, аптырашта калды. Кояшлы көнне кышкы пальто кигән, мамык шәл бөркәнгән Бибиса җиңелчә киенгән күрше хатын белән култыклашып, кайтып та житкәннәр. Күршеләре хәл белергә барган икән. Өйгә кереп, әлеге күрше күчтәнәчләре белән чәй эчтеләр. Үз аягы белән үз өенә кайту сөенечен онытасы юк Бибисаның. Әсаф еллык ялын алып килгән, шүрлектән ала да китап укый.

— Әйбәт ял булды бу миңа, — ди пошынмас тавышы белән, бөтен китапханәңне укып чыктым.

Яшьтән үк Әсаф укырга һәвәс булды, мәктәптә яхшы укыды. Аның ун сыйныф белән чикләнеп калганын белгәч, сабакташы бик гаҗәпләнгән иде. Чөнки үзе хәзер математика фәннәре кандидаты, ә мәктәптә алгебра, геометрияне Әсафтан күчерә торган булган. Аның каравы, Әсафның өч баласы, уңган хатыны бар. Урман хуҗалыгында тракторчы-механик. Тормышыннан зарланмый, шәһәрнең бозык һавасын иснәп яшәмәвенә шат.

## Шомырт чәчәк атканда

### I

Берничә көннән Казанга җыенып чыгасы иттеләр. Бибисаның якташы Мәмдүзә күршеләре белән «Жигули» турында сөйләшкән икән, иртәнге алтыда урамны аркылы чыгып, билгеләнгән урынга килеп бастылар. Машина юк иде әле. Берәмләп тә, төркемләп тә эшкә баручылар уза. Ун, унбиш минут үтте, ярты сәгать тә узды, машина юк. «Жигули» хуҗасының телефон номерын әйтеп, Мәмдүзә эшкә йөгерде, Әсаф шалтыратырга кереп китте. Урам себерүчеләр, печән чапкан кебек, себеркеләрен каерып-каерып селтиләр. Берсе Бибиса утырган эскәмиягә якынлашты. Юл сумкаларын калдырып, Бибиса шактый читтәге бүтән эскәмиягә күчте. Ярый сумкалар эскәмия өстендә иде, күтәреп куясы булмады. Әсаф һаман юк. Бибисаның аякларына салкын үтә башлады. Әсафка ни булганын кереп белешер иде, тыкрык ягыннан китсәң, аның урам капкасыннан чыгуы бар, аймылыш булырлар. Әйберләрне дә юл өстендә калдырып китеп булмый, ничаклы батырайса да, Бибиса сумка күтәрә алмый әле. Урам себерүчеләр дә эшләрен бетереп киттеләр. Ниһаять, артык кабаланмый гына Әсаф килеп чыкты.

— Хатыны һаман көттерде, гаражга китте, хәзер кайта, чәй дә эчмәгән, ди.

— Соң?

— Шул киткәннән кайтмады, ди.

— Ә мин инде сиңа йөрәк приступы-мазар булгандыр дип торам...

Уйлаштылар да, Бибисаны әйберләре белән өйгә кертеп, Әсаф такси тотарга автовокзалга йөгерде. Сигез-ун минут дигәндә шакмаклы машина белән выжт итеп ишек төбенә килеп тә туктады. Кузгалдылар. Бибисаның йөрәге әрнеп куйды: башта ук шулай итмичә, кешегә ялынып... Алдан белеп булмый шул, буш таксиларның очрамавы да мөмкин. Башта запас белән чыкканнар иде чыгуын, байтак вакыт узды, самолетка өлгерә алмаслардыр.

Үз рейсларына соңладылар. Артык зыянлы булмады, больница кәгазе тәэсир итте, бәйләнми-нитми, икенче рейс белән очырдылар. Өйдә озак торган өчен Әсафка үпкә сүзләре әйтелмәсә, тагын да яхшырак буласы икән.

Казан аэропортына килеп җиткәч, троллейбуска утырдылар. Аннан соң да шактый ара бар иде, клиникага барып җиткү Бибисага шактый авырга туры килде. Әсафка сиздермәскә тырышты. Болай да әллә нишләп, югалып калган кебек. Урман арасыннан килгән кешегә шәһәр ыгы-зыгысы ят, анда-монда йөгереп, такси тота белми. Акчасы да исәптә, аның әле кайтасы бар. Бибиса исә үз җаена атлый торырга риза, артык борчу гына чыкмасын.

Кремль калкулыгына күтәрелделәр. Бибисаның сулышы кинәет киткәндәй булды. Бу урдә ничәмә-ничә гасыр сугыш-ызгыш барган, дәрья-дәрья кан коелган. Ә ул, әнә, кунак көткән сыман, манараларын акшарлаган да, ялгы кояшта балкып утыра. Җиргә салган хезмәте яшәгәндә Кеше мәнге яшәр. Чал манаралар гүя борынгыларның сыны — ак беләкләрен күккә сузып, тереклеккә мәдхия укый. Зур талантлар, күп корбаннар күргән мәйданга шагыйрь Муса кайтып, һәйкәл булып баскан: жаныңны богаулатма, Кеше, җиңгәнче көрәш!

Кайберәүләр ни хакына, ничек көрәшергә белмиләр. Авыл кызы Бибиса мәйдан эзләп, сәхнәгә менде. Сәнгать ысуллары белән коралланып, битарафлыкка, гайбәткә, ялагайлыкка каршы көрәш ачты. Нәтиҗәсен күрмичә китәргә ярыймы соң...

Кыш башында, гастрольгә чыкмый калган атналарның берсендә, ул Казанга, иҗат командировкасына килгән иде. Яшь драматург белән Кремль тирәли сөйләшеп йөрделәр. Бибиса бүгенге көн героинясын уйныйсы килүе турында әйтте. Юлдашы хәзерге заманда конфликтлар табуның авырлыгын искә алды. Актрисаның ризалашасы килмәде:

— Тормыш, югыйсә, гел каршылыклардан тора. Мәсәлән, минем бер эшем дә шома гына бармый, әллә үзем уңмаган.

— Көндәлек ыгы-зыгы күп тә бит...

— Зур тормыш көндәлек вак-төяктән төзелмимени?

Бүген, тарих сакчысы булып баскан мәһабәт манаралар яныннан узганда, Бибиса шул әңгәмәне исенә төшерде. Язучы үзе белмәгәнгә салыныбрак актрисаның бүгенге сәхнә турындагы уйларын сөйләтергә тырышты.

Караңгы төшкән иде инде, карлы юлда алардан башка кеше күренми.

Акрын йөрүдән Бибиса туңа башлагандай булды, җитди генә сөйләшеп барган җиреннән кинәт кызулап китте, дилбегә кагып, ат куган хәрәкәтләр белән, кычкырып җырлап җибәрде:

Сүс дилбегә, юка чана,
Алып булмый акчага.
Сырхауларга дарулар бар,
Сагнуларга юк чара,
Сагнуларга юк чара,
Бибисара-а-а...

Юлдашы да анардан калышмый, кар ерып, янәшә бара. Аркаларыннан җил этә, кар бөртекләре һавада бөтерелә. Язучы җырның дәвамын көтә.

— Хәтерләмим бугай. Бәләкәй чакта эти мине атка утыртып йөртә иде. Урманга керсә, шушы җырны башлый.

— Хәтерегезгә төшерегез инде...

— Мин бит ул чакта биш-алты гына яшьтә идем.

Бибиса тагын кызурак китте. Авылда чакта кызының шулай кинәт алмашынуына әнисе гаҗәпләнә, бераз исәррәктер син дия иде. Язучы хәзер аның турында ни уйлыйдыр. Уйламагае... Бераз мөңгерәп баргач, артыннан килгән юлдашына Бибиса кинәт йөзе белән борылды.

— Шулайрак иде бугай, кайбер сүзләрен үзем уйлап чыгардым:

Яна күмер, уза гомер,
Узган гомер бичара...
Узган гомер дә ничава,
Бәхетең җуйсаң, ни чара,
Бәхетең җуйсаң, ни чара,
Бибисара-а-а...

Язучы көлеп җибәрде.

— Нигә көләсез?

Тегесе ниндидер ачыш ясагандай, әйтеп салды:

— Мин сезнең өчен роль язачакмын! Сөембикә манарасы шаһит булсын!

Яннарына кеше сукмагы өзелмәгән меңъяшәр таш коймалар икенә күңелгә кагылышлы вәгъдәләргә дә шаһит булганнардыр, тарих борылышын хәл итәрдәй антлар да ишеткәннәрдер. Ул чакта Бибиса каләм остасының сүзләрен сәхнә кешесенә сокланучыларның бер жылы сүзе дип кабул итте. Таш коймалар эченнән бүген ул өн кабат ишетелгәндәй булды. Сөембикә шаһит... Ул өн актриса гомеренең дәвамын вәгъдә итә...

Кирмәннең[1] арткы урамына төшеп, онкология клиникасына килсәләр, мөсафирларны аянычлы хәбәр каршы алды: районнан җибәрелгәннәрне монда кабул итмиләр, республика больницасы яңа бинага, шәһәр читенә күчкән. Савыгып чыгу шатлыгыннан ныклап белешеп килмәгәннәр. Андый-мондый тоткарлык булса, туп-туры Яшьләрдә булып киткән докторга мөрәҗәгать итегез, сезнең хакта ул белә, үзе шулай кушты, дигән иде Аллаяров. Аның исемен дә әйтеп карады Бибиса. Республика клиникасында эшли ул диделәр. Ярый әле, регистратурадагы кыз игътибарлы сөйләште, югыйсә, Бибиса елап җибәрү чигенә җиткән иде.

Бу урамда таксилар бөтенләй йөрмиләр бугай, шома машиналар выжылдап узып кына китәләр. Шулай үрә катып бару Бибисага яхшырактыр да, җиңел машина эченә бөгелеп керәсе була, эче өзелеп авырта башлады. Пычкы белән урталайга кискән сыман. «Эчем өзелә» дип, үзләре кичереп караган кешеләр әйткәндер. Казанның таш урамнары буйлап бик озак баргач, трамвайга керделәр. Халык күп түгел иде, утырыр урыны җайлы. Трамвайдан соң тимер юл аркылы үтәсе булды. Түмгәкләр, чокырлар... Бибисаның маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Җитмәсә, юлда ниндидер таныш очрады. Бибиса аны хәтерләми, аның каравы, теге таный, хәл-әхвәл сораша. Бибисаның сөйләшерлек хәле юк. Ул тирәкләр артында күренгән саргылт бинага барып җитү турында гына хыяллана. Бердәнбер теләге шул. Танышлары ник алдына килеп егылмыйлар, ул аларга тел әйләндереп бер сүз әйтә алмас.

Регистратура тәрәзәсе янында кеше юк иде, тоткарлык булмады. Икенче катка менделәр. Бибиса чират көткән кешеләр рәтенә, иң ахыргы урындыкка терәлде. Теләкнең берсенә ирешкәч, икенчесенә, зуррагына ирешәсе килде. Аякларны сузып ятарга иде хәзер... Кайсы игелекле бәндәнең эше булгандыр, Бибисаны чиратсыз чакырып алдылар. Өстәл артында яшь кенә хатын-кыз утыра, башлыгыннан чыккан чал чәче ап-ак киеменә ятышып тора. Врач ханым ассистентны чакырырга кушты. Ир-ат керде, Сабанаеваның кәгазьләре белән таныштыы.

— Үзегезне шул дәрәҗәгә җиткергәнсез, ә?

Яратып кына әрләве. Каты бәрелми. Бибисаның хәтта көче арткандай булды. Тагын бер ак халатлы мөлаем хатын керде. Бусы Бибисаны бирәдә күрүенә чиктән тыш бәхетле сыман елмая.

— Сезне якыннан күрер көн дә бар икән!

Бибиса аны танымыйрак карый. Мондый шифаханәләрдә эшләүче халыкның ачык чырайлы булуына ул баягы клиникага кергәч үк игътибар иткән иде.

[1] Кирмән — крепость.

— Сез уйнаган спектакльләрне калдырмый карап барам мин. Казанга сирәк киләсез. Кызым сезнең өчен үлә инде, бер спектаклегезне икешәр-өчәр кат карый.

Кызы быел тугызынчыда укый икән. Балалар турында сөйләшеп киттеләр. Бибиса үзенең сырхау икәнлеген оныта язды.

— Ике урынлы бер генә бүлмәбез бар, сезне шунда урнаштырабыз. Тыныч булыр. Энегез яныгызга тоткарлыксыз керер. Ул яктан бездә иркенлек, шәһәр чите. Бераз хәл алгач, һавага чыгарсыз, шомыртларыбыз чәчәккә бөреләнгән, быел яз иртә килде, шомырт иртә чәчәк атачак.

Зөбәйдә Вәлиевна күптәнге танышын очраткан сыман култыклап алып, сөйләнә-сөйләнә Бибисаны кием алыштыру бүлмәсенә озатты. Бөтен больницага бер дорфа кеше булса, ул — авыруларны кабул иткәндә анкета тутыручы хатын. Гаиләсендә бәхетсездер бу, дип уйлады Бибиса, аңа ияреп ярсып китмәде. Ачуы килсә дә, хәзер кая барсын?

Әсаф Әскәрне эзли китте. Аңа күренгәнче Бибисаның бераз хәл аласы килә иде, бүген килеп йөрмәскә кушты.

Билгеләнгән палатага кереп, караватка ятуга ук галәмәт авырттыра торган укол кададылар. Бу көнне Бибиса әллә уяу булды, әллә саташты. Аркасының нәкъ үзәге кыздырылган тимер баскан кебек янып сызлый башлый да, юан тимер келәшчә белән күкрәк читлеген кысып ала. Кычкырсаң, үкерсәң дә ул келәшчәдән котылып булмый. Күпмедер газаплангач, беразга җибәрә. Аннары тагын җәзалау башлана.

Янәшә караватта бүген генә операциядән чыккан авыру ята. Янында ак халатлы ир-ат утыра. Ире булыр. Бибиса аларны журнал битләрендә күргәндәй генә күреп кала. Ыңгырашмаска иде, ак мендәргә ташланып чалкан ятучы хатынга тынычлык кирәк.

Икенче көнне дә Бибиса саф һавага чыга алмады. Арка-күкрәге сызлау кимемәде, укшытты. Энеләре килгәндә Бибиса бераз гына тынычланып, караватта утырып тора иде. Ак халаты астыннан Әскәрнең курсант формасы күренеп тора. Ул аңарга оялгандай итеп, капларга тырыша. Бибиса аның укуы, тулай торак хәлләре турында сораша. Әскәр исә монда нинди азык бирүләре белән кызыксына, ни алып килергә дип сорый. Әсаф иртәгә Казаннан туры авылга ук кайтып китәчәк иде, хушлаштылар. Бибиса әйтеп калды:

— Май бәйрәменә Әскәр белән кайтырбыз, бу арада гына мәшәкатьләнеп, килеп йөрмәгез.

— Әскәрне кайтармасалар, хәбәр итегез, Әсфирә килер.

Сеңелләре Әсфирәнең үз гаиләсе, йорт-җире, хуҗалыгы бар. Май аенда бакча эше башлана. Гомумән, авыл җирендә тавык чүпләсә дә эш бетәрлек түгел. Килер җае булмаса, Әсфирәне дә бик кыстамаска кушты Бибиса. «Кемгә игелек күрсәткәнем бар, ә кешегә ничаклы борчу салдым», дип уйлады үзе турында. Тагын да күбрәк мәшәкать ясамас өчен савыгырга кирәк.

## 2

Кылычбаев Яшьләрдән үк шалтыратып Бибисаның хәле турында дәвалаучы врачтан сорашты, дәвалауның беренче курсы тәмамланганын белде. Казанга килгәч, авыруның соңгы рентген күрсәткечләре, кан анализлары белән танышты. Кан күренеше аны сөендермәде. Иң хәвефлесе — бавыр бераз шешенке, үт юлы ачык күренми, ни беләндер капланган. Шундый операциядән соң ни белән икәнлеген чамаларга була. Гомумән, күрсәткечләрдә күңелле әйбер аз. Зәгыйфь организмны химиотерапия белән агуларга күңеленнән Гыйлфан башта ук кар-

шы иде, әмма бүтән сыналган ысул тәкъдим итә алмаганлыктан, дәшми калды. Чит илдә чагында ул күнеләнә кереп калган бер ысулны бела сыман, ләкин ныклап сынап карамаган, кеше өстендә тәҗрибә ясарга аңа беркем дә рөхсәт итмәс, үзе дә андый юлга басмаячак. Үз абыйсында сынап карарга да тәвәккәлли алмады, сыналган химнотерапия белән дәвалап, абыйсының гомерен шактый озайтты. Бибиса исә Аллаяровның авыруы. Хәтта Аллаяровныкы гына да түгел. Яшьләргә онкологлар киңәшмәсенә баргач, республика клиникасының дәрәҗәле һәм тәҗрибәле белгече Сабанаеваның авыру тарихы белән таныштты, теккән җәрәхәте төзәлү белән үз больницасына җибәрергә кушты. Менә хәзер шул дәвалауның нәтиҗәсе. Алда ни буласын әлегә төгәл әйтүе кыен. Қанга үт таралу әйбәт фал түгел...

Килгән чагында Бибиса бу бинадан исән чыгуына бик үк өметләнмәгән иде. Бүген аны каршы алырга бәйрәмчә киенеп килгәннәр. Күз агы саргаюның хәтәр нәрсә икәнлеген ул врачларның карашларыннан сизә, әмма төшенкелеккә бирелмәскә тырыша. Менә алар зәңгәр күктә ак болытлар өстеннән очалар. Түгәрәк тәрәзә артында күз камаштыргыч кояш. И, якты дөнья, нинди кадерле син! Үпкәләшү, әрләшүләр, дан, дәрәҗә, байлык — синең бөеклегең алдында тузан бөртеге чаклы да юк. Гомереңбеткәннән соң яңадан бер ай яшәвең дә бәхет... Самолет җиргә кунды. Тирә-як ямь-яшел. И, зифа каен, сиңа таянып бер кычкырып җырлар өчен әлләниләр бирерлек!..

Җиңел машина Бибисалар өе янына килеп туктагач, Гыйлфан, хушлашып, ары китте. Бибиса аны өйгә керергә кыстамады, мона чаклы дөньяда барын-югын да сизмәгәндәй йөреп, авыргач кына чакыра башлауны килештермәде. Бераз ямансу булып китте. Дөньяның яме Гыйлфан киткәннән генә тоныкланмагандыр ла? Аның шушы шәһәрдә яшәвенә, теләсә кайчан очрашырга мөмкин булуына Бибиса әле булса күнегеп җитә алмый.

Җиңү көнендә Бибиса зур кара күзлек киеп, мәйданга чыкты. Күргән-белгән кеше бу килеш аны танымый.

Ленин һәйкәле яныннан сафка тезелеп, сугыш ветераннары уза. Күкрәкләре тулы орден-медальләр. Иң алда хатын-кызлар. Унсигез яшьләрендә фронтка киткәннәр... Мәктәп балалары ветераннарга кызыл чәчәкләр бүләк итә. Яклап, саклап калуыгыз өчен рәхмәт сезгә, рәхмәт!.. Хатыннарның барысы да диярлек киң түшлеләр, гәүдәгә калыннар. Алда, сул яктагысы зифа гәүдәле. Яшел гимнастерка түшендә медальләр... Баш түбәсенә өелгән куе кара чәче... Бибиса аның Сакмарова икәнлеген абайлады, танымасын дип, кешеләр артына посты.

Ветераннардан соң призывниклар артык яшь, сабый булып күренәләр. Ә бит бүгенге карт солдатлар да нәкъ шушы яшьләрендә утлы мәхшәргә барып кергәннәр. Кичәге үсмерләр иртәгә ил сакчылары. Ил язмышын халык шуларга ышанып тапшыра. Командага атлаганда алар әле буталып куялар, аяк белән кулны бергә күтәрүчеләр дә бар. Көлмәгез, ирләр, көлмәгез, хәлиткеч минутта ялгыш адым ясамаслар.

Хәрби часть узганда мәйдандагы һәр кешенең тәне чымырдап куйгандыр. Адымнар тигез, миллиметрына чаклы исәпләнгән. Буйлары кыркып кискән кебек. Күн итекләр таш юлга сәгать секунды сыман төгәл төшә: чек-чек... Ирексездән алда узган үсмерләрне уйлыйсың: мондый төгәллеккә ирешер өчен күпме күнегү үтәселәре бар... Ә ветераннар... Алар да кайчандыр шушындый корыч ташкын булганнар. Хәзер исә хәрби комиссарның сәламләвенә бер авыздан җавап әйтә алмыйлар, гүя һәрберсе аерым җавап кайтара.

Бибиса Әскәрне уйлап, горурланып куйды. Берне булса да, ил сакчысы үстерде. Бибисаның сакчысы бар. Ул да бүген үз сафы белән бергә атлыйдыр.

Халык билгесез солдат һәйкәле янына агылды. Дәррәү дулкынга Бибиса ияр алмады, арыган иде. Һәйкәл янына ул соңыннан, мәйдан бушагач барачак. Солдат истәлегенә куячак гөле тәрәзә төбендә чәчәк атып утыра.

Иртән тору белән Бибиса көзгегә карый. Көн саен шулай. Күзендә-йөзендә сары кимеми, хәтта арткан кебек. Кич эштән кайтышлый Мәмдүзә кереп йөри, якташы өчен азык-төлек хәстәрли. Аның үз эше дә житәрлек, шәһәр читендә бакчасы бар, атнага бер кереп, хәл белсәң, шул житәр, ди аңа Бибиса.

— Шулай итәргә туры килер әле. Гыйлфанны күргән идем, сине үзе килеп дәваламакчы. Имче карт кебек сөйләшә, шифалы дарулар таптым ди. Аның дәү әнисе мәрхүмә шифалы үләннәр белән дәвалары, йөзәр чакрымнан эзләп килерләрие үзен.

— Шулай да кызын савыктыралмаган. Гыйлфанның әнисен әйтәм, бик яшьли вафат булган бит.

— Ирен урман караклары кыйнагач, сарыга сабышты диләр аны. Үз каныма шифам ярамый дип әйткән ди анасы мәрхүмә. Оныгын да үләннәр белән генә алып калган бит, бәләкәй чагында Гыйлфан бик каты чирләгән икән.

Кухня өстәле янында утырган Бибиса, башын учына салып, уйга батты. Мәмдүзәнең кулында савыт-саба шылтыравы тынгач, сорап куйды:

— Безнекеләр күренмиме?

— Директорыгызны очраткан идем. Артистлар өч айга Чиләбе ягына чыгып киткәннәр. Сине сораша, кайчан эшкә чыга, ди.

— Алай сорашкач, рәхмәт инде...

Директорның да хәленә керергә кирәк. План куып, артистларга ял бирми икән, моны бит ул үз мәнфәгате өчен эшләми, аның өстеннән дә житәкчеләр бар, таләп итәләр.

Шәһәрдә ялгыз калуына Бибиса шат. Хәстә килеш иптәшләренә күренәсе килми. Ул хәзер киерелгән кыл сыман, аз гына чиртсәләр дә, сыкрау тавышы чыгарыр сыман. Хәсрәтен кешегә күрсәтмичә, көч жыясы килә Бибисаның.

## 3

Мәйданга жыелган халык арасында Хөснә берара Бибисаны шәйләп алды. Кара күзлек, йон берет, шундый ук ак йоннан бәйләгән жилетлы чалбар кигән. Хөснә аны әллә кайдан таныды, чалбарлы костюмын гастрольдә йөргәндә Бибиса үзе бәйләгән иде. Ят киемнәр кисә дә таныр иде, чөнки ун елдан артык гомер эчендә актрисаның Хөснәгә таныш булмаган бер чалымы да калмагандыр. Бибиса Казаннан кайткан, димәк. Мәктәп балалары халык арасыннан йөгереп чыгып, ветераннарга кызыл тюльпаннар бирделәр. Нәкъ кырык бишенченең маендагыча... Ул чакта Хөснә Польша жирендә иде, аңа нибары егерме ике яшь иде. Жиңү шатлыгыннан, кайту көне якынлашу шатлыгыннан йөрәге жилкенүенә әмәл тапмаган чагы иде. Ә бүген? Яшьлек тә, кайту шатлыгы да күптән үткән, ә йөрәге һаман тасырдый. Нигә дисәң, баш өстендә зәңгәр күк, кулда ал чәчәкләр, күз алдында гөлдерәшеп килгән балаларның бәхетле елмаюлары...

Хөснә Бибисаны халык арасыннан эзләп караса да, яңадан күрә алмады. Тюльпаннарын билгесез солдат һәйкәленә куеп, кайтып килгәндә, таныш түгел яшь кызлар очрап, Хөснәгә өч бөртек чәчәк бирделәр дә, артларына борылып карый-карый китеп бардылар. Тюльпан-

карның һәрберсенә Хөснә исем бирде: өскә карап, тажларын тырпайтканы «Берәү». Башын ия төшкәне — «Хөснә». Арада нәзегрәге «Икенче берәү». Чәчәкләрне сабакларыннан тотып, кемгәдер бирергә теләгәндәй, алга сузды. «Хөснә» белән «Икенче берәү» парлап янтайдылар. «Берәү» ялгызы бүтән якка бөгелде. Чәчәкләрнең хуҗасына бу ошамады, күрәсең, «Хөснә»не «Берәү» ягына борып куйды. Өенә кайтып чәчәкләрне сулы вазага утырткач та, тыңлаусызларны үзе теләгән рәвешкә күчерде. Бу юлы ул «үзе»н ялгыз калдырып, тегеләрне икенче якка каратты. Ялгызы гына уйлыйсы уйлары бар.

Өстәлдә ике телеграмма ята.

«Тормышыбызда иң якты көн белән котлыйм. Шатлыкның сиңа иң олысын телим, ләкин андый корбаннар белән яуланганы булмасын...» Полкташы. Ветераннар советы ярдәмендә Хөснә аны узган ел хат аша эзләп тапты. Ул да бүген Хөснә сыман япа-ялгызы яшәп ята икән...

«Җиңүең көне белән тәбриклим. Күңелемнән бөтен дөньяның ирләрен синең алдыңда баш идерәм. Унсигез яшеңнән үзең теләп фронтка киткән фидакарь кыз буларак, син ул хөрмәткә лаек...»

Ничаклы нәзакәтле булмасын, сабакташының телеграммасы Хөснәне шатландырмады. Бөтен ирләрне баш идерә, янәсе. Ә үзе?..

Ялгызлык шушындый тантаналарда үзен сиздерә. Башка көннәр эш белән уза. Хөснә кинәт мәйданда Бибисаны күрүен исенә төшерде, телефон трубкасын алып, номер җыйды. Озын гудоклар. Авырган чакта ялгызлык бигрәк тә ямандыр. Яшь артистка алдында Хөснә үзен гаепле сизә. Үз тормышы мисалында ул аны иргә чыгудан биздермәде микән! Хөснә бөтенләй чыкмады түгел, хәтта икегә чыкты. Беренчесе җаны белән сәнгатькә тартылучы, йомшак күңелле кеше иде. Хөснәнең партнерларыннан көнләде, янына килеп иркәләнсә:

— Уйнама... Тормышта уйнаган кешене яратмыйм, — диде.

Читләшебрәк йөрсә:

— Сәхнәдә үбешеп туйдыңмени? — дип җанын әрнетте. Хөснә, Казанны ташлап, Күчмә театрга китте. Икенче ире артист иде. Хөснәнең талантыннан көнләште. Хөснә белән уйнарлык партнер була алмаган ачуын агу итеп чыгарды. Сакмарова, аны ташлап, яна оешкан театрга күчеп китте. Шуннан соң тормышын беркем белән дә бәйләмәде. Сәйарә белән Бибисаны сәхнә өчен югалтудан куркып, үз тормышын мисал итеп китерә иде.

Сакмарова сигаретын сүндерде дә, баягы номерны кабат җыйды. Кайтмаган. Кемгә дә булса кергәндер. Түбән катта почта ящигы шылтыраганга колагын торгызды. Чыгып, газета-журналлар күтәреп керде. Ниһаять, күптән көткән хат. Шәмәхә каралы адреска, конверттагы чәчәкләргә карап, Хөснә озак утырды. Үзенең соңгы хатына бик ягымлы җавап көтми иде. Телеграммасыннан ук билгеле: бөтен ирләрне баш идерә... Соңгы айларда аларның хат ташулары дипломатик сугыш төсендәрәк бара. Сугышны, әлбәттә, Хөснә ачты. Сабакташының абруйлы дәрәҗәсе, пенсиягә чыккан ипле хатыны белән рәхәт гомер сөргәне өчен ачу итеп... Бер-берсен алар дүрт ел элек туган авылларында, сабакташлар очрашуында таптылар. Бер фронтта сугышканнар, көнбатыш шәһәрләрнең берсенә бер көнне барып кергәннәр. Сабакташ шунда госпитальдә ятып калган. Хөснә ары киткән. Сабакташ, гаилә корып, чик буе шәһәрендә бөтенләйгә калган. Ничә еллардан соң туган якларына кайтып, табыштылар. Хатлаша башладылар. Сүз куешып, елына бер-ике тапкыр очраша торган булып киттеләр. Сабакташының көтеп алынган хатлары актрисаның чын назга сусаган җанына әллә күпме илһам бирделәр. «Кадерлем... Бердәнберем... Үткәнем һәм киләчәгем...» Хөснә гомергә ишетмәгән назлы сүзләр ишетте.. Ничек кенә назлы булмасыннар, алар шул бары тик сүзләр генә. Читтән торып гыйшык тотудан Хөснә арыды. Сөекле кешеңнең бүтән берәүнең кую-

нында ятуын белеп яшәү җинел түгел. Ул анда хатын рәхәтен күрсен, син монда бер елдан очрашуга өметләнеп, илһамланып яшә...' Янәсе, ялгыз дәрвиш булып яшәгән өчен мә сиңа сәдака...

Хөснә кайчы алды, конвертның бер кырыен пөхтә итеп кисте. Бит тутырып язылган хатны күз йөгертеп, укып чыкты. Әһәмиятләрәк тоелган урыннарына озаграк тукталып, кабат укыды. «...Зинһар ярсыма, үзеңне кулга алырга тырыш... Язмышыбызның аймылыш булу сәбәпләре бик күп, бу хакта үзең дә беләсең... Саксыз сүзләр ычкындырып, бер-беребезне җәберләмик. Җәй айларында сабакташлар белән очрашу билгеләп, сабыр гына сөйләшик, кайбер нәрсәләрне ачыкларга тырышыйк...»

Хат язган кешегә карата йөрәгендә ачу кайныймы, әллә мәхәббәт утымы, Хөснә моны аерыр дәрәҗәдә түгел. Хат адресаттан бер баш югары торып язылган. Бу деталь үзе үк Хөснәне чыгырыннан чыгарды. Элегрәк Хөснәнең өстенлеге хәреф саен сизелә иде. Бу юлы хөрмәтле сабакташ үзенең җитәкче иптәш икәнлеген исеннән чыгармыйча язган.

Актриса сигарет кабын чүп савытына ыргытты да, ларекка чыгып, тартырга алып керде. Дүртенче каттан йөгереп төшү, йөгереп менү аны бераз тынычландыргандай итте. Хатны ул тагын бер тапкыр җентекләп укыды. Акыллы, сүз әйтерлек түгел. Соңгы вакытта Хөснә, чыннан да, ямьсезләнеп китте. Баш режиссерны читтән чакырасы түгел иде дә бит, Сакмарова олыгаеп бара. Өстәвенә, югары белеме юк. Ә ни сәбәптән юк? Театр студиясен ташлап, медсестралар курсына, аннары фронтка китәргә туры килде. Сугышны бетереп кайткач, укырга соң кебек тоелды, тамакны туйдырырга, өс-башны карарга кирәк иде. Кем гаепле?.. Бу сорауларга сабакташ, әлбәттә, дөрес җавап бирә ала. Хөснәгә исә «лаеклы ялга» китүдән гайре берни калмый, дирекция эшне шул юнәлештә алып бара. «...Аймылыш булуның сәбәпләре күп...» Ачыклар кара хәзер аларны. Ачыклау белән генә төзәтеп булса икән...

Бүлмә буйлап йөренә торгач, Хөснә телефон янында тукталып, Бибисага шалтыратты. Теге якта эндәшмәделәр.

## Ай гөле

### 1

Фәннәр кандидатының үз бүлегенә килүен Аллаяров хуплый, әмма бу эшнең ахыры ни белән бетәчәген күз алдына китерә алмый. Яшь белгечнең төп максаты хирургия бүлеген лаборатория итеп, тикшеренүләр үткәрүме, әллә авыруларны дәвалаумы? Беренчесе аның өчен мөһимрәк булуы мөмкин. Яңа дәрәҗә, яңа исем... Алардан беркем баш тарта алмый. Аллаяров үзе диссертация язарлык вакытын авыруларга бирде. Этләр белән тәҗрибәләр үткәреп маташты, нейрохирургия буенча китмәкче иде. Тормыш аңа бөтенләй башканы тәкъдим итте. Хирургиянең бер генә тармагы белән шөгыльләнү мөмкинлеге булмады. Тора-бара нейрохирургия бөтенләе белән травмотологларга күчте. Аллаяровка ашказаны, бавыр, бөер ише әйберләр торып калды. Үпкәгә, йөрәккә операция кирәккәндә, Казандагы махсус клиникаларга мөрәҗәгать итәргә тиеш булсалар да, Аллаяровка андыйлардан да өлеш тия. Кеше гомерен коткару өчен минуты кадерле очраклар еш чыгып тора. Казан ерак, ә Аллаяров янәшәдә генә. Театрга барып, спектакльне ахырынача караганы сирәк Аллаяровның. Соңгы вакытта андый җирләргә бөтенләй бармас булды. Телевизор коткара. Чакырсалар, ул мәхлукның колагын борып куясың да, чыгып китәсең.

Бүлектә онкология буенча белгеч кирәклеге бик сизелә. Яхшы белгеч кирәк, практик. Операция ясаучы кирәк. Рак белән көрәшнең иң ышанычлы юлы — хәзергә хирургия. Аллаяровтан фәнни эш сорамыйлар, сәламәт кешеләр таләп итәләр. Бүлектә моңарчы эшләгән онколог пычак тота белми.

Гыйлфан Кылычбаевның кулы житез, нык. Аллаяров күңеленнән сизенгән нәрсәләрне фәнни нигезләп бирмәсме? Квартира юлларга кирәк. Ганиләсен алып килсә, төпләнеп калыр. Алып килмәсә — монда вакытлы кеше икәнлеге алдан ук күренеп тора. Андыйларның үзләре монда, уйлары тегендә була.

Изоляторда авыр хәлдә бер кыз ята. Тире дә сөяк. Егерме дүрт яшендә, кырык алты килограмм. Озак-озак бюллетеньдә йөргән, тагын эшкә чыккан, тагын бюллетеньдә. Күршебез дип, аны санитарка алып килгән иде. Анализлар үтте. Рентгенологлар берни күреп булмый диләр, эчәк элмәкләренә газ тулган. Мондый күренеш эчәге яки ашказаны тишелгән чакта була. Кичекмәстән операция өстәленә салырга кирәк дигән сүз. Аллаяров ашыкмаска булды. Авыруның сулыш алуы тыныч, маңгаенда, тәнендә, перитонит очрагындагы кебек, салкын тир сизелми. Бер тәүлек ятты, хәле кискен үзгәрми. Ашавы юк дәрәҗәдә, гемоглобины аз. Рентгенны кабатладылар. Эчәк элмәкләре сыекча белән кабарган. Диафрагма астында тар гына буй газ җыелган. Төгәл диагноз куеп булмый. Эчәгедә шеш булырга тиеш, шуның аркасында азык-төлек үтми. Озак күзәтеп, соңга калырга да ярамый. Баш хирург аны Кылычбаевка тапшырды. Очрак аның һөнәре буенча булырга охшый. Аллаяров үзе поликлиникага китте, бүген аның кабул итү көне.

Чиратта ничаклы халык... Һәммәсен яхшылап карыйм дисәң, өч көн кирәк. Бүлмәгә керү белән Аллаяров сестрага әйтте:

— Врачлар тарафыннан стационарга дәваланырга жибәрелгәннәрен генә кабул итәбез. Калганнары урологка күренсеннәр.

Аллаяров ишеге янында һәр вакыт халык күп була. Иңенә челтәрле ак шәл салган пациент керде. Юка ак күлмәктән, йөзе сап-сары. Кулында зур кара күзлек. Сабанаева ич бу. Хәл-әхвал сорашу. Бар да яхшы икән, тик менә сары... Хирург көлә:

— Ә нигә сез сарыга каршы? Шундый расалар яши бит жирдә, бер дә зарланмыйлар.

— Аларның күзләре сары түгел бит...

— Кара күзлек астыннан сезнеке дә күренми.

Бибиса сагышлы елмая. Аллаяров авыруның Казаннан кайткан язуларын карый, житдиләнә.

— Боткин авыруы [1] буенча тикшерелергә туры килер.

— Тегендә тикшерделәр, юк. Акрынлап бетәр, дигәннәр иде.

— Монда да тикшереп карыйк.

Аллаяров һаман елмая. Үзе елмая, эче сыкрый. Нигә кешене азаплап йөртергә, сарының нидән икәнлеге билгеле түгелмени? Тикшермичә барыбер ярамый. Операциядән соң яман шеш хәзер үз позицияләрен кире ала булыр. Үт юлын каплаган, үт хәзер кан юлына юнәлгән. Бавыр кабарынкы, кулга ук сизелә.

— Йогышлы сары булмаса, без дәваларбыз, барып кайтыгыз.

Хирургка вакытны сузарга кирәк. Күп яшисе калмаганга охшый... Операциядән соң күпме вакыт узды әле? Монда бер ай, тегендә бер ай. Күзе янган пыяла кебек. Бибиса алдында Баязит үзенең көчсезлеген сизде. Пыскып янган күз карашында ул рәнҗү күрде. Гүя ул караш

[1] Боткин авыруы — йогышлы сары.

«Сезнең пычактан да өстен нәрсәләр бар бу дөньяда», ди, хирургны мыскыллап көлә. Авыру каршында мескен хәлендә калдыңмы—бетте...

Йогышлы авырулар бүлеге шәһәрнең теге очында, анда ничек барырга инде ул? Машина белән илтергә иде, ашыгыч ярдәм машинасы белән. Ә ашыгып ни файда? Киресенчә, вакытны сузарга тели түгелме? Карарын үзгәртергә дә, икеләнеп, уйланып утырырга да хирургның вакыты юк, ишек катында — чираттагы пациент.

— Узыгыз, утырыгыз. Нәрсәдән зарланасыз?

Караңгы төшкәнче шулай. Ә больницада, хирургның хөкемен көтеп, яралы лейтенант ята. Күрше район егете, ялга кайткан. Хулиганнардан, үсмер малайны яклыйм дип, җәрәхәт алган. Каны күп киткән. Казаннан ашыгыч ярдәм чакырганнар. Яшьләрдән Аллаяровны дәшегез, ул тизрәк барып житәр, дигәннәр. Медиклар көне, бәйрәм, андый чакта Аллаяровны гына борчырга мөмкин. Баязит эченнән генә шулай сукранып маташса да, башкала белгечләре белән бер рәткә куюларына күңеле канәгать. Авыруга урында кан бирделәр. Аллаяров аны үз больницасына алып килде. Операция ясарга ашыкмады. Әгәр үпкәне киссәң, операция уңышлы чыкканда да, хәрби хезмәткә егет кире кайта алмый. Кан агу тукталды, консерватив ысуллар белән аякка бастырып булмасмы. Бүген Касыймов дежур тора, бер мөгез чыгармагае, өйгә кайтканчы, анда сугылырга кирәк.

Аллаяров кузгалырга өлгерми калды, терапия бүлеге мөдире бер авыруны ияртеп керде. Озын буйлы, яшь кенә ир кеше, төсе качкан. Йөзенә күз ташлау белән «өмет юк монда» дип уйлады хирург. Беренче ямьсез уйны куарга тырышты. Беренче туган фикерләренә ябышып, күпме врачлар ялгыша.

— Аллаяр, кара әле минем егетне.

Утыз өч яшьтә. Инженер. Өйләнгән, баласы бар. Бер ай терапия бүлегендә яткан, гастриттан дәваланган. Билендә җылыткыч билбау. Димәк, бөердә. Точно, сул бөер шактый зурайган. Култык асларың, муен тирәләре ничек? Җилкә бизләре төерле.

Авыруны коридорга чыгаралар.

— Бөер рагы.

Терапевт чайкалып киткәндәй була.

— Операциягә алынасыңмы?

— Булмый, Динислам, метастазалар[1] башланган.

Карашын бер ноктага текәп утырган коллегасын Баязит кызганып куйды.

— Ачып карарга була, гарантия бирә алмыйм.

Терапевт, бөкрәя төшеп, чыгып китте. Баязит ашыгып киенә башлады, тагын тотып калулары мөмкин.

Аллаяров, кешенең күзенә карап, чирне белә дип сөйлиләр. Күзенә үк карап белмәсә дә, авыруның яшәрме, үләрме икәнен ул алдан сизенә. Ни өчен Сабанаевага операция ясый башлады. Шешнең зурлыгына караганда, ул дәрәҗәдән узган иде. Яшәренә ышандымы? Бу сорауга хирург үзе дә җавап бирә алмый. Сиземләү мәсьәләсендә данлыклы врачлар турында төрле мәзәкләр сөйлиләр. Имеш, профессор Н. ны бер авыру янына чакырганнар, квартирасына. Дәрәҗәле кеше, ютәлдән буыла, врачлар бер чир дә тапмыйлар. Профессор авыруның йөзенә карый да, тирә-якка күз йөгертә. Тәрәзә кашагаларына текәлеп тора.

— Сез, туганкай, жиз тузаны сулыйсыз, тәрәзә чаршаулары эленгән жиз таякларны да, жиз бөжраларны да алып ыргытыгыз, — ди.

Шул ук профессорга Кавказдан бер ханым кызын алып килә. Алдан хатлашып, кабул итү вакытын белешкән булалар. Самолет вакы-

[1] Метастаза — ракның бүтән әгъзаларга таралуы.

тында очмау сәбәпле, сәфәрчеләр билгеләнгән вакытка килеп өлгермиләр. Хат аша ундүрт яшьлек кыз баланың эч авырту белән интеккәнен хәбәр иткән булганнар. Соңлаган пациентларны профессор шелтәле сүзләр белән каршылый:

— Мин сезне сәгать буе көтеп утырам, ә сез күнел ачып йөрисез. Бу вакыт эчендә мин ун авыруны кабул итәр идем. Күземә күренмәгез, югалыгыз күз алдымнан!

Ана белән кыз елап чыгып китәләр. Профессор һаман тынычлана алмый, артларыннан чыгып, кычкырып кала:

— Ишетәсезме, башка мине борчып йөрмәгез! Ә кызыйга бандаж кидерегез, бөере төшкән кызыгызның?

Мондый мәзәкләрдә күпмедер дәрәҗәдә дөреслек булырга тиеш, чөнки озак еллар эшләгән һәр һөнәр иясендә күзәтүчәнлек, сиземләү көчәя. Фән кешеләре аны интуиция диләр.

Нәкъ менә шул сиземләү аркасында Аллаяров яралы лейтенантка операция ясамый торырга булды. Әгәр хәрбигә тиз арада бер-бер хәл булса, хирург операцияне тоткарлау сәбәпләрен аңлатырдай дәлилләр китерә алмаячак.

Хирургия бүлегенә юнәлгәндә, Аллаяров шуларны уйлап барды. Түбәндә аны кызыл чәчәкле кара кәшемир яулык бәйләгән ханым каршы алды. Хәрбинең әнисе. Улының хәле? Әлегә ярыйсы. Операция? Операциянең бәлки кирәге дә булмас. Кем әйтә хәле авырайган дип? Хирург бүген аның янында булды, хәзер дә шунда баруы.

— Керерсез. Улыгыз янына хәзергә ярамас, минем янга керерсез.

Сөйләшүне Аллаяров сузмаска тырышты, өске катка менеп китте. Авыруның анасына Касыймов нидер әйткән булырга тиеш. Шулай булып чыкты да. Касыймов үзе үк кабинетка чәчрәп килеп керде:

— Мин, хирург була торып, күз алдында кеше һәлак булганын карап тора алмыйм!

— Тукта әле, коллега, аңлатканны көт...

— Мин үзем дә кайбер нәрсәләрне аңлыйм. Хәзер операция өстәле әзерлиләр, сез курыксагыз, мин алынам! Бөтен җаваплылыкны үз өстемә алам!

Касыймов, мөгаен, баш врач белән киңәшкән, бу чаклы усаллашмас иде. Авыру яткан палатага Аллаяров белән бергә Касыймов та кермәкче иде, баш хирург аңа торып торырга кушты.

Авыру яныннан хирург үз-үзенә ышанган кыяфәттә чыкты.

— Төнне тыныч кына үткәрсен, иртәгә консилиум җыярбыз, — диде Аллаяров, Касыймовка каты бәрелми генә. — Әгәр сез шуны теләсәгез, — дип өстәде. Аннары дежур сестрага әмерен әйтте:

— Миннән башка авыруга кагылмаска!

Баш хирургның әмере Касыймовка да кагыла иде, тегесе ирен чите белән елмаеп куйды. Мин үз фикеремне әйттем, янәсе, калганы синең вөҗданыңда.

Касыймовның хәлен баш хирург аңлый. Хәтта аны кызганып та куя. Аллаяров үзенең авторитеты белән аны бастырып тора, күрәсең. Бүлек белән җитәкчелек итәсе иде аңа, шуңа омтыла да ул. Бүтәннәр сыман җаваплы операцияләрдән качмый. Бәгъзеләр бит, катлаулырак очрак булса, авыруны Казанга очыралар да — вәссәләм. Андыйларда үлем аз була, сүгелмиләр, шелтә алмыйлар.

Яралы лейтенант буенча Аллаяров консилиум җыймады. Күпчелек аны яклар дигән ышанычы юк иде. Кул кушырып торуга караганда, операцияне өстенрәк күрәчәкләр. Бер-ике көн үтсен, консерватив дәвалауның нәтиҗәсе бераз күренсен.

Тагын бер тәүлек зыянсыз узгач, операция кирәкмәгәнлеккә Касыймов та ышанды бугай.

Ыгы-зыгылы гадәти көннән соң өенә кайтканда Баязит аяклары сыгылып китүен, уң кулы сызлавын тойды. «Әллә авырыйм инде?» — дип уйлады үз-үзеннән көлгәндәй. Иртә белән әллә ниткән ямьсез җил чыгып, суытып җибәргән иде. Баязит үтә җиңел киенеп чыккан икән, бөтен гәүдәсен ачы җил бөтереп алды. Шунда бераз салкын тиеп калмады микән? Хәзер бит җәй белән кыш буталды, җәй көне кар, кышын яңгыр ява. Кайткач, үәй эчте дә ятты. Градусник утыз сигез ярымны күрсәтә. Шул гына җитмәгән иде. Дәлия мәтрүшкә кайнатып, чәй эчерде, аспирин бирде. Иртәгәсен дә хирургның кәефе әйбәт түгел иде, бүлеккә барып, каты авыруларның хәлен белде, дәвалар билгеләде. Операциягә алынмады. Шулай да тиз генә кайтып китә алмады, бүлектә барлыгы өч хирург калган. Кайсы ялда, кайсы киңәшмәдә. Төнлә эшләгән хирургны икенче көнне алыштырыр кеше юк. Артык эш сәгатьләре өчен түләү мәсьәләсендә баш врач белән тагын конфликт. Төнге дежурны эш сәгате исәбенә билгеләгез, ди, түләргә акчалары юк. Ә эш сәгате өчен хирургны каян алырга? Авыруларны көндез дә караучысыз калдырып булмый бит. Төнге хезмәт өчен өстәмә түләү мәсьәләсен профсоюз җыелышына куеп, карар күчермәсен баш врачка җиткерергә хәл кылдылар. Күчермәне Касыймов тапшырырга булды, ул үзенекен алмый калмас.

Аллаяров эштән кайтып, урынга ятуга, телефон шалтырады. Трубканы Дәлия алды: балалар больницасыннан, Аллаяровны сорыйлар. Үтә авыр очрак бар икән, консультациягә чакыралар. Дәлия: «Баязит Алмасович үзе югары температура белән ята», — диде. Уңайсыз тынлык. Шалтырау кабатлана. Дәлия үзе ышандыра алмагач, трубканы Баязитка бирә. Бала үлем куркынычы алдында. Ялынып сорыйлар. Барырга кирәк. Кемдер хәл эчендә ятканда врачның авырырга хакы юк. Баязит институтта укыганда шундый хәл булды. Профессор авырып, лекциягә килмәде. Шул ук төнне үлгән. Машинада. Инфаркт. Авыру янына ала килгәннәр икән, баш тартырга кыймаган. Вөжданы саф килеш үлгән. Ашыгыч ярдәм машинасына утырганда Баязит шул хәлне күңеленнән кичерде.

Ике яшьлек малай. Врачның үз баласы икән. Аллаяровның диагнозы: шонлейн-геноха[1] нигезендә перитонит. Сирәк очрый торган авыру, балалар авыруы. Гадәттә аны операциясез дәвалыйлар. Бу очракта кай урыннандыр эчәге тишелгән, ашыгыч операция кирәк. Кичектерсәң, соң булачак. Баланы өстәлгә салалар һәм коткарып калалар. Киеренкелек хирургка хәл кертә, уңышлы башкарылган эш аңа куәт өсти.

Бүлектә хәвеф-хәтәр юк, лейтенантның хәле әйбәтләнә. Хәтта сөенче алдылар: төнге дежурство өчен түләргә дигән приказ чыккан. Элеп куймаганнар әле, әмма кемдер ишеткән, кемдер күргән.

## 2

— Яхшы артист син.

Бибиса Гыйлфанга шулай диде. Гыйлфан кире какмады, акланмады. Бөтенләй дәшмәде.

— Мин бит барын да беләм. Ачыктан-ачык сөйләшсәң, яхшырак булмасмы?

Гыйлфан аның нәрсә белүе турында да сорашмый. Бибисаның нинди дарулар эчүе белән кызыксынган иде. Аллаяров язып биргән никодин, колодиннарны күргәч, йөзенә ризасызлык чыкты. Бер мизгел-

[1] Шонлейн-геноха — сирәк очрый торган авыру, балаларда ашкайнату әгъзаларында була.

гә генә. Бибиса шуны сизеп алган. Бу дарулар канны үттән чистартырга ярдәм итәләр, әмма үт килүнең төп сәбәбен бетермиләр. Төп чыганакны дәваларлык дару юк булып чыга. Бибиса шуны аңлады. Даруга ышанычны какшатырга тиеш түгел иде Гыйлфан. Аллаяровка Бибиса аллага ышангандай ышана. Гыйлфан да үзен Бибиса өчен бер куркыныч нәрсә дә юк сыман тотты. Аллаяровның даруларын шик астына куйган икән, хәзер ул Бибисаны үзенә ышандырырга тиеш булып чыга.

Әйе, Гыйлфанның үзен тотышына караганда Бибисага бер нинди куркыныч янамый сыман. Бибиса бүген аның бер мизгелдә генә рольдән чыгуын күрде. Акыллы тамашачы фальшьны тиз тота. Чыннан да, күпме дару эчсә дә, йөзендә, күзендә сары кимеми. Аллаяровка чиратка торганда бер хатын аңа:

— Өй эчендә дә кара күзлек кигән булып, кыланып утырма инде, — дигән иде. Якын итеп, турысын әйткән кешегә Бибисаның да ачык җавап бирәсе килде, күзлеген салып, әлеге хатынга тутырып карады. Хатын өркеп, чигенгәндәй итте:

— И, бәбекәем...

— Беләктә сизелмиме әллә?

— Кояшта янган кебек кенә... Кара сары булмасын тагын...

Шул сөйләшүне исенә төшерде Бибиса. Кара сарының ачык сарыдан яманрак булуын да чамалады.

— Нәрсә ул кара сары?

— Бавыр авыруы.

— Беләм. Дәвасы бармы?

Гыйлфан Бибисаның кышкы тәрәзә пыяласына охшап калган күзләренә карый, Бибисаның карашы карлы-бозлы, берни күрешле түгел. Кәҗә мамыгыннан бәйләнгән кофта, кулдан бәйләнгән озын йон чалбар кигән, ак мамык яулык бөркәнгән. Караватта аягын юрган эченә яшереп утыра. Шул киемнәре белән йоклый, тына, күрәсең, дип уйлый Гыйлфан. Бибисаның аяк очына утыра, аның нәни кулын учына ала. Гүя араларында еллар ятмый, әйтерсең Гыйлфан беренче тапкыр кызлар кулы тота... Кышкы авыл өе...

— ... Кулың нинди йомшак...

— ... Ә синең кулың көчле...

— ... Мин сине гомер буе яратырмын...

Шушы минутта, мөгаен, алар икесе дә әллә кайда, еракта калган кышкы кичне күз алларына китерделәр. Тун тәрәзәнең бозы дымлангандай булды. Гыйлфан җитдиләнде.

— Дәвасы бар. Терелә сең.

— Тагын чегәнлеккә керештеңме?

Гыйлфан үз учындагы кулга карап, йомшак кына елмайды, чөнки аның әйтәчәк сүзе чегәнчәрәк булачак, тик тискәре ягы белән:

— Тик бер шарт белән: син миңа бер нәрсә дә яшермичә сөйләп бир. Кай җирең авырта... Иртән, төнлә, кич?

Бибиса кулын Гыйлфан учыннан сак кына тартып ала, хәйләкәр елмая:

— Бер җирем дә авыртмый. Хәлем генә юк.

Гыйлфан «нишләргә синең белән?» дигән кебек, озак итеп Бибисага текәлеп тора. Дәрья-күлдә очрашканда ук аның күз карашында җан әрнеткеч сулпанлык бар иде. Зур кайгы кичереп, өметсезлеккә бирелгән кешенеке кебек. Үзе дә аңлашмастан, Гыйлфан аны шифалы үләннәр белән таныштырырга тырышып йөрде. «Син авырыйсың, чарасын күр», — дип, тиктомалга ничек әйтәсең?.. Кайбер кешеләрдә күрәзәлек аннан алдарак йөри.

Нәрсәгә дип омтылды Гыйлфан Яшьләргә? Анализларны Казанда ясатып, монда әзер нәтиҗәләр алу фәнни эшенә әллә ни өстәмәячәк.

Бибисаның сүнеп барганын күреп торып, каберенә туфрак салыр өчен килмәгәндер бит? Нидер эшләргә кирәктер ләбаса. Табигатьнең үзендә бөтен авыруларга дәва бар, табарга, файдалана белергә генә кирәк. Алай гына да түгел, һәр чиргә дәва кешенең үз организмында, үз күзәнәгендә эшләнә. Дару бүлеп чыгаручы күзәнәкләргә ярдәмче көчләр кирәк...

Урман буе. Алтынсу-сары чәчәкләр... Тәлгәш-тәлгәш... Тәңкә-тәңкә... Гыйлфанның кечкенә чагы. Чәчәк өзеп ала, яшел сабактан кызыл тамчы тама.

— Инәй, чичкәдә кан...

— Чичкәләр, улым, бәндәләр кебек, кирәкмәгәнгә өзәргә ярамый, яшь ага, кан тама. Чичкә каны — бәндә каны. Чичкә орлыгы туфракка төшеп, тамыр җибәргәндә кеше җаны яралса, алар игезәк булалар. Игезәкнең каны игезәккә шифалы. Кеше каны бозылса, чичкә аңа үз канын бирә. Кирәкмәгәнгә өзәргә ярамый чичкәне...

— Ә син нигә өзәсең?

— Чир кышлы-язлы килүчән, ә чичкәне кар астыннан табып булмый. Без аны, улым, киптереп куярбыз. Изге чишмә суына салып парландырсаң, кипкән кан терелә. Хәстәләнгән кешегә парландырып бирербез без аны.

— Ә бу чичкәнең каны да, яше дә юк, аны нигә өзәсең?

— Гөлбадран... Сабыр чичкә ул, ай гөле. Бүтәннәр арасында күзгә-башка ташланмас, яшен дә күрсәтмәс, канын да чыгармас. Каны бар аның, нинди суга салып эретергә белергә кирәк. Бәдер[1] көнне өзәргә кирәк аны, чичкәсе айга карап ачылган көнне. Шунда гына шифасы була.

— Кыш туган кешенең чичкәсе булмыймы?

— Була, балам, була. Кар астында аның орлыгы тамыр җибәрергә әзерләнеп, үзенең игезәге яралганны көтеп ята.

— Инәй, минем чичкәм кайсы?

— Синең чичкәңме?

Гыйлфанның дәү инәсе, моңгерәп кенә көй көйләп, болын буйлап китте. Гыйлфан аңа иярде.

> Су буенда гөлбадран,
> бөгеләдер җилләрдән...

Нидер алырга иелгән жиреннән инәсе кинәт тураеп, артка сикерде. Үлән арасында соры өтер сикергәли. Кәлтә еланы... Койрыгын өзеп качкан. Шуннан Гыйлфан үз чичкәсен сорамас булды. Дәү инәсе оныгының соравын оныттымы, болын сукмагыннан кайтканда бүтән риваять сөйләргә тотынды.

— Зәңгәр миләүшәләрне күрәсеңме? Күрмәссең шул, көндез йомылалар алар.

Гыйлфан дәү инәсенең сүзләрен яхшырак ишетергә теләп, аның итәгенә тотынган да, башын өскә күтәреп бара.

... Борын заманда ул зәңгәр чичкәләр бүтәннәр белән беррәттән кояшка карап, хозурланып үскәннәр. Үз тиңнәрен көткәннәр, көтә-көтә күзләре күгәргән. Көткән ишләре бер заман килгән, әмма боларга карамый, ал-кызыл чичкәләргә үрелә. Миләүшәләр моны күрмәс өчен күзләрен йомганнар. Хәзер алар яктыда ачылмыйлар, караңгы төндә генә зәңгәр күккә багып, тирә-якка хуш ис тараталар. Көткән кешеләренә чичкә исе җил белән барып ирешсә, һәм ул кеше караңгы төндә боларны эзләп тапса, шунда гына ачылабыз дигәннәр...

---

[1] Бәдер (гар.) — ай тулган көн.

Каенлы тауны биленнән кочып алган сукмак буйлап, урман-болын чәчәкләре күтәреп кайтучы Гыйлфан дәү инәсенең серле һәм шомлы риваятьләрен исенә төшерде. Күпме кешене савыктырды карт инәсе, ә менә үз кызына, ягъни Гыйлфан әнисенә, кирәкле үләнне таба алмады. Үз ышаныче бер югалтсаң, аны кабат табуы кыендыр, күрәсең. Исән чагында әнисе урман тереклеген атасы төсе итеп күрер, яфракларын сыйпап, сөеп йөрерие. Кешенең серле рухка ышануында матди нигез ята. Эчке әгъзаларның эшчәнлеге психологик халәткә бәйле. Йөрәк сүлпәнләнсә, кан йөреше акрыная, бу исә бүтән әгъзаларга тискәре йогынты ясый. Баш миенә азык вакытында килеп җитми, кан юлларына тоз, бавырга таш утыра. Рак авыруы да кешенең эчке халәтеннән туа. Авыр җан җәрәхәте, психиканың тетрәнүе... Кеше тәнендә бер генә рак вирусы табылса да, аңа каршы чара табу җиңеләер иде. Болай исә билгесезлеккә каршы көрәшү булып чыга. Химиотерапия авыру күзәнәкләр белән бергә сәламәт күзәнәкләрне дә җимерә, авыруның төрле чирләргә каршы көрәшү сәләте йомшара.

Чит илдә чагында Гыйлфан кулдан-кулга йөргән бер медицина журналына тап булды. «Фән һәм техника» журналларының берсендә рак авыруына каршы үткәрелгән уңышлы дәвалау тәҗрибәләре турында кызыксынып укыды, аерым урыннарын куен дәфтәренә язып алды. Әлеге язмаларның сөземтәсе түбәндәгедән гыйбарәт.

Онко-авырулар белән аралашкан кайбер кешеләрнең канында ракка каршы көрәшердәй матдәләр барлыкка килә, һәм мондый кеше донор була ала. «Препарат»ны донорның канынннан аерып алалар да, авыруга кертәләр. «ТФ» дип исемләнгән бу препарат (трансферре) ракны турыдан-туры үзе дәваламый, әлеге чиргә каршы иммунитет булдыручы күзәнәкләргә уңай тәэсир ясый. Шушындый иммунотерапия үткән рак авыруларының савыгу очраклары булган. Хирург скальпеле шешне кисеп ташлаганнан соң үткәрелгән дәвалау аеруча уңышлы чыккан.

Гыйлфан болында дәү инәсенең шифалы үләннәрен барлап йөргән шикелле булса да, шул тәҗрибәләр турында уйланды. Шәһәр шаушуыннан еракка китеп, ялгыз йөрисе килде.

Чит илгә җибәргәндә аларны киң профильле белгеч итеп әзерләделәр. Яшьләр үзәк больницасының өр-яңа лабораториясендә тән тукымасы һәм күзәнәкләр өстендә тәҗрибәләр үткәрү мөмкинлеге бар, гистология нәтиҗәләрен хәзер Казаннан көтеп ятмыйлар, урында тикшерәләр. Каннан ТФ ны аерып алырдай җайланмалар хәзергә юк югын. Аның каравы, Гыйлфан хәвефле авырулар белән аралашкан кеше, аңарда, әлбәттә, «көрәшче» күзәнәкләр бар. Иң мөһиме, Бибиса үзе төшенкелеккә бирелмәсен, үз күзәнәкләре каты көрәш алып барсын. Бөтен хикмәт — кешенең үз күзәнәкләрендә...

3

Яктырмаган иде әле, Гыйлфан кинәт уянды. Йокыга киткәндә ул Бибиса турында уйлап ятты, уянгач та шул уйларның дәвамы башланды. Өендә Бибиса бөтенләй ялгыз. Казаннан кайткан мәлне ничә тапкыр телефоннан шалтыратты, ишегенә барып кагылды, өй эчендә җан иясе барлыгы сизелмәде. Ахыр чиктә Мәмдүзәне эзләп тапты. Аның әйтүенә караганда, Бибиса беркемгә ишек ачмый икән, телефон чыбыгын өзеп үк куйган. Врач та чакыртмый, алар үз эшләрен эшләделәр инде, ди икән. Гыйлфан теге вакытны Бибиса янына Мәмдүзәдән ачкыч алып керде. Бүген дә авыру янына барырга уйласа, Мәмдүзә эшкә киткәнче аңардан ачкыч алып калырга кирәк.

Кабат йоклап китә алмасын аңлап, Гыйлфан торды, киенде, алдан

әзерләп куйган кирәк-яраклар салынган портфелен алды да, өченче каттан түбән төште. Тулай торак йокыга талган. Тимер келәләр шылтырауга, йокылы күзләрен йодрыгы белән угалап, дежур апа килеп чыкты.

— Кая болай, таң белән кубып...

— Барасы җирем бар, йокыңнан уятканга рәнҗемә инде.

— Нинди рәнҗү... Әйбәт кенә йөр.

Дежур хатынның соңгы сүзләреннән Гыйлфанның кәефе булды: бу шәһәрдә аның турында кайгыртучы бар. Урамда юка яфраклары шыбырдашып каршы алды. Мотоцикл пытырдап үтте. Кайдадыр машина елаталар. Шәһәр уянып килә. Каенлы тау артында таң кабынган. Ул якта күк төнлә дә кызгылт, газ факелларының шәүләсе төшә.

Ак ташлардан мәңгелек итеп салынган дүрт катлы йорт. Почмактан өченче, дүртенче тәрәзәләр Бибисаныкы. Пәрдәсе төшерелмәгән тәрәзәдә ут күреп, Гыйлфан гаҗәпләнде. Ут эчтәрәк күренә, ванна тәрәзәсеннән төшә булыр. Бәлки кичтән сүндерергә онытканнардыр. Тар урамның асфальт тротуары буйлап Гыйлфан ары узды да бире килде. Агач ботакларына эленгән йолдызлар төсле чаган яфраклары җилферди. Алар да Бибисаның тәрәзәгә каравын көтәләр кебек. Көтеп арыганнары Гыйлфанның аяк очына килеп төшә. Тәрәзәдән күргәннәрен хәбәр итәргә телиләрме әллә? Өйдә ул, уяу, хәлен белми китмә, диләрме?

Электр кыңгыравы тынып, күпмедер вакыт узгач, йомшак кына басып килгән аяк тавышлары ишетелде. Шул ук мамык кофта, йон чалбар кигән Бибиса кунакны уздырып артка атлады да, ике кулын кушырып, юка гәүдәсен кочаклады. Дымсу күзләрендә газап катыш гаҗәпләнү. Гыйлфанны күрүгә ул сөенми, аның беркемне дә күрәсе килми.

— Ачуланма, Бибиса, бәлки бирәр ярдәмем тияр.

Бибиса дәшми, бөкрәебрәк басып тора. Гыйлфан чакырганны көтми, чишенә. Портфелен алып, кухня ягына уза. Хуҗабикә кунак артыннан иярә. Гыйлфан кай арададыр ак халат киеп алган, юган кулын сөлгегә сөртә-сөртә, ванна бүлмәсеннән килеп чыкты.

— Кая, карыйм әле мин сине...

Бибиса алдында кыюсыз егет түгел, үзсүзле врач. Авыру бүлмәгә кереп, тахтага ятарга мәҗбүр булды.

— Монда ничек?.. Ә монда?.. Кагылгач кына авыртамы? Һәрвакыт... Туктамый сызлыймы, әллә вакыты-вакыты беләнме? Иртәнгә таба... Ничегрәк авырта?

Доктор авыруның өстенә юрган япты, кухняга юнәлде: «Мин хәзер».

Нилләрдер шылтырады, шыбырдап су акты. Бер мәл бүлмәгә болын исе, урман исе таралды. Ак халат җиңнәрен сызганган Гыйлфан тыңлаучан бала кебек яткан Бибиса янына чыкты.

— Мин кушканнарны эшләсәң, бар да әйбәт булыр.

Доктор Бибисаны җилтерәтеп күтәрде дә, ванна бүлмәсенә китте. Аударган урындык өстендәге таста кызгылт сыекчадан пар бөркелеп тора. Авыру шушы парга утырырга тиеш.

— Ванна читенә тотын, авып китмә. Мин кухняда газет караштырам, кирәгем чыкса, аваз бирерсең.

Хатын-кызның уңайсызлануын сизмәгәнгә салышыр өчен, Гыйлфан туктаусыз сөйләште. Ванна ишеген ябып, кухняга чыкты, плитә өстенә чәйнек куйды, түр бүлмәгә кереп, өстәлдән газета-журналлар алды. Пөхтә итеп җыештырылган бүлмә эченә күз йөгертеп, ихтыярсыз туктап калды. Тәрәзә төбендә, идәндә төрле зурлыктагы чүлмәкләрдә гөлләр. Идәнгә кояш нурларына охшаган парчалы палас җәелгән. Тахтада сары-яшел чаган яфраклары төшкән җаймә. Менә ни өчен урам тротуарларында яткан чаган яфраклары таныш тоелган икән.

Тахта турысында, алсу акшарлы стенада шул ук акшарны зәңгәрләтеп, көянтә-чиләкле Ай кызы сурәте төшерелгән, гүя ул шәфәкъ алсулыгында зәңгәр томан булып, эреп бара... Үткән килгәндә Бибисаның саргайган йөзенә карап, боларның берсенә дә игътибар итәлмәгән. Китап шүрлегендә берничә агач сын. Урманда йөргәндә табып алганнар да, җәнлек сурәтенә охшатып, бастырып куйганнар. Жираф баласы муенын сузып тора. Тәвә кошы башын аз гына кырын салган да, сыңар аягына басып, уйланып тора. Шүрлек кырыена төрле-төрле мәрҗәннәр эленгән. Гыйлфан шүрлек каршына басып, китапларга күз төшерде. Таҗи Гыйззәт... Кәрим Тинчурин... Чехов. Джон Рид, «Дөньяны тетрәткән ун көн»... Укырга алып торсаң, яхшы булыр иде, бүген үк сорау уңайсыз. Плитә өстендәге чәйнекнең гөбердәп кайнавы ишетелә. Газета-журналларын күтәреп, Гыйлфан кухняга юнәлә.

Кәгазь кыштырдавы белән ишетелмәгән, ванна бүлмәсеннән акрын гына Бибиса килеп чыкты. Туры карарга оялыпмы, башын түбән иеп тора. Гыйлфан аны алып килгәндәгечә күтәреп илтмәкче иде, Бибиса ике кулын докторның күкрәгенә терәде.

— Үзем...

Пациентканың иңеннән кочкан килеш, доктор туктап калды. Бакчада йөрүче егет белән кыз кебек, акрын гына атлап киттеләр.

— Хәзер җылы гына төренеп ятарга... Бал бармы? Яхшы.

Бибисаның йөзе алсуланып киткәндәй булган, йөзенә сабыйларча елмаю кунган.

— Хәзер шифалы чәчәк белән парландырган чәй эчәсең...

Бибиса шифалы чәй эчкәндә, доктор тагын кухня ягына китте, анда шактый озак торып, төрле инструментлар күтәреп чыкты.

— Хәзер синең каныңа дөньядагы бөтен чирләрне егып сала торган дару бирәбез... Тере дару...

Тахта янына Бибисага таныш «җан сакчысы» басты. Тик бусы бик пөхтә һәм, күрәсең, җыелмалы, ишектән кергәндә докторның кулында озын әйбер күренмәгән иде.

... Дошман тылына төшкән десантчылар сыман, тере тамчылар бер-бер артлы Бибисаның кан юлына кереп югалдылар. Бергәләп көрәшер өчен аларның каннары кушылды. Гыйлфанның канында ракка каршы көрәшүче тылсымлы «ТФ», һичшиксез, булырга тиеш.

— Арыдым... Йоклыйм хәзер...

Бибиса юрганын иягенә чаклы күтәрә дә, уң як яңагын мендәргә куя. Доктор яулык очы белән аның борын очына бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртә...

Гыйлфанның кулын дымлы кайнар нәрсә өттереп алгандай булды. Күзләрен йомган Бибиса, саташкан сыман, докторның кулын үбә... Гыйлфан иелгән килеш хәрәкәтсез калды. Аннары Бибисаның куклшел күз кабакларына, дерелдәгән керфекләренә сак кына иренен тидерде...

Ул көн төш кебек узды. Мәмдүзә килде, нидер кайнатты, Бибиса эчте. Тагын ятты, тагын төш күрде.

Биек ярның нәкъ читендә йөри. Яр убылып китә, Бибиса шуып төшә. Елгага төшеп чумдым дигәндә, ниндидер үләнгә тотынып кала. Вак кына сары чәчәкле. «Гөлбадран ул, ычкындырма», ди бер тавыш. Башын калкытып караса, яр өстендә Гыйлфан басып тора. Бибиса чәчкәгә чатырдап тотына да, аска карый. Яр астында сары батккак, төшсәң, йөзеп чыгарлык түгел. Үкчәсе белән ташта киртләч ясап, Бибиса шунда баскандай итә. Инде шуып төшү куркынычы юк. Өскә карый: текә яр, менеп җитүе, ай-һай, авыр булачак. Тырнак очлары белән киртләчләр чокый-чокый, күтәрелергә кирәк...

Көннәрнең берендә Бибиса урамга чыгып, дөнья күреп кирәргә уйлады. Җылы башлык, җылы бишмәт киде. Күзендә сары бетсә дә, кара күзлеген дә калдырмады. Дөрес эшләде, чөнки очраган берсе аңа текәлеп карый төсле. Ихатада үскән сәрби куагы янындагы эскәмиягә утырды. Озак та үтми, аның тирәсенә карчык-корчык җыелды. Кызгандылар, сораштылар. Бибисаның бу темага сөйләшәсе килми иде, урамга чыкты. Искиткеч кояшлы көн. Чаган яфраклары алтынсу-сары. Әллә Бибисаның сарысын бүлешеп алганнармы? Бөтен авыруларга дәва — табигатьнең үзендә, ди Гыйлфан. Бибиса ике кулын кесәсенә тыгып, тар урамның тротуары буйлап китте. Сырлап-сырлап үрелгән тимер капкага җитте. Ян капка ачык. Балалар бакчасы. Эчтә беркем юк, бүген якшәмбе. Аллеялар буйлап атлый. Кулын болгый-болгый, ишектән юан хатын чыкты:

— Кемне эзлисез монда?

— Эзләмим.

— Нишлисез монда?

— Йөрим...

— Монда керергә ярамый, паркка барыгыз!

Бибиса капка ягына борыла. Хатын моның сүз тыңлаучан булуыннан батыраеп, кычкыра ук башлый:

— Тапкан гулять итәр җир, монда свидание урыны дип белдеңме?! Паркта гулять итегез!

Әрепләшергә, аңлатырга Бибисаның теләге юк, көчне сарыф итәргә ярамый, яшисе бар. Маҗаралы сәфәрдән соң арыганын сизде, чишенеп ятты.

Кыңгырау моңы. Бибиса йокыга киткән икән, күзен ачты. Электр кыңгыравы белән Гыйлфан башта шулай аваз бирә, аннары ачкыч белән ишекне ачып керә.

Гыйлфан бик вакытлы килде. Бераз соңлады соңлавын. Шулай яхшыдыр да. Икенче тапкыр озак килми торуы икесе өчен дә файдагадыр. Иртәрәк килсә, тыелгысыз хисләр белән Бибиса сәхнәгә чыга алмас, халык алдында күңелен шәрран-яран ача алмас иде. Ниһаять, Гыйлфан аның йөрәк тавышын ишетте. Тылсымчы кебек килде дә, бәгырь ташын эретте.

— Гөлбадраным...

— Шундый озак көттем сине...

— Җирдән йолдызга чаклы ара якын түгел шул...

— Яшьләргә минем өчен килдеңме?

— Мин дөньяга ук синең өчен килдем...

Көянтә-чиләкле Ай кызы, хәйран булып, бу икәүгә карый. Бүген бәдер көне, ай тартуыннан гөлбадран чәчәге ачылган көн...

## Чылбыр

### 1

Хирург тормышында операция кичергән авырулар чылбыр бөҗралары сыман, берсе ычкынса, кабат ялгар өчен бөтен тормыш тәҗрибәңне, йөрәк көчеңне җыеп тупларга кирәк. Бөҗраларны ясау һәм тезү эшенә китаптан өйрәнеп булмый, институт һәм дәреслекләр гомум юнәлеш кенә бирәләр. Бу һөнәргә Аллаяров үз маңгай тирен түгеп өйрәнде. Өченче курста укыганда ук ул операция өчен гади җайланмалар уйлап чыгара башлаган иде. Ул чакта аны тиз күрделәр, мактадылар, шауладылар. Үзәктән китеп, практик эшкә күмелгәч, яшь врачның һәр яңалыгын күтәреп алучы булмады, Аллаяров үзе

дә шаулап йөрмәде, чөнки жайланмаларны ул күргәзмә өчен түгел, эш өчен ясады. Хирурглар җәмгыятендә әйттеләр: карале, коллега, эгоист булма, бүтәннәр дә файдасын күрсен. Шуннан соң яңалыкларның кайберләре республика һәм үзәк медицина журналларында басылып чыкты. Аллаяров практикага керткән кан тамырын тегү аппараты белән диссертация якларга була, диделәр шул ук хирурглар җәмгыятендә. Аллаяров диссертация мәсьәләсендә хәтта талпынып та карады, ләкин бу эшнең вак-төяк мәшәкате ерып чыга алмаслык күп икәнлегенә ышангач, ташлады. Җирле анестезия өчен ясаган шприц-автомат хирурглар практикасында киң кулланыла торган ысул булып китте. Авыруның тәнендә операция урыны әзерләгәндә вак тамырлардан кан агуны тиз туктатыр өчен ясалган термо-пинцет хирургның эшен кызу тотарга мөмкинлек бирде. Зона буенча хирурглар җәмгыятендә Аллаяровның исеме зур белгечләр рәтендә йөри. Хәзер ул югары категорияле хирург. Мондый дәрәҗә аңсат кына бирелми: матбугатта чыккан хезмәтләрең, төрле өлкәләрдән катлаулы (һәм уңышлы!) операцияләрең, житәрлек хезмәт стажың һәм тагын кайбер сыйфатларың булырга тиеш. Һәрхәлдә, монда саналганнарның беренче өчесе Аллаяровта бәхәссез. Авырулар һәм коллегалары арасында абруе бар. Октябрь бәйрәме көнне демонстрация вакытында халык төркеме арасыннан ак сакаллы карт йөгереп чыгып, Аллаяровның хәтта кулын үпте. Хирург аңа яңа бәвел куыгы куйган иде. «Сез минем аллам», диде, нәкъ трибуна каршында медиклар сафы алдына чыккан карт. Шундыйрак рәхмәтләрне Аллаяров телдән дә, язма рәвештә дә ала тора. Тик менә Камилла Асадовна Алкина гына хирургның казанышларын танырга теләми. Белдерүләр тактасына күптән түгел тагын бер шелтә элеп куйды. Бусы таракан аркасында. Больницага чисталык комиссиясе килгән иде, барлык бүлекләрне тикшереп йөрделәр. Хирургия бүлеген дә читләтеп узмадылар. Читләтеп узмау гына түгел, сыйпап карамаган бер тәрәзә рамы да, бер гөл яфрагы да калмады. Аш тарату бүлмәсе янына килделәр. Нинди хикмәт килеп чыгар икән инде дип, бүлек мөдире сагаеп торганда, үзенең дәрәҗәсен белеп кенә, галәмәт олы таракан килеп чыкты. Озын өстәл буйлап, җай гына атлап бара бу. Кая ул ашыгу да, кая ул тизрәк берәр ярыкка кереп качу! Җыелган халыкның аңа махсус игътибар күрсәтүен сизеп, урта бер җирдә тукталып ук калды. Мыегын селкетеп, ак халатлы адәмнәргә карап тора. «Мыегын да селкетми» дип әйтә алмыйсың инде бу очракта. Нәтиҗәдә, антисанитария өчен Аллаяровка шелтә.

Әйе, күнел рәнжерлек күп җәфалар күрде Аллаяров баш врачтан. Шулай да шифаханәнең баш врачы Камилла Асадовна соңгы елларда моңсуланып китте. Башта ул моны олыгаюга юрады. Әле ул жирендә, әле бу төшендә авыртулар ешайгач, Казанга барып, профессорларга күренде. Алар исә беравыздан «операция кирәк» диделәр. Алкина операциягә ятарга тиеш! Бу хәбәр Яшьләр больницасына яшен тизлеге белән килеп житте. Яшеннән соң күкрәү дә була бит әле. Больница хезмәткәрләрен иң нык тетрәткән нәрсә нәкъ әнә шул күкрәү иде. Алкина операцияне Аллаяровтан ясатачак!

Моңа чаклы больницада операция ясаткан врач булмады, сирәкмирәк андый мохтаҗлык чыккан очракларда Казанга, профессорга баралар иде. Ә бит Алкина гади врач түгел, баш врач... Ни өчен операцияне аңа Аллаяров ясарга тиеш? Бу хакта Камилланың үзеннән генә сорашып белергә буладыр. Ә ул үзенең эч серләрен теләсә кемгә ача торганнардан түгел. Һәрхәлдә, Аллаяров тагаен генә бер нәрсә дә әйтә алмый. Баш врач үз больницасының хирургына ышаныч күрсәтә, язмышын аның кулына тапшыра — вәссәләм.

Операция өстәлендә әйтерсең ак мәрмәр сын ята, пычак тидерергә кызганыч. Мондый асыл сөякне еш күрергә туры килми. Хирург каршына күбрәк ите сөяктән аерылган шәлперәйгән гәүдәләр килә. Шулай, Камилла ханым, син дә хирург алдында шыр ялангач. Татарчагына әйткәндә, тыпырчынма, Камиләкәй, хәзер без сине, профессор Алексеев әйтмешли, бик әйбәтләп кисәбез. Хирургия бүлегеннән анадан яңа туган кебек чыгып китәрсең.

Аллаяров үз хәрәкәтләренең житезлегеннән ләззәт тапкандай, операция кырын җәһәт кенә ак япмалар белән әйләндереп алды. Жонглерларча матур селтәнеп, йод сөртелгән тәнне скальпель белән сызып төшерде. Аллаяров скальпеленнән кан кача дип сөйлиләр хирурглар. Хак сүздер, ассистент белән бергә, ике фокусник кебек нечкә тамыр очларын төенләп бетереп киләләр, кан акканы күренми. Ягез, карыйк, мәрмәр сынның эчендә нинди яшерен серләр бар?

Хирургның маңгаена мул булып тир бәреп чыга. Янәшәсендәге интерн үрелеп сөртә, сөртеп бетерә алмый.

— Эчке яктан тәрәзәне ачыгыз...

— Ачык...

— Жылыткыч батареяләрен шул чаклы кыздырмасалар да ярар иде, алдан әйтеп куярга онытылган.

Операционныйда халык күп булуга карамастан, гадәттән тыш тынлык. Ни күреп кереп тулганнар? Беркем кермәсен дип сөйләшкәннәр иде. Алкина Казаннан профессор чакыртуга да каршы булды.

Бүлмәгә өлкән сестра кереп, хирургның җилкәсе аша дәшә:

— Гинекология бүлегенә Казаннан профессор килгән, хәзер урынбасар бүлмәсендәләр, керергә рөхсәт сорыйлар.

Аллаяров интернның кулбашына маңгаен сөртеп ала. Урынбасар ханым тәки профессор чакырган икән. Андый-мондый хәл булса, кул кушырып утырмадылар, чарасын алдан күрделәр, янәсе.

— Керсеннәр...

Ике минут үтүгә баш врач урынбасары олы кунак ияртеп керде. Аллаяровның җилкәсе аша профессор өстәлгә үрелеп карый. Буйга ул хирургтан шактый тәбәнәк, карарга җайлы булсын өчен, аяк астына кечкенә эскәмия куялар. Артыграк үрелеп, авып китмәгәе дипме, интерн аны тотарга әзер тора. Интернга бөтән шөгыль табылгач, хирург хәзер маңгай тирен «мәрмәр сын»ның аяк очындагы җәймәгә иелеп сөртә. Бөтен күзләр Аллаяров кулына текәлгән. Профессорның сузылган муенында зәңгәр кан тамыры бүртеп тора. Менә, хирург яшерен урыннан кечерәк кавынга охшаган түгәрәк нәрсә кисеп алды да, ярылмасын дигән сыман, саклык белән генә идәндәге табакка салды. Шуны гына көткәндәй, профессор эскәмиядән ялт кына төште, табакны эләктереп алды да, читкә китте. Ак яу аның артыннан иярде. Операция өстәле янында хирург, ассистент, операция сестрасы калды. Хәтта анестезиолог та наркоз өрдерүдән тукталып, табакка күз төшереп килде. Маңгаеннан, битеннән чишмә булып аккан тирен Баязит өстәлдәге ак җәймәгә сөрттереп алды.

Ассистентлык иткән Кылычбаев «ак яу» ягына күз салды. Профессор «кавын»ны кискәли, бүтәннәр ач күзләре белән табакка текәлгәннәр. Ике арада йөргән җыештыручы Нажия операция сестрасына карап, «кавын»га ымлый:

— Ошамый мина...

Профессор тагын хирургның җилкәсе аша карый, үзенең фикерен житкерә. Аныңча, кисеп аласы әйбер тагын бар. Сабанаевага операция ясаганда, профессор урынында Алкина торган иде. «Әллә кисмисезме соң?» — дигән иде. Хирург Алкинаны тыңламады. Бу юлы профессор-

ны тыңламый. Кисүе кыен түгел, кисми калдыру җаваплырак. Табигать кешегә бер артык әйбер дә куймаган, бар да кешенең камиллеге өчен яратылган.

Профессор хирургның кетгут[1] экономияләвенә игътибар итә. Ни өчен Аллаяров аның киңәшен тотмавы турында ул соңыннан җентекләбрәк уйланыр. Хәзергә аның игътибары хирургның кулында. Кырык сантиметр җеп белән хирург өч төен бәйли. Кетгутка кытлык еллардан калган гадәт. Яхшы гадәт. Укучыларын хирург саклыкка өйрәтә. Югыйсә, күпме хезмәт салынган әйбернең туксан тугыз проценты файдасызга чыга. Чит илдә салфетка, мамык, җеп ише әйберләрне экономияләргә мәҗбүр булган Кылычбаев та бу хәлгә башта гаҗәпләнгән иде. Аллаяров әнә, әрәм-шәрәмгә юл куелган җирдә муллык булмаячак, ди.

Бөтен халыкны гаҗәпкә калдырып, операция бүлмәсендә бер чебен очып йөри. Кирәк бит, профессор килгән көнне...

— Эчке тәрәзәне ачкан идек бит, тәрәзә арасыннан чыгып тереләгән ул.

— Спирт белән исерт син аны, Нажия.

— Ничек исертим соң?

— Тот та, авызына сал...

Аллаяровның теле ачылды, димәк, операция уңышлы тәмамлана. Башкалар да үзара сөйләшә, бер-берсенә карап елмаеша башладылар.

— Сәгать ярым! — диде анестезиолог, наркоз өрдерүне туктатып, беләгендәге сәгатенә карагач.

Фәрханә алгы яктагы стена сәгатенә карап, аны төзәтте.

— Бер сәгать тә егерме җиде минут.

Баш врач урынбасары белән профессор күңелле генә сөйләшеп, чыгу ягына киттеләр. Урынбасар ханым, ике бит уртасында матур чокырлар ясап, «менә бездә нинди белгечләр бар!» дигән сыман елмая, тегесе разый булып баш кага. Хирург исә «мәрмәр»гә тегү әнәсе белән соңгы бизәкләр төшерә.

### 3

Аллаяров театр афишаларына күз сала торган булып китте, таныш исем эзләде. Ниһаять, тапты. Татарстанның атказанган артисткасы Бибиса Сабанаева. Кулында спектакльгә билетлар булса да, күрәсе килгән исемне табалмам дип, хәвефләнебрәк эзләгән иде. Ни гомер шифаханәгә аяк басмаган Сабанаева, чакыру билеты төсендә килеп, хирургны гаҗиз калдырды. Афиша белән чагыштырып, билетларның чынлыгын дөресләгәч, хирург җил-җил атлап үз юлына китте. Сабанаеваның авыру тарихын сөйләсәң, бер хирург та ышанмый. Яки Аллаяров шыттыра, яисә анализда хата киткән диләр. Ә Кылычбаев докторлык диссертациясе яза. Темасы бик хикмәтле: «Ракны дәвалауга уңай эмоцияләрнең тәэсире». Яшьләрдә ул шактый материал җыйган, төп козыре Сабанаева. Фәннәр кандидатының сайлаган темасы баш хирургның йөрәген чеметтереп куйды. Аллаяров эшли, башкалар нәтиҗә ясый. Ә бит Аллаяровның скальпеле кичекмәстән эшкә тотынмаса, актрисаның, күп дигәндә, ай ярым гомере калган иде. Скальпель үз эшен эшләгәч, әлбәттә, химиотерапиянең ярдәме зур булды. Алай дисәң, Казаннан кайткач, авыруның бавыры нормадан зуррак иде. Аллаяров ул чакта кан юлы белән таралган фетнәче күзәнәкләр бавырда тукталып, «ныгытма» кора башлаганнар дип фараз кылды.

---

[1] Кетгут — сарык эчәгесеннән ясалган җеп, операция җөйләре тегү өчен кулланыла.

Хәзер исә бавыр шештән түгел, ә химиотерапия биргән токсикоздан ялкынсынган дип уйларга кала. Гомумән, анамнез[1] серле, һәм Кылычбаевның аны өйрәнергә алынуы мактауга лаек. Тире белән сөяккә калган авыру кыз да исән-сау, анысына операцияне Кылычбаев үзе ясады.

Җыеп кына әйткәндә, Кылычбаев талантлы доктор. Үз эшен әдәм рәтле итеп эшлим дигән һәр кешегә азмы-күпме талант кирәк. Кеше гомерен пычак очында тотучы чын талант иясе булырга тиеш.

Куелачак спектакль турында сестра кызлар таныш артисткаларыннан мәгълүматлар алып өлгергәннәр. Драматург бу пьесаны Бибисара Сабанаевага багышлап язган, бөтен артистлар алдында шулай дип әйткән. Язучы үзе премьерага киләчәк ди, өйләнмәгән егет икән, героинясына күңеле төшмәде микән?.. Шәфкать туташлары спектакльдәге җырны да өйрәнергә тырышып, мөңгерәп йөрделәр:

...Сырхауларга дарулар бар,
Сагнуларга юк чара,
Бибисара-а-а...

Аллаяровлар парлап, карлы юлдан шыгыр-шыгыр атлаганда, билгесез һәм таныш хисләр белән дулкынланып бардылар. Ашыксалар да, соңга калдылар, өс киемнәрен салып кергәндә залда ут сүнгән, сәхнә ягыннан музыка яңгырый. Иелә төшеп, үз урыннарына кереп утыруга пәрдә ачылды.

Антракт вакытында Аллаяровлар фойега чыкмадылар, башта да соңга калгач, бөтенесенең күзенә чүп булып керүләреннән кыенсындылар. Аннары, Баязит тартмый, медицина практикасына керешкәч тә ташлаган иде. «Хирурглар җәмгыятенең күчмә утырышын биредә уздырырга мөмкин икән» дип уйлады ул, үзалдына шукланып. Уңышлы узган катлаулы операцияләрне нигезләп, дәлилләп күрсәтер өчен җәмгыятьнең конференцияләренә пациентларның үзләрен чакыралар. Бер метр нечкә эчәк белән яшәүче Сәгыйтов, үпкәсенә пычак җәрәхәте алып, консерватив юл белән дәваланып чыккан лейтенант... һәм бик күп башкалар... Актриса өчен спектакльдән дә әйбәтрәк демонстрацияне уйлап табып булмый. Бу хакта Баязит шаяру катыш Дәлиягә әйткән иде, тегесе күтәреп үк алды:

— Соңгы спектакльләре түгелдер, обязательно алып кил хирургларыңны...

Сәхнә йолдызының Баязит өчен бары тик пациент булуы Дәлияне үстереп җибәргәндәй итте. Икенче бүлектә бүтәннәр кулъяулыкларын күз тирәсенә тидергәләгәндә, ул үзенең сөйкемле борынын җебетмәскә тырышып утырды.

Артистлар сәхнә алдына басып, кат-кат баш игәч, залдан авторны чакырдылар. Чем-кара чәчле, кара мыеклы егет дәррәү алкышлардан бераз югалып калды, кинәшче эзләгәндәй, як-ягына каранып алды. Сәхнә артыннан пәйда булган озын буйлы, шәм кебек төз гәүдәле режиссер аның кулын кыскач кына, нишләргә кирәклеген абайлап, артистларның кулларын кыса башлады. Героиняның кулын бик нәзакәтле итеп үпте... Дәлия антракттан соң залга кереп килүче Кылычбаевны күреп калган иде, ул утырган якка борылып карады. Яшь хирург бүтәннәр сыман артык кабынып китми, салмак кына учын учка тидерә...

4

— Бүген бәдер көне...
— Соң?
— Ай тулган көн бүген, Бибисара, гөлбадран чәчәге ачылган көн...
— Кар өстендәме!

---

[1] Анамнез — авыру турында белешмәләр.

— Бөтен кыйммәте дә шунда, — Гыйлфан Бибисарага кипкән чәчәк сузды. — Кичәге җиңүең белән!

— Кичә... үзең күрдең бит, Гыйлфан... Мина... бәхетле булырга ярамый.

Гыйлфан аңлады бугай, гаҗәпләнмәде, тын гына утыра бирде. Кичә спектакльдән соң ул таныш тротуар буйлап байтак йөрде, Бибисараның тәрәзәләре караңгы калды. Урамның теге очыннан күңелле төркем бу якка якынлаша башлагач, тыкрыктан түбән төшеп китте, ерак тукталышка барып, троллейбуска утырды. Бибисаны күзәтеп йөриме әллә? Гыйлфан үз-үзенә ямьсез күренде. Артистларның премьераны билгеләп үтүләре табигый, автор үзе дә килгәч...

Бибиса утырган урынынан торып, бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады.

— Бәхетсез кеше бәхетлене уйный икән, ул үзенең хыялын күз алдына китерә. Ә бәхетле... Бәхетсезне...

Гыйлфан Бибисаның сүзләрен чынга алмый бугай, һаман сынап карый, карашында ләкин шикләнү түгел, соклану чагыла. Аның карашыннан Бибиса үз сүзләренең чынлыгына үзе ышанмый. Ул, ахрысы, уйный, кичәге героинясы халәтеннән арынып җитә алмаган... Шуны абайлап, йөргән җиреннән шып туктады, бүлмә уртасында басып калды. «Бусы да поза» дип уйлады үзе турында. «Менә мин нинди сәламәт, сылу» янәсе, шуны күрсәтәсең киләме? Сәхнә түгел бу, айны, ниһаять! Чит кеше сыман тахта читенә килеп утырды. Бусын да ошатмады. Нигә урындыкка түгел, тахтага? Янына Гыйлфан килеп утырсын өченме? Ялганы тотылгандай куркып, Гыйлфанга карап алды. Курыкканы сизелмәсен өчен, ашыгып әйтте:

— Айга бер ачыла торган чәчәкнең ни хаҗәте бар сиңа? — Куңагы һаман дәшмәгәч, авыр сулап, өстәде: — Мин режиссерлыкка укырга китәргә уйлыйм...

Гыйлфан, чыннан да, урындыктан тахтага күчеп, Бибиса белән янәшә утырды. Актрисаның ни әйтергә теләгәнен Гыйлфан, әлбәттә, бик яхшы аңлады. Сәхнәдә үзен югалтудан курка ул. Чөнки Гыйлфан аны үз ихтыярына буйсындырды, бөтенләй яулап алды. Аларның каннары кушылды... Күп тапкыр... Гыйлфан Бибисаның ихлас сөйләмәвен дә сизми калмады.

— Миңа да бит чамадан тыш бәхетле булырга ярамый, — диде ул, ике тезенә таянып утырган җиреннән кызга борылып карап. — Югыйсә, кеше хәсрәтен аңламый башлармын.

Башларына уй төшкән ага белән сеңел сыман күпме шулай янәшә утырганнардыр, көянтә-чиләкле Ай кызы гына тәгаен белә. Хәер, икәүдән-икәү генә артык озак юаналмаслар, икесен ике төбәктә юл чатына чыгып баскан язмышлар көтә.

1976—1978. Әлмәт.

Ләбибә Ихсанова

# СТЕЛЛА — ЙОЛДЫЗ ДИГӘН СҮЗ



Машинаның йомшак миндәренә аркасын терәгәч кенә Равил, көндезге ыгы-зыгыларның, юлга җыену мәшәкатьләренең артта икәнен уйлап, җиңеләеп, тынычланып калды. Каршыга йөгереп килгән ак каеннарга, юл читендәге бетон түмгәкләргә, тәгәрмәч астына шуышып кергән юеш асфальтка игътибарсыз гына карап бара башлады. Бераздан бүген әле газеталар укымаганы исенә төште. Чыгып китешли генә алып кесәсенә тыккан «Правда»ны ачты. Кыр эшләреннән хәбәрләр... Укытучылар съезды... Бер төркем укытучыларга Социалистик Хезмәт Герое исемен биргәннәр. СССР Верховный Советы Президиумының хезмәт алдынгыларын бүләкләү турындагы указларын таныш фамилияләр очрамасмы дигән бер кызыксыну белән карый торган иде ул. Әллә арыганлык, әллә гамьсезлек булды, бу юлы газетаны күңел күзе белән түгел, өстән-өстән генә карап чыкты да икенче битен ачарга җыенды. Шул вакыт кемдер аның янтыгына төртепме, колагына пышылдапмы әйтте кебек: игътибар беләнрәк кара!

Равил билгесез шушы тойгыга буйсынып, газетаның беренче битенә яңадан кайтты һәм менә сиңа! Ничек күрмичә уздырган соң әле бу исемне. Фамилиясе булмаса районы, туган авылы игътибарны тартырга тиеш иде бит. Акка кара белән язганнар лабаса: Габдрахманова Стелла Зәкиевна. Татарстанның Арча районы Яңа Кенәр урта мәктәбендә рус теле һәм әдәбият укытучы.

— Стелла Зәкиевна!

Таксист пассажирының тавышын ишетеп, ләкин ни әйткәнен аңламыйча, борылып карады.

— Знаешь, друг, моей учительнице дали героя! — диде Равил, егетнең җилкәсенә кулын салып.— Учительница, которая учила меня русскому языку — герой труда! Понимаешь ты этого или нет?

Таксист сүзчән кеше булып чыкмады. Гаҗәп хәл түгел, дигәндәй елмаеп, иңбашларын җыерып куйды. Шоферның битарафлыгы Равилне бераз җәберсендерде, билгеле. «Шундый зур хәбәрне ишетеп сөенми калырга мөмкинме соң инде? Күрсә икән ул Стелла Зәкиевнаны, бер генә утырса икән аның дәресендә!» — дип уйлады.

— Укытучыларга герой исеме бирү бик кирәк ул,— диде таксист, бераз баргач кына.— Әле өйдә бер бала белән ни эшләргә белмисең, алар 30—40 баланы кеше итеп чыгаралар. Уен эш түгел ул.

Равил яшь кеше. Шулай да мәктәпне тәмамлап үзенең яраткан һөнәрен тапканчы шактый кыенлыклар күрде. Күңеле төшеп, ихты-

ярсыз калган чакларында Стелла Зәкиевнаны исенә төшереп, күңеленнән генә булса да аның белән киңәшә. Ул биргән дәресләрдән, мәгънәсенә ул төшенергә булышкан тормыштан гыйбрәт алырга тырыша иде. Равил чая малай булып үсте. Әдәби геройларның да Камо, Чапаев, Маресьев кебекләренә тартыла, аларга охшарга тырыша иде. Мондый геройлар турында сөйләгәндә укытучының гадәттәге тыныч һәм йомшак тавышы ук үзгәрә. Дөрләп янган учак кебек, бар класска утлы очкыннар чәчә һәм ул очкыннар балаларның йөрәгендә кабына да күзләрендә нур булып яна башлый. Стелла Зәкиевна Александр Твардовскийның «Василий Теркин» поэмасын яттан, артистлар укыган кебек, сөйләп чыккач, тәэсирләнүдән соң чиккә җиткән укучылар беравык сүз дә әйтә алмый утырганнар иде. Ул бервакытта да ирексезләп укытмый, балалар үзләре аның дәресләрен сагынып, көтеп ала торган булдылар. Бу дәресләрнең һәркайсын укучылар үзләренчә кичергән, үзләренчә истә калдырганнардыр. Ә менә Равилнең әледән-әле искә төшергәне «Нәрсә эшләргә?» романын үткән чак булды. Яшүсмернең күп сорауларына җавап бирде ул дәресләр. Чын кеше нинди булырга тиеш? Бу сыйфатларны үзеңдә ничек тәрбияләргә? Чын кешеләрнең бер мисалы итеп, Стелла Зәкиевна роман авторының тормышын сөйләгән иде. Егерме бер ел салкын себер төрмәләрендә газап чиккән, яшьләгән, сәламәтлеген шунда калдырган, алай да көрәштән туктамаган, халыкның җиңүенә өметен җуймаган Н. Г. Чернышевскийны ул аллалар кабызган утны урлап кешеләргә бүләк иткән һәм шуның аркасында мәңгелек газапка дучар булган Прометей белән тиңләгән иде.

Анри Барбюсның революционерлар турында әйткән сүзләрен дә хәтердә калдырды Равил. «...Горизонтта төрмә, сөрген, дар агачы чекрәеп тора. Бу эш белән теләсә кем шөгыльләнә алмый. Тимер сәламәтлек, барын да җимереп ташларлык энергия кирәк. Туйганчы йокы йокламаудан рекорд куярга, шуның чемпионы булырга кирәк. Ачыга белергә һәм салкыннан тешләрең шакырдаса да түзәргә, тешләреңне коеп бетерсәләр дә, кызган тимер басып җәзаласалар да түзәргә, көрәштәшләреңнең исемнәрен, адресларын әйтмәскә кирәк. Ләкин бу да җитми әле. Җелекләреңә хәтле өмет белән сугарылган булырга тиешсең. Хәтта иң дәһшәтле минутларда да җиңүгә ышанычны югалтмаска кирәк». Бу сүзләрне дә ул Стелла Зәкиевна дәресендә ишеткән иде.

Әнә шул дәресләр, мәктәп походларында, бәрәңге, чөгендер басуларында сөйләшкән сүзләр эзсез калмаган икән. Анри Барбюс әйткән сыйфатларны үзендә тәрбияләгән Рахметов образын үрнәк итеп алды да Равил, әз генә булса да шул идеалына охшарга тырышып яши башлады. Хезмәтнең дә ул авырын, үзеңне һәр вакыт тәртиптә тотарга кирәген, корычтай ныклык, сәламәтлек таләп иткәнен, берни белән хисаплашмыйча, тормышыңны халык интересларына буйсындыра белүне сораганын сайлады.

Укытучысына герой исеме бирелү турындагы хәбәрдән соң менә ничә көн инде Равилнең күңеле гел туган якларында, якташлары, укытучылары янында булды. Газетаның Указ басылган битен кисеп, китель кесәсенә салып куйды. Аннан утырып, озын итеп, Яңа Кенәргә хат язды: «...Мәктәп еллары, 9 һәм 10 классларда укып йөргәннәр искә төште. Сез һәм башка укытучылар турында гел уйладым. Мәктәптән киткәнгә 5 ел бит инде. Төрлебез төрле якка таралдык. Олы юлга төрлечә чыктык. Минемчә, безнең күбебез мәктәптә алган яхшы сыйфатларны сакларга тырышты. Сез безне кеше булырга, тормышта үз урыныбызны таба белергә өйрәттегез. Мин үзем Сез биргән рус теле һәм әдәбияты дәресләрен еш хәтерлим. Кыюсыз һәм оялчан укучыларыгызда да үз көченә ышану сыйфатларын булдырырга

тырыша идегез. Яшь белән бергә тәҗрибә дә арта икән ул. Тирәюньгә дә ачыграк күз белән карыйсың. Мәктәптән соң кичергәннәремне сөйләп бетереп булмый, баштан кичкән кайбер хәлләрне . әле хәзер дә аңлатып бирә алмам кебек. Күтәрелгән, түбән төшкән вакытлар, уңышлар һәм хаталар булды. Характер формалашу чорын үттем, ахры. Шул авыр чакларда мин юлымда очраган әйбәт кешеләрне, шулар белән бергә Сезне дә, Стелла Зәкиевна, уйлый идем. Билгеле, Сезнең кебек булырга ерак әле миңа, кадерле укытучым. Ләкин мин Сезгә охшарга тырышам. Тормышымда Сез һәр вакыт минем укытучым булырсыз.

Хәрби сәлам белән Равил».

Егетнең хатын Стелла Зәкиевнага рус теле һәм әдәбияты кабинетында тапшырдылар. Мәскәүдән, укытучыларның Бөтенсоюз съездыннан алып кайткан материалларны стендларга куялар иде. Балалар булышлыгы белән үзе төзегән шушы кабинетта эшләргә ярата ул. Стенада рус әдәбиятына олы мирас калдырган язучыларның портретлары. Аларның акыллы-зирәк күз карашлары белән очрашкан саен укытучы үзендә рухи көч артканын сизә. Үзе биргән дәресләргә тагын да яратыбрак әзерләнә башлый. Л. Толстой да: «Үз фәнең белән балаларны тәрбияләргә уйлыйсың икән, син аны башта үзең ярат һәм үзең яхшы бел»,— дигән бит. Кабинет стеналарында әдәбият корифейларының әнә шундый акыллы сүзләре язылган таблицалар күп. Аларның әсәрләре турындагы фәнни хезмәтләрдән өзекләр, газета-журнал битләрендә бүгенге көн әдәбиятына карата басылган рецензия һәм тәнкыйть материаллары аерым альбомнарга җыелып бара. Колхоз клубында лекция ясыйсыңмы, чираттагы сочинениегә әзерләнәсеңме, я шушы бүлмәдә үткәргән әңгәмәләрдә сөйләргә нигез ителәсе сүзләр эзлисеңме — теләсә кайсын ач та кара. Кабинеттагы һәр таблица, альбом, кино һәм диафильм тасмалары, рәсемнәр һ. б. бик күп материаллар кешелекнең гасырлар буе җыелган акыл сәләтен, яхшылыкка, сафлыкка омтылуын, намусын күрсәтерлек итеп тупланган. Шушы изге максатның билгесе булып, стенада эмблема тора: уч төбендә кояшлы шар!

Ашыгыч эше булмаганда да шушы бүлмәгә килә Стелла Зәкиевна. Укытучы хезмәтенең нечкәлекләре турында ялгыз гына калып уйланырга, бигрәк тә укучылары белән түгәрәкләнеп утырып, әдәбият һәм сәнгать, тормыш хәлләре турында сөйләшергә ярата.

Әдәби геройлардан башланган сүз кайвакыт язучының үз шәхесе турындагы әңгәмәгә әйләнеп китә. —Кешеләрне яраткан, аларның язмышын кайгырткан язучылар гына үлмәс әсәрләр бирәләр, —ди Стелла Зәкиевна. Бервакыт ул балаларга Чехов замандашының истәлеген сөйли. А. П. Чехов —Стелла Зәкиевнаның яраткан язучысы. Аның кешеләргә карата мөгамәләсе, гуманизмы бала чагыннан ук кызны әсир иткән иде. Еллар үткән саен бу хис сакланып кына калмады, аның әсәрләрен күбрәк укыган, аның турындагы истәлекләр белән танышкан саен үсә, ныгый барды. Дөрес, барлык балаларын да бертигез күргән ана кебек, Стелла Зәкиевна язучыларның барын да бердәй яратырга тырышты. Программа буенча үтелгәннәренә аерууча сак һәм игътибарлы була иде. Укытучының хисләре, мәхәббәте укучы балаларга да күчә бит. Мәктәптә алар барын да бер тигез яратсыннар, бердәй тырышлык белән өйрәнсеннәр. Үсеп җиткәч инде үз таләпләренә, үз зәвыкларына ирек бирерләр. Күңеленә аеруча якын булган Чехов турындагы истәлекне дә ул әңгәмәнең рухына туры килгән өчен генә сөйләде.

— Бервакыт шундый хәл була: санаторийда дәваланып яткан Антон Павлович кичкә таба буылып йөткерә башлый. Һава бөркү, яшенле яңгыр яварга тора. Андый чакта үпкәләре сәламәт кешегә дә тын

алуы кыен икәнен беләсез инде,— дип башлый ул әдип турындагы әңгәмәсен.— Менә җир бетереп күк күкри, яшен яшьни башлый, коеп яңгыр яварга тотына. Чеховның йөткергәнен тыңлап, кызганып яткан күршесе шул зилзилә арасыннан аның тавышын ишетмәс була. Бераздан яңгыр басыла, дөнья тына, тагын йөрәк яргыч ютәл тавышы килә. Соң дәрәҗәдә борчылган кеше күршесе янына керә һәм ак мендәрдә кан косып яткан язучыны күрә.

— Антон Павлович! Сезнең хәлегез авыр, ахры?— дип сорый ул күм-күк булган Чеховтан.

Антон Павлович аңа карап елмаерга тырыша:

— Кадерлем, мин сезгә йоклап китәргә комачаулыйм бит,— ди ул.

Сүзгә сүз ялгана. Берәүләр Тукайны искә төшерә, икенчеләре Муса Җәлилне телгә ала. Стелла Зәкиевна Муса Җәлилнең Абдулла Алишка багышлап язган «Дуска» дигән шигырен сөйләп күрсәтә дә:

— Мусаның Александр Фадеев белән дуслыгын беләсезме, балалар,— ди. Аннары Җәлилнең Мәскәүдә яшәгән, рус язучылары белән аралашып эшләгән чакларын сөйли.

— Мусаның билгесез язмышын ачыклауда Фадеевның тырышлыгы бик зур булды,— ди ул.— Мусаның тормыш иптәше Әминәгә хат язганда ул каты авыру була. Бу эш белән кая барырга, кемгә мөрәҗәгать итәргә кирәклеген киңәш итеп язган хатының ахырына да ул, авыру булмасам, үзем ярдәм итәр идем, дип куя. Шулай да шагыйрьнең язмышын ачыклаганда һәм аңа лаеклы бәя биргәндә иң күп тырышлык күрсәткән кеше Фадеев була.

Әнә шундый әңгәмәләрдән соң Стелла Зәкиевна үзе дә, укучы балалар да ничектер сафланган, күңелләре яхшырып калгандай булалар. Яңгырлы юлдан машина үткәндә өскә чәчрәгән пычрак, кояш чыккannан соң кибеп, коелып беткәндәй, сабыйларның йөрәк бәгырьләренә үтеп керергә өлгермәгән тормыш типлары шушы бүлмәдә юылып калгандай була.

Андый чакларда укытучы һаман бер уйга әйләнеп кайта. Балалардагы шушы сафлык, самимилекне гомерләренең ахырына кадәр җитәрлек итсә иде. Дөньядагы яхшы эшләр изге күңелле кешеләр кулыннан гына килә лабаса. Тормыштагы комсызлык, ялагайлык, карунлык, каты бәгырьлелек каян килә? Андыйлар да бала чакларын мәктәптә үткәргән, укытучысының күзенә карап дәрес тыңлаган бит, югыйсә. Кайда, ничек кулдан ычкындырабыз соң без аларны? Нәни башларына дыңгычлап белем тутырабыз да, кешелек сыйфатларына урын аз калдырабызмы әллә? Киләчәк бит безгә белемле кешеләр генә түгел, әдәпле, иң югары мораль сыйфатлы кешеләр тәрбияләү бурычын да куя.

Кайчагында Стелла Зәкиевна балаларның күзләренә карап кайсының кем булып үсәчәкләрен чамаларга тели. Күзгә кыю караганнары шатландыра аны. Кояшлы көндә ташлары ялтырап яткан тирән су төбен күргәндәй була. Әле генә хаты килеп төшкән Равилнең дә күзләре шундый якты, өметле иде. Бу малай да борчуны аз китермәде, югыйсә. Дәрескә әзерләнми килгәне дә, малайлар белән тиргә батып сугышкан чаклары да, укытучы әйткәнне эшләргә теләмәгән вакыты да булды. Ләкин бер генә тапкыр да алдалап, хәйлә корып котылу ягын карамады.

Баладагы шаянлык белән мәкерне аера белергә Стелла Зәкиевна иң элек әнисеннән, гомере буе укытучы булып эшләгән Зәйнәп ханымнан өйрәнде. Зәйнәп Лотфуллина Н. К. Крупская исемендәге Мәскәү Фәннәр академиясен (хәзер Герцен исемендәге Ленинград педагогия институты) тәмамлаган кеше. Казанда Халык мәгарифе комиссариатында эшли. Соңыннан, үзе теләп, авыл балаларын укытырга

китэ. Җырчы, биюче, авыл театрларының режиссеры һәм артисты, мандолина тотып өйдән-өйгә йөрүче агитатор Зәйнәп авыл халкында гына түгел, кызы Стелла күңелендә дә тирән эз калдырды.

Казан педагогия институтына укырга килгәч, Стелладан, ни өчен укытучы булырга телисең, дип сорыйлар. Буйга да җыйнак, тавышы да чак кына чыга, үзе бик юаш күренә, укучыларны тыңлата алырмы икән бу кыз бала, дип уйлаганнар, күрәсең. Шул чагында Стелла үзе дә сизмәгән бер тәвәккәллек белән:

— Әнием укытучы минем. Әнием кебек буласым килә,— дип әйтә.

Аның шушы тәвәккәллеге ышандырды, ахры.

Гомере буе халык арасында эшләгән Зәйнәп ханым кешене кешедән тиз аера иде. Кызын да шуңа өйрәтте:

— Авыру бала гына шаяра белми... я гадәттән тыш явыз бала. Син әнә шундыйларга игътибарлырак бул.

Өйдәге «педсоветларга» Стелланың тормыш иптәше, шушы ук мәктәптә физика укытучысы, ТАССРның атказанган укытучысы Хәбир Фәйзерахманович та, хәтта Стелланы карап үстергән әбисе дә катнаша.

— Син хәзер генә шундый, Стиллә бәбкәм, бәләкәй чакта, ай-һай, күрсәттең нужаны,— дип, һаман шул үзәгенә үткән бер вакыйганы сөйли башлый иде ул.— Бервакыт Стиллә суга баткан дип килеп әйттеләр. Һушсызлар калдым шуны ишетүгә. Атлап кына китә алмыйм бит аякларымны. Ничек барып җиткәнемне хәтерләмим, шунысы гына күз алдымда тора, тез өстенә каплап салганнар да бәбкәчемне, эчкән суын костыралар.

Йөз яшьлек әбинең бу хикәятен йөз кат ишеткән булсалар да, аның күңеле булсын диптер инде, бердәй кызыксыну белән тыңлыйлар. Әбинең оныклары Светлана белән Айдар хәтта сораулар бирә-бирә төпченәләр:

— Тагын, тагын сөйлә әле, әбием.

— Аннары ничек булган әле ул?

— Ничек дип, бала-чагадан җунле эш көтәсеңме соң инде. Мамык юрганнарга төреп кенә яткырыйм әле, мәтрүшкә чәйләре эчертим дисәм, урамга чыгам дип җирләр акырып җылый бит Стилләм. Югары очтан хәл белергә дип түтием килгәние. Шул әйтә, су җене кагылган, өшкермичә ярамас, ди. Шуны ишетеп кенә туктады. Инде йоклап китте, ахры, бу бала дип, без дә тынычлап чәй эчәргә чыктык... Самаварны каккач карасак, җилләр искән Стилләмнән. Тәрәзәдән төшеп качкан. Урамга чыгып сорашсам, су буена китте ул, диләр. Менә шулай үзсүзле идең син, бәбкәчем, бәләкәй чагында.

Үзсүзлелек бәлки балалык холкы гына булгандыр. Әмма тотынган эшен яратып, ахырга җиткергәнче эшләү гадәте Стеллада гомер буена калды.

Яратып укытканга аның дәресләре укучылар өчен мәҗбүри бер эш түгел, ә көтеп алынган сәгатьләр була. Ә дәрестән соңгы эшләр үзе бер күңелле дөнья. Әдәби кичәләр, рус теле атналыклары, сәнгатьчә уку ярышлары, әдәби темаларга КВНнар... Алар чыгарган әдәби газеталар, бюллетеньнәр яныннан атналар буе кеше өзелми.

Соңыннан мәктәпне тәмамлап чыккан күп укучыларның күңелендә әнә шул шау-шулы, мавыктыргыч еллар белән бергә рус теле укытучылары Стелла Габдрахманова да онытылмый саклана торгандыр.

Һәркемнең яраткан укытучысы була. Стелла Зәкиевнаның да бар андый кешесе. Сугыш елларында Ленинградтан күчеп килгән рус теле укытучысы Любовь Федоровна Приображенская ул. Кечкенә буйлы бу укытучының ак чәчләре күзләренең карасын тагын да карарак итеп күрсәтә иде, ахры. Җәйге җылы төн кебек шул кара күз-

ләрнең, талчыккан һәм хәсрәтле кара күзләрнең тылсымы бар иде дисәң. Бу күзләргә карагач, сугыш михнәте белән өшәнгән бала күңеле җылынып, яралары төзәлеп киткәндәй була иде. Арча урта мәктәбендә Любовь Федоровна укыткан балалар аның акыллы киңәшләрен әле дә булса онытмыйлардыр. Кыз бала булып үсеп килгәндә бик кирәк булган ул сүзләрне Стелла хәзер, үз тәҗрибәсен дә кушып, укучыларына тапшыра. Любовь Федоровнаның дәрес бирү алымнарын исә ул әледән-әле искә төшереп, аларны үзе дә файдаланырга тырыша. Ул вакыттагы рус теле һәм әдәбияты дәресләре күзәтүчән, тырыш кыз күңеленә нык сеңеп калган иде, күзең йомсаң, әле булса шул дәресләрдә утырасың кебек. Рус классикасының җәүһәре булган «Слово о полку Игорове»ны үткәндә укытучы балаларны кыпчак далаларыннан Ватан сугышы кырларына алып кайткан иде. Ерак тарихтан килгән козгыннар авазын түгел, бүгенге ерткычларның туп тавышларын ишеткәндәй булдылар алар, кылганнар арасында ятып калган борынгы батырлар урынына, немец фашистларына каршы көрәшкән әтиләрен, туганнарын, авылдашларын уйладылар. Ватан дигән төшенчәнең никадәр изге булуын, туган җирнең газизлеген, аны саклау өчен борын-борыннан күпме каннар коелганын Любовь Федоровна шул вакытта укучыларына бик гади һәм гыйбрәтле сүзләр белән төшендергән иде.

Яраткан укытучысының тагын бер сүзен хәтерли Стелла Зәкиевна. Шулай бервакыт ул укытучылар бүлмәсенә диктант дәфтәрләрен күтәрешеп керде. Буранлап торган кышкы көн кичкә авышып килә иде. Почмакларга караңгы иңгән. Лампочкадагы электр яктысы әлегә кызыл җеп булып кына яна. Аны соңыннанрак, караңгы төшеп беткәч кенә көчәйтәчәкләр. Любовь Федоровна әнә шул кызыл җепкә карап торды да шаярган булып:

— Менә шушы минутта бер могҗиза булсын иде дә, Ленинградның ак төннәре башланып китсен иде,— дип куйды.

Бу сүзләрдән Стелланың күңеле ачылып китмәде, боегып, моңсуланып калды. Шуңа күрә ул дәшмәде, башын иеп, әкрен генә ишеккә атлады. Укытучының сизгер күңеле ярым ятим баланың хәлен тиз төшенде, юатып, кыз баланыкыдай кечкенә һәм йомшак кулларын Стелланың арык иңбашларына куйды. Бу юлы инде җитди һәм уйчан тавыш белән:

— Синең исемең йолдыз дигән сүз, балакай. Исемеңә лаек булырга тырыш. Гомереңбуе кешеләргә яктылык бир. Шушы караңгы бүлмәдә әйткән сүземне онытма, Стелла ул йолдыз дигән сүз,— дип әйтте.

Уйлап карасаң Стелланың укытучы булуына юнәлеш биргән кешеләр Зәйнәп ханым белән Любовь Федоровна гына да булмаган икән. Кенәр урта мәктәбенең бөтен коллективы булышкан аңа. Йомыркадан гына чыккан чебеш кебек тәҗрибәсез кызга үрнәк алырлык кешеләр күп була бу коллективта. Математика укытучысы Кави Нуриҗанов аны үзенең җыйнаклыгы, төгәллеге белән сокландырса, Фаракшат Бигишева, мәсәлән, яшь коллегаларына аеруча игътибарлы булуы белән яраттырды.

Стелла Зәкиевна хәзер үзе рус теле укытучыларының куст методик берләшмәсе җитәкчесе. Фаракшат Нуриевна кебек ул үзе хәзер яшь укытучыларга булыша, әледән-әле ачык дәресләр бирә, өлкә матбугатында методик хезмәтләр бастыра.

Габдрахманова Равилгә җавап хаты язарга утырган иде. Кайчагында хат язу дәрескә әзерләнүдән дә кыенрак. Бигрәк тә үзеңдә укып чыккан кешеләр белән язышканда шулай була. Исәнлек-саулык хаты гына түгел бит. Укытучы язган хатлар тормыш турында сөй-

ләшүгә әйләнә. Теләсәң-теләмәсәң дә, андый чакта үзеңнең гомер сәхифәләреңне дә ачкалап карарга туры килә.

Укытучыдан бер читтә альбом карап утырган балалар арасында кинәт бәхәс купты. Берәүләр укытучылар съезды Кремльнең Зур Сараенда үтте, диләр, икенчеләре — Съездлар Сараенда, ди. Балалар арасындагы бәхәсләргә ашыгып кушылырга яратмый Стелла Зәкиевна, фикер йөртергә өйрәнсеннәр, дөреслекне үзләре табарга күнексеннәр, ди. Бу юлы балалар үзләре аңа мөрәҗәгать иткәч тә, эшеннән аерылмыйча гына:

— Укытучыларның 9 нчы Бөтенсоюз съезды Съездлар Сараенда, булды,— дип куйды.

Балаларның сорау бирүе сүз башлау өчен генә иде, шуңа күрә укытучының кыска җавабына канәгатьләнмәделәр, аларның күбрәк ишетәсе килә иде. Дөрес, бу съездда кунак булып катнашкан Стелла Зәкиевнаның сөйләгәннәрен ишеттеләр инде алар. Ләкин анда күргәннәрне бер-ике утыруда гына әйтеп бетереп буламыни.

Бу юлы да ул, кәгазьләрен калдырып, укучылары янына күчеп утырды.

— Күз алдыгызга китерегез әле, балалар. Менә сез Кызыл мәйданнан үтәсез, ди. Менә Кремль капкасыннан керәсез. Анда — бөтен дөньядан килгән туристлар, һәркайсы үзләренчә сөйләшә-сөйләшә, чал тарихның шаһите булган палаталарны, алтын башлы манараларны, музейларны карап йөриләр. Мәңгегә тынган туп көпшәсенә атланып балалар рәсемгә төшә. Ә сез, шуларга карый-карый, Съездлар Сараена барасыз. Каршыгызда ак мәрмәр бина тора. Аның диварында кызыл байрак җилферди. Советлар Союзының барлык республикаларыннан, өлкәләреннән җыелган укытучылар шул байракка карап килә. Әйтерсең лә бу бина дөньядагы иң яхшы кешеләрне җыеп, бер-берсе белән очраштыру өчен төзелгән.

Бу ел җәй яңгырлы булды. Шыксыз кара болытлар күк йөзеннән китеп тормады. Җир-күк, күзге көн кебек, иртә караңгылана иде. Стелла Зәкиевнаны тыңлап утырган укучыларның берсе дә бүлмәгә эңгер-меңгер иңүен сизмәде. Торып ут кабызырга да уйламадылар.

Шаулап килеп кергән хат ташучының тавышы гына сискәндерде аларны.

— Абау, нишләп караңгыда утырасыз?— дип, ул ишек төбеннән ут кабызып җибәрде, бүлмәгә көлтәсе белән нур чәчелде.

— Өегезгә үк төшеп тормадым, Стелла Зәкиевна, тукта әле, мин әйтәм, иң элек шкулдагы бүлмәсеннән карыйм әле, шунда утырмыймы икән дим. Сөенечле хатлар бит, көтеп ятмасыннар,— дип сөйләнәсөйләнә, Стелла Зәкиевна Габдрахманова алдына бер өем хатлар китереп салды.

Хатлар КамАЗдан, Казаннан, Чиләбе һәм Уфадан... Күбрәге үзендә укып чыккан егетләр һәм кызлар хаты. Съездда очрашкан коллегалары, республикабыз мәктәбенең рус теле укытучылары, яшьлек дуслары, таныш һәм таныш булмаган кешеләр яза.

Мәскәү я Казаннан гына түгел, район үзәге булган Арчадан да бик ерак утырган авыл укытучысын Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем алуы белән котлыйлар. Бу хатларны укыганда Стелла Зәкиевна Ленин шәһәреннән килеп, татар балаларын укыткан карт укытучының талчыккан, ләкин ягымлы кара күзләрен хәтерли. Әйтерсең ул да хуплап елмая һәм чал башын аз гына кыңгыр салып әйтә сыман:

— Стелла ул йолдыз дигән сүз!

# ИЛГИЗ КӘЛИМУЛЛИНГА 50 ЯШЬ



*Шагыйрь Илгиз Кәлимуллинны мин һәр вакыт ашкынып, җилкенеп алга атлаучы, бураннарда да, давылларда да үз юлыннан читкә борылмаучы юлчы итеп күз алдына китерәм. Бер уйлаганда «юлчы» сүзен гомер йомгагының җебе коляска тәгәрмәчләренә уралган кешегә карата куллану дөрес тә түгел кебек. Әйе, Илгиз Кәлимуллинга гамьсез балалык сукмакларыннан зәңгәр офыкларның читенә барып җитәргә теләп озак йөгерергә, агачларның иң биегенә менеп шәфәкъ нурларына сокланырга туры килми. Каты авыру яшьли үк аның аякларына богау булып урала.*

*Әмма Илгиз юлыннан туктамый. Ул бара. Ул шигърият канатларында үзенең югалган бала чагына, яшьлегенә бара. Ул бара. Аның артыннан матур-матур юллар сузылып кала. Бу гадәти юллар гына түгел — шигырь юллары. Алар әсәрдән әсәргә, китаптан китапка сузылып, еракка-еракка китәләр: әле илнең үткәннәренә, әле бүгенгенең бөек төзелешләренә алып чыгалар. Шагыйрьнең иҗат дип аталган олы магистрале әнә шулай уравыч юллар аша кешеләргә таба сузыла.*

*Илгиз Кәлимуллинның узган ел Мәскәүдә басылган китабы «Кешеләргә юл» дип атала. Кешеләргә юл! Кешеләр күңеленә юл — иң авыр эш. Моның өчен күпме түземлек һәм тырышлык, күпме йокысыз төннәр һәм җиңелү ачылары татырга кирәк. Минем Илгиз Кәлимуллиннарда булганым бар. Ул туктаусыз эштә, үзен аямый, көннең һәр минутын файдалы итеп үткәрергә тырыша. Аның китап шкафларында бөтендөнья классикасы да, илебезнең атаклы язучыларыннан башлап бүгенге көн әдипләренең әсәрләре дә күп. Шагыйрь һәр вакыт шуларга мөрәҗәгать итә, күңелен баета, осталыкка өйрәнә.*

*Илгиз Кәлимуллинга хәзер 50 яшь. Шуның егерме елдан артыгын ул иҗатка биргән. Аның 1956 елда чыккан беренче китабы «Һаман сафта» дип аталган иде. Аннан соң инде ул рус телендә иҗат ителгән дистәгә якын китап чыгарып өлгерде. Аны татар укучылары яхшы белә, үз итә, ярата — чөнки шигырьләрен күренекле шагыйрьләр тәрҗемә итәләр. Узган ел Казанда чыккан «Җиргә мәдхия» исемле җыентыгы аны татар укучыларына тагын да якынайта төште.*

*Әйе, ул замандашларыннан калышмыйча, алар белән гел бергә атлый. Ул һаман сафта, ул һаман юлда.*

**Фәнис ЯРУЛЛИН,**
М. Җәлил премиясе лауреаты

## Илгиз Кәлимуллин

### Бунтарь портреты янында

*Поэмадан өзек*

Иртәнге томан эчендә
Тын ага иде Сакмар.
Күк күкрәтеп чабып үтте
Ярсулы җитез атлар.
Кошлар уянды сискәнеп,
Киекләр куркып чапты,
Җирне барабан иттереп
Ат тояклары какты.
... Киң дала. Биектә бөркет.
Бөркет юлы — томанда.
Оренбур яклары, сау бул!
Гаскәр китте Уралга.
... Уралда туп, ядрә ясап,
Чакыру ташлап һәркемгә —
Пугачевның отрядлары
Ашкындылар Иделгә.
Куып баручы Михельсон
Пугачның җуйгач эзен,
Язмышын каргап, ачынып,
Ләгънәтләп сүкте үзен.
Аңлый алмады Михельсон
Җитез, кыю Пугачны.
Емельян — дала бөркете,
Киң җәйде шул колачны.
Сембердә дә, Тамбовта да —
Ул гел халык телендә:
Байларга — өрәк, ярлыга
Ышаныч ул күңелдә.
Ул иртә таңнар белән үк —
Турыдан да, урап та —
Оча киң далалар буйлап
Я туры, я бурлы атта.
Гаскәре аның — мужиклар,
Сакаллы кара халык.
Бил буарга кирәк икән —
Юкә алалар ярып.
Аларның кулы туйдырган
Патшасын, ялчыларын.
Тик үзләре «ашаганнар»
Байларның камчыларын.
Әнә анда шадра абзый,
Пугачтан яклау тапкан.
Түрәләр аның сеңлесен
Этләреннән талаткан.

Берсенең бала-чагасын
Авыру кырып салган.
Берсенең яраткан кызын
Байбәтчә тартып алган.
Тирән буага ташланган
Мыскылланган кыз бала...
Ярлылар бүген җыелып
Барсы өчен үч ала.
Үч алалар палачлардан,
Явыз канечкечләрдән.
Салтычиха өереннән,
Комсыз ришвәтчеләрдән.
Мужиклар камчысы уйный
Бүген алар сыртында.
Бурыч язылган дәфтәрләр
Дөрли учак утында.
Империя ут эчендә,
Ачның ачуы яман.
Түрәләр өйләрен ташлап
Ялтыраталар табан.
Пыр туздырып ташланылган
Дворяннар оясы.
Харам байлыгын кызганып
Дер калтырый хуҗасы.
Байбәтчәләр түшәгеннән,
Әй, мамыклар оча соң!
Болар Әби патшаның да
Йолкырлар чәч учмасын.
Үз хокукын яулап чыккан
Җәяүле, атлы бүген.
Киндер күлмәкле Россия
Пугачев яклы бүген.
Аларга барып кушылган
Минем нәсел-нәсәп тә:
Туган булып киткән шулай
Степаннар — Әхмәткә.
Күз алдыма килә минем
Баш күтәргән шул халык:
Казанканы кичте алар
Күкрәк белән су ярып.
Атлар пошкырган тавышка
Тып-тын елга уянды.
Яр буе көрәшчеләрнең
Каннарына буялды.
Калдылар төтен эчендә
Алачыклар, төрмәләр.
Туплар атудан яңгырап
Торды якын тирәләр.
Арча кырына җыелган
Халыклар төркеменә
Карап сөйләде бер егет,
Сүзне бик белеп кенә:
«Бетсен дөньяда явызлык,
Тигезсезлек һәм нужа.
Байлыкны кемнәр тудыра,
Аңарга шулар хуҗа.
Без мужик патшасы белән

Байларны себереп ташлап —
Китәрбез Мәскәү, Питерга
Ярлыга ирек даулап».
Бу сүзләр бик хуш килделәр
Мужиклар күңеленә.
Сөртте берәү күз яшьләрен
Биш ямаулы җиңенә.
Киң яңаклы, сакаллы карт
Баскан җирендә биеп,
Куанды: «Тәңре безгә дә
Рәхмәтен салды», — диеп.
Ант итте шунда егетләр
Тотынышып күсәккә:
«Мужик патшасы Пугачны
Ташламабыз үлсәк тә!»
Аларның антларын раслап
Гөрселдәделәр туплар.
Казан Кремленә таба
Очты ядрәләр, уклар.
Казанда аткан тупларның
Тавышы — китеп еракка —
Тетрәтте Кышкы Сарайның
Таш диварларын хәтта.

**Фәнис Яруллин** тәрҗемәсе

## Больницада бүлмәдәшем

Табигать һәм кеше яклы бер заттыр мин.
Бүлмәдә беркемне һич тыныч яткырмыйм.
Сөйләшәм. Сорашам. Ә аның һәр сүзе —
Бик ямьле дә үзе, бик тәмсез дә үзе.

Көн буе чәйни ул белмәгән-белгәнен:
Бүлмәгә ник кереп ник җилләр өргәнен.
Зарлана: ник ярдәм итмиләр дарулар?
Ник бетми дарудан хәлсезлек, арулар?

Гаепли табибне: әгәр дә башыма
Кан менми башласа — ни ярдәм бар шуңа?
Бер сырхау йоктымы — без тиеш бетәргә,
Ә фәннән нәрсә бар һәм нәрсә көтәргә?!.

Мин әйтәм күршемә — бүлмәдәш кешемә:
— Сине бит түшәм дә, идән дә төшенә,
Сине бит берәү дә тыңларга теләми...
Шуны соң синең җан аңлыймы, беләме?

Зинһар, дим, аңла син үзеңне, кешене,
Тормыштан зарланып чарлама тешеңне.
Йөрүем бар дип бел интегеп, каңгырап,
Уйларым булмаса зирәгрәк, аңлырак.

**Зәки Нури** тәрҗемәсе

**Әсгат Мирзаһитов,**
Башкортстан язучылар союзы идарәсе председателе

# БӨЕК ОКТЯБРЬ ҺӘМ БАШКОРТСТАН ӘДӘБИЯТЫ

Башкорт совет әдәбияты «үзенең күп планлы романнары» һәм «гүзәл поэзиясе» белән РСФСР язучыларының беренче съездында «Россия Федерациясенең куәтле, өлгереп җиткән әдәбиятларының берсе» дип билгеләп үтелде[1].

Чынлап та, Совет власте елларында бүтән тугандаш әдәбиятлар белән тыгыз хезмәттәшлектә ул җитез өлгерешле үсеш юлы үтте. Башкорт әдәбиятына бүген тематик диапазон киңлеге, жанр һәм стиль төрлелеге хас. Трилогия, трагедия, драматик поэма кебек башкорт сүз сәнгатенә элек таныш булмаган жанрларның һәм эпик романнарның соңгы чорда күпләп барлыкка килүе дә, аерым алганда, шул хакта сөйли.

Әдәбиятыбызның тамырлары, аның тәүге чыганаклары тирәннән, халыкның ерак заманнардагы поэтик иҗатыннан башлана. Туган ил һәм аның күрке булган ир-егетләрне данлаган асыл кобайырларны, «Урал-батыр», «Акбүз ат», «Күсәк би» кебек героик поэмаларны, «Кузы Күрпәч белән Баянсылу» кебек гаҗәеп хикәятләрне эченә алган башкорт халык эпосы һәм сокландыргыч җыр-моң үрнәкләрен туплаган башкорт халык лирикасы, зур рухи хәзинә буларак буыннан-буынга, гасырдан-гасырга күчеп, кешеләрне зәвыкландыра, аларны поэтик иҗатка һәвәсләндерә килгән.

Үткән гасырлардагы иҗтимагый тормышның аяныч шартлары, табигый ки, башкорт халкына үзенең материаль һәм рухи культурасын әзлекле үстерү өчен тиешле мөмкинлек бирмәгән. Социаль шартларның авырлыгы халык массаларын әледән-әле азатлык хәрәкәтенә күтәрә килә, гасырлар-чорларны берсен икенчесенә әдәби әсәрләр түгел, ә тарихи күренешләр үзләре — изелгән халык массаларының күтәрелеше, берсе сүндерелүгә икенчесе кабынып торган зур яки кече күләмдәге восстаниеләр ялгап бара. Мәйданга шагыйрьләр түгел, бәлки халыкны көрәшкә җитәкләгән сугышчы батырлар чыгалар.

Шуңа күрә бер дә гаҗәп түгел: башкорт халкының тәүге билгеле шагыйре Салават Юлаев патшалар империясен тетрәткән ир-арысланнарның үзләре арасыннан туды. Салаватның иҗаты бөтен килеш безгә килеп җитмәгән, аның халык арасында сакланып калган поэтик мирасы нибары җиде-сигез шигырьдән гыйбарәт, ләкин алар патриотик эчтәлекле, азатлык өчен көрәш идеясе салынган булулары белән кыйммәтле. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышының легендар герое Салават Юлаев бер башкорт халкының гына түгел, ә бөтен Россиянең күрке булып

---

[1] Л. Соболев. Әдәбият һәм заман. «Литературная газета», 8 октябрь, 1958 ел.

танылса, үз халкы йөрәгенә якын беренче шагыйрь булуы белән ул үзен башкорт әдәбиятының җуелмас күрке итеп раслады. Пугачев-Салават явы бастырылганнан соң күп тә үтми, 1789 елда патшалык Өфедә Россия мөселманнарының дини идарәсен (Диния назаратын) ача. Бу реакцион ислам оешмасы башкортлар арасында дөньяви мәгърифәтнең җәелеп китүенә, реалистик иҗтимагый фикер үсешенә нык комачаулык итә. Нәтиҗәдә әдәбиятның төп юнәлешен һәм идея-эстетик йөзен байтакка тикле иҗатларында дини-мистик карашлар өстенлек алган шагыйрьләр билгеләли.

Башкорт демократик әдәбияты бары XIX гасыр азагында һәм XX гасыр башында гына үсеп китә. Алдынгы рус һәм татар иҗтимагый фикере йогынтысында формалашкан башкорт мәгърифәтче-демократларының әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге асылда мөселман фанатизмы поэзиясенә каршы куела һәм критик реализм юнәлешендә үсә.

Революциягә кадәрге язучылар арасында Мәҗит Гафури (1880—1934) башкорт совет әдәбиятына нигез салучыларның берсе булып танылды. Дөньяны революцион үзгәртеп кору идеясенә, хезмәт ияләренең социаль омтылышларына турылыклы булу һәм шул идея-теләкне иҗатта иҗтимагый эстетик идеал итеп күтәрү — Гафурига да һәм, гомумән, бөтен башкорт әдәбиятына да хас төп сыйфат әнә шул иде. XX гасыр башында, бигрәк тә 1905 ел революциясеннән соң, Башкортстанда әдәбият мәйданына, М. Гафуридан кала, Афзал Таһиров (1890—1937), Давыт Юлтый (1896—1938), Сәйфи Кудаш кебек иҗатлары халык тормышы һәм уй-хыялы белән тыгыз бәйләнгән реалистик язучылар килде.

Бөек Октябрь, башка халыкларныкы кебек үк, башкорт халкының да тормышын һәм мәдәниятен социалистик нигездә үзгәртеп коруга киң юл ачты. 1919 елда милли дәүләт — Башкорт автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелде, ана телендә әлифба барлыкка килде. Шул ук чорда халык матбугатының киң челтәре, китап басмасы, тәүге башкорт театры туды. Газета-журналларда эшләү, революцион вакыйгаларда һәм совет төзелешендә актив катнашу язучыларның политик карашын киңәйтте, аларга яңа темалар бирде, иҗат юнәлешләрен билгеләде, революцион массаларның гомумиләштерелгән образын җырлауга илһам өстәде. Мәҗит Гафуриның «Кызыл байрак», «Ант», «Изге юлда», Давыт Юлтыйның «Атлан, батыр!» шигырьләре көрәшче-каһарманнарга дан булып яңгырады, яшь язучылар өчен өлге булды. Шул елларда Сәйфи Кудаш, Шамун Фидаи, Гариф Гомәр, Ярлы Кәрим, Төхфәт Янәви кебек публицист-шагыйрьләрнең тавышы ныгыды.

Көрәшче халыкның һәм хезмәтчел халыкның мәһабәт образы Афзал Таһировның, Давыт Юлтыйның, Г. Ниязбаевның, А. Тангатаровның революциянең тәүге елларында иҗат иткән нәсерләрендә, хикәяләрендә, пьесаларында төп урынны алды. Шул ук герой егерменче еллар әдәбиятында, аеруча Афзал Таһировның «Ташкын дәрья тамакларында», «Йәмәлкә тавы», Имай Насыйриның «Вагонда», «Һөҗүм», Мәҗит Гафуриның «Тормыш баскычлары», Гариф Гомәрнең «Революция җилләре» повестьларында үзәк фигура итеп күрсәтелде. Башкорт совет әдәбиятының тәмам формалашып җитүе, аның бөтен төрләре һәм жанрлары барлыкка килүе, милли мәдәниятнең магистраль үсеш юлына чыгуы да нәкъ менә шушы елларга туры килә. Әдәбиятыбыздагы беренче романның (Гайнан Хәйринең «Борылыш»ы) язылуы, мәсәлән, күп нәрсә хакында сөйли. Ләкин роман жанрының ныгып җитүе утызынчы елларга — Афзал Таһировның «Солдатлар», «Кызылармеецлар», «Кызылгвардеецлар», Давыт Юлтыйның «Кан», Имай Насыйриның «Күзәй» әсәрләре язылу вакытына туры килә. Бу әсәрләр башкорт язучыларының тарихи вакыйгаларга художестволы бәя бирүдә өлгереп җитүләрен, яшь әдәбиятның зур күләмле эпик жанрлар мәсьәләсен уңышлы хәл итә алуын һәм башкорт сүз сәнгатендә реализмның тирәнәюен күрсәтте. Утызынчы еллар әдәбиятында социалистик җәмгыять төзүче замандаш, яңа тип эшче, производство алдынгысы образлары тууы да шуның белән аңлатыла.

Әдәбиятның үзәк темаларын һәр вакыт совет чынбарлыгы үзе билгеләде. Әйтик, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, сыйнфый көрәш һәм яңа шәхеснең формалашуы Сәйфи Кудашның «Хат», «Кушкаен», Һәдия Дәүләтшинаның «Айбикә», Имай Насыйриның «Җиңелгән яту», Сәгыйть Мифтаховның «Сакмар», «Дуслык һәм мәхәббәт» әсәрләрендә, ә Башкортстанда нефть ачылуы, индустриаль үсеш Мәҗит

Гафуриның «Златоуст», «Төнге смена», Имай Насыйриның «Сибай», Али Карнайның «Ишембай», Рәшит Нигъмәтинең «Тимер юл» һ. б. әсәрләрдә калку сурәтләнешен тапты.

Милли әдәбиятыбызның идея-художество һәм жанр-стиль җәһәтеннән баюына шулай ук бүтән әдәбиятлар белән элемтә киңәюе дә булышлык итте. Башкорт язучылары, шагыйрь Г. Сәләм әйтмешли, «һәйкәл итеп җирдә... социализмны» күтәрүче кешеләр образын тудыру максатында рус һәм башка тугандаш халыкларның художество-эстетик тәҗрибәсен иҗади үзләштерделәр.

Бөек Ватан сугышы еллары башкорт совет әдәбиятында да һәр каләмнең штыкка тиң булып эшләве белән характерлы. Шул заманда дөнья күргән китапларның һәм әсәрләрнең исемнәре үзләре үк шуны раслый: «Мәхәббәт һәм нәфрәт җыры», «Үтер, улым, фашистны!», «Үч ал, патриот!», «Күбрәк нефть, иптәшләр!» (Рәшит Нигъмәти), «Башкорт атлылары» (Баязит Бикбай), «Сәлам сезгә, Ленинградны яклаучылар!», «Бирмәбез» (Сәйфи Кудаш), «һөҗүм алдыннан», «Ватан өчен» (Кадыйр Даян) һәм башка күп санлы әсәрләрдә патриотизм темасы халыклар дуслыгы темасы белән үрелеп бирелдә, шушы көч явыз дошманны җиңүдә төп ышаныч дип каралды. Фронт һәм тылдагы көндәлек вакыйгаларны чагылдыруда прозаның кече жанрлары — очерк белән хикәя зур роль уйнады (Сәйфи Кудашның «Дон далаларында», Сәгыйть Агишның «Фронтка», Баязит Димнең «Тәүге алыш», Али Карнайның «Ул көнне», Кирәй Мәргәннең «Безнең поход» һ. б.). Халык батырлыгын җырлауда, совет солдатының җиңелмәс рухын данлауда халык авыз иҗаты традицияләре дә реалистик сурәтләүләр белән оста кушып файдаланылды: Рәшит Нигъмәтинең «Башкортстан сүзе», «Синең кәләшеңнең хатлары», Мостай Кәримнең «Үлмәсбай», «Башкорт халкына җавап хат», «Декабрь җыры», Сәйфи Кудашның «Ленин һәм солдат», Хәниф Кәримнең «Солдат турында баллада» һ. б.

Сугыштан соңгы һәм хәзерге башкорт әдәбиятының үсеш баскычлары төрле елларның яңа ачышлары һәм тупланган яңа тәҗрибә сыйфаты белән билгеләнеп килә. Илленче һәм алтмышынчы елларда, мәсәлән, вакыйгаларны, образларны тасвирлауда психологик анализга, геройларның гуманистик-әхлакый сурәтләнешенә игътибар көчәйде. Шәхеснең эчке дөньясын ачып бирү, кешенең рухи мөмкинлекләренә ышану, аның гражданлык активлыгына мөрәҗәгать итү соңгы елларда туган әсәрләрне аеруча бизи. Прозада рухи сафлык өчен көрәш, социаль-этик, эстетик карашларның камиллеге алгы планга куела. Шундый ук проблемалар драматургларның күпчелек әсәрләрендә уңышлы хәл ителә. Соңгы вакытта укучы белән ихлас сөйләшүгә корылган лирик проза активлашты, монолог-әсәрләр ишәйде, гомумән, әдәбият кешелеклерәк, шигъриятлерәк, тормышчанрак була бара.

Замандашның яңа сыйфатларын ачуда поэзия аеруча зур уңышларга ирешә. Кешенең хезмәткә, дөньяга, дәвернең иң кайнар бәхәсләренә мөнәсәбәтен чагылдырган халыкчан һәм көр рухлы шигырьләр уйчанрак, тирәнрәк, хислерәк була баралар, гомуми фикерләрне кабатлау, ялкыткыч риторика, вагон тәрәзәсеннән яки самолет иллюминаторыннан карап язылган эч пошыргыч сокланулар азайганнаназая. Шигъриятнең өлгергәнлек чорына хас фәлсәфи акыл, шул ук вакытта яшьләрчә ярсу, куанычлы дәрт, тормышны яңача күрү сүзләрен — төп сүзне, әлбәттә, ветераннарыбыз Сәйфи Кудаш белән Мостай Кәрим әйтә.

Соңгы елларда Нәҗәр Нәҗми, Хәким Гыйләҗев, Муса Гали, Әнгам Атнабаев, Рафаэль Сафин һәм Равил Бикбаев әүвәлгечә активлык күрсәтә, аларның иҗаты башкорт укучысы алдында да, союз күләмендә дә актуаль һәм тәэсирле яңгырый.

Заман героена мөрәҗәгать итү романнарны да читләтеп үтмәде. Әкрам Вәли, Динис Исламов, Хәким Гыйләҗев, Ногман Мусин, Яныбай Хамматов һәм башка язучыларның әсәрләре авыл хуҗалыгында булып үткән уңай үзгәрешләрне художестволы яктыртуга өлеш кертсә, Кирәй Мәргән, Әнвәр Бикчәнтәев, Шакир Янбаев һәм башка прозаикларның романнары эшче темасын чагылдыра. Бүгенге көн эшчесенең рухи дөньясын сурәтләүдә шулай ук Әхияр Хәкимов, Рәшит Солтангәрәев, Булат Рафиков, Гайфулла Вәлиев повестьлары да уңышлы булды.

Әдәбиятта бүген традицион темалар белән берәттән философик темалар, халкыбызның рухи кичерешләр проблемасы, заман таләпләренә җавап бирердәй мәсьәләләр куела. Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә», «Салават», «Ташлама ут-

ны, Прометей!» трагедияләре зур яңгыраш алды. Үткәндәге тарих җирлегендә халык язмышын философик гомумиләштерүгә омтылу соңгы елларда иҗат ителгән зур эпик полотноларга да хас. Бу җәһәттән Зәйнәп Биишева, Фәрит Исәнголов, Яныбай Хамматовларның трилогияләрен, Һадия Дәүләтшина, Баязит Бикбай, Гали Ибраһимов, Динис Исламов, Ногман Мусин, Җәлил Киекбаев, Шәриф Биккол, Кәтибә Киньябулатова, Рамил Хәкимов, Ибраһим Гыйззәтуллин, Әмир Гәрәев, Кирәй Мәргән һәм башка авторларның әсәрләрен атап әйтергә мөмкин. Аларны укучы зур кызыксыну белән кабул итте.

Күренүенчә, Октябрь тудырган башкорт совет әдәбияты чагыштырмача кыска вакыт эчендә олы үсеш юлы үтте, профессиональ осталыкның өр-яңа биеклекләренә күтәрелде. Дөнья әдәбиятының төрле жанрларын үзләштереп, башкорт сүз сәнгате алдынгы әдәбиятлар сафына басты, социалистик җәмгыятебезнең уртак эстетик хәзинәсенә үзеннән лаеклы өлеш кертте. Шагыйрьләребез, прозаикларыбыз, драматургларыбызның күп кенә әсәрләре бөтенсоюз һәм дөнья аренасына чыгуы шул хакта сөйли.

**Мостай Кәрим,**
СССР Дәүләт премиясе лауреаты,
Башкортстанның халык шагыйре

●

Борынгы Персиядә бурычка алу
хурлык исәпләнгән.
Геродот буенча.

Туган илем! Һаваларга ашкан
Шөһрәтеңнең хаклы байраклары.
Җир шарының ике яртысында
Салютыңның балкый шаңдаклары [1].

Шундый чакта мин я чүгеп төшәм,
Я күкләргә тия түбәләрем.
Бер карасаң, үзем балкыш, имеш,
Бер карасаң, бары күләгәмен.

Ни булсам да, рәхимеңә рәхмәт.
Миңа ышандың кара көннәреңдә.
Башкаеңа төшкән бәлаләрдән
Өлеш салдың минем иңнәремә.

Мин яраклы булдым чыдамыңа,
Каткан сынык, татыр суларыңа.
Һәм яраклы булды минем каным
Синең туфрагыңны сугарырга.

Җиңүеңә мин яраклы булдым.
Хәйран шәмнәр синдә кабынганда,
Бәйрәмеңә мин яраклы булдым —
Читкә тибәрмәдең табыннарда.

---

[1] Шаңдак — кайтаваз.

Рәхмәт, илем! Бирсәң, үлчәп бирдең.
Кылганыма хакны таманладың.
Мактар булсаң, хәттин аштырмадың,
Чама белән генә яманладың.

Кимсетмәдең син бурычка биреп
Икмәк, тоз, су, бүләк, дәрәҗәләр.
Бик бәхетсез иткән булыр идең,
Син бурычка бәхет бирсәң әгәр...

Сәйфи Кудаш,
Башкортстанның халык шагыйре

## Гомер сөрәсем килә

Туксаныма тартып
Сиксән вагон күмер тарткан
Бер паровоздай гөрләп,
Сиксән ел гомер биштәрләп,
Киләмен юлдан үрләп,
Метеор кебек гөрләп.

Туксанымның тупсасыннан
Атлар өчен тупылдап,
Йөрәгем тибә дөпелдәп,
Чапкан аттай ухылдап,
Тирем тама чупылдап.

Әле якмаган утларны
Шунда ягармын кебек.
Әле казнамда юкларны
Шунда табармын кебек,
Шунда язармын кебек.

Күпме зур булса да диңгез,
Бар төбе, бар читләре.
Бары шагыйрь өметенең
Юк төбенең төпләре,
Юк чигенең чикләре...

Кыш көнг үләсем килми,
Язны күрәсем килә.
Язны күреп, гөлләр үреп,
Җирне чигәсем килә,
Илне бизәсем килә.

Яз көне үләсем килми,
Җәйне күрәсем килә.
Яз утырткан гөлләремнән
Таҗлар үрәсем килә,
Кешегә бирәсем килә.

Җәй көне уләсем килми,
Көзне күрәсем килә.
Яз чәчә торган җирләрне
Көздән сөрәсем килә,
Кардан биләсем килә.

Көз көне уләсем килми,
Кышны күрәсем килә.
Кышларымны язга кушып,
Еллар үрәсем килә,
Гомер сөрәсем килә.

Таңда нигез корган йортны
Төзеп бетәсем килә.
Яңа өйләнгән егеттәй
Дөнья көтәсем килә.

Гомернең йомры йомгагын
Сүтеп чорныйсым килә.
Үзебез яшәрткән җирне
Зурлап җырлыйсым килә.

**Нәҗәр Нәҗми,**
Салават Юлаев премиясе лауреаты

## Башкортстан

Башкортстан! Татлы балсың кебек,
Дегетче бер оста кебексең —
Киемеңә мазут исе сеңгән
Син гүя бер эшчән егетсең.
Башкортстан! Ярсу атсың сымак,
Өерләрең — утлы өермә.
Кымыз исе, җәйләүләрнең хисе
Җырлап керә җырлы өеңә.
Башкортстан! Син икмәкле туфрак,
Яшел урман, болын, тау, дала.
Җаның нәрсә тели — синдә шул бар:
Син ут һәм су, һава һәм дәва.
Бар булганың синең үзеңнеке —
Җир өстең һәм астың — хәзинә.
Китапларың юкта, китап итеп,
Тарих язгансың син ташыңа.
Нинди җир син?! Җир алтының түгел,
Күңел алтыннарың мең алтын.
Җырлап тора телең. Йөрәгеңдә —
Җирләр тетрәтерлек дәрт, ялкын.
Шул дәртең һәм шул ялкының күчкән
Җиреңдәге һәрбер халкыңа.

Бер яшәве мең яшәүгә тора
Дуслык һәм туганлык хакына.
Кешенеке түгел, үзеңнеке
Һәр авазың, төсең, һәр нурың.
Үз болытың күктә йөзә кебек,
Ява төсле тик үз яңгырың.
Нинди дәүләт үзең! Сулышларың,
Табигатең, холкың бер түгел.
Бер үк мәлдә Зилаерда җылы,
Ә Дуванда дулый салкын җил.
Кайнарлыгың, салкынлыгың белән
Син җанымда минем, тәнемдә.
Тоям сине дегет исендә дә,
Әлеге шул балың тәмендә.
Тел ачылган синдә, күз ачылган,
Бар тапканым синдә табылган,
Табылганга гомер табынмадым,
Мин — гомергә сиңа табынган,
Җирем-суым — Башкортстан!

## Хәким Гыйләҗев,

Салават Юлаев премиясе лауреаты

●

Әҗәл белән айкашканда,
Көнгә карап мин җыр яздым.
Булды миңа моңлы сазым —
Атам рухы, әнкәм назы,
Асылыкүлнең ярсулары,
Сәрмәсәннең күркәм язы.

Окопларны сикерсәм дә,
Абайламый калдым сазын
Бу тормышның.
Фани дөнья
Басар диеп кем уйлаган?
Язмышым ерак илләрдә
Торып калса, нәрсә булган?

Көннәр болытлы булса да,
Аяз иде күңел күге.
Нигә бүген җәберсенәм,
Ярам сызлый нигә бүген?

Кайда югары тойгылар,
Илаһилыгы саф сөюнең?
Даулы яшьлек, күз яшь булып,
Нигә тамакка төелдең?

Миңа ямансу, күңелсез...
Ояламын үз уемнан.
Оялам туган туфрактан,
Ояламын Уралымнан!..

Таяныр кыям булганга,
Гомерем яугир[1] җырлар язды,
Чөнки булды моңлы сазым —
Атам рухы, әнкәм назы,
Уралымның күркәм язы!..

## Муса Гали

### Ышанам

*Мостай Кәримгә*

Бу дөньяның әче җилләренә
Каршы бару түгел җиңелдән.
Кеше бара, кеше нидер көтә —
Көтә җирдән, көтә күгеннән.
Кеше бара. Адымнары белән
Тынмый яра гомер юлларын.
Бер уракчы кебек җыеп ала
Тапкан көнен, язган җырларын.
Тайгакны да берәү таймый үтә,
Такырда да мин гел абындым.
Азмы юлда ташны мендәр иттем,
Юрган итеп болыт ябындым.
Каным аккан көннәремне иснәп,
Ваклыклардан дәррәү кагындым.
Үлем белән яшәү чикләрендә
Акыл тапканнарга табындым.
Йолдызлардан бәхет эзләмәдем,
Күк серләре җиргә ишмени?
Сыгылсам да, үз йөгемне тарттым,
Йөкне ташлау иргә эшмени!
Ни югалтып, ниләр тапканмындыр,
Үлчәсеннәр аны бүтәннәр.
Күкрәгемдә һаман өмет янды,
Иман бирде миңа үткәннәр.
Шуңа хәзер, күкләр гөрселдәтеп,
Болыт куган җилгә ышанам.
Пакь күзләре белән миңа багып,
Леп-леп килгән гөлгә ышанам.
Янар-янмас сукыр утка түгел,
Соңлап сүнгән нурга ышанам.

---

[1] Яугир — сугышчы ир.

Җан көйдергеч моңсызлардан туйдым,
Җан эретер җырга ышанам.
Үтте җилеп, шашып чабышулар,
Адымнарга хәзер ышанам.
Сабырсызлар белән бәла җыйдым,
Сабырларга хәзер ышанам.
Өмет өздем шаулы дулкыннардан,
Чишмәләрдән хәзер көч алам.
Чүлдә мираж күреп мең алдандым,
Тик чыннарга хәзер ышанам.
Тик чыннарга гына ышанам.

## Шәриф Биккол,

Г. Сәләм премиясе лауреаты

### Озата кил

Сайра, сайра, сандугачым,
Сиртмә-сиртмә талларыңда;
Хыялыйлар иткән идең
Мине яшьлек таңнарымда.

Әле булса, тыңлый-тыңлый,
Моңнарыңа хәйран калам,
Чут-чут сайрар минутыңны
Мин зарыгып көтеп алам.

Чиртә-чиртә күңелемнең
Иң-иң нечкә кылларына,
Озата кил гомеремнең
Яшәләчәк елларына!

## Гыйлемдар Рамазанов

### Дүрт мәхәббәт

Бу тормышның бормалары аша,
Бер көлдереп, берчә елатып,
Үткәннәрдән килер көнгә мине
Дүрт мәхәббәт килә озатып.

Дүрт мәхәббәт — дүрт тәгәрмәч төсле
Үтәр өчен гомер юлларын,
Дүрт сөюдән дүрт ягым да якты,
Дүрт йолдызга багам югары.

Беренчесе — туган төбәгемә,
Әнкәм назы шунда татылган,
Шул бердәнбер изге туфракка мин
Мәңгелеккә тиеш кайтырга.

Сөюемнең икенче бер моңы —
Гүзәл калам — гомер бишегем,
Монда йортым.
Кешеләргә һәр чак
Ачык булды минем ишегем.

Бәхетемне шунда очраттым мин,
Фикердәшләр таптым, тиңдәшләр,
Монда килде җан тетрәткеч сөю,
Тамды шунда татлы күз яшьләр.

Олы сөюемнең өченчесе —
Башкалага, бөек Мәскәүгә.
Синнән мәңге сүнмәс чаткы алдым
Тормыш күкләрендә яшьнәргә.

Синең тугры сакчың булып калам,
Илтсәләр дә юллар кайларга!
Солдат чакта кайнар сөемне
Каным белән яздым карларга.

Бер күңелгә күпме тойгы сыйган!
Мин гомергә гашыйк кебекмен.
Мәхәббәтнең мәңге шиңмәс таҗы —
Бердәнберем син бит, сөеклем!

Өйрәндем мин, ахры, зур дөньяга,
Синең күзләр белән багарга,
Кайгыларың өчен ут йотарга,
Ярсуларың өчен янарга.

Алга әйди мине дүрт мәхәббәт,
Иң кадерле, изге дүрт тойгы,
Дүрт мәхәббәт — дүрт тәгәрмәч сымак,
Дүрт почмагы кебек йортымның.

**Әнгам Атнабаев,**

Башкортстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Сәләм премиясе лауреаты

## Горурлык

«Туган илем! Син бит минем өчен
Хәтта җаным фида кылырлык
Туган әнкәм кебек якын!» — дисәм,
Бу — төчелек түгел — горурлык!

«Туган илем — минем җылы өем,
Башка җирдә миңа урын юк!» —
Дип шатлансам синдә яшәвемә,
Бу — төчелек түгел — горурлык!

«Туган илем — минем туган телем,
Шушы телдән башка җырым юк!» —
Дип җырласам әгәр җырларымда,
Бу — төчелек түгел — горурлык!

«Туган илем, синең үткән юлың —
Минем юлым, башка юлым юк!» —
Дип соклансам барыр юлларыңа,
Бу — төчелек түгел — горурлык!

**Равил Бикбаев,**
Г. Сәләм премиясе лауреаты

## Башкортстан монда башлана

Сөн ярыннан еракларга бактым,
Офыкларда дәрья — басу акты,
Бар тарафта дөнья нинди якты,
Кан тибешем офыкларны какты:
— Башкортстан монда башлана!

Туктап калдым Җаек тугаенда,
Ак нур ягыла кебек һәр каеннан,
Талпына да күңелем күктә дулый,
Яз аенда сабан тургаедай:
— Башкортстан монда башлана!

Башкортстан мине каршы ала,
Кайтсам сулар кичеп, ил урап.
Кабыргасын, сыртын бора белми,
Кояш кебек карый туп-туры.

— Республикам, менә башландың! — дип,
Әйткәнемдә җиргә капланып,
Ишетәмен җирем куеныннан
Сабыр гына тавыш акканын:

— Җаек тугаеннан Сөн ярына,
Юшатырдан Әйгә кадәрле
Җәйрәп яткан җирнең күңеленә
Һәр карашы,
Һәр карышы, беләм, кадерле.

Кайткан саен сыенасың миңа,
Берчә көлеп, берчә уйланып.
Тик мин сукмаклардан гына түгел,
Башланам бит синнән, оланым.

Мин бит башланамын синнән, аннан,
Кешеләрем, сездән башланам!
Юллар сезне кайда гына илтми,
Язмыш сезне кайда ташламас...

Ә мин мәңге монда — Уралымда,
Тик булмышым инде өр-яңа:
Минем янга дөнья килмәсә дә,
Үтеп чыктым бөтен дөньяны.

Моң-шатлыгын илнең тигез күреп,
Ил алдына сүзен тиң әйтеп,
Оланнарым кайда гына йөрми,
Колачымны минем киңәйтеп.

«Башкортстан!» — диеп, улларыма
Ерак кыйтгаларда карый җир.
Кешем намусында кер күрсәләр,
Гарьлегемнән йөзем караер.

Мин башланам сездән, кешеләрем!
Күңелегездән сезнең яралдым.
Йөзегез ак булсын — минем кебек,
Минем кебек — Башкортстан кебек
Бу дөньяга туры карарлык.

## Рәшит Назаров

### Башкорт

*Кечәгең дә, бүгенгедәй,*
*Күңелемә якын минем.*

М. Кәрим.

Бүгенгедәй аның үткәне дә
Уелып калган Урал ташына....
... Курай очыннан сызылып тамган моңы
Ал кан булып ташка ягылган.
Кайгылардан каелып чигелсә дә
Тирмәләрнең соры бизәге,
Йөрәгендә яткан иярле ат
Шылтыраткан, ярсып, йөгәнен.
«Уралым!» — дип оран ташлап ауса,
Күмгәндә дә туфрак-җир үзен,
Йөрәгеннән чыгып иярле ат
Чапкан яуга,
Ир данына биреп тезгенен.
Үткәнедәй, бүгене дә данлы,
Тик каемый данны кайгы, кан:
Иңнәрендә — бәхет кошы сайрый,
Ияренә кунып килә таң!

## Рәмзилә Хисаметдинова

### Буранбай

Аяк өсте басып, түбәтәен салып,
Бер карт җыр башлады: «Буранбай».
Мондый җырлар басып җырланыль,
Мондый җырлар утырып җырланмый!

Халкым кайгысыдай озын көй бу,
Себер юлы төсле озын көй.
Әй, озын көй!
Озын Уралдай — «Буранбай».
... Әй, Буранбай!
Синең язмышкаең
Кайсы төбәкләрдә буранлый?!

Мин, оялчан башкорт кызыкае,
Сөюемнән әмма тартынмам.
Нәкъ декабрист хатыннары төсле,
Мин китәрмен синең артыңнан.

Зынҗырларың чыңын басар иде
Күңелләрең язган бер чын җыр,
Кулыбызны беректерсә әгәр
Сөю дигән иң нык бер зынҗыр!

Әй, Буранбай!
Синең белән бергә
Башкорт иле өчен яныйм мин,
Илкәемә картлар елатырлык
Табак-табак хатлар языйм мин.

Талдай нечкә кулларыма бакма:
Синең кебек мин нык кешемен,
Мүк җиләге төсле, синең өчен
Кышның чилләсендә пешәрмен!

Себер бураннары озын-озын,
Озын көйдәй озын — буранлый...
Буранны да синең белән кичәм,
Мин дә буран кошы, Буранбай!

... Җыр өзелде.
Җырдан килде дә ул,
Җырга кире китте Буранбай...
Йөрәгемдә олы мәхәббәтнең
Озын хәсрәтләре буранлый.

# Фәрит Исәнголов

# АГЫЙДЕЛНЕҢ АРЪЯГЫНДА

хикәя

*Сез кызлар, егетләр сыер сауганга көлмәгез. Сезнең әнкәләрегез симәнә ташыганда, җигелеп сабан сөргәндә, без елый идек...*

*(Ватан сугышы инвалидының колхоз җыелышындагы чыгышыннан.)*



Иркә кызларның бит очындагы уймактай чоңгыллар ясап алкынып-талпынып ага Агыйдел. Бәйгедәге ярсу аргамаклар шикелле түземсезләнеп, ашкынып, дәртләнеп, йөзәр чакрым юл үткән гүзәл елга бер мәлне Чулман белән кавыша. Бу урында ул аеруча тулылана, тирәнәя.

Бирге якта — Башкортстан. Аръягында — Татарстан. Хәер, елганың кайсы яры чынлап та «аръяк», кайсысы «биргеяк» икәнен аерасы бар әле. Кем тарафыннан әйтелә бит?.. «Агыйделнең аръягында...»—дип җыр башлаганда аръяктагылар—бирге якка, бирге яктагылар — аръякка карап җырлый. Әйе, башкортның да, татарның да күп җырлары «Агыйделнең аръягында» дип башлана шул.

Ике якның көймәләре елга уртасында очрашканда, кешеләр берберсеннән: «Кая барыш?» — дип сорасалар, һәр ике як: «Агыйдел»-гә! — дип җавап бирә.

Гаҗәп түгел. Ике як ярда ике «Агыйдел» колхозының җирләре җәелеп ята. Ә Агыйдел, ярларын чайкап, дулкын кагып ага бирә. Ике як колхозның җәйләүләрендә дә эш кайный.

Менә төш алдыннан башкорт ягыныкылар барлык савыт-сабаларын, шылтырата-дыңгырдата, юарга алып төште. Көлешүләр, шаян сүзләр яңгырады. Бер чаясы араларындагы бердәнбер ир затына төрттереп алды:

*Сыер сава бер егет,*
*Ап-ак халатын киеп.*
*Трактористлар узып китә,*
*Нинди уңган кыз, диеп...*

Башкалары дәррәү күтәреп алды:

*Аетбай — үзеңә,*
*Ике матур күзеңә...*
*Тырышып-тырышып сыер саусаң,*
*Кияү чыгар үзеңә...*

Кайсысы башлагандыр — батырышулар, тәч тә тәч су сибешүләр китте. Берүзе ничек каршы торсын — эш, гадәттәгечә, Аетбайның өс-

те лычма су булу, күңеле кырылу белән бетте. Сер бирмәс өчен егет елмаерга тырышып кызларга бармак янады да, читкәрәк китеп, тал куаклары артына ышыкланды, сыгып эләргә дип, өстен чишенә башлады.

Кызларга сиздермәсә дә, Аетбай нык кына үпкәләгән, тамагына гарьлек төене төенләнгән иде. «Аюдай гәүдәң белән сыер савып йөре инде! Кызлар дөрес көләләр! Кул селтәргә дә, ташлап кайтып китәргә!..»

Армиядә Аетбай элемтәче булды. «Отличник-связист» дигән значогы да бар. Үз һөнәрен яраткан иде ул. Кайткач та шуңа тотынырга дәртләнгән иде. Әмма коммутаторда урын тиз генә бушардай түгел. Ялгыз әңкәсен ташлап, читкә чыгып китәсе дә килми.

Кыш башында, вакытлыча дип, аны фермага җибәрделәр. «Кызкыркынга саву аппаратларын көйләштереп йөрерсең»,— диделәр. Алай итеп кенә буламыни? Эшкә батыр Аетбай савуга үзе үк тотынды да китте. Аппаратка биреп бетермәгәнен менә дигән иттереп чажлатып кулы белән дә савып куя.

— Бармаклары нинди җитез!— дип көлеште хатын-кыз.

Мактап көлсәләр дә, моңа аз булса да мыскыл катышкан икәнен Аетбай сизә иде. Башка җирләрдә ир-ат заты әллә кайчаннан бирле савучы булып эшли. Хәтта орденлылары, герой исеме алганнары да бар. Анда ир-ат савучыга аптырап карамый торганнардыр, мөгаен. Ә менә бездә, әллә нишләп, кәмит урынына күрәләр? «Аз гына эшлим дә ташлап китәм!»— диде Аетбай. Фермада савучылар җитми иде — азга гына түзәргә, калырга булды. Тик кызлар, сәбәбе чыккан саен, аңа төрттереп көлешеп алуларыннан туктамадылар. Аеруча — кыйгач кашлы, коңгырт-кара күзле, таза гәүдәле Зөләйха. Никадәр яшерергә тырышса да, аның Аетбайга күз атып йөргәне беленеп тора. Тик егетнең сыер сауганын гына өнәп җиткерми, шуңа күрә бу һөнәреннән биздерергә тели.

Ферманы ташлап китүне суза-суза, егет инде бүтәннәр белән җәйләүгә дә чыкты. Тик, күрәсең бит, кызлар мыскыллавы җәйләүгә дә ияреп килгән икән...

Аетбайның ике күзе — аръякта, колагы — куак артында чәкердәшкән кызларның сүзен аулый.

— Бу ниткән эш, ирдәүкәләр!— дип, араларындагы Гөлгайшә исемле тол җиңги кызларны тирги.—Саву аппаратыгыз көйсезләнсә, Аетбай бик кирәк. Елга буена төшсәгез — ник кирәк...

Арттырыбрак җибәреп моны, чынан да, үпкәләттек, ахры, дип, әле генә чыр-чу килгән кызлар да шым булдылар.

Гөлгайшә, сүзен уенга салып, дәвам итте:

— Ипләбрәк кыланмасагыз, йөзек кашыдай бердәнбер Аетбаегыздан колак та кагып куярсыз әле...

— И, аның күзе әллә кайчаннан аръякта инде...— дип эләп алды кызларның берсе.

— Килен итеп алдылар, киттеләр! Һи-һи-һи!..

— Аңа ни... «Агыйдел» урынына — «Агыйдел». Җәйләү урынына җәйләү.

— Әллә ни микән...— Кайчандыр аръяк «Агыйдел»дән килен булып төшкән Гөлгайшә, мут елмаеп, күз кысты.— Бер дә китеп кенә котылыр төсле түгел әле. Эш, болай барса, киленне үзе төшерүгә көйләнә. Күзегезне шар иттереп, менә дигән чибәркәйне бирге якка алды чыкты, көнчелектән гомерегез ут йотып үтәр, каенсеңелкәйләрем...

— Әй, сөйләгән буласың шунда, җиңги! Ишетеп калса, я борынын күтәрер...— дигән булды Зөләйха.— Безнең егетләр шул теге як кызлары дигән булалар да... бер дә бирге якныкылардан узган җирләре юк. Танауларына әүвәлрәк ис кереп, түш-башларын иртәрәк үй-

наклата башлаулары гына бар инде. Безнең юләрләрнең шуңа исләре китә...

Зөләйханың сүзләре Аетбай колагына исәп тотып әйтелүе һич яшерен түгел иде.

Юеш киемнәрен сыгып, тал ботакларына элгәч, Аетбай, чуер ташларны шыгырдатып, кояшка сузылып ятты. «Морҗалары кыек булса да, төтеннәре туры чыга!— дип уйлады ул.— Нинди зирәкләр! «Аръяк» турында үземнең дә әле юньләп уйлап җиткергәнем юк. Алар тоемлап та өлгергән!»

Әйе, Аетбайның бүген иркенләп су керү сылтавы белән кызлардан аерылып каласы килә иде. Теге як савучылары гадәттә су буена соңрак төшә. Чөнки кара-каршы ярда гына утырсалар да, ике сәгатькә аерма. Аетбай беләгендәге сәгатьнең теле унбердә. Ә аларда — яңа гына тугыз тулды. Кызык!

Ике як җәйләүләрдәгеләр җәй буенча бер-берсен танып, белеп өлгерәләр. Су өстеннән тавыш шәп ишетелә бит. Тик менә Аетбай да, башкалар да аръякныкылар җәйләвенә яңа килгән яшь кызны әле белеп җиткермиләр. Ул ерактан караганда бүтәннәрдән аерылмый да сыман. Әмма Аетбайга беренче мәртәбә күзгә чалынуы белән үк ничектер үзгә бер зат булып күренде.

Ике яктагылар яр буена бер мәлдә төшсәләр, бер-берсенә исемнәрен үк әйтешеп исәнләшәләр, хәбәрләшәләр. Тик Аетбайның гына байтакка кадәр теге «үзгә бер зат» булып күренгән кызыкайның тавышын ишеткәне булмады.

Әллә нишләп моңа кадәр күрмәгән-белмәгән шул кызыкай Аетбайның исенә төшә дә тора. Теге ярда ак халатлар күрендеме — ирексездән күзләре шуны эзли, тапса — шатлана, йөрәге рәхәт итеп тибә башлый. Кызыксыну җиңде. Егет түзмәде, бер көнне яшереп кенә биноклен алып төште. Буш вакытында кояшта кызынуны аңа байтак көтәргә туры килде. Һәм ни күрде дисез — кызыкай су буена ялгыз килде. Кыз халатсыз иде. Өстендә ак кофта, тубыгыннан югары кара юбка, алтын-сары чәче беләк юанлыгы толымга үрелгән иде. Биле өзелеп кенә тора. Ул яр башыннан оста биючедәй гәүдәсен уйнаклата-уйнаклата атлап төште: су читенә җитәрәк сикергәләп тә алды. Аннан аягына кигән босоножкиен абайсыз гына салып комга ыргытты да, балтырына кадәре суга кереп, дулкын чыгарып йөри башлады. Җай гына бара да, кинәт иелеп учы белән су болгатырга керешә. Шунда челтерәтеп көлгәне дә ишетелеп кала. Ә-һә, бу вак балык көтүләрен өркетеп кинәнә икән.

Аетбай беренче күргәндә үк аны балалыктан чыгып җитмәгән бер үсмер кызыкай дип уйлаган иде. Әле шул тойгысы тагы ныгый төште. Озакламый кыз, иркен кыланып, өстендәгеләрне тоташ салып ыргытып, зәңгәр купальниктан гына калды. Шул минутта егетебез, уңайсызлык кичереп, кинәт үзалдына кызарынды һәм биноклен йонлач тастымалга төреп куйды, аннан әзмәвер гәүдәсе белән комга сузылып, бары күккә генә карап ятканга салышты. Шунда Аетбайның баш очындагы текә ярдан тотанаклы гына «и-һи-һи!» дигән тавыш ишетелде. Савучы егет җелт иттереп башын күтәрә салды. Аңа игътибар да итмәгәндәй, халат итәкләрен җилләндереп, Зөләйха үтеп бара иде.

Җәйләүдә Аетбайны савучы кызлар сүз катмый каршылады: шулай итеп, аны үзләреннән бөтенләй аердылар да куйдылар сыман тоелды егеткә. Бары Гөлгайшә җиңги генә:

— Ак болытлар бүген кайсы якка йөзә иде, кайниш?— дип, кашын чөеп күз кысты. Кызлар, читкә карап, пырх-пырх килеп көлештеләр.

«Бу Зөләйха-саескан җиткергән икән!» — дип, Аетбай эчтән генә сукранып алды. Шунда кинәт бинокле исенә төшеп, тәненә салкын тир бәреп чыкты һәм аны тиз генә шомырт куагы күләгәсендә торган мотоциклына тыгып, брезент япма белән томалап та куйды.

Бәхетенә каршы, ул турыда авыз ачып сүз әйтүче булмады. Күреп өлгермәгән икән теге саескан. Югыйсә, беткән иде башы. Күзен дә ачырмаслар иде. Хурлыгыңнан җәйләүне ташла да кач.

Татарстан «Агыйдел»е савучылары төш алдыннан елга буена бергә килделәр; кабаланалар иде булса кирәк, уен-көлкесез генә юынып-коенып чыктылар да, дәррәү бергә күтәрелеп, куаклык арасындагы сукмакларына кереп юк булдылар. Вак балык өркетеп уйнарга ярата торган шаян кызыкай да аерылып калмады. «Әй-й, аның нәфис сыйфатларын үзем генә уйлап чыгардым, ахры»,— дип уйлады Аетбай. Тик кичен йокларга яткач, егет шуны сизде: аккошлар шикелле ак халатлы аръяк кызлары аның күз алдыннан һич китмәделәр. Кара син аны! Күзне йомдың исә, каршыңа әлеге кызыкай килеп баса... Әнә, чынаяктай ак битен юарга суга иелгән иде, беләк юанлык алтын толымы иңбашыннан җай гына шуып төште дә очын суга манып, дулкын уңаена чайкала башлады...

Икенче кичне аръякта учак дөрләде. Җәйләүдәгеләр янына авылдан егетләр килгән иде булса кирәк. Баян тавышы яңгырап торды. Кызлар башлаган җырга егетләрнең калын тавышы кушылды. «Аларда нинди күңелле!» — дип уйлады Аетбай. Шунда чыгып, уенга кушылып китәсе килә иде аның. Тик егетләр генә җырлаган бер җыр тора-бара берничә тапкыр кабатланып, сүзләрен дә отып алгач, Аетбай сагаеп калды. Үзе шаян, әзрәк үпкәчел төртмә җыр иде ул:

*Исеме Мөхәссәнә...*
*Сөйсәң — сөй, сөймәсәң — сөймә,*
*Сөймәсәң — сөймәсәнә...*

Бу җыр тагын аның исенә баягы кызны китереп төшерде. Аның исеме нәкъ Мөхәссәнә булырга тиеш. (Нинди кызык исемнәр бар татарларда!) Бәлки авылдан сагынып килгән егетләр Мөхәссәнәнең үзенә генә карап җырлыйлардыр!..

Ә кичә Агыйдел буена татар кызлары тантаналы итеп, туй җырлары җырлап килделәр. Аетбай мотоциклының сиртмәсе төбеннән биноклен тартып алганын үзе дә сизми калды. Иң алдан иңенә сыгылмалы көянтә салып, бизәкле зәңгәр чиләкләр элеп, әлеге кыз төште. Биек үкчәле кызыл читек киеп, вак-вак басып җитез генә атлый иде ул. Бала итәкле зәңгәр күлмәге, билен өзелдереп буган каюлы алъяпкычы аны күз алдында озын буйлы кыз иткән дә куйган. Кызыл мәрҗәннәр белән каелган ак калфак та, җемелдәшеп торган чулпы, сыргалар да бик килешә икән кызыйга. Аңа ияргән кызлар туй җырлары җырлый. Димәк, яшь киленне су юлы башлаталар. Димәк, яшь килен... менә ничә көн инде ирексездән Аетбайның Идел аша күзе төшеп йөргән кыз. Димәк, үзен күрмәс борын ук аннан колак какты егет...

Шуңа күрә Аетбай бүген елга буена төшмәм дип сүз биргән иде. Кызлар бөтен савыт-сабаны, флягаларны ком белән ышкып юуны уйлап таптылар. Савучы булгач, бу эшкә катышмый калу ярамый иде.

Эш беткәч, Аетбай нииндидер билгесез өмет белән аръякны күзәтергә кереште һәм... морадына ирешге. Татар ягының кызые, бу юлы кызыл чалбар киеп, алтын толымын башына кибән итеп ураган да, кулындагы сыек тал чыбыгын уйната-уйната, ыргаклап төшеп килә.

Кинәт аның чая тавышын ишетте егет:

— Аетбай абый! Мине чыгып алып, көймәдә йөрет әле!

Ул колагына ышанмый торды. Кара син аны, әллә кайдан исемен дә белеп алган! Ничек матур, назлы иттереп әйтте!

Аетбай шунда гына үз янында ярга төртелеп бер көймә торганын абайлады, сикереп торып, аңа ташланды. Ишкәкләре дә бар иде.

— Кара, кара! Шаярып кына әйткән идем! Чыгып та килә! — диде кыз, бераз каушаган тавыш белән.

Юк, Аетбай аның шаярып әйтүен теләми иде. Шуңа да качып китә күрмәсен дип, мускулларын уйнаклатып, катырак ишәргә кереште.

Юк, качмады кызый. Борыны белән аръяк комына килеп кадалган көймәгә кыю атлап керде; хәтта беренче тапкыр күргән ишкәкченең иңенә йомшак кына таянып, койрыкка узды. Шунда гына исәнләшү исенә төште.

— Саумысыз, Аетбай абый! — Зәңгәр күктәй зәңгәр күзләре белән матур итеп карап, Агыйдел чоңгыллары кебек бит очындагы чокырларын күрсәтеп ихлас елмайды аңа шомырт кебек зифа буйлы бу кыз.

— Исememне дә белеп алган әле сылу! — диде Аетбай да, рәхәт елмаеп.

— Кызларыгыз телennән төшерми ич! — Ул тагы көлде. — Бигрәк яраталар, ахры, үзеңне. Аеруча әнә теге яр башыннан күзәтеп йөргән апа... Һи-һи-һи...

— Юк, артык иркәләмиләр, Мөхәссәнә...

Кызыкай, күзләрен зур ачып, утырган урыныннан артка чайкалып куйды һәм Агыйдел өстен тутырып кычкырып көлеп җибәрде.

— Һа-һа-һа! Үләм! Белмәдең, белмәдең! Минем исемем Мөхәссәнә түгел. Минем апам ул — Мөхәссәнә. Ул инде ике ел җәйләүгә чыга. Ә мин, былтыр техникумга керә алмагач, быел гына килдем...

Ачык күңелле бу кызыкай белән күзгә-күз карашып сөйләшә-сөйләшә елга үренә каерып ишүе дә Аетбайга җип-җиңел сыман тоелды. Әйтерсең алар бу шаян татар кызы белән әллә кайчан танышлар да, көн саен күрешеп торалар.

— Алай булгач, кичә егетләрегез җырны апаңа атап җырлаганнар икән!..

— Әйе шул, апама. И-и, аны күрсәң, исең китәр иде... Егетләр үлешә яза...

— Егетләрегез шулай усалмыни? Көймәдә алып киткән өчен мине тотып тукмамаслармы соң?

— И-и, Аетбай абый, шушы гәүдәң белән тукмалудан куркасыңмы? Һа-һа-һа!

— Бик курыкмыйм да... — Егет юри җитди чырай белән дәвам итте. — Шулай да башым-күзем күгәреп йөргәнне сөймим...

Кыз үртәп:

— Шулай булгач, куркасың була инде. Куркасың, куркасың, куркасың! — дип кабатлады. Һәм шунда ук тавышын үзгәртеп: — Ә минем өчен бер егетнең дә сугышканы юк әле. Кызык буламы икән ул, Аетбай абый?

— Белмим шул, минем дә, шушы яшемә җитеп, бер кыз өчен дә сугышканым юк. Нинди кызык, икебез дә бер чама икәнбез...

— Һи-һи-һи! — дип көлеп җибәрде кызый.

Исемеңне әйт инде хәзер!

— Үзең бел!

— Мәфтуха!

— Юк!

— Мәхмүзә!

— Һа-һа-һа! Ай, көлдереп үтерәсең, Аетбай абый җаным!

Аетбай, аның саен дәртләнеп, теленә килгән бер хатын-кыз исемен атады:

— Миңнурый... Гөлкагыйдә... Васфиҗамал...

— Ай-ай! Үләм! Җитте! Онытылып беткән әллә нинди исемнәр казып чыгара башладың...

— Әйтеп котыл!— дип кыса бирде Аетбай.— Югыйсә, аннан да искерәген табам да үзеңне гомер буе шулай дип йөртәм.

— Ой-ой! Бетте, бетте, абый җаным! Мәндүзә! Мәндүзә минем исемем!— Үзе үк өстәп куйды: — Матур бит?

— Бик матур! Дөньяда иң матур исем!— диде Аетбай, әсәрләнеп.— Моннан соң гомеремдә дә телемнән төшермәм исемеңне, Мәндүзәкәй!..

— Барыбер соңга калдың. Мин инде, Аетбай абый, синең исемеңне биш көн телемнән төшермим.— Кызның бит очлары кып-кызыл булды, түбән карады. Һәм шунда, акланган сыман итеп: — Бигрәк матур исем шул! Җырга кушып кына җырлап йөрерлек,— диде.

Әзрәк тын килгәч, Аетбай шактый артта калган аръяк җәйләвенә күз салды.

— Борылмыйкмы инде, Мәндүзә сылу?!

— Нигә, әллә арыдыңмы, Аетбай абый? Арыгансыңдыр шул. Агым бик каты...— диде ул, мөлдерәп түгелергә торган зәңгәр күзләре белән егеткә карап.— Әйдә, булмаса, икәүләп ишәбез!— Ул, җавап та көтеп тормый, көймәне чайкалта биреп кузгалды да, һичбер тартынусыз, ишкәкченең култык астына ук сыенып килеп утырды һәм озынча ак куллары белән Аетбайның кызарган йодрыгы яныннан ишкәк сабына тотынды.

Мәндүзәнең бу кадәр кыю хәрәкәтеннән басынкы егет шактый каушап калды. Ишү үзенең талгынлыгын югалтты. Ишкәкләрнең әле берсе, әле икенчесе өстән генә шуып китеп су чәчрәтте. Мәндүзә чәче белән Аетбайның битен кытыклап, чигәсен аның иңенә тидерептидереп, рәхәтләнеп көлде.

— Кайткач сиңа ни диярләр инде?..

— Кем ни дисен миңа? Әйтеп карасыннар!..

— Ә киявең?

— Киявем?!— Мәндүзә сискәнеп куйды. Ул, каерылып, Аетбайга гаҗәпсенеп карады: — Нинди киявем ул?

— Кичә сине кемдер килен итеп алды түгелме соң?

Мәндүзәнең кинәт исенә төште. Ул, су өстен яңгыратып, тыела алмый көләргә тотынды.

— Ой, үләм! Аетбай абый, тот мине! Хәзер суга сикерәм, югыйсә! Миңа дигән кияү әле... бишектә тибрәнеп ята... Һа-һа-һа!..— Ул көлүеннән тынды һәм аңлатып бирде: — Без бит кичә ял вакытында, дәртләнеп китеп, үзебез уйлап чыгарган «Туй» дигән спектакль уйнадык. Чынлап та, мин килен идем шул. Кызлар су башлатканын күреп калгансың икән... Һи-һи-һи...

— Шулаймыни?..— Аетбай кызның иңенә кагылып мут кына итеп күзен кысты.— Югыйсә, көнчелегемнән үләр чиккә җиткән идем.

Мәндүзә көлмәде. Ул назланып Аетбай күкрәгенә тагы да ныграк сыена төште:

— Әллә мин сиңа ошыйммы, Аетбай абый?

— Бик ошыйсың, Мәндүзә... Мин сине беренче күргәч тә...

— Бинокльдәнме?— дип, шук кына өстәп куйды кызый.

— Юк, аңа кадәре дә әле... — диде Аетбай кызарынып.

— Мин дә сине ошаттым, Аетбай абый...— Ул үз сүзләреннән үзе калтыранып куйгандай итте.— Юк, юк, син көлмә. Кичә генә мактап-

тән чыккан исәр бер кызыкайның акылсыз сүзләре дип... Исемеңне беренче ишеткәч үк, син миңа батыр кешедер сыман тоелдың. Шуннан гел якыннан күрәсем килеп йөреде... Рәхмәт мине чыгып алганыңа...— Бу сүзләрен ул, ниндидер тирән моңга бирелеп, хисләнеп әйтте. Бу инде әле генә теленә ни килсә шуны сөйләп килгән шаталак кызыкай түгел иде. Кара син аны, нинди җитди дә була ала икән үзе!

— Таптың батыр кешене!— дип көлемсерәде Аетбай.

— Юк, юк, батыр!— дип каршы төште Мәндүзә.— Савучы булып килгән кешеләр — чын батырлар алар. Мин аның нинди кыен эш икәнен килгәч кенә белдем. Ташлап качып кайтырга да уйлаган идем, оялдым гына... Шуннан күнектем. Хәзер шатланып бетә алмыйм.

— Мин дә... — дип үзенекен әйтә башлады Аетбай. — Мин дә нәкъ синең кебек...

Кыз үзенекен әйтеп бетермәгән булып чыкты.

— Ә ир-атка савучы булу аеруча кыен. Өстәвенә, кызлар көлгәнгә дә түзәргә сабырлык кирәк, әйе бит, Аетбай абыем?— Ул акыллы, уйчан күзләре белән янә егеткә каерылып карады.— Шулай булгач, син батыр булмый кем батыр булсын?..

Аетбай зур кинәнү кичерә иде. Үз күңеленңне аңлаган кеше белән серләшүе никадәр рәхәт! Ә ул, беренче мәртәбә якыннан күрешүләре булса да, сиңа олы ышаныч белдереп, күкрәгенә сыенып ук утыра.

— Әйе,— диде егет, дулкынланудан өзек-өзек итеп.— Ярату... Яраткан эш шатлык китерә. Мин... әйе... Соңгы вакытта аны тагы да ачыграк тоя башладым. Бүген тагы да ныграк... — Һәм тиктомалга чын ихласланып:— Рәхмәт сиңа, Мәндүзә!— дип әйтеп салды.

— Бәй, Аетбай абыем, миңа нигә рәхмәт?

— Әйе, сиңа рәхмәт!.. Агыйделнең аръягында син булган өчен... Чыгып ал!— дип кычкырганың өчен...

— Юк, юк, иң башта үзеңә... Мине чыгып алганың өчен...— Ул иркәләнеп башын «абыйсының» иңбашына салды.

Агыйдел, көймә читенә чулт-чулт дулкын кагып, тын гына ага да ага. Ике яр да, куаклар да артка йөгерә.

Тавышлар ишетеп, икесе дә кинәт аңнарына килделәр. Арт белән утырганга күрмәгәннәр икән. Ике ярга ике «Агыйдел»нең савучылары чыгып баскан. Көймәдәгеләргә кул болгыйлар, көлешәләр.

— Ай, Аетбай абыем!..— Мәндүзә аның култык астыннан чыгып көймәнең койрыгына барып утырды. Ул сытылырдай булып кызарынган иде.

— Ах, кызларыгыз кирәгеңне бирә инде хәзер!— дип үртәде аны Аетбай, үзенең уңайсызлануын каплар өчен.— Мөхәссәнә апаң чеметеп, күгәрмәгән җиреңне калдырмый, болай булгач...

— Кагылып карасыннар!.. Агыйделгә ташланырмын да... синең янга йөзеп чыгармын... Якларсың бит, Аетбай?— Менә исемен «абый»дан башка да әйтте Мәндүзә.

— Яклармын, яклармын...— диде егет теле белән. Ә күңеленнән: «Чыккач, үзебезнекеләр нишләтер икән? Күземне дә ачырмаслар инде!»— дип уйлады.

Татар «Агыйдел»е кызы әйтерсең аның уен ишетеп торган:

— Ә син сер бирмә, Аетбай!

Шунда башкорт «Агыйдел»енекеләр җыр башлап җибәрделәр:

*Аллар бирсәң — аламын...*
*Гөлдән юллар саламын...*
*Сөйгән ярым теге ярда,*
*Йөзеп чыгып аламын...*

Татар ягыныкылар бердәм кушылды:

*Сөйгән ярым теге ярда,*
*Йөзеп чыгып аламын.*

Күмәкләп көй уңаена кабатлыйлар:

*Һи-һи-һи! Һа-һа-һа!*
*Йөзеп чыгып аламын!..*

Якынайгач, башкорт ягыныкылар кычкырдылар:
— Аетбай, кире илтеп мәшәкатьләнмә инде!..
— Берьюлы үзебезгә генә ал да чык чибәркәйне!..
— Әйе, әйе! Бездә дә савучы җитми!..
— Я борыл инде үзебезнең якка!..
Татар ягыныкылар риза булмый кычкыра:
— Юк, юк, Мәндүзә, үзең алып чык!..
— Бездә дә егетләр бик кадерле!..
— Аетбай кебек оста савучылар безгә дә кирәк!..
— Борылыгыз бирге якка!..
Аларның тавышы көрәйде:
— Ана, ана, безгә борылдылар!..
— Молодец, Мәндүзә! Алып чык, алып чык!..
Чиктән ашып оялган кызый алтын чәчен туздырып төшергән дә, битен учлап, түбән карап шым калган. Һуш алырдай матур иде ул шушы мәлдә! Ә үзе, ишетә күрмәсеннәр дигән шикелле, тузгыган чәчен кушып кыскан бармаклары арасыннан пышылдый:
— Ә без сер бирмик, Аетбай абыем... Мине иртәгә дә чыгып ал... аннан соң да... тагы да, ямә?..
— Ярар, Мәндүзә, мин көн саен...
Чиксез шат иде Аетбай. Яшәвенең мәгънәсе бермә-бер арткандай булды хәзер. Дөнья искитмәле матур иде.

## Тәүфикъ Әйди

# ТЫЛСЫМЛЫ СУРӘТЧЕ

Ленинград. Рус музее. Ыспай киенгән җитен чәчле бер ханым «Тукай Кырлайда» рәсеме янына әйләнә дә килә, әйләнә дә килә. Әле ерактан сокланып карап тора, әле якынрак килеп, буягыч эзләренә күз сала. Хәйран тамаша! Кара син бу көлеп торган чәчәкләргә, кара син бу яшьнәп торган үләннәргә — бу бит табигатьнең, гөрләп торган тормышның үзе. Арада таныш булмаган гөлләр дә бар, үлән яфраклары да сәеррәк. Әмма аларда күзне иркәли торган күпме ямь, күпме тереклек һәм серлелек. Табигатьтә серләр бетмәгән кебек, бу рәсемдә дә без киләчәктә ачасы яңалыклар бар сыман. Әнә шул гөл-чәчәкләр арасында уйга талып яткан мөлаем йөзле егет кайсы мөхитләрдә йөзә икән? Ихлас карашлы, якты чырайлы бу егет тә үзен урап алган әнә шул гөлләр төсле табигать анабызның иркә бер баласымы? Чәчәкләр искиткеч матур, тик алар үз кочагына алган кешене каплый да, аны тоныкландыра, төссезләндерә дә алмый. Тамашачы кабат-кабат якынлашып, суратнең нәкъ үзәгендә тын гына, моң гына яткан Габдулла Тукайга төбәлә, аның саф күңелендә нилләр гәүдәләнүен беләсе килә. Барыбыз өчен дә үтә якын хыяллар бөреләнәдер, теләкләре ак, максаты хактыр, чөнки рәсемнән көлтәсе белән пакьлек, яктылык бөркелә.

Ханым, янәшәсенә кара костюм, галстуктан, чәченә кырау төшкән бер ир килеп баскач:

— Нинди шигъри рәсем, һәр чәчәге җырлап тора. Бу сурәтченең монда бүтән картиналары да юкмы икән? — дип эндәшә.

Ир көлемсери:

— Белмим. Ә нәрсәсе әйбәт аның? Майлаган да майлаган, җитмәсә, тоташ ботаника!

Җитен чәчле ханым сәерсенеп карый, таныш түгел ирга каты бәрелергә бик уңайсызлана, әмма чын сәнгатьне якламау оят булыр иде.

— Димәк, сез берни дә аңламыйсыз!

Һәм кисәк борылып залдан чыгып китә. Көлсу чәчле ир елмая. Эчкерсез ханымның кәефен кырырга теләмәгән иде ул, бары тик фикер алышу, сынау өчен генә әйткән иде. Бик мәзәк кенә килеп чыкты әле бу... Ханымны куып җитеп гафу үтенәсе һәм рәхмәт әйтәсе иде дә бит, ярамый, килешмәс. Чөнки ул шушы рәсемнең авторы — Фәйзерахман Әминев үзе!

1972 елның апрелендә Казанның сынлы сәнгать музеенда шәхси күргәзмәсен тамаша итәргә килүчеләр белән Ф. Әминев инде болай шаярырга базмады. Монда да аны танучылар сирәк иде. Шуннан файдаланып, ул бу юлы да сәнгать сөючеләр арасында булды, әмма хуплау, бәхәсләшүләргә колак салып кына йөрде.



*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Фәйзерахман Әминев.*

— Халыкның эчке рухи дөньясына, табигатьне сиземләвенә тирән үтеп кергән, аны төсләр-сурәтләрдә шушылай күркәм итеп чагылдырган мондый художникны әле мин беренче тапкыр күрәм,— диде иптәшләренә бер ир кайнарланып.

— Карап туйгысыз гүзәл иҗаты белән татар халкы сәнгатен киң дөньяга чыгарган өчен бу кешегә нинди генә рәхмәтләр әйтергә икән? — диде шатлыгы йөзенә бәреп чыккан бер ханым.

Егетләрнең берсе аны татарның республикабыздан читтә яши һәм иҗат итә торган күренекле сурәтчеләре Әмир Мәҗитов, Әсгать Сәфәргалин, Әхмәт Кытаев, Илдар Ханов, Чыңгыз Әхмәревләр сафына бастырып, Фәйзерахман Әминевне арада иң үзенчәлекле, кадерле санавын белдерде. Ә өлкән яшьтәге бер апа: «Кешеләрне, табигатьне шул кадәр тере итеп ясау сәләте кайдан килә икән бу Фәйзерахманга»? — дип гаҗәпләнде.

Кайдан килә икән соң ул?

Фәйзерахман Әминев фикеренчә, моның җавабы татар халкының дөньяны бизәкле, төсле, образлы итеп күрүендәдер. Аның бу сәләте ислам дине тарафыннан гына изелеп, сытылып килгән. Дини тыюларның бер очы Фәйзерахманга да тиде әле. Өч-дүрт яшьләрендә булгандыр, ул бер китап битенә тотты да җизнәсенең рәсемен төшереп куйды. Бу «пычратылган» китап «һәфтияк» икән, атасы малайны азуы, изге басманы эштән чыгаруы өчен, яхшы ук кыздырмакчы иде дә, рәсемнең кияүгә хәйран охшашлыгын күргәч кенә, шелтәләү белән чикләнде. Әмма малай икенче гөнаһы өчен җиренә җиткереп җәзаланды.

Мәдрәсәдә укыган чагы. Фәйзерахман, дәрес бирүче хәлфәне онытып, тәрәзәдән тышны күзәтә, кызыгып китеп, күбәләк карлар явуын тагын китап битенә төшерә. Хәлфә, арттан килеп, яңагына чапкач кына исенә килә һәм... куркудан тәһарәтен дә чак кына бозмый кала.

Әмма сурәт белән мавыгуын ташламый Фәйзерахман. Күрәсең, бабаларымның берсе кайчандыр рәсемчелек белән шөгыльләнгәндер, шуның һәвәслеге, маһирлыгы буыннан-буынга күчеп килгәндер, дип уйлый ул. Әмма әнә шул потенциаль куәтнең җимеш бирүе өчен иҗтимагый тормышта тирән үзгәрешләр булуы кирәк иде.

Кем соң ул Фәйзерахман? Аның әнкәсе Зиһникамал Татарстанның Апас районы Кече Кайбыч авылында, әткәсе Габдрахман Кайбычтан унбиш чакрымнар ераклыктагы Татар Танаенда туып үскән. Ике яшь йөрәк, башлы-күзле булып гаилә корып җибәргәч, читкә — Кизел шахтасына чыгып киткән, иркен тормыш эзләп, Көнгер шәһәренә дә килеп җиткәннәр, һәм менә шушында «һәфтияк» пычратучы «дәһри» туган.

Бала чак — күңелләрдә мәңге саклана торган гаҗәеп сихри дөнья. Ул хатирәләр дистәләрчә зур картиналарга һәм нәниләр өчен чыгарыла торган китапларның җыйнак сурәтләренә азык бирә ала. Габдулла Тукайның Фәйзерахман бизәгән «Карлыгач» китабын алыгыз да берәм-берәм битләрен ачыгыз әле. Менә «Бишек җырына ясалган сурәт. Чәчәкле ак чыбылдык белән капланган сиртмәле бишек. Озын күлмәк кигән, яулыгын таратып бәйләгән ана бала тирбәтеп утыра. Бу — Фәйзерахман тирбәлгән бишек, аның әнкәсе түгелме икән? Сәке, сәкедәге ястык-мендәрләр, идәнгә җәелгән палас-келәм, түрдәге сандык та таныш. Фәйзерахманга да, безгә дә. Бу сурәттәге һәр нәрсә татар халкы көнкүрешендәге бер чорны бик төгәл һәм матур итеп күз алдына бастыра. Гади һәм ямьле. Менә шул рәсемнәр балада үз халкына мәхәббәт тәрбияли.

Ел фасылларын сурәтләгән рәсемнәр дә күзне иркәли. Аларда ата-анасы сөйләгән истәлекләр белән күңелгә кереп калган Кайбыч ягы табигате дә, Көнгер яклары күренешләрен дә табарга мөмкин. Табигать һәм кеше хезмәте белән барлыкка килгән нәрсәләр нинди гармоник бөтенлек тәшкил иткән. Ә «Гали белән Кәҗә»не күргәч, елмаймый булдыра алмыйсың. Нинди кызыксыну һәм үз-үзен оныту Галидә! Аның өчен дөньяда кәҗә сыйлаудан башка һични юк. Ул җитдилек, ул һәвәслек! Сурәтче аны гаять зур мәхәббәт, юмор белән ясаган. Бер генә тотам ите булган малайга яхшы ук иркен күлмәк, төбе салынып торган чалбар кидергән. Крестьян малаен чолгап алган тирәлек тә бик төгәл детальләр белән гәүдәләндерелгән. Икеләнми әйтә алабыз: нәкъ Тукайча бу, шагыйрь күргәнчә!

— Бала чактан ук әткәй-әнкәй сөйләгән Г. Тукай шигырьләре, әкиятләре, әйтик, «Шүрәле», «Су анасы», «Кәҗә белән Сарык» һәм башкалар минем күңелдә онытылмаслык тирән эз калдырган. Хәзерге көнгә кадәр бу әсәрләр мине тирән дулкынландыра, — ди Ф. Әминев.

Рәссамның бала чагы аның бүгенге иҗатында чагыла. Ул иҗат сурәтченең сабый чак хатирәләреннән бүгенге татар балаларының рухи байлыгына сузылган күпер, аңа кушылган кыйммәтле хәзинә. Моны күрер өчен Ф. Әминев тарафыннан бизәлеп, Мәскәүдә зур тираж белән чыккан «Шүрәле» китабын ачып карыйк.

Беренче сурәттә Кырлай табигате, авыл тормышы, татар халкының көнкүреше гәүдәләндерелә. Кимә-арбада бала тирбәтүче кыз, аның янында кыршау тәгәрәтеп уйнаучы малай һәм суга барырга чыгып килүче әнкәләре. Монда һәр деталь җентекләп уйланган, рәссам нечкә график сызыкларда үзенең дөньяны күрү рәвешен, аны сурәтләүдә үз алымнарын, табышларын калку күрсәтә алган. Агач, такталардан матурлап ясалган капка, йорт түбәсенең түмгәк-түмгәк булып кабарып торуы, хатынның куштанлы итәк-җиңнәре, күкрәп үскән агачлар, үләннәр һәм гөлләр, аларның чуклы-чачаклы яфраклары, чачкәләре — монда барысы да гадәттән тыш куе төсләргә бизәлгән. Агач күләгәсенә поскан йорт, яргаланган бүрәнә, әләмәч-тәләмәч килгән читәннәр, яшел чытырманлык — табигатьнең мондый гаҗәеп бер почмагында тагын ни генә булмас дисез?!

Менә яшь егет урманга бара. Серле әкият дөньясы тагын да куера төшә. Бу урманның агачлары да гади агач кына түгел, кеше сынын, нә мәгълүм җан ияләрен хәтерләтә, аларның ботак-куллары юлаучыга үрелгән, җитмәсә, кояшы да баеп килә, эңгер караңгылыгы җәелә. Ә егет тыныч, хәтта йокымсырап та бара бугай әле.

Сурәт арты сурәт. Берсеннән икенчесенә күчә барган саен киеренкелек арта. Карурман дәһшәтле төскә керә. Мондый куелыкта хыялый җанварлар, шүрәләләр яшәсә дә гаҗәп түгел. Агач кайрылары да фантастик кыяфәттә күзгә бәреләә, гөмбәләре дә эшләпәңнән дәүрәк. һәм искиткеч үләннәр, үләннәр! Алар рәсемнәргә аерым бер матурлык, байлык, сихрилек төсмере бирә. Аларда авторның үз фантазиясе, табигатьне яратуы ачыла. Бу чәчәкләрнең кайберсе, ихтимал, дөньяда юктыр да. Әмма алар бик урынлы, килешле тоела, кабатланмас төс-бизәкләре белән сокландыра. Алар я кайчандыр үскән, я киләчәктә шытып чыгар — һәрхәлдә, безгә алар бик тансык, бик хаҗәт. Сурәтче аларны гаять зур саклык белән ясый.

Рус сурәтчесе И. И. Шишкин табигать күренешләре, урман рәсемнәрен ясавы белән танылган. Үсемлек дөньясын бик оста гәүдәләндерсә дә, Шишкин кеше һәм хайван сурәтләрен ясарга кыенсынган икән. Фәйзерахман Әминевнең «Шүрәле» әкиятенә иҗат иткән рәсемнәренә күз салсак, сурәтче осталыгына тагын бер сокланмый булмый. Коты алынган ат рәсеменә, Былтырга һәм шүрәләләргә нинди табигыйлек хас! Ә шүрәләләрнең һәркайсы үзенә генә аерым рухи халәте белән тотып алынган. Монда ачулы кисәтү ясаучысы да, аптырашта калганы да, мыскыллы көлүчесе дә, куркуга төшкәне дә бар. Әйтергә кирәк, Ф. Әминев Шүрәлене үзенчә ала, үзенә кадәр иҗат иткән бүтән рәссамнарны кабатламый.

Бу сурәтләрдә Ф. Әминевнең композиция остасы булуы да күзгә чалына. Шүрәленең алдануы рәсемендә күзебез башта ярсыган атка, аннары бармак янап торучы Былтырга төшә. Сәер буынтыклы агачлар фонында, ниһаять, Шүрәле үзе күренә. Ат һәм егет ничек кенә игътибарны җәлеп итмәсен, без котылгысыз рәвештә Шүрәлене эзлибез, ә егет рәсемнең комик каһарманына бармак изи һәм шулай безгә юл күрсәтеп тора. Шүрәленең артында — кара урман, алдарак — тәфсилләп су-



*Тукай үзенең әкият геройлары арасында. Киндер. Темпера.*



рәтләнгән агачлар. Барысы да кызыксынып карала, чагыштырмача тыйнак нисбәттә һәм арттарак торуга карамастан, Шүрәленең үзәк фигура булуы аермачык. Ирексездән, әгәр Ф. Әминев язучы булса, мавыктыргыч сюжет остасы икәнлеген тагын да бер кат раслар иде, дип уйлыйсың.

«Ихтимал, үз арабыздан маһир рәссамнар чыгып, Шүрәленең кәкре борын, озын бармак, мөгезле башларын һәм дә кулы кысылуларын, шул тасвир кылынган урманнарны — һәммәсен тәрсим кылып чыгарлар», дип хыялланган иде Г. Тукай.

Без бүген «Шүрәле» әкиятен истә кала торган итеп һәм чын сәнгатьчә рәсемләгән Бакый Урманче, Байназар Әлминевләрне атыйбыз, алар сафына талантлы Фәйзерахман Әминев кушылуын, бу затның Шүрәле мотивларын тагын да югарырак баскычта образлы гәүдәләндерүен, аларны үстерүен зур шатлык белән әйтә алабыз. Фәйзерахман Әминев шаулап чәчәк аткан табигатьне, кеше белән табигать бердәмлеген Тукайга хас бугланча тирән һәм халыкчан итеп сурәтли.

Кайда өйрәнгән соң ул мондый осталыкка?

Бүтәннәр кебек чабата киеп, Көнгер татар мәктәбенә укырга йөргән малай ул. 1922 елдан башлап Пермьнең сигезенче татар-башкорт мәктәбендә белем алган һәм монда рәсемнәр ясавын дәвам иттергән. Менә шунда инде ул сурәтче буларак танылган, һәр язны мәктәптә аның сурәтләре күргәзмәсен оештыру гадәткә кергән. 1927 елда Фәйзерахман Троицкидан килгән икенче бер талантлы татар егете Чыңгыз Әхмәрев белән Пермь сәнгать техникумына укырга керә һәм аны 1930 елда уңышлы тәмамлый.

Ф. Әминев хезмәт юлын Пермь опера-балет театрында рәссам ярдәмчесе булып башлый, бераздан инде ул мөстәкыйль рәвештә «Севиль чәчтарашы», «Кәмитчеләр» спектакльләренең декорацияләрен ясый. Шәһәрнең театр сөючеләре афишаларда Әминев исемен торган саен ешрак укый башлый, пәрдә ачылуга бәшта егерме ике яшьлек Фәйзерахман иҗатына кул чаба.

Әмма яшь егетне театрда рәссам булып эшләү канәгатьләндереп җиткерми, аның татар тормышыннан алып үзе теләгән темаларга әсәрләр иҗат итәсе килә. Моның өчен әле белем дә, тәҗрибә дә җитмәвен тойганга күрә, ул укуын дәвам итәргә омтыла һәм күренекле сурәтче И. И. Бродский ярдәме белән Репин исемендәге Ленинград сәнгать институтының эшче факультетына урнаша. Монда ул яраткан остазы Бродский, соңрак Р. Р. Френц остаханәләрендә сурәт сәнгате серләрен өйрәнә, көннәрен төнгә ялгап, төсләр уенын, үлчәмнәр нисбәтен, сюжет, композиция кору осталыгын үзләштерә. Уку озакка сузыла, сугыш елларында өзелеп тә тора, бары 1948 елда гына ул, «Сабантуй» картинасын иҗат итеп, диплом яклый. Шуннан соңгы чорда рәссамны тулысы белән диярлек Тукай темасы һәм татар халык авыз иҗатыннан алынган сюжетлар били ала.

Бөек шагыйребезнең әсәрләре Ф. Әминев өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы ул. Бер-бер артлы «Тукайның бала чагы», «Тукай Петербургта», «Тукай үзенең әкият геройлары арасында» һәм башка сурәтләр барлыкка килә. Аларның кайбер-

ләре инде Ташкентның Алишер Нәвои исемендәге, Казанның сынлы сәнгать, Кырлайның Г. Тукай музейларына куелган.

Казанда аның шәхси күргәзмәсенә килүчеләр «Кырлай», «Тукай Кырлай урманында», «Былтыр», «Пар ат» картиналарында билгә кадәр күкрәп үскән үләннәрне, аллы-гөлле чәчәкләрне, тереклек тантанасына мәдхия булган бәдрә каеннар, баһадир наратларны күреп таң калды. Алар гаять пөхтә, зур тырышлык һәм сабырлык белән искиткеч нәфис ясалганнар. Сурәтче табигать дөньясын киндергә түкми-чәчми, буяуларына тузан хәтле дә кер кундырмый төшерә белә. Хәтта болындагы чәчәкләреннән хуш ис бөркелгәндәй, каен тәлгәшләре җилдә тирбәлгәндәй тоела. Ул рәсемнәрне тамаша иткәч, профессор-биолог Утәй тәэсирләнеп, авторга:

— Нәфис талантыгыз өчен — шул кадәр нечкә ясалган, сөйләшәсе килеп торган җанлы рәсемнәр рәвешендә Г. Тукайны безгә терелтеп алып килүегез өчен Сезгә күп рәхмәт. Сез татар халкының тарихына реаль күренешләр биргәнсез, — дип язган.

Ф. Әминевнең яратып һәм бирелеп эшли торган бер өлкәсе — әйткәнебезчә, татар халык иҗаты мотивларына нәкыш әсәрләре иҗат итү. Бу әсәрләрнең кайсына гына тукталсаң да, сурәтченең төрле төс-бизәкләр сайлаудагы кабатланмас үзенчәлеге ярылып ята. Менә «Айлы кич». Бәлки аны «Зәңгәр моң» дип атарга кирәктер? Күк йөзе, күл өсте, агач һәм үләннәр, агач тамыры сыман Шүрәле — аларны гәүдәләндергәндә зәңгәр төснең нинди генә төсмерләре кулланылмаган! Шигърият өстәүче ай урагы, тонык яктылыкта кура җиләге төсенә кергән кызыл чәчәкләр...

Сабый чактан таныш «Сак-Сок! бәетеннән алып эшләнгән сурәт реалистик планда гаять образлы гәүдәләндерелгән. Без инде аны ни өчендер дини шаукымнарга урап, ахирәт күренешләренә манчып кына хәтергә ала идек. Баксаң, ул матди җирлектәге халык фантазиясе җимеше, мифик төсмерләре исә сәнгатькә хас шартлылык һәм символлардан гына үсеп чыга икән. Ф. Әминев «Сак-Сок»ны үтә кешелекле, халкыбызга хас әхлак кануннары белән сугарып, гыйбрәтле кыйсса рәвешенә кертеп сурәтли, тамашачыны үз трактовкасы белән килешергә мәҗбүр итә. Ул бу



*Айлы кич («Шүрәле»). Киндер. Темпера.*

әсәре белән татар халык мифларын сынлы сәнгатькә алып керүнең матур бер үрнәген бирә.

Күргәзмәгә килүчеләр «Хуҗа Насретдин» картинасын да озаклап тамаша иттеләр. Бик җыйнак, бик пөхтә эшләнгән, юморга бай рәсем. Фәс чугы да, кәҗә сакалы да, укуга мавыгып китапка баккан яман җитди йөзе дә тамашачыда елмаю уята. Чөнки Хуҗа ишәгенең койрыгына карап атланган, юк, атланмаган, бер аягын бөкләп, тәмләп җәелеп утырган, китабы исә чамасыз калын. Ә ишәкнең гыйлем иясе Хуҗада эше юк, ваемсыз гына алпан-тилпән атлый бирә, кырыйга кагылырга да күп алмый. Анда исә — текә яр!

«Барлык хезмәтләрегезне рәхәтләнеп ике мәртәбә карадым, — дип яза запастагы полковник Котляровский, — милли колориты таң калырлык, эчтәлеге һәр милләт кешесенә аңлаешлы».

«Күргәзмә миңа зур тәэсир ясады», — ди Советлар Союзы Герое М. Девятаев.

Украиннар һәм үзбәкләр, руслар һәм башкортлар, грузиннар һәм яһүдләр — барысы да тамашачылар кенәгәсенә, чын сәнгать белән очрашу шатлыгын уртаклашып, язулар язып калдырганнар.

Сурәтче Ф. Әминев иҗатында башка темалар да лаеклы урын алган. Ватаныбыз каһарманнарына багышлап «Салават Юлаев», «Советлар Союзы Герое Муса Җәлил» картиналарын иҗат иткән ул. Казандагы күргәзмәсенә Ленинградта яшәүче якташларыбызның портретларын алып килеп, сурәтче тагын бер кат безне таң калдырды. Анда без «Профессор-хирург Фәттах Котыш», «Педагогия фәннәре кандидаты Энҗе Сәгыйть», «Филология фәннәре докторы Габдрахман Таһирҗан», «Физика-математика фәннәре докторы, астроном Шәфика Шәрәф» кебек фән-культура, халык хуҗалыгының төрле тармакларында эшләүче күп кенә хөрмәтле кешеләрне күрдек. Бүгенге көннең хезмәт батырларын сурәтләгән бу рәсемнәрнең замандашларыбызда эшкә мәхәббәт тәрбияләве бәхәссез. Рәссам аларны гәүдәләндергәндә каһарманнарының эчке кичерешен, уй-теләкләрен ниндидер бер кабатланмас хәрәкәт аша ачарга омтыла. Ф. Әминев якташларыбызны зур хөрмәт белән тасвирлый, геройларына күркәм тышкы кыяфәт кенә түгел, эчке рухи байлык, ихтыяр көче дә хас икәнлеген басым ясап күрсәтә.

Бу әсәрләре белән ул нәкыш сәнгатебезнең колачын киңәйтә, яңа рух өсти, аны милли характерлар белән баета.

Беренчедән, ул халкыбызның гасырлар төпкеленә барып тоташкан шигъри иҗат чишмәсенең шифалы суларын бала чактан татып үскән кеше икән. Икенчедән, кайда гына яшәсә дә, үзен бу куәтле чыганактан аермаган, халкы белән элемтәсен һәрчак ныгыта килгән.

«Бу күргәзмә миндә бик олы, матур, бай тәэсир калдырды, — дип язды 1972 елның апрелендә Нәкый Исәнбәт.— Фәйзерахман Габдрахман улы үзенең туган халкына һәм аның үткән, хәзерге әдәбияты-мәдәниятенә, сәнгатенә булган җылы, тирән мәхәббәт хисләрен шушы кадәр якты, матур, күпьяклы, күркәм әсәрләрендә чагылдырган. Алар ватанчыл, халыкчан, сәнгатьчә нәфис һәм әкиятчә гүзәл, оригиналь һәм үзенчәлекләләр. Рәсемнәренә караганда, Фәйзерахман иптәш гүяки ерак Ленинградта яшәми, гомер буена монда, безнең арабызда, безнең белән бер һаваны сулап, бер үк суларны эчеп, үз туганнары һәм татарның зур талантлы шагыйрь, галимнәре, бигрәк тә Тукай һәм аның үлемсез геройлары белән чолганып, бергә яши кебек».

Казан тамашачылары күргәзмәдәге «Күл буенда» рәсеме янында да озаклап тукталдылар. Монда да Әминевчә ясалган чәчәкләр, каеннар. Ә уртада суга барырга чыккан кыз. Чиккән калфак өстеннән чәчәкле-чуклы шәльяулык беркәнгән, күз явын алырлык бизәкле кофта кигән. Муенса һәм алкалар таккан. Көянтә-чиләкләре дә бизәкле-сырлы. Ирексездән: «Сания апа суга бара, алма-алма чиләге...» дигән җыр яңгырый башлый. Әмма рәсемдә шалтыравык һәм хәтта яңгыравык аһәңнәрнең эзе дә юк. Кыз уйга талган, керфекләре йомылган, кашлары тартылган, шыгырдап уйны, шалтырап тынлыкны бозмасын өчен, бер кулы белән капканы, икенчесе белән чиләкне тоткан. Ниндидер йомшак бер моң бар бу күренештә.

«Картиналарыгызның музыкаль булуы гаҗәп. Мин алардан бинихая тәм таптым,

үзенчәлекле сурәтләрегез мине тәмам әсир итте. Сезнең белән горурланам!» СССР халык артисты, композитор Нәҗип Җиһанов бу тәэсирләрен уртаклашканда Ф. Әминев әле махсус музыкаль сериясен иҗат итә башламаган иде. Ул ният соңрак борынлады.

Татар халык җырларын элек-электән ярата иде ул. Эш арасында көйләп тә җибәргәли:

> **Тау астында салкын чишмә**
> **Чылтыр-чылтыр агадыр.**
> **Сөйгән сөйгәнен аладыр,**
> **Безнең сөйгән каладыр...**

Бер көнне шулай мавыгып эшләп ятканда башына хәйран кызыклы уй килде: халкыбыз үз гомерендә бик матур көйләр иҗат иткән бит. Алар авыр чакларда йөрәккә юаныч бирә, күңел җилкенгәндә канат куя, сөенечле көннәргә ямь өсти. Ә менә нәкыш сәнгатендә шундый ук әсәрләрне үз вакытында тудыра алмаган безнең халык. Әгәр татар нәкышенең үз «Салкын чишмә», «Кара урман»нары барлыкка килсә, нинди шәп булыр иде! Алар кайчан да булса яралырга тиеш. Фәйзерахман нигә соң әле бу эшкә алынмый? Ялгызы гына авыз эченнән көйләгәндә күңелендә аермачык образлар барлыкка килә ләбаса!

Һәм ул эшкә керешә.

Рәссамның Фин култыгы ярына урнашкан унынчы каттагы остаханәсендә инде аларның кайберләре белән танышырга да мөмкин. Менә темпера белән язылган «Салкын чишмә». Бала итәкле, шоколад төсендәге озын күлмәк кигән, зәңгәр кәшимир яулык ябынган кыз агачлар арасыннан чыгып килә. Җиң очлары, изүләренә ак челтәр тегелгән. Киеме дә, үзе дә нәфис, матур. Әмма ул бик уйчан, алдагы язмышын күзаллый, җаны теләмәгән никахтан котылу әмәлен эзлидер төсле.

Менә «Җизнәкәй». Зифа буйлы, бөтеренке мыеклы фырт егет. Түшендә сәгать чылбыры, ул чылбырга бәхет дагасы да тагылган. Кулында яулык, бармагында балдак. Балдызын әсир итәргә ул әзер — әтәч кебек гайрәтләнгән!

«Әпипә» сурәтендә өч кеше гәүдәләндерелгән. Әти кеше гармун уйный, әни кеше кул чаба. Ә аларның орчык-кызлары бөтерелеп бии.

«Кара урман». Алгы планда аксыл озын күлмәк кигән кыз. Аның артында кызны үзенә каратырга омтылган камзуллы егет. Кызның нәрсәгәдер хәтере калган, күңеле сүрелгән. Егет юмалап, дус булырга өнди. Артта койрыгын болгап урманга таба ераклашып баручы юрга ат. Зәңгәр күктә ай тонык саргылт нурларын чәчә. Бу рәсемдә безнең каныбызга сеңгән нәрсәләрнең барысы да бар: «Кисеп алдым кушкаен, аерылмыек, дускаем» да, «Карурманны чыккан чакта атым китте су буйлап» та, тагын башкасы да.

Ф. Әминевнең татар халык җырлары темасына ясаган нәкышләре атаклы музыкаль әсәрләргә гади иллюстрация генә түгел. Алар тормыш, чынбарлыкның үзе кебек бай әчтәлекле, салават күпере сыман барлык төсләрне үзенә җыйган. Бу сурәтләр татар халкы тормышын бөтенләй башкача һәм бүтән яклардан ача, үткәнебезне, милли тарихыбызны образлы рәвештә күз алдына бастыра, үз-үзебезне яхшырак төшенергә, дөньяны тирәнрәк танып белергә булыша.

1972 елда Ф. Әминев күргәзмәсен карагач, М. Горький премиясе лауреаты Сибгат Хәким:

> **...«Су анасы» кайтты,**
> **«Шүрәле»ләр кайтты,**
> **«Сак-Сок»лар.**
> **Рухым кайтты,**
> **Казан урамында**
> **Күңелләргә сыймый шатлыклар,**

— дип язган иде.

Рәссамның яңа тәмам иткән хезмәтләрен карагач, соклану-шатлык хисләре тагын да арта, киләчәккә якты өметләр канат җәя, күңелләр сафлана.

«Автор үзенең иҗаты белән татар сынлы сәнгатен үстерүгә гаять зур өлеш керткән», — дип яза инженер Мәлик Мөхәммәтҗанов. «Сезнең иҗатыгыз татар сәнгате өчен саф җәүһәр. Киләчәктә дә кулыгыздагы палитрада буяулар кипмәсен, безне шатландырырлык әсәрләр языгыз. Чын күңелдән рәхмәт!» — дип кушыла аңа сурәтче Харис Якупов.

Тәэсирләр альбомына төрле кешеләр тарафыннан язылган бу юлларда фикерләрнең гаҗәп бердәйлеге күзгә ташлана — алар бар да соклану, сурәтчегә рәхмәт хисләре белән тулы. Тамашачылар үзләренең теләкләрен, тәкъдимнәрен дә язалар. Рәсемнәрнең төсле репродукцияләреннән альбом чыгару, әсәрләрне Казан музейларында күбрәк күрсәтү кирәклеген искәртәләр алар. Ул тәкъдимнәрнең бер өлеше тормышка да ашырылды инде — Ф. Әминевкә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде, кайбер әсәрләре Татарстанда мәңгегә төпләнеп калды.

Ф. Әминев бөтен гомере буена үз халкының мәдәни үзәкләреннән читтә яшәде һәм Казанда оештырылган күргәзмәсе белән татар җәмәгатьчелегенә көтмәгәндәрәк ачылды.

Чыннан да, ул татар халкының гасырлар буе формалашкан үзенә генә хас матурлык төшенчәсен һәр күзәнәгенә сеңдереп, үз халкының традицион сәнгатьчә зәвыгын дөнья сәнгате эстетик таләпләре белән чагыштырып, заманыбызның сурәтчелек техникасы һәм чаралары казанышларын файдаланып иҗат итә.

Татар тормышында гасырлар буе типкедә булган нәкыш сәнгатен милли җирлектә үстереп китү өчен замана агышында тупланган асыл сыйфатлар тиешле дәрәҗәдә, теләгән микъдарда булмый. Ф. Әминев ул сыйфатларны халыкның шигъри иҗатын, музыкасы һәм бию сәнгатен күңеленә сеңдереп, аларга хас хасиятләрне үз йөрәге аша үткәреп, синтезлап, сәнгатьнең яңа өлкәсе — нәкыштә дә шыттырырга, шулай итеп, сынлы сәнгатьтә милли сыйфатларны бәреләндерергә алына. Әйтик, музыкада татарга пентатоника, моңлылык, мелизмнар хас. Татар биегәндә кул, гәүдә хәрәкәтләренә саран, ул аягы белән «чигү чигә». Менә шушы сыйфатларга бәрабәр хасиятләрне нәкыштә дә барлыкка китерергә кирәк була.

Фәйзерахман Әминев татар нәкыш сәнгатенең табигатен, милли җирлеген, үзенчәлеген нечкә сиземли, үзенең идеалына, яраткан темаларына гомере буе турылыклы булып кала.

Казандагы күргәзмәсен тамаша иткәндә Татарстан җәмәгатьчелеге Ф. Әминевнең картиналарын төрле җиргә таратмыйча бер үзәккә туплау, аларны халкыбызның художество зәвыгын тәрбияләү, ватанчыллык һәм хезмәткә мәхәббәт хисләрен үстерүгә хезмәт иттерү мәсьәләсен күтәргәннәр иде. Урынлы кайгырту. Чөнки Фәйзерахман Әминев профессиональ рәсем сәнгатебез аякка баскан чорларда ук аның нигезләрен салышкан рәссамнарның берсе. Без Әминевне иҗатының милли рухлы, шул ук вакытта интернациональ эчтәлекле булуы, халыкчанлыгы, башка сурәтчеләргә ясар йогынтысы, үрнәге өчен, бер дә икеләнмичә, татар нәкыш сәнгатенең якты йолдызы дип әйтә алабыз.

**Флера Сафиуллина,**
КДУ доценты

# РУХИ МАТУРЛЫК ҖЫРЧЫСЫ

*Ә. Еники поэтикасына кайбер күзәтүләр*

Әмирхан Еники исемен телгә алу белән, изге күңелле Акъәби, беренче очрашудан ук рухи сафлыгы бөркелеп торган Рәшидә, самими хисләр ташкынына ия Гөләндәм туташ, тыйнак, эшчән, юмарт, рухи бай гаҗәп кешеләр бер-бер артлы күз алдыннан уза. Бу геройлар әдипнең үзе кебек үк искиткеч тыйнак, итагатьле — алар күпне дауламыйлар. Алар **яшиләр,** без аларның һәр сүзен, хәрәкәтен аңлыйбыз, кабул итәбез, күңелләрендәге һәр таяпылышны сизеп торабыз. Әдипнең аларга ихлас теләктәшлеген, хөрмәтен, мәхәббәтен тоябыз. Хәтта рухи гарип кешеләрне (Зөфәр, Мостафин, Коръәнхафиз һ. б.) сурәтләсә дә, Ә. Еникинең уңай геройларына хас яктылык, сафлык, эчке инану ахыр чиктә җиңәчәгенә чын күңелдән ышанабыз.

Ә. Еники турында язу бик авыр. Моның өчен Еники талантының серен ачып бирерлек оста булырга кирәк. Әдип әйтергә теләгәнне тәнкыйть теле белән әйтеп бирү гаять кыен. Иң яхшысы — аның әсәрләрен уку. Укыган саен, тирәнрәк аңлый барасың, матур җанлы геройларына тагын да сокланасың, әдипнең сурәтләү осталыгына таң каласың. Ә. Еникинең хикәяләве ялыктырмый, туйдырмый. Кайбер әсәрләре халкыбызның күңеленә салынган, гасырлар буе аның рухи байлыгы булган сүзсез моң кебек. Аларда — сагыну да, шатлану да, боегу да, талпыну да, көч тә, бөтен авырлыкларны, кайгыларны җиңеп чыгуга ышаныч та...

Ә. Еникине кеше күңеленең җырчысы диярга мөмкин булыр иде. Аны кешенең эчке дөньясы, рухи байлыгы кызыксындыра. Әсәрләренә салынган иң зур идея — кешенең рухи матурлыгын күрсәтү яисә аның рухи түбәнлегеген ачып салу. Персонажның эчке дөньясын бөтен нечкәлекләренә кадәр ышандырырлык итеп сурәтләве белән Ә. Еники чын сәнгать әсәрләре тудыра. Әдип моңа ничек ирешә соң? Нинди алымнар кулланып эш итә?

Әдәби әсәрнең уңышы язучы тудырган образлар һәм идея эчтәлеге белән генә билгеләнми. Аларга ирешү, аерым алганда, тел чараларыннан башка да мөмкин түгел. Еники әсәрләренең җырдай ритмикасы, аһәңлелеге, күңелгә ятышлы булуы, сүз, сүз мәгънәләре белән генә түгел, иң элек сүзнең җөмләдәге урыны, аның ятышлыгы, җөмләләрнең, абзацларның бер-берсенә бәйләнеше, шуларның гомум бербөтен барлыкка китерүе белән дә аңлатыла. Бу турыда Ә. Еники болай дип яза: «Без әдәби осталык турында сөйлибез. Ләкин әдәби осталык, беренче чиратта, тел осталыгы, телгә байлык, телне дөрес куллана белү дип аңларга кирәк. Язучы кешедә телгә карата аеруча бер сизгерлек булырга тиеш: ул һәр сүзнең

тулы мәгънәсен аңлау гына түгел, аның эчке әһәңен, кай урында ничек яңгыравын, ниһаять, сүзләрнең үзара бәйләнешен тоярга тиеш». («Хикәя турында». — Язучылык хезмәте турында. Казан, 1958, 175 бит.)



Язучы осталыгының сере — синтаксиста, дигән А. П. Чехов. Ә. Еники иҗатында бу аеруча нык сизелә. Еники стилен сүз түгел, сүзләрнең ничек оешуы, ягъни синтаксис хәл итә. Язучының индивидуаль стилен, телен тикшергәндә, кайбер формаль нәрсәләрдән качу, әлбәттә, мөмкин түгел. Мәсәлән, әдип нинди тезелмәләрне өстен күрә, җөмлә тезелешендә нинди чараларны аеруча яратып куллана һ. б. Болардан башка стиль юк. Шуңа күрә беренче карашка саф тел күзлегеннән фикер йөртелсә дә, китерелгән мисаллар Еникинең үзенчәлеген күрсәтә алыр дип уйлыйбыз.

Ә. Еникине башка прозаиклардан аерып торган бер үзенчәлек бар: аның хикәяләве күп очракта уртак сөйләмгә корылган. Автор (хикәя итүче) һәм персонаж өчен уртак булган сөйләм әдипнең беренче әсәрләреннән соңгыларына таба һаман үсә бара. «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», «Рәшә», «Йөрәк сере», «Әйтелмәгән васыять», «Төнге тамчылар» һ. б. әсәрләрендә хикәяләүнең төп үзенчәлегенә әйләнә. Уртак сөйләмне чит сөйләмнең бер төре дип таныган хәлдә дә, аның әдәби әсәрдәге идея-эстетик, структур функцияләрен галимнәр бик әһәмиятле дип бәялиләр. Татар прозасының башлангыч чорында — Ш. Мөхәммәдов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал әсәрләрендә күренә генә башлаган уртак сөйләм 60—70 нчы еллар татар прозасында киң кулланыла башлый. Иң беренче чиратта ул тирән психологизм белән сугарылган Ә. Еники иҗаты өчен хас.

Геройларның эчке дөньясын реалистик сурәтләү, кеше күңелендә кайнаган хисләрнең серенә төшенү, күңел диалектикасына үтеп керү, уй-фикер һәм кичерешләргә үз мөнәсәбәтен белдерү өчен, Ә. Еники башка барлык тел-стиль чараларыннан да бигрәк уртак сөйләмгә мөрәҗәгать итә. Язучы шунда персонаж булып уйлый, сөйли башлый, аларның икесе өчен уртак булган фикерләр, сүзләр әйтелә. Әсәрдәге «икетавышлылык» сурәтләнә торган вакыйгалар, тормыш күренешләре турында тирәнрәк һәм төрле яктан килеп фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Әдип катлаулы чынбарлыкны эчке яктан яктыртып, аның кеше психологиясендә чагылышын күрсәтә; кеше күңеленең иң тирән почмакларына үтеп кереп, шул тирәнлектә яткан драматизмны үзенчә осталык, төгәллек белән ачып бирә.

Автор хикәяләвеннән уртак сөйләмгә күчешне әдип төрле чаралар ярдәмендә оештыра. Рухи халәтне белдергән (борчылу, хәтере калу, шомлану, уйлану, дәлилләү, сорауга җавап эзләү һ. б.), күрүгә мөнәсәбәтле булган (карау, күзәтү, күз ташлау һ. б.), искә төшерү, күз алдына китерүне һ. б. мәгънәләрне белдергән сүзләр ярдәмендә уртак сөйләм башланып китә: «Хәер, берсеннән икенчесенә күчкәндә, киләчәк турында да ашыкмыйча тыныч кына **уйлый** башларга ярый иде... Киләчәк! **Сугыш китергән иң авыр, иң газаплы бер заманда кешеләрнең бердәнбер юанычы, өмете, татлы хыялы иде ул... Әмма ничегрәк итеп күз алдына китерергә мөмкин соң бу киләчәкне!..»** **(«Рәшә».)** «Кызлар күзләрен елтыратып әбиләренә **карап** тора башладылар. **Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җиңле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән!»** («Әйтелмәгән васыять».)

Ә. Еники иҗатына төрлечә каршылыклы бәя бирүләр аның хикәяләү үзенчәлеге, аерым алганда, уртак сөйләмне хикәяләүдәге төп алым итеп сайлавы белән бәй-

ләнешле түгел микән дигән сорау туа. Әсәрдәге вакыйгаларга карата «авторның позициясе ачык түгел» дип язучылар Ә. Еникинең күзгә бәрелеп тормаган, әмма гаять зур мәгънәви йөккә ия булган тел чараларына игътибар итеп җиткермиләр, күрәсең.

Уртак сөйләм — туры сөйләмнең автор сөйләменә механик рәвештә кучүе генә түгел. Мондый сөйләмдә геройның уй-фикерләре белән беррәттән шул геройга авторның мөнәсәбәте дә, сурәтләнә торган вакыйгаларга авторның бәяләмәсе дә күренеп тора. Без «Рәшә»нең беренче битләреннән үк Зөфәргә мөнәсәбәтебезне билгеләп куябыз; хикәяләү дәвамында язучы аңа карата һич тә битараф түгел, ул Зөфәрне автор исеменнән ачы тәнкыйть уты астына ала. Зөфәрне мораль яктан тар-мар итә. Әсәрнең соңгы юллары беренче карашка бик оптимистик рухта яңгыраса да («...Тормыш бу... Исәп белән тотарга кирәк!.. Әйе, бары исәп белән, исәп белән, исәп белән, кадалып киткере!»), без моны Зөфәрнең мораль җиңелүе дип аңлыйбыз. Рәшидә, күлдәге рәшә кебек, аның өчен ерак, җитә алмаслык хыял гына булып калды; Зөфәр исәп белән өйләнеп, чын дусларсыз калды; бөтен тормышын исәпкә генә корып, чын мәхәббәт, чын дуслык, кешелеклелек, эчкерсезлек кебек сыйфатларны төштә дә күрә алмаган бер затка әйләнде. Әсәрнең буеннан-буена шушы затның буш, салкын, чирканыч эчке дөньясын сурәтли әдип, Зөфәрне турыдан-туры «бу — шулай, бу — тегеләй» дип бәяләми. Әмма һәр сүз укучыга бу кешенең кем икәнен аңларга ярдәм итә. Әсәр Зөфәр Сабитовның тугызынчы май таңында күргән төше белән башланып китә. Көне үк сагайта. Ник бу көнне Зөфәр Сабитов үз өендә рәхәтләнеп төш күрә-күрә йоклап ята? Бу көнне алар йортына сугыш беткән дигән хәбәр килеп керә. Менә шул хәбәрдән соң, язучы, персонажга тагын да ачыграк мөнәсәбәтен белдерергә теләп, уртак сөйләмгә күчеп болай ди: «Менә ул көн, менә кайчан килеп җитте ул күпме курку-шомланулар, күпме яшерен өметләр белән көткән көн! Бетте, шушы минуттан курку да, шомлану да бетте, җилкәдән әйтерсең һималай тавы төште!» Нигә курыккан соң бу кеше? Алга таба укыйбыз. Бөтен дөньяда шатлык. Күршеләре Зөфәрне дә Җиңү бәйрәме белән котлый. Язучы үз мөнәсәбәтен уртак сөйләм аша тагын да ачыграк белдерә башлый: «Зөфәр, үзе дә аларга елмаеп, зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узды. Шулай ул, бу дөнья! Әле кайчан гына шушы күршеләре аны, сәламләү түгел, бөтенләй күрмәмешкә салыналар иде яки яшерен бер дошманлык белән артыннан карап калалар иде. Янәсе, бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөри... Ни өчен коммерсантка мондый оҗмах, имеш... Билгеле, авыр иде бу ят итеп, дошман итеп карауларны күтәрүе, әмма, тешен кысып булса да, аңа чыдарга туры килде. Ә хәзер бетте, бетәргә тиеш, хәзер фронт та юк, тыл да юк — бөтен кеше бертигез. Һәм ул бүгенге көннән берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак». Менә кем икән ул Зөфәр! Сугыш буе тәэминат бүлегендә сау-таза килеш, бронь алдыра-алдыра яшәп яткан. Сугыш бетү Зөфәр алдына ике конкрет мәсьәләне тизрәк хәл итүне китереп куя: сугыш елларында җыйган «акчаны малга әйләндерү, ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; икенчесе — аңа тиз һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү...» 9 май көнне шушы ике уйдан башканы күз алдына китермәгән кеше кем икән ул? Автор бөтен әсәр буенча шушы шәхеснең күңелен ачып сала, мещанлыкның, рухи ярлылыкның искиткеч үрнәге булган бу затны Ә. Еники автор һәм геройның үз исеменнән сурәтли. Моның өчен иң кулай алым уртак сөйләм булып чыга. Сүз уңаенда шуны да әйтик: Ә. Еники хикәяләвенең төп сыйфатын билгеләгән бу алым хәзерге татар әдәбиятында торган саен киңрәк урын ала бара.

Ә. Еники хикәяләвендәге үзенчәлекле яңгыраш кабатлаулар исәбенә дә барлыкка килә. Кабатлаулар — телнең грамматик төзелешендә дә, стилистикасында да шактый зур урын алып тора. Кабатлау — сүз ясый, кабатлау — эмоциональ бизәк була, кабатлау — мәгънәви басымны арттыра, кабатлау — үзенчәлекле яңгыраш барлыкка китерә... Һәр язучы бу алымнан файдалана, әлбәттә. Әмма, башка язучылардан аермалы буларак, Ә. Еники бу алымга искиткеч күп мөрәҗәгать итә. Һәм аның кабатлаулары ялыктырмый, туйдырмый. Чөнки әдип аларның яңадан-яңа төрләрен, калыпларын, чиратлашуларын таба, әсәрнең аһәңен көчәйтеп җибәрерлек төрләрен сайлый. Алар ритмик төгәллек, камиллек, аһәң алып киләләр. Ә. Еники

җөмләне тәмамлаучы хәбәрне кабатларга ярата, әмма аның алдыннан кабатлаучы акларлык итеп, өстәмә мәгълүмат биргән сүзне өстәп куя: «Ә алар **китәләр,** сабыр гына, әдәп белән генә **китәләр»** («Гөләндәм туташ хатирәсе»). «Әнә алар **киттеләр,** буш, тын авыл өстенә таңкәләр чәчкәндәй, җыр, моң сибә-сибә **киттеләр»** («Җиз кыңгырау»). Хәбәрләр кабатланып раслау, ышанып әйтү мәгънәсен алып килә: «Салих **югалмады** минем өчен, юк, **югалмады!»** «...Мин аңа **үпкәли алмыйм,** юк, һич тә **үпкәли алмыйм»** («Гөләндәм туташ хатирәсе»).

Ә. Еники логик басым алган сүзнең мәгънәсен тагын да ассызыклау өчен, аны җөмлә ахырында тагын кабатларга ярата: **«Ике еллап** узды бит, **ике ел»** («Рәшә»). «Я хода, **яз** ич бу, **яз! Ләйлә** ич бу, **Ләйлә!»** («Төнге тамчылар»).

Затка характеристика биргәндә, аның бер билгесен өстәп, шул зат кабатланып әйтелә. Мондый кабатлау җөмләне түгәрәкли, мәгънәви яктан да үстерә: **«Сөембикә,** кечкенә кара күзләре белән аңа хәйләкәр елмаеп караган **Сөембикә,** ферма кызлары тирәсендә аның кайгысын кайгыртып йөргән икән» («Рәхмәт, иптәшләр!»).

Әдип кабатланып килгән кисәкләрнең соңгысына еш кына тиңдәш кисәкләр өсти, шул рәвешле хикәяләүдә эмоциональ яңгыраш, хисләр гаммасы туа: «Минем **җырым** бу, җанымны сызландырган моңлы, ләззәтле **җырым!»** «Менә кайда икән ул... мәхәббәт! Тилерүгә якын ниндидер иңрәүле, ялварулы, газаплы, хәтәр **мәхәббәт!»** («Гөләндәм туташ хатирәсе»).

Кабатланган кисәкләр сурәтләнә торган күренешне билгесе ягыннан үстерәләр, шул рәвешле үзенчәлекле мәгънәви градация барлыкка китерәләр: «Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик **җыр** булсын, **җыр** туктамасын. Татар **җыры,** Таһирә **җыры,** туган ил **җыры...»** («Кем җырлады?»). «Күтәрелебрәк тәрәзәдән карасам, тышта **кар** яуган икән ләбаса! Беренче **кар!** Тансык **кар!»** («Гөләндәм туташ хатирәсе»).

Җанлы сөйләм өчен хас кабатлаулардан Ә. Еники персонаж телен сурәтләгәндә дә киң файдалана, әмма алар автор хикәяләвендә нечкә зәвыклы кабатлаулардан интонацион яктан шактый аерылып торалар: «— **Бөрмәле капчыкка** салыгыз барысын да, ишетәсезме, **бөрмәле капчыкка!»** («Гөләндәм туташ хатирәсе»). «— Әйтәм алайса... Мин **өйләнергә** булдым, менә сиңа **өйләнергә,** аңлыйсыңмы, Рәшидә, сиңа!» («Рәшә»).

Кабатлау — Ә. Еники синтаксисының аерылгысыз бер сыйфаты. Аваз кабатлауларының нәфис үрнәкләреннән алып, сүз, **сүзтезмә, җөмлә** кабатлауларының искиткеч матур чагылышларын табарга була әдиптә. «Төнге тамчылар» хикәясенең башламындагы «Караңгы, тын урамнарда тып-тып тамчылар тама» дигән җөмләне искә төшерик. Җөмләнең ритмы да, «т» авазының кабатлануы да, «а» һәм «ы» сузыкларының ешлыгы да кеше күңелен гөлдәй ачып җибәргән язгы кичне хәтерләтә. Янсә менә «Әйтелмәгән васыять» повестендагы беренче җөмләне искә төшерик: «Йомшак кына җәйге җил исә...» Мондагы «й»,«җ» авазларының кабатланып килүеннән җәйге эссе көндә яланда искән җилне тойгандай буласың. Шул ук хикәянең беренче абзацындагы сүз һәм җөмлә кабатлаулары да зур поэтик әһәмияткә ия: «Дала буйлап **кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә.** Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып **йөгерә** кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан **чабасы да чабасы** килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... **Рәхәт, һәй, рәхәт тә** соң!.. һәм **ямансу.** Нигәдер бик **ямансу** да шул!..» Автор табигатьнең эчке моңын шулай бирә. Бу юллар җанлы даланы күз алдына китерәләр. Көмеш кылганнарны күргәндәй, аларның кыштырдавын ишеткәндәй буласың. Кабатлаулар моңлы бер көй барлыкка китерә. Кабатланып килгән һәр сүз яңа мәгънәви төсмер ала, хикәяләүнең агышын төрлеләндерә.

Әдипкә хас шигърилек, нәзакәтлелек, моңсулык, нәфислек ул язган әсәр исемнәрендә үк чагылып тора. Аларның һәрберсе кеше күңелендәге изге, саф хисләрне барлык мөмкинлеге белән уятырлык итеп сайланган, әсәрнең идея-эстетик кыйммәтен тулысынча биреп җиткерерлек итеп әйтелгән. «Рәхмәт, иптәшләр!», «Туган туфрак», «Матурлык», «Төнге тамчылар», «Әйтелмәгән васыять», «Җиз кыңгырау», «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Рәшә», «Яшьлек хатасы», «Йөрәк сере» h. б. һәрберсе энҗедәй кадерле, әдипнең тынгысыз күңеле, йөрәге аша үтеп, бердәнбер мөмкин

булган исем дәрәҗәсенә күтәрелгән. Әсәр исемнәренең күбесе хикәяләү белән мәгънәви, идея-эстетик һәм композицион-структур яктан тыгыз бәйләнгәннәр.

Ә. Еники әсәрләренең сюжет, композицион яктан төгәлләнгән, аерылгысыз бербөтен булуы, сәнгатьчә югары эшләнеше хикәяләүнең беренче җөмләләрендә — башламнарда да ачык чагыла. Башлам — музыкаль әсәрдәге беренче аккорд кебек, хикәяләүнең бөтен тональностен билгели, вакыйгаларның я шатлыклы, я тантаналы, я моңсу, я ироник, я кайгылы булуына ишарә ясый.

Менә «Төнге тамчылар» хикәясе. Аның беренче җөмләсе үк безне вакыйгаларның моңсу булачагына әзерләп куя. Әдип кеше күңеле кузгала торган яз көннәрен сурәтләүдән башлый: «Апрель киче. Юеш, җылы, томанлы. Караңгы, тын урамнарда тып-тып тамчылар тама». Бу җөмләләрдәге моңсулык алга таба тагын да тирәнәя төшә, чөнки абзац башламы буларак алар, бераз үзгәртелеп, алга таба да кабатланалар. Башлам җөмләнең кабатланып килүе әсәрне бер синтаксик бөтен итеп оешутыра, таркаулыкка юл куймый. Әдипнең «Әйтелмәгән васыять» әсәрендә дә идеяэстетик кыйммәткә ия шундый ук хәлне күрәбез. Бу башламда да табигать картинасы үзәк фон булып тора һәм башламнан алган тәэсир әсәрне укып чыкканчы дәвам итә.

Язучының «хикәя-истәлек» дип исемләнгән «Җиз кыңгырау» әсәрендә дә абзацка тигез синтаксик бөтенгә корылган башлам бар: «Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган... Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм ниндидер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя». Шушы башлампрологтан соң автор туйга бәйле бала чак истәлекләрен искиткеч бер самимилек белән, кадерләп, үткәннәргә зур ихтирам белән сурәтләп күрсәтә дә бетем абзацында яңадан шул ук башламны кулланып язып китә: «Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора»... Җиз кыңгырауның көмештәй саф, нечкә, дәртле тавышы үзгәрмәгән кебек, «мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калган: бу — кешенең яшьлеге, кешенең мәхәббәте!.. һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа — аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана».

Әдәби әсәрнең исеме, башлам һәм бетем арасындагы эчке, мәгънәви бәйләнеш әдипнең «Туган туфрак» хикәясендә дә аермачык күзгә ташланып тора.

Хикәяләүнең төсмерен, интонациясен билгеләүче мондый башламнардан тыш, Ә. Еники вакыйгаларның кульминацион ноктасын күрсәткәннәрен дә куллана: «Былтыр көз булып үткән район партия конференциясендә делегатлар райкомның икенче секретаре Шакир Мостафинны тәгәрәттеләр» («Саз чәчәге»). Бу җөмлә зур кызыксыну уята, күп сораулар тудыра. Кем ул Шакир Мостафин? Нигә аны тәгәрәткәннәр? Ул ничек шундый хәлгә барып җиткән? Әсәрдә сурәтләнгән бөтен вакыйгалар шул сорауларны ачыклау юнәлешендә сурәтләнәләр. Мондый динамик башламнар әдипнең «Без дә солдатлар идек», «Коръәнхафиз», «Узып барышлый» әсәрләренә, һәм бигрәк тә сатирик һәм юмористик хикәяләренә аеруча хас.

Тирән психологизм белән сугарылган әсәрләреннән аермалы буларак, Ә. Еникинең юмористик әсәрләрендәге башламнар бөтенләй үзгә: алардан автор ирониясе сирпелеп тора, хикәяләүнең шушы стильгә генә хас булган җорлыгын, усаллыгын сизәргә була. «Сүз дә юк, шәп тора Фәхри Гыймадиев» («Күңелсез мәҗлес»). «Әгәр дә сез өстенә җәйге ак пальто, башына каурый канатлы эшләпә кигән тулы гәүдәле хатынның берәр магазин ишегеннән кереп киткәнен күреп калсагыз, белеп торыгыз, ул Күсия ханым булыр. Иңбашлары бөрмәле, тар билле куе-кызгылт пальтоның киң итәкләре берәр магазин эчендә күз алдыгыздан җилфердәп узса, ялгышмассыз, ул да Күсия ханым булыр. Аягына ак фетр ботылар, өстенә кара котик манто кигән хатын универмаг тирәсендә күзегезгә чагылып калса, алданмассыз, Күсия ханым булыр ул!» («Күсия ханым»).

Ә. Еники өчен генә хас булган тагын бер үзенчәлеккә игътибар итик. Әдип татар телендә күптәннән килә торган парлы сүзләр ясалу кагыйдәсен нигез итеп алып, яңа

сыйфатлар ясый. Аның телендәге талгынлык, нәзакәтлелек шушы сүзләр аша да сизелеп тора. Менә нинди сүзләрне очраштыра Ә. Еники: салкын-тонык күзләр («Рәшә»), җиңел-сылу кыз («Төнге тамчылар»). Ә. Еники төсләре дә ярым тоннардан тора, алар җылы, матур тойгылар уята. Ул төсләр күзне ардырмыйлар, күзгә бәрелеп тормыйлар: «Авыл өсте **зәңгәрсу-якты»** («Рәшә»). «Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның **куксел-кара** иде» («Матурлык»). Ә. Еникидә яшел төс аеруча күп төсмерләр белән баетылган: «Өй эченә тулган су төбедәй **яшькелт-зәңгәр** яктылыкта, өрәк шикелле, күпмедер вакыт тик кенә басып торды» («Рәшә»), «... дөрестән дә, бала табигатлерәк иде бу түгәрәк битле, **яшькелт-соры** күзле биюче кыз» («Рәшә»). «... **кучкыл-яшел** сөрелмәгән чирәмнәр» («Матурлык»). Әдип бер билге, төп билге белән генә күрсәтми, шул билге янына икенчесен, тагын да төгәлләбрәк килүчесен өсти; ике билге бергә килеп, авторның теге яки бу геройга мөнәсәбәте дә белдерелә: «... рәхәт аның **арык-җиңел** гәүдәсенә» («Рәшә»). «Гәүдәсе һаман шулай **җыйнак-сылу...»** («Ялгызлык»), «Егет өстендә таза-туль гәүдәсенә бик килешле утырган зәңгәр бостоннан әйбәт костюм...» («Рәшә»).

Әдипне **моңсу** дип әйтү генә канәгатьләндерми, ул һаман эзләнә, тагын да нечкәрәк мәгънә төсмерләрен эзли. **Моңсу-зәгыйфь көлемсерәде, моңсу-назлы итеп елмайды, уйчан-моңсу гына карады...** Бу сүзләр Акъәбинең бөтен тормышы шикелле гади, самими, моңсу. Әдип сүзнең төп мәгънәсеннән генә канәгать түгел, күпне тоя, сизә, сурәтли алган художник буларак, ул һаман эзләнә, сыйфатларны бөтен нечкәлекләре, ярым тоннары белән бирергә тырыша. **Җитди** сүзен генә алыйк. Нинди генә төсмерләрен тапмый әдип бу сүзнең?! **«Салкын-җитди** басып тора» («Шаяру»), **«җитди-сынаулы караш»** («Яшьлек хатасы»), **«җитди-йомык кыяфәт»** («Төнге тамчылар»), **«җитди-җылы караш»** («Матурлык»), **«җитди-моңсу кара күзләре»** («Ялгызлык») һ. б. Болар исә үз чиратында геройларның психологик халәтен тагын да тирәнрәк күрсәтергә мөмкинлек бирәләр.

Тагы бер мисал: «Карчык исә һич үпкәсез, әмма **боек-сагышлы** итеп, тирән генә сулап куя («Әйтелмәгән васыять»). **Боек** сүзе генә карчыкның хәлен биреп бетерә алмый, **сагышлы** дисәң дә фикер башкача. Ике сыйфатны бергә кушып, әдип зур мәгънәви көчкә ия булган сүз ясый. Кеше күңеленә үтеп керү, аны укучы алдына бөтен каршылыклары белән ачып салу менә шундый сүзләрне куллану аша да мөмкин була.

Төсмерләр, төсмерләр, төсмерләр... Ә. Еники аларны гаять оста итеп бирә ала: **«тирән-хәсрәтле сулау»** («Рәшә»), **«авыр-басынкы тавыш»** («Яшьлек хатасы»), **«җылы-якын дәшү»** («Матурлык»), **«гади-җылы якынлык»** («Рәшә»), **«гади-ваемсыз сорау»** («Төнге тамчылар») һ. б.

Әдипнең геройлары үзләренең исемнәренә хас мәгънәләр, ассоциацияләр белән дә хәтергә уелып кереп калалар. Менә алар: гомере буе изге күңелле **Акъәби** (« — Минем исемем Акбикә, — ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып. — Кыз чагымда мине Аксыл дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...» («Әйтелмәгән васыять»); тыйнак, самими, яңа ачылып килә торган гөл чәчәге кебек Гөләндәм түташ («Гөләндәм түташ хатирәсе»); егерме биш ел буе профессор Ишмаев күңелендә йөртерлек **Ләйлә түташ** һәм аны Ләйләдән бик оста тартып алган **Мәрвәр ханым** («Төнге тамчылар»); авылга беренче тапкыр кайткан шәһәр кызы **Клара** («Туган туфрак»); Зөфәр Сабитов өчен кул җитмәслек рәшәдәй ерак булып калган саф йөрәкле **Рәшидә Сафина** («Рәшә»); явызлыгы белән кешеләр күңеленә кереп калган **Корьәнхафиз** («Корьәнхафиз»); яшьлеге узып китүдән җаны әрнеп, ике яшьнең саф мәхәббәтеннән көнләшеп, **үзенең өлешенә шундый бәхет тимәгәннән кемнәндер үч алучы Диләрә ханым** («Шаяру»)...

Ә. Еники сурәтләгән авылларның исемнәре дә гаҗәеп шигъри, укучыда аларны күрәсе килү теләге уяна: Акъәбинең туган җире Юлкотлы, шәһәр кызы кайткан Каракош, Зireклебаш, авыл малае үткән юлдагы Абзан, Сынны авыллары...

«Һәр кошның — үз моңы» ди халык. Ә. Еники дә әдәбиятыбызда үз моңы, үз темасы,үз яңгырашы булган әдип.

Аның әсәрләреннән аерылуы кыен. Сирәк язучының әсәрен икенче, өченче кат укып була. Ә. Еникине кайта-кайта укыйсың. Укыган саен әдипнең тирән фикеренә, кешенең бөтен барлыгын бирә белүенә, хикәяләү осталыгына, теленең байлыгына һәм аһәңлелегенә сокланасың.

Әхсән Баянов

# ВАКЫТ СУРӘТЛӘРЕ

Журнал битләрендә, китап нәшриятларында Әнвәр Давыдов шигырьләре өзлексез басылып тора. Әйтерсең ул һаман безнең арада яши һәм, күп дигәндә, каядыр ерак командировкага киткән дә, әсәрләрен шуннан җибәреп тора. Күрәсең, ул үзенең күп кенә шигырьләрен вакытында чыгарып өлгермәгән, яки аларны төгәлләнеп, ахырынача эшләнеп бетмәгән дип уйлагандыр. Ләкин алар көн таләпләренә һәм зәвыкларына җавап бирәләр — кешенең җиңелмәс рухы хакында чын сәнгатьчә сөйләүдә дәвам итәләр. Беренче тапкыр дөнья күргәннәре генә түгел, элегрәк басылганнары да һаман кызыклы — хәзер дә акылга хәбәр, күңелгә якты җылылык өстиләр.

Гадәттә, искермәүнең сәбәбен әсәрләрдә гомумкешелек өчен әһәмиятле булган темалар кузгатылуы белән бәйлиләр. Бу фактны истә тотарга кирәк, әлбәттә, Әнвәр Давыдовта да мәхәббәт, нәфрәт, яхшылык, явызлык һәм кешенең башка шундый тойгылары үзәккә куелган әсәрләр бик күп. Ләкин әсәрләрнең искермәү көчен мин ул тойгыларда гына түгел, ә башлыча кешенең көндәлек тормышын сурәтләгән конкрет картиналарында, кабатланмас рәвешләрендә күрәм.

Шигырьләрнең язылу тәртибенә, хронологиясенә ияреп барам. Тыңлыйм. Һәм шул вакыт миңа җиңү залплары тавышы кабат ишетелә башлый...

Әсәрләрнең җисемнәренә кагылганчы, исемнәре үк конкрет чорны күзалларга мәҗбүр итә: «9 май иртәсе», «Очрашырбыз, дускай» һ. б. Җиңү шатлыгы, полкташлар белән аерылышу моңсулыгы. Матур, тыныч тормышның беренче көннәре тудырган хисләр нәфислеге һәм дошманга карата сөрелеп тә бетмәгән үч катылыгы. Солдатның туган җир туфрагын алып кыскан куллары, шул туфракны үпкән ереннәре. Җылы бөркеп яткан яңа буразналар...

Бу сурәтләрнең кайсы чор галәмәтләре икәнлеген ачыклау өчен озак уйлап торуның хаҗәте бар микән? Юктыр дип уйлыйм. Бу күренешләрдә кеше язмышы белән ил язмышы синтезлаша. Кеше тормышында тарихи вакыйгалар төсмерләнә. Кеше биографиясен укып, ил биографиясен күз алдына китерәсең.

Кеше биографиясе — революция, төзелеш, сугыш, тагын тыныч тормыш. Бусы инде тарих түгелме соң? Ә тарих дидеңме, фикер көндәлек вакыйгалардан узып, ераграк китә башлый.

Әнвәр Давыдовның беренче шигырьләре сугыш картиналары тасвирламаларыннан, гомеренең иң кискен, хәлиткеч, тетрәткеч вакытларыннан башлана. Билгеле инде, куркыныч каршында характер ялангачлана — кемнең кем икәнлеге, нәрсәнең нинди булуы хак төсендә, шулай әйтергә яраса, натураль рәвешендә алга килеп баса. Элекке төшенчә яки кыяфәтнең чынлыгы яки ялган булуы, кешенең батырлыгы яки куркаклыгы чынбарлыгында өскә калка. Күңелдәге нәфрәт яки мәхәббәт тә ут һәм төтен аша дөресрәк күренә.

Ядрәләр ярылалар,
Мин сине эзләп барам.
Беренче шатлыгым минем,
Беренче йөрәк ярам.

Тән җәрәхәтенә хәтле үк йөрәк ярасы булган икән ләбаса! Тик ул ничектер яшерен торган, ә мондый хәтәр вакытта яшерүнең инде кирәге калмый. Син вөҗданың белән күзгә-күз очраштың. Шунысы хәерле, очрашу — кеше файдасына, сафлык тантанасына хезмәт итә, характерны баета, чыныктыра. Фронт шартларында сафлык кыйммәте халык бәхете бәрабәренә туры килә, яшәүнең символик мәгънәсенә әверелә.

Фронтта мәхәббәтләрен тапкан һәм яклаган егет белән кызның маһәрләре санлыкларга сыя торган түгел. Бөек байлык: көрәш белән үткән һәр карыш җир, бергә сугышып алган шәһәрләр, шуларга өстәлгән полкташлар дуслыгы, утта сынау, чыныгу ныклыгы.

Кыңгыраулар чыелдатып түгел,
Самолетлар, туплар гөрләтеп
Төште туебыз, халык бәхете белән,
Җиңү туе белән берләшеп.

Конкрет кеше тормышына караган, кечкенә тоелган вакыйга тарихи вакыйгаларга кушылды да кеше үзе җәмгыять вәкиленә әверелде. Ә менә шушы конкрет биография, конкрет детальләр булмаса? Тарих, әлбәттә, үз барышында калыр, ләкин ул сәнгатькә күчмәс иде. Колак пәрдәләрен ертырлык итеп купме генә кычкырсаң да, шулай тиеш дип фараз ителергә мөмкин булган гомуми идеяләр, уйлар һәм фикерләргә ышанган хәлдә дә, мин аларны тойгылар сыйфатында кабул итә, күз алдына китерә алмаган булыр идем.

Көн саен газеталарда, эфирда, чыгышларда кабатлана торган публицистик фикер күпчелек очракларда нәкъ шундый туп-туры, ялангач хәлендә телдән-телгә күчеп йөри. Әгәр ул, информация бурычын үтәү белән канәгатьләнеп, сәнгать факты булуга дәгъва итмәсә, монда бөтен нәрсә үз урынында буласы. Ләкин сәнгатьнең бурычы үзгә — информация аның максатына керсә дә, чарасына туры килми. Сәнгатькә конкрет форма, ярдәмче детальләр кирәк. Әйтик, Давыдов солдатлары: «Төрле милләт кешеләре булсак та, тарихи һәм көндәлек зур идеяләр аркасында, без барыбер туганнар!» — дип турыдан-туры кычкырмыйлар. Алар — тыйнак. Аларның бердәмлегенә фронт берлеге өстәлә, чөнки туплар һәркемгә бер телдә эндәшә.

Русча начар белүемнән
Көлә иде дус-иш.
Фашист ләкин тиз таныды:
— О, ду зольдат русиш!

Менә син шушындый вакытта милләтләрне аерым тоеп кара! Кечкенә бер факт, бер сүз бөтен бер армиянең кем икәнен әйтте дә бирде!

Менә тагын шундый «кечкенә» деталь. Дәһшәтле кырык беренченең бер көне. Улап килгән утлы корыч көч солдатларны Днепрга китереп кыскан. Котылу эзләп биргә ярга омтылучы машиналардан һәм кешеләрдән буа ясап, шул урынны юнкерслар бомба-чукмарлары белән төеп дыңгычлыйлар. Ә безнең зениткалар ядрә йодрыкларын сузып, күкне генә тишкәли алалар. Күктә һәм җирдә өстенлек иткән дошманга безнең истребительләр ташлана.

...Чыгарып шунда ут сөңгесен,
Чәнчә кинәт юнкерсның берсен.

Дошманның тәкәббер корыч аждаһасы, кара төтенгә уралып, җиргә сөңгәч, бүтәннәре кайту ягына кача башлый.

Шагыйрьнең төп бурычы — җиңүнең төп нигезен, совет кешеләренең чыдамлыгын, батырлыгын, ватандарлыгын күрсәтү. Йөрәкләр бәрелеше. Безнең 1945

елда килгән олы тантананың да башы — менә шушы «кечкенә» җиңү бит. Сурәт менә ни сөйли!

Хәтердә, фикердән бигрәк, шушы вакыйга, конкрет очрак яши. Шагыйрь үз биографиясеннән алып язган хәлләр безнең дә күңелләргә гомерлеккә кереп урнаша. Бу тотрыклылык, сүз дөреслегеннән бигрәк, сурәт конкретлыгында, вакыт галәмәтләренең дөреслегендә, чынлыгында.

Шигырьләрнең эчтәлекләре алмашына, чөнки тормыш алга бара. Инде яңа картина: кечәге солдат бүген зур өметләр вәгъдә иткән киләчәккә карый. Аның белән бергә — бөтен авыл халкы. Сугыштан солдатлар кайтканны каршылыйлармыни:

— Кайталар! Кайталар!

— Кемнәр?

Өр-яңа тракторлар, яңа бәхетләргә вәгъдәләр тәяп, шаулап кайталар. Халык менә ни өчен тантана итә, ни өчен сөенә. Халык белән бергә, кичәге солдат шатлана, чөнки алар гадәти тракторлар гына түгел, ә танкларга әйләнми калган тракторлар, болар — сугыштан соңгылар, сугыштан соңгы — беренчеләр. Җиргә, туфракка да беренче бөртекләр төшә:

**Улын сагынып көткән ана кебек,**
**Ачты аңа җир киң күкрәген!**
**Тойдым тесле җылы туфракның**
**Тормыш көче белән тетрәвен.**

Кайчан язылуы мөмкин бу юлларның һәм нинди чорны күз алдына китерү мөмкин аларны укыгач? Сорау үзе үк артык шикелле. Монысы да шагыйрь хезмәте — ул мәңгелек картиналар эзләп үзен дә, безне дә интектермәде:

**— Юк, энекәш,— диде Әптерәш,—**
**Монда бодай үсмәс. Үсмәс!**
**Туфрак ярлы. Балчык көйгән,**
**Гранит кебек каты һәр кәс!**

Туфракның кайчангы икәне һәм бу сүзләрнең кайчан ишетелергә мөмкин булуы шигырь юлларының үзләрендә аермачык булып — туфракка төшкән бөртекләрдәй күренеп ята.

**Алтын булып, байлык булып**
**Әверелде монда һәр кәс.**
**— Әйе, энекәш, — диде Әптерәш, —**
**Солдат даны үлмәс. Үлмәс!**

«Солдат турында баллада»дагы геройның үз кыяфәте дә — аның буш җиңе, хәрби киеме, сүзләр һәм эшләр авырлыгыннан тешен кысып кырны өйрәнүе, аннан сүз көтеп тын торган бригада кешеләре, мылтык корычына күнеккән кулдан ятсынмаган сабыр сабан, ул калдырган тирән буразналар, һәр гектарга ике центнер кергән суперфосфат оны, шуның белән берләшкән тир тамчылары да берсенә-берсе табигый ярашып тора. Прозага хас детальләргә матурлык сулышы кинеп керә. Бернинди купшылыксыз, кырыс шәрехләр — бары тик шулар гына зарурдыр, дигән уй туа. Чорга хас кырыслык. Бары тик шул таләп итеlә. Әйе, ышанырга мөмкин бу хәлләргә, булды бу хәлләр тормышта. Шуннан соң гына:

**Солдатның Дан орденына**
**Тук башаклар үрелделәр.**

Тормышның сүздә, полотнода яңадан иҗат ителүе, шуның бәрабәренә билгеле бер фикердән бигрәк — караш, мөнәсәбәт һәм, димәк, тойгы кузгалуы — сәнгать факты шушы бит инде. Сәнгате булдымы, аңа тарихи фактлар үзләре дә сыя.

Мин Әнвәр Давыдовның бу чорда язылган шигырьләрен укып, шул чорның үзен, кешеләрен, хәтта әдәби хәрәкәтен кабат күрәм.

Ул чакта да әдәбиятта төрле тенденцияләр бергәләп яши килде. Сәламәт, житди агымнан хәтта алгарак чыгарга тырышып ук түгел микән әле, шундый бер омтылыш, соңыннан «лакировка» дигән исем белән йөртелә башлаган бер шаукым

булып алды һәм, хәзер карасаң, ул Әнвәр Давыдов шикелле чын шагыйрь иҗатында да үзенең кайбер төсмерләрен мөһер сыманрак итеп йоктырып калдырган икән. Яхшылыкка, матурлыкка, шатлыкка, тыныч бәхеткә артык сусау аркасында барлыкка килгән ашыгу хикмәте булды бугай ул. Сәнгатькә бары тик социаль мәгънәләр эзләп мөрәҗәгать итү, эстетик категорияләр белән исәпләшергә бик үк теләмәү кебек җиңеллекнең дә тәэсире булмый калмагандыр, әлбәттә. Шунысы бәхәссез, сугыштан соңгы елларда ясалма ситуацияләр һәм ялган бизәкләр, тема мөһимлеге һәм социаль фикер ачыклыгы белән кызыктырып, үзләренә беренчел дәрәҗәдәге шөһрәтне дәгъвааладылар. Безнең бу темага Әнвәр Давыдов белән бәхәсләшкән вакытлар да булгалады бугай. Һәрхәлдә, аның иҗаты да бу шаукымнан бөтенләй азат булды дип әйтү кыен.

Тантаналарга, бәйрәмнәргә ашкыну, ашыгуның тарихи нигезләре зур өметләр багларга мөмкинлек тудырган бөек төзелешләр иде. Безгә бигрәк тә якыннары Иделдәге гидростанцияләр, табигатьне үзгәртеп кору дaулары, кыр-урман полосалары, яшь бакчалар музыкасы — бөтенесе бергә киләчәктән бүгенге көнгә искиткеч гүзәл аһәңнәр рәвешле колакларда чыңладылар. Шул вакытларда табигый рәвештә мавыгып, киләчәкне бүгенге көнгә күчереп кую да бик җиңел иде.

Мәйдандагы арыслан йөрәкле егет скульптурасы, стадион, гөмбәзле театр, колонналы мәктәп...

**Бу сарайларны**
**Төзегән батырларның**
**Тәннәренә тазалык өстәгез!**
**Шаулый электростанция шарламасы,**
**Тамчылар җемелдәвен**
**Көн матурлыгына кушып...**
**Бу шәһәрнең исемен эзләп аптырама син,**
**Иптәш,**
**безнең авылыбыз — шушы!**

Аз да түгел, күп тә түгел. Шулай. Шагыйрь туган авылын шәһәр кыяфәтенә кертте, тик аның белән дә канәгатьләнә алмыйча, андагы юлларны «Москва юлы, Ленинград шоссесы» белән чагыштырып, шул юлдан килер өчен кунаклар үк чакыра башлады. Ә кунаклар... якын елларда, әйтик, шагыйрь үзе яшәгән елларда килсә?

Кунакны чакырган кеше үзе каршыласа дөресрәк бит. Әйе, кунаклар чынлап та килсәләр? Хуҗа ни дип акланыр иде икән? Ихтимал, үзенең артыграк мактап җибәргәне өчен уңайсызрак хәлдә калыр иде ул. Аның баягы сүзләренә ышанган булырлар иде алар, чөнки ул сурәтләрне дөньяда гаделлек өчен көрәшкән, илне, тормышны саклап калган элекке солдат, хәзерге игенче тасвирлаган бит. Солдатның каны, игенченең икмәге алдауны белми... Аның сүзләренә һәркемнең ышанасы киләчәк.

Нигезсез вәгъдәләрнең, ә катырак әйткәндә, мактана төшүләрнең теоретик җирлеге дә юк түгел: типиклык ул бүген күп таралган күренешләр җыелмасы гына түгел, бүген сирәк очрап та, киләчәктә үсә, киңрәк тарала алачак күренешләр типик була ала. Син кешенең улын күз алдына китер, аның портретын юрап бел дә, шул рәсем астына атасының исемен яз. Курыкма, тормышны бозып күрсәтү түгел бу, ә алдан күрү.

Яхшымы бу, начармы? Тарих белән бәхәсләшү җайсыз. Бер генә нәрсәне шикләнмичә әйтергә мөмкин: шулай булды. Тормышта булмаса — әдәбиятта.

Уйланырлык сәбәпләр, бәхәсләшерлек фикерләр юк түгел, әлбәттә...

Шагыйрь шушы дәрәҗәдә тукталса, бәлки бәхәсләшмичә түзәргә дә мөмкин булыр иде. Мәгәр ул арырак уза. «Москвада» шигырендә инде аны кунакка дәшү өчен һәр телдә җылы сүз әзер. Һәр «Победа», мотор сулышын акрынайтып, аның янында туктала, утыртырга әзер икәнен әйтә һәм автор яңадан авылындагы Мәскәүгә (гади калага да түгел, башкаланың үзенә!) охшашлы якларның артуын уйлап дулкынлана башлый. Нәкъ шул мәлдә, автор теләгән тойгандай, Мәскәү әллә кайдагы колхоз радиоузелын тоташтыра да меңләгән мәскәүле дуслар репродукторларга сыена. Колхоз кызы Гөлсинәнең гүзәл авазын халык артисты Глиэр отып калырга

ашыга. Дәүләт премиясе лауреаты К. Симонов исә бригадир Гариф рифмаларына соклана...

Була ала микән шундый хәлләр? Хәзер була алуы бәхәсле, ләкин элегрәк шиксез булды. Тормышта булмаса, — әдәбиятта.

Чор әдәбиятының кайбер арттырып җибәрүләре акрынлап шартлылыкка юл бирә барды һәм үзе дә шуңарга охшарга тырышты. Ә хәзер исә андый шаукымнар тарихи күренеш булып кына калды шикелле. Алардан бушаган җирдә чын публицистик поэзиягә урын киңәйде. Әнвәр Давыдов иҗатында да шулай булды.

Гаҗәп бит бер карасаң: көн ыгы-зыгысы, көндәлек мәшәкатьләр һәм... Мәңгелек төшенчәсе, бармы бәйләнеш? Мәңгелек һәм Кеше. Язмышлар, дөнья, аның мәгънәләре, матурлыгы, фаҗигалары. Туу, яшәү, үлү дигән төшенчәләр хәрәкәтләнә башлый. Шул «ваклыклар» бөтенесе бергә Мәңгелекнең үзен бар итәләр түгелме соң? Бүтәнчә аны ничек күз алдына китерергә мөмкин? Уйлый торгач, мәгънә төсмерләнә: конкрет хәлләр, конкрет күренешләр мәңгелек категориясен барлыкка китерәләр. Сәнгатьтә дә мәңгелек дигән объектив төс алган темаларны аерым вакыйгалар, тарихи хәлләр аркылы гына күз алдына китерергә мөмкин. Заманнардан аерым яши алган темаларны сәнгать белми. Мәңгелек һәр вакыт заман костюмын киеп яши.

Ә. Давыдов китапларыннан берсен «Тормыш лирикасы» дип атаган. Аны кулга алгач, «Бүтәнчә лирика буламыни?» дип сорыйсы килә. Ләкин соңыннан ачыклана: шагыйрьнең артык зурдан купмыйча гына гади нәрсәләр хакында сөйләргә тырышуы, гуманистик омтылышы икән бу.

**Ә күкләрдә йөзә болытлар,**
**Тракторлар йөри кырларда,**
**Ил буенча чаба поездлар,**
**Машиналар ашыга юлларда.**

Бөтен нәрсә гади, көн саен үзебез күреп торганча — күк зәңгәрлеге, болытларның ап-ак булып шунда сәяхәт иткәне, кырда игеннәр шавы — иркенлек, чиксезлек. Кеше күрә, тыңлый, ниндидер сер эзли. «Нәрсә кирәк икән бу кешегә?» дигән кебек аңа кемдер.

**Нәрсә кирәк!**
**Нәрсә кирәк сәнгать музеенда**
**Венераның сыны каршында,**
**Сәҗдә кылган кебек, оеп калган**
**Түбәтәйле татар картына!**

Куйбышев өлкәсендә Камышлы дигән авыл бар — үзенә генә хас табигате: урманнары, сулары, кешеләре... Алабута арасында көн буе йөгереп арган малай төнлә төшендә Лермонтовның Бэласын коткара. Нәрсәдер бар бу дөньяда, ниндидер хикмәтле нәрсә...

**Рәхмәт сиңа, шаулы бала чак,**
**Мин кайткач та туган туфракка,**
**... Сер сөйләдең минем колакка.**

Шагыйрь яшәү мәгънәләре, тормыш ваклыклары тудырган сорауларга җаваплар таба һәм үзе өчен ачылган серләрне күңелендә биклəп тота алмыйча, бүтәннәр белән дә уртаклаша:

**Кулларыңның каты икәнен,**
**Яргаланган булуын күрдем мин.**
**Тик алардан куркып китмәдем,**
**Йөрәгемне сиңа бирдем мин.**
**Кайчак: «Авыртмыйм, — дисең миңа, —**
**Йөрәк, каты куллар тиюдән!»**

Шагыйрь үзе дә конкрет шәхес, аның һәр көне, бөтен тормышы — үзенә бирелгән вакыт гәүдәләнеше. Шагыйрь яши — көлә, елмая, кайгыра... сөя, ярата.

Җирдә бүген бөтен нәрсә анык. Җирдә өмет бар, ышаныч дигән, мәхәббәт дигән бөек яктылык бар. Аны башкаларга, бүтән күңелләргә күчерү җиңел эш түгел, котočкыч авыр эш. Иҗат итүне шагыйрь бөек бәхет дип кабул итә. 1950 елда «Беренче бөртек» дигән китап үсеп чыккан. Аннан бер-бер артлы «Алгы сафтагылар», «Сине сөюем», «Ферма кызы», «Чорлар чатында», «Тормыш лирикасы» һәм башкалар — татар телендә, рус телендә.

Шәхес үзенчәлекләре шагыйрь үзенчәлекләре булып әверелә... Аның тавышы поэзиягә бүтән беркемне дә кабатламый торган яңа тавыш булып кушылды — башта хәтта сәеррәк тә ишетелә иде ул. Шуңа күрә бәхәсләр дә кузгала иде. Әйтик, поэмалар — «Коммунизм таңы» колхозында», «Алгы сафтагылар», «Ферма кызы», «Ташу» һәм башкалар. Эпик жанрда язылгангамы, аларда прозага хас элементларны — хикәяләү, шәрехләүне, урыны-урыны белән очрый торган очеркка хас публицистиканы кабул итеп бетерү кыен иде. Шулай да стиль яңалыгы, ритмика сыгылмалылыгы, строфалар иркенлеге, ниһаять, иң мөһиме, авыл картиналарының дөреслеге — барысы бер җәлеп итә иде. Димәк, тормышның үзеннән килгән бизәкләр болар, ялган сүзләр түгел.

Бу поэзиядә, гомумән, публицистик башлангыч беренче урында тора. Шуңа күрә ул үзенә ныклырак игътибар сорый. Ил турында, халык һәм партия турында риторик канатлы, социаль әһәмиятле бик күп сүзләр, фикерләр, хәтта акыллы сүзләрне дә күп язарга мөмкин. Ләкин коры декламация булып калмасын өчен, сүз сәнгатькә әйләнсен өчен шигырь дигәнне гомер белән расларга бар — шунда гына чын поэзиягә әйләнә ул.

**Тешем кысып чыгып барамын.**
**«Хиросима» фильмын карадым.**

Җир буйлап «сугыш» дигән шомлы күләгә йөри — кара шәүләсе язмышлар өстендә уйный. Ничек кенә ишетергә, ничек кенә күрергә теләмәсәк тә, үлем дигән нәрсә бар дөньяда. Тормыш тоташ шатлык, тоташ бәхет, тоташ бәйрәм генә түгел — катлаулы, авыр, һәм аның кадерен белергә, сакларга кирәк. Балалар үлгәнне, нәни тәнне ташлар күмгәнне, бакчалар көйгәнне—үлем тантанасын, аның үкереп, улап шатлануын күрмәс өчен — көрәшергә, бар көчеңне җыеп көрәшергә тиеш син.

Бу инде гади чакыру, акыл сүзе генә түгел, ә кичереш. Тынычлык турындагы әрнүле хисләрен шагыйрь, кешеләргә, тормышка булган олы сөюен саклаган хәлдә, Бөек Ватан сугышы фронтларыннан алып кайткан.

Бер ышандыңмы, инде син шагыйрьне тагын да зуррак ихтирам белән тыңлыйсың. Кеше хыялы, уйлары, хисләре интим тынлыктан иҗтимагый киңлеккә барып чыга.

**Материя хәрәкәтеннән**
**Җирдә тормыш туган шикелле,**
**Халык омтылышыннан, өметеннән,**
**Җиңелмәс көч булып син килдең**
**Бу дөньяга, бөек партия!**

Бу сүзләрне әйтү өчен дә дәреслекләр уку гына җитми. Аларның беренче кат телгә килгән чагы менә кайчан: утлы тимерләргә сыдырылып, шагыйрьнең күлмәкләре телгәләнеп беткән. Тирә-якта — дошман. Тузан, төтен, ут аркылы үлем сулышы ишетелә. Шагыйрь йөрәгеннән нәфрәт дигән эсселек пешерә. Менә шул чакта ул үзен партиянең бер тамчы каны итеп тоя. Юк, партия таш сын, тәнсез идея түгел, ә шундый ук кан тамчыларыннан җыелган җисемле, җанлы көч:

**Уртак безнең шатлык кайнары да,**
**Кайгының да әрем ачысы...**

Кеше характеры, кеше хисләре дә, тормышның үзе кебек үк, гаять катлаулы һәм бай. Чын шагыйрь тормыш каршылыкларыннан, хисләр тирәнлегеннән курыкмый — дөньяны булган хәлендә ярата һәм андагы гариплек, ямьсезлекне дә яшермичә, аның тагын да камилләшүенә ярдәм итә. Чөнки бомбалардан курыкмаган

куңелне юк кына сүз, әшәкелек харап итеп ташларга мөмкин бит. Усаллык, явызлык белән көрәшкән шагыйрьнең йокысыз төннәр үткәрүе дә гаҗәп түгел. Ләкин нык ихтыяр, яхшылыкка ышану аны якты иртәгә яңадан китереп чыгара:

**Тагын тормыш, хезмәт шавы**
**Куды газап чыңнарын.**
**Шатланалар, сөенәләр**
**Һәм көләләр җырларым!**

Шагыйрь иҗатының, бөтен тормышының бер йокысыз төнгә җыелып тыгызлануы, барлык шигырьләре һәм поэмаларыннан күчкән, шигъри осталык дип исемләнгән, бөтен гомере буе тупланган тәҗрибәсенең бер әсәргә тупланып яңгыравы — шулай ук табигый нәтиҗә булды. «Йокысыз төннән соң» дигән роман-симфония калдырып китте шагыйрь — бу аның соңгы әсәре... Анда бүгенге көннең нигезе узган чорларда ук салына башлануы аермачык күрсәтелгән:

**Хәзер безнең кулда күпме көч бар!**
**Уебыз: йолдызларга оча алу.**
**Ләкин нинди көчне таләп иткән**
**Шәм яктысында, себер мунчасында,**
**Көн яктырыр диеп ышану!**

Дөньяга шул шәм яктысы, кайчандыр Ленин яндырган шәм яктылыгы төшеп, мең-мең илләргә сузылган. Бу яктылык — мәңгелек.

Кич.

Таш өйләрне караңгылык чорнаган. Ләкин тәрәзәләр... Йөзләрчә йөрәкләр кайнарлыгы! Йөзләрчә гомерләр.

Бер тәрәзә — анда ут янса да, кешеләр хакына яшәлгән олы бер гомер сүнә. Ә икенче тәрәзәләр урамнарга йөз күзле шатлык бүләк итә. Кемнәрдән соң да шулай таш өйләрдә меңнәрчә тере йөрәкләр кала. Менә шушы инде — тормыш, аның матурлыгы, аның мәгънәсе. Шуны инде без поэзия дип атыйбыз. Шагыйрьнең гомере шунда — уйлары, хисләре, язмышы, аның фәлсәфәсе, минем фәлсәфә, безнеке... тормышның үзендә.

Кояш яктысында, ай яктысында, кичке утлар балкышында — урамнарда, бакчаларда, урманнарда — җил белән яфраклар сөйләшә. Бу сөйләшү — мәхәббәт шикелле, бәхет шикелле. Матурлык — табигатьнең үзендә.

Гасыр билгеләрен, вакыт кисәкчәләрен киләчәккә алып киткән әсәр — үлемсез.

Эльмира Бариева

# ГАЛИМ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ

Тәнкыйть мирасыбызның туплана килгән матур сәхифәләре совет әдәби тәнкыйте казанышлары биеклегенә таба күтәрелә баручы тарихи адымнар үремен хәтерләтә, тарихи үсеш чылбырының элэклелеген, бөтенлеген тәшкил иткән зарури звенолар буларак та күз алдына килә. Әдәби тәнкыйть тарихының төрле чорларында актив иҗат иткән авторларга без бүгенгене төзешүчеләр итеп карыйбыз, үз вакытында фәнгә алып кергән яңалыкларыннан чыгып бәя бирәбез. «Тарихи хезмәтләр турында тарихи эшлеклеләрнең хәзерге таләпләр белән чагыштырганда нәрсәне **бирмәүләренә** карап түгел, бәлки аларның үз элгәреләре белән чагыштырганда **нинди яңа нәрсә бирүләренә** карап хөкем итәлә», — дип өйрәтте В. И. Ленин[1].

Узган чорлар белән бүгенге көн, кичәге табышлар белән киләчәк ачышлар, элекке эшлеклеләр белән туачак бөек кешеләр арасында өзелмәс элемтәләр яши икән, бу бүгенге тәнкыйть фәне өлкәсендәге уңышларның моңа кадәр ирешелә килгән биеклекләргә турыдан-туры бәйләнешле булуын раслый торган диалектик нигез. «Заман прогрессы белән горурлану — бүгенге шәхси казанышлар белән генә мактану, элек эшләгән кешеләрдән ераграк, биегрәк, яхшырак һәм аларга карaганда да лаеграк булу дигән сүз түгел»[2],— дип язган В. Г. Белинский. Алдынгы мирас заман рухына кушылып яңара, бүгенгенең нигезенә яткан, эчтәлегенә сеңгән килеш киләчәккә китеп бара. Димәк, ул тарих сәхнәсендә һаман хәрәкәттә.

Күренекле татар филологы, галим Габдрахман Сәгъдинең 90 еллык юбилеен билгеләп үткән бу истәлекле көннәрдә аның шәхесенә, иҗатына, әдәби-фәнни мирасына без әнә нәкъ шул яктылыкта якын киләбез. Г. Сәгъдинең бай гыйльми мирасы татар совет тәнкыйте казанышларының үзәгенә үрелеп керган, аның корылмасына базык өлеклэр булып күтәрелгән, нигезенә игелекле туфрак булып яткан.

Культурабыз тарихына Г. Сәгъди талантлы педагог, танылган әдәбият тарихчысы, тирән эрудицияле лингвист һәм, барыннан да бигрәк, тәнкыйтьче буларак кереп калган. Тәнкыйть эшчәнлеген ул, нигездә, Октябрь революциясеннән соң башлый һәм 20 нче еллар марксистик татар әдәби тәнкыйтен формалаштыруга гаять зур өлеш кертә. Әдәбият галимнәре аны бик хаклы рәвештә Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Галиләр белән беррәттән татар әдәбият белемен фән буларак нигезләүчеләр рәтенә кертеп карыйлар.

20 нче еллар әдәби хәрәкәтенә Г. Сәгъди бай тормыш тәҗрибәсе белән килеп керде. Революциягә кадәр үк дөньяга материалистик карашлы, халык интереслары ягында торучы, демократ рухлы каләм остасы иде ул. Изелгән халык ягында бул-

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Т. 2, 5 нче басма, 172 бит.
[2] В. Г. Белинский. Полн. собр. соч. Т. 10, 185 бит.

ганы, шулар файдасына эшләгәне (революциягә кадәр ул төрле урыннарда мөгаллимлек итте, гади хезмәт халкына аң-белем, мәгърифәт тарату эшенә күп көч салды), язганы өчен патша самодержавиесе Г. Сәгъдигә «политик ышанычсыз» дигән ярлык тага, эзәрлекләүләргә дучар итә.

Габдрахман Сәгъди пролетариат революциясен, Ленин идеяләрен һичбер икеләнүсез кабул итте, җаны-тәне белән социалистик тормышка хезмәт күрсәтү эшенә кереште. Әдәбият тарихын өйрәнүчеләр аның бу елларда гаҗәп зур дәрт белән эшләвен билгеләп үтәләр.

Газета-журнал сәхифәләрендә, бигрәк тә «Безнең юл» журналында, Г. Сәгъдинең әдәбият мәсьәләләре һәм әдәби тәнкыйть буенча чыгышлары даими рәвештә басыла килә.

Әдәбият-сәнгать күренешләренең материаль-экономик тормыш шартларына бәйләнешен аңлау, аларның иҗтимагый мәгънәсенә төшенү, камил сәнгать әсәренең халыкчан рухлы булуын яклау юнәлешендәге фикерләре белән сәнгать методологиясенең кайбер мөһим критерийларын үз алдына инде элек үк билгеләп куйган галим совет чорында язылган мәкалә һәм хезмәтләрендә дә әдәбиятны халык тарихы, иҗтимагый тормыш фактлары белән тыгыз бәйләнештә карады, яңа татар әдәбиятының халыкчан һәм партияле рухта үсүе өчен көрәште. Егерменче еллар — халыкчанлык, сыйнфыйлык, партиялелек, әдәби мираска мөнәсәбәт мәсьәләләренең көн тәртибенә куелган, актуальләшкән чагы, алар хакында бөтен тәнкыйть фронтында җитди сөйләшүләр барган вакыт. Культурабыз мирасына хөрмәт белән караган, иҗатның иҗтимагый-сыйнфый мәгънәсенә җитди төшенгән галим бу мәсьәләләргә дә үз карашын белдерми кала алмады, әлбәттә. Аларның фәнни-теоретик хәл ителеше 20 нче еллар татар марксистик әдәби тәнкыйть методологиясен эшкәртү өчен зур әһәмияткә ия булды.

Г. Сәгъдинең «Октябрьның сигез елы эчендә татар әдәбияты» (1925), «Әдәбиятны җәмгыять белеме белән баглау» (1926), «Әдәбият укыту тәҗрибәсе» (1926), «Безнең юл»да әдәби-гыйльми тикшерүләр, тәнкыйтьләр» (1927), «Татар пролетариатының беренче әдибе — Г. Коләхметов» (1927), «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» (1923), «Ф. Әмирхан» (1926), «Кандалый турында» (1927) кебек мәкаләләре, «Татар әдәбияты тарихы» (1926), «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (1930) кебек зур күләмле хезмәтләре югарыда искә алынган җитди проблемаларны яктыртуга багышланган иде. Галим тәнкыйть анализында методологик нигез итеп марксистик әдәбият концепциясен сайлады. Әле егерменче еллар башында ук Галимҗан Ибраһимов Г. Сәгъдине әдәбият күренешләрен «марксистик система»га салып өйрәнүдә беренче практик адымнар ясаучы буларак бәяләде [1].

Г. Ибраһимов сүзләрендә дөреслек бар иде. Г. Сәгъди үзе дә татар әдәбияты материалларын марксизм нигезенә алып өйрәнүне «омтылган бер ноктасы» дип санады. «Татар әдәбияты тарихы»на (К., 1926) сүз башында ул әнә шулай язган иде. Ә инде «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» (К., 1930) автор тарафыннан «иҗтимагый-әдәби процессларны марксизм системасы астына алып аңлатуның беренче тәҗрибәсе» буларак тәкъдим ителде. Бу хезмәтләр «бүген дә кулланудан төшмиләр, әдәбият белемебез үсешендә күренекле урын алып торалар», — дип язды Х. Хәйри үзенең «Әдәбият фәнебезнең үсү юлы» дигән мәкаләсендә [2].

Дөрес, галимнең марксистик концепциядән читкә тайпылган яисә аны эзлекле үткәреп бетермәгән очраклары да булмады түгел. Югарыда искә алынган мәкалә һәм хезмәтләрендә уңышлы, файдалы фикерләр белән бергә, вульгар социологик хаталар, бәхәсле моментлар да еш очрый. Моны искәртми үтү мөмкин түгел. Әмма шул кадәресен дә онытырга ярамас, егерменче еллар — марксистик-ленинчыл эстетиканың яңа формалаша, марксистик-әдәби анализ принципларының тәнкыйтьтә яңа файдаланыла башлаган чоры. Билгеле, мондый эш берьюлы капылт кына башкарыла алмады, бу процесста эзләнү, буталу, ялгышулар табигый иде. Бүгенге югарылыктан караганда ул хаталар аеруча ачык күренәләр. Әмма егерменче еллардагы марксистик әдәби тәнкыйть өчен көрәшнең, шул исәптән Г. Сәгъдинең әдәби тән-

---

[1] Г. Ибраһимов. «Иҗтимагый әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы». — «Безнең юл», 1922 ел, 1 сан.
[2] Х. Хәйри. «Иҗат чишмәләре» дигән җыентык. Казан, 1975, 201 бит.

кыйть өлкәсендәге эшчәнлегенең төп пафосын без ул ялгышларда күрмибез. Бу күрәшнең кыйммәтле башлангычы, авыр һәм катлаулы эзләнү юлында табылган таза-сәламәт орлыклары кадерле безгә.

Әдәби тәнкыйть методологиясе мәсьәләләренең уңай хәл ителүе өчен партия документлары һәм карарларының ни дәрәҗәдә әһәмияткә ия булулары турында әйтеп тә торасы юк. Алар «әдәбиятны аңлауда төп нигезләрне утырталар, әдәбиятны тикшерү һәм өйрәнүнең методология ягыннан булган төп сызыкларын күрсәтәләр»[1]. Әдәбият мәсьәләләренә мөнәсәбәттә партия күрсәтмәләрен, марксизм-ленинизм классиклары өйрәтмәләрен торган саен тирәнрәк үзләштерә барган галим аларны үзенең тәнкыйть практикасында да эзлекле үткәрергә тырышты. Мисал өчен аның әдәби мирасыбызга мөнәсәбәтен ачыклап үтү урынлы булыр.

Әдәби мираска Ленинча мөнәсәбәт булдыру 20 нче еллар татар марксистик тәнкыйте өчен гаять зур әһәмияткә ия иде. Ленинның «Пролетариат культурасы капиталистик җәмгыятьнең, алпавытлар җәмгыятенең, чиновниклар җәмгыятенең изүе астында кешелек дөньясы барлыкка китергән белем запасларының закончалыклы үсеше булырга тиеш»[2] дигән күрсәтмәсен истә тотып, халкыбызның үткәненә, аның культура һәм әдәби мирасына Г. Сәгъди дә һәр даим кайгыртучан мөнәсәбәттә булды. Һәм моның матур үрнәкләрен аның эш практикасында күпләп табарга була.

1923 елда тәнкыйтьче «Безнең юл» журналында «Татар шагыйрьләре арасында Тукай» исемле мәкалә белән чыгыш ясады. Г. Тукай иҗаты тирәсендә җитди фикер каршылыклары яшәгән, аның бөтен мирасына мөнәсәбәттә төрле карашлар көрәше барган бер чорда мондый мәкаләнең язылуы үзе бер вакыйга иде. Һәм аңа, Тукайга, аның иҗатына дөрес, объектив бәя бирелде. Тукай шигырьләрен әдәби мирасыбызның иң лаек үрнәкләреннән санап, тәнкыйтьче Г. Сәгъди, гомумән, классик мираска якын килү, аны сайлау, аралау принципларын сызып калдырды.

Әдәби әсәрнең тарихка керүен, мәңгелеген тәэмин итүче әһәмиятле факторларның берсе, тәнкыйтьче фикеренчә, язучы яки шагыйрьнең табигый таланты, шагыйрьлек көче. Бу яктан алганда, Тукай кебек шагыйребезнең шигъри осталыгына карата бернинди шик булуы мөмкин түгел — аны бары мәшһүр Пушкин белән чагыштырып була. Рус халкы өчен Пушкин никадәр бөек шагыйрь саналса, татар өчен Тукай шундый. «Тукай һич шөбһәсез татарның Пушкины иде», — диде Г. Сәгъди.

Классик мирас дәрәҗәсенә күтәрелүнең икенче күрсәткече — шагыйрь иҗатының халык күңеленә үтеп керә алуы, ягъни аның халыкчанлыгы. Тукай поэзиясенең бөеклеген һәм мәңгелеген Г. Сәгъди нәкъ менә шагыйрьнең халыкчанлыгында күрде. «Тукайның гаммә шагыйре булганлыгында шигебез юк, — диде тәнкыйтьче, аның кем һәм кайсы сыйныф шагыйре булуы хакындагы сөйләшүләрнең урынсыз булуына басым ясап, — гаммәгә якынлык, ярлыларга дуслык шагыйрьдә һәр нәрсәдән бигрәк күренә.» Әгәр Тукайны «карты-карчыгы, егете-кызы, сабыйлары, яшүсмерләре» укый, аңлый икән, әгәр аны үз заманы һәм аннан соңгы заманнар үз шагыйре дип кабул итә икән, димәк, тарих шагыйрьгә тиешле мөһерен басып куйган инде. Тукай — халыкныкы, бу мәгънәдә ул безнең «беренче шагыйребез».

Язучы иҗатының классик мирас югарылыгына күтәрелүе өчен, аның тагы тормыш дөреслеген чагылдыруда реалист булуы шарт. Тукай мирасы бу таләпкә дә тулысынча җавап бирә: «Ул халыкның моң-зарларын, теләк-өметләрен, шатлык вә куанычларын үзенә алган, үзенә суырган һәм шуларны кире татар дөньясы өстендә яңгыратып калдырган». Тәнкыйтьче күрсәтүенчә, тормыш дөреслеген бирү белән халыкчанлык үтә тыгыз үрелгән принциплар, алар берсеннән-берсе аерылгысыз мөнәсәбәттә яши. Сәгъди, бер үк вакытта, чынбарлыкны дөрес чагылдыру шагыйрьлек көченә дә зыян китерергә тиеш түгел, дип күрсәтте. Һәм, дөрестән дә, тормыш материалының сәнгатьчә оста бирелүе һәм халыкчан эчтәлектә булуы ягыннан Тукай шигърияте классик әдәби мирасыбызның иң гүзәл үрнәкләре буларак бәяләнергә хаклы иде. Г. Сәгъди Габдулла Тукай шигырьләрен һичнинди икеләнүләрсез гасырлар дәвамына китәрлек югалмас кыйммәткә ия булган әсәрләр дип бәяләде.

---

[1] Г. Сәгъди. «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты». Казан, 1930, 11 бит.
[2] В. И. Ленин. Яшьләр союзларының бурычлары.— «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында», Казан, 1976, 362 бит.

Әдәбият галимнәре аның бу мәкаләсенә зур бәя бирәләр, аны «шагыйрь иҗатына дөрес һәм тулы анализ», «гаять дөрес караш»[1] дип күрсәтәләр.

Әдәби мираска мөнәсәбәттә Г. Сәгъди Г. Ибраһимов тәкъдим иткән принципларны алга таба үстереп алып китте. Г Тукай иҗатына карата нәкъ менә Г. Сәгъди тәкъдим иткән критерийлардан чыгып эш итү сорала иде. «Халык өчен Октябрьга кадәрге татар әдәбияты мирасыннан бу якка күчереп алынган хәзинә — Г. Тукай әсәрләре — иң кадерлесе, иң якыны иде. Егерменче еллар башында яңа, пролетариат әдәбияты өчен җанлы мирас бездә барыннан да бигрәк Г. Тукай иҗатыннан гыйбарәт булды»[2],— дип язды Мансур Хәсәнов. Әмма 20 нче елларда тәнкыйть методологиясендәге вульгар-социологик хаталар еш кына тикшеренүчеләрне дөрес юлдан читкә алып китте. Һәр әдәби күренеш шул чорның материаль җирлегеннән үсеп чыга дигән вульгар карашка таянып, һәр чорның әдәбияты һәм язучысы шул чорның хаким идеологиясенә хезмәт итә дигән ялгыш караш яшәде. Нәтиҗәдә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек демократ язучылар буржуа язучылар исемлегендә йөрделәр. Аларны бөтен әдәби мираслары белән бергә революциянең теге ягында калдырырга, социализм әдәбияты фондына алмаска дигән фикерләр әйтелде. Вульгар-социологик ялгышулар Г. Сәгъдинең үз тәнкыйть практикасында да шактый, һәм бу ялгышлар, гомумән, 20 нче еллар әдәби хәрәкәтенә катнашкан бер генә кешене дә читләтеп узмады. Тик шунысы куанычлы, эзләнүләр, кайбер каршылыклар аша булса да сизгер тәнкыйтьче ахыр чиктә барыбер дөрес нәтиҗәләргә барып ирешә иде. Галимнең көчле интуициясе, бай әдәби зәвыгы теге яки бу язучының кем һәм нинди булуын тиз аерды, аңа объектив бәя бирергә нык ярдәм итте.

Вульгар-социологик тәнкыйтьчеләр реалист язучы, демократ Фатих Әмирханны «аристократ язучы» һәм аның әсәрләрен «татар буржуазиясенең фантазиясе» дип бәяләгән бер вакытта Г. Сәгъди аны «гимназист вә гимназисткалар әдибе, шуларның художнигы» дип чыкты[3]. Әлбәттә, Ф. Әмирханны «аристократ»лыкта гаепләү фәнни сукырлыктан башка берни түгел. Г. Сәгъди Ф. Әмирханның мулла гаиләсеннән чыкканы һәм сайлап алынган типлары шул даирә кешеләре булганы өчен генә буржуаз язучысы дип саналуын мәгънәсезлек дип аңлады, язучының көчен әсәрләренең сәнгатьчә камиллегендә һәм реалистик кырыслыгында күрде.

Тәнкыйтьче әдәби мирасыбызның классик үрнәкләрен тудырган Г. Камал, Г. Коләхметов, С. Рәмиев, Дәрдмәнд кебек шагыйрь һәм язучылар иҗатына да тукталды, алар хакында үзенең җитди фикерләрен әйтеп калдырды.

Дәрдмәндне буржуаз дәвер шагыйре дип, аны танымау турында күп сөйләшүләр барган елларда Г. Сәгъди аның «шигырьләренең киң, тулы мәгънәле булучылыклары һәм оста кул белән эшләнгән символ-сурәтләргә байлыклары» ягыннан «әдәбият тарихыбызда югары урын» алырга тиешлекләрен даулады[4].

Г. Сәгъди Дәрдмәнд поэзиясенең үзеннән соң килгән буын шагыйрьләргә көчле йогынты ясавын күрде. Бу аеруча Такташ белән Туфан иҗатында сизелде. Туфанны «фикер-төшенүләрне оста тәгъбир һәм тасвир итүдә татар әдәбиятында Дәрдмәндтән соң күренгән беренче шагыйрь»[5] дип атады тәнкыйтьче.

Г. Сәгъди Галиәсгар Камалны «татарның беренче чын сәнгатьчә драматургы» дип бәяләде һәм аның «беренчелеген тарих каршында бераүгә дә алу мөмкин булмаячагын[6] ассызыклады. Пролетар язучы Г. Коләхметовның тормыш һәм иҗат юлы, әсәрләре, татар әдәбияты тарихында аларның тоткан урыны турында шактый тәфсилле анализны да Г. Сәгъди бирде[7]. Галимнең әдәби мирасыбызга мөнәсәбәтле кайсы гына мәкаләсен, язмасын, фикерен алып барласаң да, үз культурасы тарихына тирән ихтирам белән караган, үз әдәбиятын яраткан, аның реалистик, демократик канатын яклаган белгеч күз алдына килә. Ул үткәндәге әдәби мирасыбызны барларга, тупларга, кадерләп сакларга өйрәтте, җентекләп өйрәнергә чакырды.

---

[1] М. Гайнуллин, Габдрахман Сәгъди. «Казан утлары», 1971, 7 сан.
[2] М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964, 176 бит.
[3] Г. Сәгъди. Ф. Әмирхан. «Безнең юл», 1926, 3 сан.
[4] Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930, 84 бит.
[5] Шунда ук.
[6] Г. Сәгъди. Татар әдәбият тарихын тикшерүдә кайбер хаталар. «Безнең юл», 1927, 1, 2 саннар.
[7] Бу язучы хакында авторның материаллары «Безнең юл» журналында (1927, 13 сан), «Татарстан» газетасында (1927, 13 сан) һәм «Татар әдәбияты тарихы»нда (Казан, 1926) бирелгән.

XIX йөз шагыйре Габделҗаббар Кандалыйның тормыш һәм иҗат биографиясенә караган кайбер яңа материаллар табылу уңае белән Г. Сәгъди «Безнең юл» журналында махсус мәкалә белән чыга [1]. Тәнкыйтьче күрсәтүенчә, шагыйрь мирасының безнең әдәбиятыбыз өчен кыйммәтле ягы шунда, «ул татар лирикасында иске суфилык, мистикачылык кысасын җимереп чыгып, беренче мәртәбә реализм сызыгына аяк баскан... сыйнфый каршылык, сыйнфый дошманлык чаткылары ялтырата башлаган шагыйрь». Менә шуның өчен «Кандалый һәм аның шигырьләре безнең әдәбият тарихында аерым бер игътибар белән тикшерелергә, өйрәнелергә тиешләр». Сәгъди журнал укучыларына, Кандалый хакындагы материаллар, истәлекләр күренә калса, бу турыда гыйльми үзәккә хәбәр итүләрен сорап мөрәҗәгать итә.

Әдәби материалларны теркәүдә Г. Сәгъди тарихи эзлеклелек, хронологик төгәллек, сыйнфый ачыклык белән эш итүне сорады. «Әдәбиятны тикшерүдә кайбер хаталар» дигән мәкаләсендә ул тарихчы Газиз Гобәйдуллинның әдәби-гыйльми тикшерену алымын әнә шул принципларда төзелмәгәнлеге өчен тәнкыйть итте. Сыйныфларга бүленгән җәмгыятьтә сәнгать һәм әдәбият сыйнфый ноктадан чыгып тикшерелергә тиеш иде, чөнки әдәбият-сәнгать төбе-тамыры белән җәмгыятькә, аның төрле социаль катлауларына хезмәт итә торган иҗтимагый-сыйнфый күренеш.

Г. Сәгъди революциягә кадәрге татар әдәбиятының «ике юлдан, ике агым белән барганын» күрде [2]. Мондый методологик принциптан чыгып эш итү революциягә кадәрге татар әдәбияты үсешен бердәм агым, бердәм эстетик процесс итеп карауга чик куйды.

Галим һәм тәнкыйтьче әдәби тәнкыйть методологиясендә бик тә зур әһәмияткә ия булган, әдәбият-сәнгать әсәрләрендә эчтәлек белән форма берлеге яклады. «Болар бер үк нәрсәнең бер-берсе белән бик нык бәйләнгән ике ягы, — дип күрсәтте ул. Элек «нәрсә тасвир ителү» ягы әһәмиятле булса, **шуның белән бергә үк** (ассызык безнеке — Э. Б.) аның «ничек тасвир ителү» ягы әһәмиятле» [3]. Әдәбият галименең әлеге берлек турындагы тезисының методологик әһәмияте шунда иде ки, әдәби әсәрдә форма һәм эчтәлек берлеген яклау белән бергә ул әдәби тәнкыйтьтә социаль һәм эстетик анализлар берлеген яклауга килде. 20 нче еллар әдәби тәнкыйтендә әлеге принципларны теоретик теркәү Г. Сәгъдинең казанышы. «Мөндәриҗә белән форманың бер-береннән аерылмас бер нәрсә икәнен күрсәтү — марксизм әдәбият методологиясе яки марксизм сәнгать социологиясенең төп таләбе» иде. Г. Сәгъди бу фикере белән үзенең җитди хәзерлекле марксист әдәбиятчы булуын күрсәтте. Сәнгать формадан гына гыйбарәт дип санаучы теорияләр янсә аны бары тик «икътисади-иҗтимагый» нигезләр белән генә бәйләп аңлатучы коры социологизм карашларына каршы үзенең фәнни дөрес положениеләрен формалаштырды.

Г. Сәгъди тәҗрибәле өлкән иптәш, авторитетлы тәнкыйтьче буларак, яшь язучылардан К. Нәҗми, Ш. Усманов, М. Максуд, Х. Туфан һ. б. иҗатына еш мөрәҗәгать итеп торды, алар эшчәнлегенә күзәтүләр ясап барды. Бу язучыларга уңышларын, җитешсезлекләрен итагатьле рәвештә күрсәтеп, аларны киләчәк иҗади уңышларга канатландырды, алга таба дөрес үсеш юлыннан китәргә зур ярдәм итте. Әле 1924 елда гына Г. Кутуй һәм К. Нәҗмиләрнең формализм белән мавыгуларын уңай күренеш дип бәяләгән тәнкыйтьче [4], «Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты» дигән хезмәтендә формализм, имажинизм, футуризм һ. б. шундый «изм»нар юлы белән сәнгать әсәрләре иҗат итү күренешен «дөрес юлдан аяк таю» дип бәяләде. «Шигырь ачык, җиңел, пролетариат аңларлык булсын», — дип язды ул. Әсәрнең «мөндәриҗәсе белән бергә үк аның теле, формасы да күпчелек аңлый торган бер рәвештә булырга тиешлеген» [5] Г. Сәгъди әдәбиятта халыкчанлыкның бик әһәмиятле бер моменты итеп санады.

Талантлы яшь шагыйрь Х. Туфанның «әсәрләрен җиңел аңлауга комачаулый торган кайбер азаплану»лардан котылуын тәнкыйтьче уңай күренеш дип бәяләде, шагыйрьнең шул юнәлештә алга таба да уңышлы эшләвен теләде. Сәгъди Х. Туфанның

[1] Г. Сәгъди. Кандалый турында. «Безнең юл», 1927, 7 сан.
[2] Г. Сәгъди. Татар пролетариатының беренче әдибе Гафур Коләхметов. «Безнең юл», 1927, 1 сан.
[3] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930, 18 бит.
[4] Г. Сәгъди. Яңа әдәби алымнардан футуризм. «Безнең юл», 1924, 3 сан.
[5] Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930, 12 бит.

талант көчен, шагыйрьлек осталыгын «хикмәт чыгаруда» түгел, ә бәлки «пролетариат идеологиясен үзенә суыра белеп, шуны шигъри калыпка салыша алуында һәм яңа тормыш фикерләрен сәнгатьле тәгъбир итә» белүендә күрде.

Ш. Усманов хикәяләрендә сәнгатьлелекнең аксавын да вакытында күрсәтеп чыгучы Г. Сәгъди булды. Хикәяләрендә Ш. Усманов тормыш күренешләрен реалистик чагылдыру, бөтен барлыгында бирергә тырышу, бар булган-күргәнне сөйләү, шуны һич үзгәртүләрсез күрсәтү, «вакыйгаларны ялангач көенчә урнаштыру» белән мавыгып китә, ә мондый алымның натурализмга илтү куркынычы бар иде. Тәнкыйтьче Г. Сәгъди чын сәнгать әсәренең фактографиягә корылмавын, ә бәлки реаль тормыш фактларын сәнгатьчә үзгәртеп бирүдә икәнлекне әйтеп чыкты. «Сәнгатьчелек, әлбәттә, әйтеп, аңлатып бирүдә түгел, тасвирда; сәнгатьле сурәтләр, картиналар аркылы әйтергә теләгәнне нечкә яшертен сиздертә белүдә»[1]. Шунысы әһәмиятле, Г. Сәгъдинең яшь язучылар адресына әйткән тәнкыйть фикерләре һәрчак олыларча кайгырту, дустанә киңәш, итагатьле гадел тәнкыйть үрнәге рәвешен ала иде.

Мәкаләдә Г. Сәгъдинең әдәби тәнкыйть эшчәнлеген һәрьяклап яктырту максат итеп алынмады, ә бәлки аның 20 нче еллар татар марксистик әдәби тәнкыйть методологиясен эшкәртү юнәлешендә әйтелгән кайбер фикерләренә, фәнни-теоретик положениеләренә һәм практик эш алымнарына игътибар ителде. Г. Сәгъдинең тәнкыйть эшчәнлеге татар совет әдәби тәнкыйтен формалаштыру һәм аның методологик нигезләрен калыплауга бик вакытлы, кирәкле һәм файдалы өлеш булып кушылды.

Татар совет әдәби тәнкыйтенең чишмә башы булган 20 нче еллар әдәби тәнкыйте һәм аның күренекле вәкилләреннән берсе Г. Сәгъди эшчәнлеге бүген дә гаять зур әһәмияткә ия мирас буларак әдәби хәрәкәттә яши.

---

[1] Г. Сәгъди. Пролетариат диктатурасы дәверендә татар әдәбияты. Казан, 1930, 71 бит.

**Рәшит Шәрипов**

# МӨХӘММӘДЬЯР ИҖАТЫНДА БӘХЕТ МӘСЬӘЛӘСЕ

Би вафа ирмеш бу дөнья— аңладым,
Әсри күп ирмеш җәфасы —аңладым.

* * *

Ингам вә ихсан йиредер бу җиһан,
Хәйру-ихсан булгусидыр күәт җан.

Кеше, борынгы заманнан ук бәхеткә омтылып, яшәү мәгънәсен аңларга, тормышның асылын табарга тырышкан. Шул омтылышлар фәлсәфәдә, әдәбиятта, поэзиядә, фольклорда чагылган. Дөнья тарихының төрле чорларында яшәгән акыл ияләренең иҗади хезмәтләрендә кешене бәхетле итү турындагы гаҗәеп тирән, гуманистик фикерләр сакланган.

Бәхеткә омтылуны фәлсәфә кеше тормышының табигый элементы итеп карый. Философлар, элек-электән фәлсәфәдәге махсус мәсьәләләр[1] белән бергәттән, бәхет һәм аңарга омтылышны тирәнтен танып белергә тырышканнар. Мәсәлән, Демокрит һәм Платон (безнең эрага кадәр V—IV гасырлар) «бәхет җанда тупланган, дип исәпләгәннәр»[2]. Демокрит бәхетне «җанның хозур халәте дә, тынычлыгы да, гармониясе дә, талгынлыгы да, борчылусыз булуы да» дип таныган. Гомумән, бәхетне ул, асылда, кеше җаны, кеше аңы белән бәйләгән.

Гарәп фәлсәфәсендә дә бәхеткә бик зур әһәмият бирелгән. Мәсәлән, Әл-Фәраби (IX—X гасырлар) бәхетнең мәгънәсен, бәхетле булу юлларын эзли. Аның фикеренчә, бәхет — «кеше җанының яшәү өчен материягә бүтән мохтаҗ булмаслык камиллеккә күтәрелүе»[3]. Бәхетле кешенең җаны тәнгә бәйле түгел һәм мәңге яши. Кеше бәхетне яхшылык эшләп, игелек күрсәтеп таба.

Күренекле материалист, немец философы Фейербах (XIX гасыр) исә бәхетне тирәнрәк аңлата: «Бәхеткә омтылыш — омтылышларның омтылышы ул. Һәрбер омтылыш — бәхет исеме белән аталмаган бәхеткә омтылыш, чөнки омтылыш кешенең үз бәхете дип уйлаган предмет исемен ала»[4]. Шулай итеп, Фейербах кешенең теләсә нинди омтылышын бәхеткә мөнәсәбәтле рәвештә аңлый. Бәхеткә зур әһәмият бирел, ул бәхетне кешенең тормыш максаты дип күрсәтә. Әмма, чикләнгәнлек күрсәтеп, бәхетне кешегә кирәкле предметлар белән генә бәйли.

Әйтергә кирәк, бәхетне тегеләй яки болай аңлау философларны төрле нәтиҗәләргә, еш кына иҗтимагый тормышны үзгәртү уйларына да китергән.

XVI гасырның беренче яртысында яшәгән татар шагыйре һәм фикер иясе Мөхәммәдьяр да кешене бәхетле итү теләге белән яна. Мәкаләгә эпиграф итеп алынган

---

[1] Эпикур (безнең эрага кадәр IV—III гасырлар) хәтта бәхеткә ирешүне фәлсәфәнең төп мәсьәләсе дип тә раслаган.
[2] Лурье С. Я. Демокрит. Л., 1970, 374 бит.
[3] Аль-Фараби. Философские трактаты. Алма-Ата, «Наука», 1970, 288 бит.
[4] Фейербах Л. Избранные философские произведения. М., 1955, I том, 460 бит.

бәетләрне аның иң мөһим фикерләре дип әйтергә мөмкин. Беренче эпиграфта татар гуманистының заман чынбарлыгы белән килешергә теләмәве, канәгатьсезлеге чагылса, икенчесендә аның тормыш идеалы, хыяллары, уй-теләкләре урын тапкан. Ул, «ышанычсыз, җәфалы» тормышны үзгәртеп, «игелекле һәм ярдәмле» дөнья төзергә тели.

Мөхәммәдьярның тормыш юлы, туган һәм үлгән еллары турында язылган истәлекләр сакланмаган. Аның турында без үзе калдырган мәгълүматлар аша гына беләбез. Мөхәммәдьяр бер поэмасында үзенең Казанда яшәвен, ә икенчесендә Казан ханы Мөхәммәд Әмин каберендә сакчы булып торуын язып калдырган. Әсәрләренә карап хөкем йөрткәндә, аның бик белемле һәм алдынгы карашлы булуы турында да фикер йөртергә мөмкин. Ул хан тәхете тирәсендә әйләнгән шагыйрьләрдән ерак торган, ирекле булуны өстен күргән булса кирәк. Һәрхәлдә, аның әсәрләрендә күтәрелгән күп мәсьәләләрнең чишелеше хаким сыйныфлар мәнфәгатенә каршы килә[1].

Мөхәммәдьяр безгә билгеле булган «Төхфәи мәрдан» («Ирләр бүләге») һәм «Нуры содур» («Йөрәкләр нуры») поэмаларында кеше тормышына фәлсәфи караш ташлый һәм үз вакытына күрә шактый алдынгы фикерләр белән чыгыш ясый. Ул Казан ханлыгы чорында изелгән халыкның уй-теләген, омтылышын чагылдыра, кешеләр мөнәсәбәтен гаделлек нигезендә үзгәртү максатын тота. Ил һәм халык патриоты буларак, илнең ирекле, тыныч һәм нурлы яшәвен тели. «Куймагам ил күңле өчен гәрдешем» кебек юллар шуңа мисал булып тора.

Ил алдында йөзен дә, сүзләрен дә ак тотуны иҗат принцибы итеп санаган Мөхәммәдьяр үз-үзенә болай дип мөрәҗәгать итә:

**Сүзләмәкдә сән йөземни ак кыйл,—**
**Сүзләреми ил күңлигә йомшак кыйл**[2]...

Шул рәвешчә татар шагыйре «ил күңелен» гади халык бәхете дип аңлый һәм бәхет турында үзенең асыл «сүзкәйләрен сүзли».

Бәхетнең мәгънәсе урта гасырларда, гомумән, ислам өйрәткәнчә аңланылган: кеше мәхлук, бу дөньяда ул теге дөнья өчен, «бәхетле» оҗмахка керергә тырышып яшәргә тиеш. Җир йөзендә, бәхетсез булсаң да, үзеңнең хәлеңне үзгәртә алмыйсың... Корьән буенча, чын бәхет — алланы үз тормышың турында уйламыйча ярату һәм аңа шикләнмичә табыну. Шул вакытта гына алла теге дөньяда бәхет бирә. Мөхәммәдьярны бу дини догмалар тулысынча канәгатьләндерми. Үз язмышы белән сөйләшкәндә, ул мондый шигъри юллар әйтә:

**Сән ходадин нә теләсәң, тапмадың,**
**Аны куеп, үзгәләрдин теләдең.**
**Ушбу михнәт кем килебдер җаныңа,**
**Нигъмәте кадрен белмәгәндиндер саңа**[3].

Шагыйрь теләге — ил, кеше бәхете. Алланы «кую»ны Мөхәммәдьяр михнәт дип атаса да, башкалардан теләү («үзгәләрдин теләдең») кебек юлларның асыл мәгънәсе әһәмиятле факт. Шул рәвешчә, Мөхәммәдьяр дини бәхеткә кизәнмичә генә дөньяви эшләргә өстенлек бирә. Аның поэмаларында әлеге характердагы фикерләр байтак:

**Бер сагат гадел кыйлмак яхшырак**
**Кем гыйбадәт алтмыш елдин озакрак. (84 бит.)**

Мөхәммәдьяр әсәрләре кеше җир өстендә бәхетле була ала һәм ул бәхетле булырга тиеш тә кебек уйлар белән сугарылган. Шулай да ул бәхетне махсус рәвештә карамый, бәхет турындагы уйларын, Әль-Фараби, Фейербах шикелле, төзек һәм тулы системага салмый. Шулай да поэмаларындагы аерым фикерләрдән чыгып та, аны бу мәсьәлә тирәнтен кызыксындырган дип әйтә алабыз.

Мөхәммәдьяр бәхетне кеше нуры, җан хозурлыгы һәм казаныш дип тә аңлата. Бәхетле кешене эче һәм тышы нур белән тулган җан иясе кебек сурәтли. Урыны

---

[1] Мөхәммәдьярның иҗаты һәм тормыш юлы белән түбәндәге китап аша танышырга мөмкин: Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар. Казан, 1966. (Кереш сүз авторы Ш. Абилов).

[2] Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар. Казан, 1966, 27 бит.

[3] Шунда ук, 51 бит.

белән, Демокрит кебек, бәхетне хозурлык («сафа») белән билгели: «Ул сафа берлә сәгадәт табылыр». Ул әледән-әле бәхет тойгысын тормыштагы казаныш яисә уңышка ирешүгә тиңли. Татар гуманисты, принципта, һәр кеше бәхет иясе була ала дигән гуманистик позициядә тора. Аның бу карашы кешеләр тигез хокуклы («Барлык җан ияләре, һәммәләре бертигез») дигән фәлсәфи концепциягә таянган.

**«Олугъ мән» димә, олугдыр — яраткан,**
**Җәмгъ мәхлук ирермез җөмлә йөксан. [33 бит.]**

Үзара тигезлек («йөксан») кешенең табигатеннән килә. Кешенең асылы игелекле, кадерләүгә лаеклы («шәриф») һәм зирәк («зариф»), ди Мөхәммәдьяр:

**Адәми худ пакь ирер, аслы шәриф,**
**Ата-анадин шәриф вә һәм зариф. [55 бит.]**

Шулай итеп, тигез хокуклылык кеше бәхетенең беренче һәм гомуми шарты була, бәхетнең потенциаль мөмкинлеге булып чыга. Бәхетнең икенче шарты — кешенең акылы һәм зирәк булуы. Аң кешене табигатьтә булган бөтен нәрсәләрдән дә өстен итә, кешегә дөньяда бәхетле булырга мөмкинлек тудыра. Кеше үз кадерен күтәрү, бәхет табу өчен акыл белән эш итеп, үзенең холкын яхшыртырга, Мөхәммәдьярча әйткәндә, «күңел сирәтләрен», ягъни сыйфатларын, камилләштерергә тиеш. Күренә ки, Мөхәммәдьяр кешенең җанында «акыл» белән «күңел»не аера һәм акылны җитәкче көч итеп күрсәтә, ә күңелне кешенең, кешеләр арасында булган мөнәсәбәтләрнең сыйфаты дип аңлый. Шагыйрьнең күңелне җанның «практик» ягы, яисә акылның кеше мөнәсәбәтләренә тәэсире буларак тануы да сизелә. Шуңа күрәдер, ул күңелгә шактый күп игътибар бирә, аны кешенең асылы, «төше» дип атый:

**Бу тыш сурәт, гарифләр пуст атарлар,**
**Күңел сирәтенә мәгыз атарлар. [34 бит.]**

Ягъни, тышкы сурәткә күп игътибар ителмичә, (чөнки тыш — кабык («пуст») кына) кешегә аның төше («мәгыз») — күңел сыйфатлары ягыннан бәя бирелергә тиеш. Күңел сыйфатларын кеше асылы дип аңлагач, әлбәттә, кешене бәхетле итү өчен, аның күңелен үзгәртергә кирәк. Яхшы сыйфатлар үзләштерүне ул кешене, аның күңелен камилләштерүгә тиңләп чыга һәм шуңа күрә һәр кешене шундый сыйфатларга ия булырга чакыра. Мәсәлән, оялчанлык («хәйа») — «чын» сыйфатларның берсе, күңелне камилләштерә торган сыйфат:

**Кем хәйа берлә бизәнер күңле чын. [95 бит.]**

Кешене камилләштерүнең Мөхәммәдьяр тәкъдим иткән ысулы, әлбәттә, фәлсәфә тарихында өр-яңа һәм билгесез ысул түгел. Платон да акыллылык, батырлык, чама белү, гаделлелек — кешенең яхшылыгы, камиллеге, шуңа күрә алар кешеләргә иң кирәк булган сыйфатлар дип санаган. Ә Кампанелла, Мөхәммәдьярдан соңрак (Кампанелла 1639 елга кадәр яшәгән), үзенең «Кояш шәһәре» дигән әсәрендә әхлак кешенең тормышында, бөтен галәмдә җитәкчелек итә дигән. һәм куәт, акыллылык, мәхәббәт сыйфатларын өстен санап, шул система буенча идарә ителүче дәүләтне идеал итеп күргән. Әмма Мөхәммәдьяр кешене камилләштерүгә конкретрак килә. Аның өчен бу мәсьәлә турыдан-туры күңел белән бәйләнгән. Кешенең 10 төрле «чын күңел сыйфатын» аерып, аларның өстенлеген исбатлый һәм шул яхшы сыйфатлар бәхет һәм байлык китерә дигән фикерләр әйтә:

**Тыңлаңыз имди сәхавәт сүзләрен,**
**Таки күргәйсез сәгадәт йөзләрен. [91 бит.]**

Бәхет («сәгадәт») йөзен күрү өчен юмартлык («сәхавәт») турындагы аңлатманы тыңлагыз һәм юмарт булыгыз — бу Мөхәммәдьярның бәхет кагыйдәләренең берсе. Әлеге өзектә әйтелгәнчә, яхшы сыйфатларның берсе — юмартлык. Юмартлыктан тыш тагы рәхим-шәфкатьлелекне, оялчанлыкны, батырлыкны, сабырлыкны, вәгъдәдә торучанлыкны, тугрылыкны, кичерүчәнлекне һәм аз сүзле булуны чын сыйфатлар исемлегенә кертә Мөхәммәдьяр. Ә «барча эш башы», кешедәге иң кыйммәтле сыйфат — гаделлек.

**Гадел берлә ил камуг булыр әман,**
**Калмаз илдә фетнә вә золым һаман...**
**Гадел берлә ил гыймарәт булыр уш,**
**Барча эшләр табар аның берлә хуш.**
**Гадел булыр барча эш башы, белең,**
**Гадел берлә дәимән бәс эш кыйлың. (84—85 бит.)**

Мөхәммәдьяр бәхетне кешеләр арасындагы «акыллы» һәм яхшы сыйфатлы мөнәсәбәтләр җирлегендә туа дип саный. Бәхет — уңай сыйфатларның дәвамы. Мәсьәлә бу сыйфатларны үзләштерүдә генә.

Инде яхшы сыйфатларны үзләштерү мәсьәләсенә килик. Демократик һәм Сократ аңлатуынча, кешенең яхшылыгы турыдан-туры аның акылына бәйле. Шулай булгач, рухи күркәмлелек яхшылыкның кыйммәтен **аңлаганнан,** яхшылыкның өстенлеген **белгәннән** килә[1]. Бу концепция бүгенге көнгә кадәр яшәп килә һәм элек-электән кайбер фикер ияләрендә ризасызлык та тудыра. Мәсәлән, Аристотель (безнең эрага кадәр IV гасыр) үз вакытында ук «белемнең исә яхшылык өчен кирәге бик аз яисә бөтенләй кирәге юк...»[2] дигән. Яхшы сыйфатларның барлыкка килүен соңгы концепция вәкилләре кешедәге гадәтләрдән күрәләр.

Мөхәммәдьяр әлеге карашларның беренчесен яклый. Ул, яхшы сыйфатларны үзләштерү өчен, аларның мәгънәсенә төшенү кирәк дип исәпли. Акыл, җитәкче көч буларак, күңелне камилләштерә. Ул, беренчедән, күңелне начарлыктан, явызлыктан («гал») һәм алдаудан («гаш») сафландыра («пакь кыйлу»): «гакыйль улдыр... күңлене галлу-гашдин пакь кыйлса». Икенчедән, күңелне, димәк, кешенең үзен дә — яхшы сыйфатлар белән баета. Шуңа күрә Мөхәммәдьярның поэмалары үгет-нәсихәт формасында һәм ул аларны яхшылык турындагы белемне кешенең аңына, акылына җиткерү максатыннан чыгып яза:

**Бел: соңыны бакмаен эш иткәннәр,—**
**Наданлыкдин үз башына йиткәннәр. (62 бит.)**

Югарыда китерелгән гаделлек аңлатмасын («бәян») гына алыйк. Автор анда гаделлекне илне имин итү («әман»), илдә фетнә һәм хаксызлыкны («фетнә вә золым») бетерүгә бәйли. Гадел булу уңышка китерә дип, һәр вакыт гаделлек белән эш итәргә чакыра. Ул игелеклелек үзенә әйләнеп кайтыр дип аңлата әсәрләрендә. Характерлы бер мисал:

**Иртә-кәчә һәркем ул кыйлса аны (яхшылыкны — Р. Ш.),**
**Әсигъ итәр үзенгә ул кыйлганы. (84 бит.)**

Ә файдалы нәрсәләрнең берсе булып бәхет («сәгадәт») тора:

**Бәс вафа берлә сафа хасыйл булыр,**
**Ул сафа берлә сәгадәт табылыр. (107 бит.)**

Мөхәммәдьяр игелеклелек һәм яхшылык эшләү сыйфатларын җиңел генә үзләштереп булмаганлыкны аңлый. Күңелдәге матур сыйфатларны олы байлык саный, бер һөнәргә тиңли. Мәсәлән, сүздә тору («вафа»)— дөньяда үзе бер һөнәр, сүздә торган кеше — хөрмәтле («мөгътәбәр») була.

**Бел, вафа ирер җиһан эчрә һөнәр,**
**Кем вафа берлә булыр ир мөгътәбәр. (106 бит.)**

Һөнәр белән чагыштыру Мөхәммәдьярның яхшылык сыйфатларын үзләштерү мәсьәләсен белемгә генә түгел, бәлки гадәткә дә бәйле рәвештә чишүен күрсәтә.

Шулай итеп, Мөхәммәдьярча, кеше бәхеткә ирешә ала. Бәхетле булу өчен ул үз-үзен өзлексез камилләштерергә, яхшы сыйфатларны үзләштерергә, җәмгыять һәм

---

[1] Бу караштa торучылардан берсе француз материалисты Гольбах (XVIII гасыр): «Кешеләр бары тик үз ихтыяҗларын белмәгәнгә генә начарлар... алар яхшылыкның җәлеп итүчәнлеген, хәтта еш кына әлеге яхшылыкның нәрсәләрдән гыйбарәт булуын да белмиләр»,— дигән. (Гольбах П. А. Избранные произведения. М., 1963, 2 том, 99 бит.)

[2] Аристотель. Этика. СП-б., 1908, 28 бит.

кешеләргә игелек күрсәтергә тиеш. Үзләштерелгән яхшылык бәхетнең соңгы һәм иң әһәмиятле шарты булып чыга.

Үзләштерелгән яхшылыкның тәэсире шактый көчле, чөнки ул үзе дә икенче кешеләр өчен бәхет шартлары тудыра:

**Кем аның берлә ярыр бу җисми җан. (106 бит.)**

Ягъни бәхетле, «сафа күңелле» кеше кайгылы, ташка әверелгән җанлы («җисми җан») кешене дә үзгәртә ала. Мөхәммәдьяр фикеренчә, бәхетнең иҗтимагый шартларын беренче булып хакимнәр булдырырга тиеш.

Шул фикергә таянып, Мөхәммәдьяр патшаларга киңәшләр бирә. Аларга үзе басым ясап күрсәткән яхшылыклар нигезендә идарә итү кирәклеген аңлата. Патшага «үзеңә ни...— үзгәгә аны сакын, йыглатып (сән) йимә үксезнең хакын», ягъни, үзеңә ни теләсәң, башкага шуны телә, дип гади халык мәнфәгатен яклый.

Мөхәммәдьярның бу идеяләре, әлбәттә, чагыштырмача беркатлы. Чөнки бәхеткә түбән катлау кешеләре революцион юлга басып кына ирешә алалар. Шулай да шагыйрьнең фикерләре әһәмиятле, алар аның гади халык ягында торуын һәм үз кулында булган чара белән киң массалар омтылышын яклап көрәшүен исбат итәләр.

Гомумән, Мөхәммәдьярның гуманизмы абстрактлы һәм утопияле. Аның бәхетне аңлавыннан да ачык күренә бу. Чөнки ул бәхетне кешенең акылы һәм күңел сыйфатлары белән генә бәйли һәм кешене камилләштерүне аерым аң эчендәге мәсьәлә дип карый. Ләкин кеше иҗтимагый нәрсә һәм һәрбер кешене камилләштерү, бәхетле итү өчен башта җәмгыятьне, иҗтимагый мөнәсәбәтләрне революцион рәвештә үзгәртергә кирәк. Аерым кешенең бәхете — ул гомуми «җәмгыять бәхете» нәтиҗәсе, ә Мөхәммәдьяр, киресенчә, ил бәхетен шәхес бәхете тудыра дип күрсәтә.

Бер үк вакытта Мөхәммәдьяр кешенең камилләшүен үзгәрмәүчән әхлакый мәсьәлә дип белә. Әмма әхлак — җәмгыять үсешенә бәйле рәвештә үзгәрүчән категория, һәм социаль революция нәтиҗәсендә генә халык төрле бәхетсезлекләрдән арынып, үзендә җәмгыятьнең яңа нигезен төзерлек көч һәм дәрт таплый.

Зиннур Мансуров

# ЙӨРӘК УЙЛЫЙ ДА БЕЛСЕН

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...
*Акмулла...*
Бер гәрәп бер китапка карады да әйтте:
«Монда хикмәт йолдызлары икән», — диде.

*К. Насыйриның «Фәвакиһел җөләса» әсәреннән*

**Фикер поэзиясе...** Әле кайчан гына бу сүзләр татар әдәби тәнкыйтендә куштырнаклар эчендә, ягъни шартлы һәм схематик мәгънәдә йөртелә иде. Бу — бәлки поэтик кыйммәтләргә иҗтимагый бәя биреп җиткермәү, төшенчәнең матди асылын тулысынча күзалламау, «шигърият агачы»ның эчке хасиятләре белән бер-берсеннән шактый үзгә булган тармакларга аерылуын күрергә теләмәү нәтиҗәседер. Җисеме булгач, исеме дә булырга тиеш ләбаса! Югыйсә, бу төшенчә, әйтик, рус тәнкыйтьчеләре телендә тулы хокукында яши, һәм фикер поэзиясе, әдәби күренеш буларак, инде күптәннән өйрәнелә. Шулай да соңгы елларда без фикер поэзиясе төшенчәсен курыкмыйчарак, «авыз тутырып» әйтә башладык шикелле. Бу — табигый, чөнки татар шигърияте тарихында мәгълүм **циклик үсеш** кичергән фикер поэзиясе хәзер чын мәгънәсендә югары баскычка күтәрелде.

«Поэзиядә хәзер уйланучылар күбәйде, — дип язды шагыйрь Сибгат Хәким, — тыныч юл белән шигырь язып яшәүчеләргә торган саен кыенрак булыр, аларны әкренләп чын талантлар кысрыклап чыгарыр — бу минем күптәнге хыялым; мин аның тормышка ашарына хәзер бик нык ышанам. Чөнки яшь поэзиянең өметле вәкилләрен күреп торам...»

Өлкән шагыйрь татар совет поэзиясен интеллектуаль баетуда, фикер поэзиясен, ниһаять, үзбашка, тулысынча мөстәкыйль яшәтә башлауда, аның «суверенлыгын» яулауда, шигъри сүзне эчтәлек һәм форма ягыннан кристаллаштыра баруда үзләреннән сизелерлек өлеш кертүче яшь иҗатчылар итеп кемнәрне күз алдында тота соң?

Алтмышынчы еллар уртасында татар поэзиясенә көчле интеллектуаль агым булып бер төркем яшь шагыйрьләр килде. Башкорт халык шагыйре Мостай Кәрим бик төгәл билгеләп үткәнчә, татар милли поэзиясендәге «шартлау»ның икенчесе (бе-

ренчесе — 20 нче еллар уртасында) нәкъ менә шушы чорга туры килә. Әлеге иҗтимагый-рухи күренешләрнең беренчесе поэзиядә форма яңаруын, яңа эстетик нормалар, сурәтләү чаралары арсеналының киңәюен барлыкка китерсә, икенчесе үзенең характеры белән фикер поэзиясен югары баскычка күтәрергә ярдәм итте. **Шигырь материясендә фикерне табигый рәвештә яшәтү**, аны поэзиянең төп нотасына, чын мәгънәсендә танып-белү коралына әверелдерү — интеллектуаль лирага ия булырга омтылучы бер төркем шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим һ. б. лар поэзиягә нәкъ менә шундый олы максат белән килделәр.

Хәлбуки, фикер поэзиясенең хуҗаларча мәйданга чыгуы иҗтимагый яшәеш диалектикасы кануннары нигезендә барлыкка килгән әдәби күренеш ул. Нык үскән социализм чорында иҗтимагый тормышта гаять тирән һәм киң колачлы социаль үзгәрешләр бара. Табигый, поэзия дә шаулы гасыр идеяләре, халыкның фән-техника революциясе тәэсирендә һаман саен катлаулана барган уй-фикерләре белән яшәргә омтыла, иҗтимагый акыл хәзинәсен тагын да тирәнрәк үзләштерү формаларын эзли. Күренекле литва шагыйре Эдуардас Межелайтис сүзләре белән әйткәндә, «... исән калыр өчен поэзия һаман катмарлана бара, «акыллырак», фәлсәфирәк була бара... Берни дә эшли алмыйсың, чоры шундый».

Яшәвебездәге рухи үсеш нәтиҗәсе буларак, поэзиянең укучы аңындагы урыны да сизелерлек үзгәрде. Әдәби-эстетик зәвыгы нечкә, дөньяга карашы киң булган заман укучысын «җиңел музыка» кебек кабул ителә торган «җиңел поэзия» генә канәгатьләндерми. Шагыйрь Р. Фәйзуллин сүзләренә кушылмыйча мөмкин түгел: хәзер фикергә сусау артты. Югары эстетик хәзерлекле һәм поэзияне кабул итүдә индивидуаль сыйфатка ия укучы хис-эмоциясен генә түгел, ә акылын да бар куәтенә эшкә җигә. «Казан утлары» журналы редакциясенә «Бүгенге поэзия турында сөйләшү» уңаеннан килгән хатларда «... фәлсәфи шигырьләр күбрәк ошый миңа» (А. Әлмиев. Зеленодольск районы), яки «тирән мәгънәле... Уйлата торган шигырьләр кирәк» (Р. Сәлимуллин. Азнакай районы) дигән ихтыяҗ һәм таләпләр белдерелү дә шигъри әсәрләрнең фикри кыйммәтенә игътибар көчәюе турында сөйли. Укучы заман шагыйрьләренә менә нинди «ультиматум» белән мөрәҗәгать итә! Ә китап кибете киштәләрендә югары интеллектка ия шагыйрь әсәрләренең «тузан җыеп» ятканын күргәнегез бармы? Юк, алар, комга сеңгән су шикелле, дөньяга чыгу белән үк адресларын таба баралар.

Бу җәһәттән әдәбият галиме Ибраһим Нуруллинның «Ни өчендер соңгы вакытларда... һәрбер шагыйрь... үзенең уй-фикер хәзинәсен укучыга тагарга тырыша» дигән нәтиҗәгә килүен берьяклы гына күзәтү дип әйтәсе килә. Чөнки поэзиянең «акыллылануы» — заман таләбе, әдәби хәрәкәттәге циклик үсеш нәтиҗәсе ул. Фикер поэзиясе, салон поэзиясе кебек, үтә камил акыл ияләренә генә адресланган яңа стиль категориясе дә түгел. Ә менә шагыйрьләрнең рухият хәзинәсендә игътибарга лаеклы «энҗеләр» чынлап та бармы? Минемчә, бу — мәсьәләнең икенче ягы. Сүз дәвамында бу сорауга җавап бирергә омтылыш ясалыр әле.

**Кумирларны искерәләр,**
**үзебезме**
**акыллыга әйләнәбез!!**
**Үзгәрәбез...**

Бу юлларның авторы Рәдиф Гатауллин. Чыннан да, кумирлар искерәләрме? Юк, алар туктаусыз акыллылана баручы шәкертләре канында яңаралар гына. Бүгенге фикер поэзиясе вәкилләре иҗатында да гасырлар буе дәвам иткән яңаруны күрмичә мөмкин түгел.

Фикер поэзиясе татар әдәбиятына каяндыр читтән «төбе-тамыры» белән күчереп утыртылган күренеш түгел. Ул үзенең тирәнгә киткән тамырлары белән Көнчыгыш һәм борынгы татар поэзиясе традицияләренә, Пушкин һәм Лермонтовлар аша рус шигъриятенә тоташа. Халкыбыз табигатенә хас хикмәтле сүз әйтү, үткен фикерлелек, чичәнлек — чишмә башы менә кайдан ук башлана! Фикер поэзиясенең беренче ярлагыларын Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Мәүлә Колый (ул үз әсәрләрен «Хик-

◆ БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ ◆

мәт» дип атаган), Габдрәхим Утыз-Имәни, Әбелмәних Каргали, Һибәтулла Салихов, Гали Чокрый, Габделҗаббар Кандалый, Акмулла иҗатларында үк инде бик ачык күрергә мөмкин. Әдәбият галиме Нил Юзиев билгеләп үткәнчә, «... хикмәтле сүз әйтүгә корылган шигырьләрне без Тукайда, Дәрдмәндтә, Гафурида еш очратабыз... Дәрдмәндтә чичәннәр традициясе — хикмәтле, фәлсәфи, үткен сүз әйтү көчле бер агым булып дәвам итә».

Билгеле булганча, шигъри фикер дөньясы танып-белү коралы ул. Фикер поэзиясенә менә нинди миссия йөкләтелгән һәм ул үзенең идея-эчтәлек диапазонын нәкъ шул юнәлештә киңәйтә бара. Без фикер поэзиясе үсешендәге әлеге тенденцияне «шигырьдә матур сүз уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде» дип белдергән Һади Такташ иҗатында да, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов, Нури Арсланов, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов һ. б. шагыйрьләрнең әсәрләрендә дә ачык тоябыз.

Бу уңайдан шуны әйтергә кирәк: татар әдәбиятында фикер поэзиясе иконче «шартлау»га кадәр шигъри әсәр эчендәге бер «автономия», ягъни **интеллектуаль элемент** буларак кына яшәде. Әйтик, егерменче һәм утызынчы еллар поэзиясендә — вакыйга һәм күренешне сөйләп бирүгә, илленче елларда салкын тасвирчылыкка нигезләнгән әсәрләр өстенлек алганда ул бөтенләй күмелеп калды. Табигый, бу «автономия» еллар үткән саен зурайганнан-зурая барды. Һәм, ниһаять, үзен өзлексез таныта баручы фикер поэзиясе алтмышынчы еллар уртасында җитлегүгә иреште, әгәр шулай әйтергә ярәса, аңа «акыл теше» чыкты.

Шагыйрьләр теләндә җор һәм шул ук вакытта кинаяле сүзләр яши: «Үзеңә шәкерт әзерләп калдыр, картаймыш көнеңдә сиңа кем акыл бирер?!» Уйландырырга мәҗбүр иткән бу киңәшне искә төшерүнең сәбәбе шул: «Ак шигырьләр, ирекле шигырьләр бармы?» дигән сорауга... аяк терәп, «бар!» дип җавап кайтарган (Р. Гатауллин) бер төркем яшь шагыйрьләрнең шигъри дебюты үзләреннән өлкәнрәк каләм ияләре иҗатына да күпмедер дәрәҗәдә интеллектуаль йогынты ясады. Дөрес, «остазларның тагын да акыллылануын» аларга гына сылтарга ярамый. Бу күренешнең төп сәбәбе — әлеге дә баягы, поэзиянең **халык акылы-зиһенен**, дөнья, яшәеш турындагы уйлануларны үз материясендә тагын да сәнгатьчәрәк итеп яшәтергә омтылу юнәлешендә үсә баруы.

Соңгы елларда «Дуга», «Кырыгынчы бүлмә», «Дәверләр капкасы» (Сибгат Хәким), «Тынлык белән сөйләшү», «Таш диварлар авазы» (Илдар Юзеев), «Һәйкәл» (Әхсән Баянов), «Таш аргамак» (Роберт Әхмәтҗанов) кебек чын мәгънәсендә интеллектуаль рухтагы поэмалар иҗат ителү генә дә татар совет поэзиясенең киң масштаблы фикерләүгә ия булуы, фәлсәфи гомумиләштерүнең кристаллаша баруы турында сөйләмимени?!

Асылынсаң асылын агачның асылына, ди халык. Шунысы игътибарга лаек: әле соңгы елларда гына үз тавышларын ишеттерә башлаган яшь шагыйрьләрнең дә шактые нәкъ менә фикер поэзиясе мәктәбендә өйрәнергә омтылалар. Ләкин бу шифалы йогынтыга бирелүне эпигонлык дип атамаска кирәк. Юк, шигъри сүздә акыллы булырга омтылучы яшьләр кемгәдер иярергә тырышып түгел, ә фикер поэзиясенең нигез ташын тәшкил иткән төп эстетик принципларга таянып иҗат итәргә омтылалар.

Соңгы вакытта эпигонлык термины фикер поэзиясе принциплары нигезендә эзләнүче, яисә ак һәм ирекле шигырьләр язарга омтылучы яшьләргә карата аеруча еш кулланыла башлады шикелле. Әмма бу мөһер күп очракта иҗат асылына төшенмичә, аның «тышкы күлмәгенә» карап кына сугыла. Тавыкка — барысы да тары, дигәндәй, кайберәүләр «гадәттәгечә» язмаган шагыйрьләрне бик тиз, күреп алалар (чөнки алар чагыштырмача азрак бит) һәм аларны, әйтик, Вознесенскийга яки Фәйзуллинга ияргә гаепләргә ашыгалар. Бу уңайдан табигый рәвештә бер сорау туа: ә «мөгез чыгармыйча» гына иҗат итүчеләр арасында эпигоннар юкмыни соң?

«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясе оештырган «Түгәрәк өстәл артында сөйләшү»ләрнең берсендә (1978 ел, август) яшь шагыйрь Роберт Миңнуллин, интеллектуаль сүз әйтергә омтылучы яшьләрне «предметсыз» әсәрләр язуда гаепләп, болай дигән иде: «Аларның шигырьләрен укыганнан соң иягенә таянып утыручы, ак

сакаллы акыл иясе ролендә утыручы малай күз алдына килә». Бәлки бу сүзләрдә күпмедер дәрәҗәдә хаклык та бардыр. Һәрхәлдә, яшь шагыйрьләрне мондый эзләнүләрдән һич тә тыярга ярамый! Киресенчә, алар шагыйрь Илдар Юзеев тарафыннан Робертның үзенә үк бирелгән киңәшне тотсыннар: «... Фәлсәфи уйланулар юнәлешендә күбрәк эшләргә кирәк». Акыл яшьтә түгел — башта, дип раслый мәкаль. Без, яшьләргә, Лев Толстойның Казан университетында укыган чакта көндәлегенә язып куйган «тормыш кагыйдәсе»н үзебезгә төп девиз итеп алу сорала. **«Үз акылыңны мөмкин булган бар көче белән бертуктаусыз эшләргә мәҗбүр ит».**

Кызганычка каршы, кайчак әдәби тәнкыйтьтә дә эстетик кыйммәтләргә объектив бәя биреп җиткермәү сизелә. Рус совет шагыйре Евгений Винокуров фикеренә кушылып әйткәндә, кайчак шул күңелне тырный: тәнкыйть тасвирый юл артыннан куyга, оекбаш кебек «размерсыз» шигырьләргә ташланасы урынга, теге яки бу яшь авторның үзенчәлекле булырга омтылуына сукрана. Мондый тенденция, аерым алганда, 1965—1966 елларда «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә «Тукай, Җәлил традицияләре һәм хәзерге татар поэзиясе» дигән исем астында барган дискуссиядәге кайбер чыгышларда да чагылыш тапты. Шунысы аяныч: без кайчакта **заманның әхлакый һәм идея ихтыяҗлары** тудырган яңа эстетик нормаларның яшәүчәнлеген тиешенчә кузалламыйбыз.

Сынлы сәнгать осталарыннан еш кына «изге һәм серле палитра» дигән сүзләрне ишетергә мөмкин. Палитрада художникның дөньяга карашын, сәнгать телендә үзенчәлекле фикер йөртүен чагылдырган, кыскасы, иҗатчының җанын кешеләргә аңлаешлы телгә күчерергә ярдәм итүче төсләр чагыштырмасы яшеренгән. Асылы белән бик үк охшаш булмаса да, поэзиядә дә шундыйрак серле төшенчә яши. Ул — **фикер һәм хис гармониясе.** Шагыйрьләрнең кайбер фикри һәм хисси үзенчәлекләрен шушы «лакмус» белән дә билгеләргә мөмкин.

Белгәнебезчә, поэзия — асылда хис белән җылытылган фикерне гәүдәләндерүнең үзенчәлекле формасы ул. Бу җәһәттән сорау туарга мөмкин: шигъри әсәрдә фикер һәм хис чагыштырмасы нинди булырга тиеш? Билгеле, аның төгәл рецептын ачыклау бик кыен һәм ул мөмкин дә түгелдер. Сибгат Хәкимнең фикер поэзиясе шагыйрьләрен күз алдында тотып әйткән мондый сүзләре бар: фәлсәфи рухтагыларның да кайсы күбрәк фикер белән, кайсы күбрәк хис белән эш итә. Бу — чыннан да, шулай. Мәсәлән, Ренат Харис әсәрләре тукымасында фикер җебе «күзгә бәрелеброк» тора, ягъни шагыйрь фикер белән күбрәк эш итә, фикерне алгырак планга чыгара. Ул философик карашының үткенлеге, поэтик материалның «үзәгенә үтеп керә» алуы белән башка шагыйрьләрдән аерылып тора. Рус шагыйре Евгений Винокуровның «Минем өчен поэзия — барыннан да элек фикер ул», — дигән сүзләре астына, минемчә, Ренат Харис та кул куяр иде кебек. Чөнки аның әсәрләрендә поэтик фикернең калку итеп бирелүе шулай уйларга җирлек бирә.

Шагыйрь Ренат Харис иҗаты белән якыннанрак танышып, аның асылына төшенә барган саен авторның ассоциатив фикерләүдә акылга өстенлек бирүен табигый үзенчәлек буларак кабул итәсе килә башлый. Шагыйрьләр «яхшы һәм төрле» булсын, дибез. Ә «төрлелек»не күпмедер дәрәҗәдә фикер һәм хис белән эш итүдәге үзенчәлек тә билгели түгелме соң?

Һәр чагыштыру аксый, ди немец мәкале. Шулай да Ренат Харисны шигъри реквизитындагы кайбер сыйфатлары, төгәлрәк әйткәндә, метафоралар сафлыгы, гадәти булмаган образлылыгы, афористик яңгырашлылыгы, фикер сөрешендәге парадоксальлеге, хәтта шигъри рәссамлыгы белән рус совет шагыйре Андрей Вознесенскийга охшатырга мөмкин кебек (алар икесе дә гомерләренең мәгълүм бер вакытында сынлы сәнгать белән мавыкканнар). Һәм аны «шәрә фикерлелектә», «иртәгәге укучылар» өчен язуда гаепләүче кайбер «агрессив» тәнкыйтьчеләргә һәм бер даирә шигырь сөючеләргә шундый сорау бирү теләге туа: ә нигә А. Вознесенский рус совет поэзиясендә, В. Маяковский, А. Блок, В. Хлебников, Б. Пастернак кебек үк, вакыйга буларак кабул ителә соң?

Бүгенге заман татар поэзиясендә дә вакыйга буларак кабул итәрлек шигъри язмышлар бар. Тик без аларны вакытында күреп ала белмибез. Югыйсә, мондый ачышлар ясау, талант «айсбергы»ның су эчендәге өлешен дә күрә белү әдәби тәнкыйтьнең иң изге вазифаларыннан санала бит.

Кемдер шигырьне динамит шартлавы белән чагыштыра, ә аны домна януына да охшатып була. Шигырь яна! «Хис — үкерә, үкси, фикер — чарт-чорт!» Бу «мич»не һәрбер шагыйрь үзенчә яга, әйткәнебезчә, **фикер белән хисне төрлечә синтезлаштыра**, төрлечә пропорцияли.

Шагыйрь Рәдиф Гатауллин шигырьләре җирлегенең төп тонын, әйтик, романтик кайнарлыктагы фикер билгели. Аның идеалы, рус шагыйре Николай Языковтагыча (1803—1846), «йөрәк бәйрәме» булып яңгырый. Шагыйрь лирасының нәкъ менә шушы шат авазлылыгын һәм эмоциональлеген игътибар үзәгенә алып, Әхсән Баянов аның әсәрләрендәге фикер һәм хис гармониясе үзенчәлеген бик ачык итеп күрсәткән: «Рәдифнең иң яхшы шигырьләрендә фикер халыкча туры, афористик рәвештә әйтелсә дә, ул — тойгылы фикер. Ул — риторика түгел, чөнки анда конкрет хис ята».

Әдәби тәнкыйтьтә (ташка язылмаган булса да) бер кызыклы кагыйдә бар: «көчле тавышка ия» шагыйрьләр «новатор» да һәм шул ук вакытта «интеллектуаль» дә була. Әлеге поэтик разрядларга шагыйрь Равил Фәйзуллин да туры килә, һәм алай гына да түгел, ул үз иҗаты белән татар поэзиясендәге интеллектуаль «шартлау»ның үзәген тәшкил иткән шагыйрь. Бу фикерне хәзер шикләнмичә әйтергә мөмкин. «...Фикер тирәнлеге һәм шул фикерне укучыга җиткерүгә хезмәт итә торган үтемле поэтик чаралар эзләү һәм табу»да (И. Нуруллин) һәм, гомумән, фикер поэзиясенең эстетик нормаларын хакыйкать дәрәҗәсенә күтәрүдә аның беренчеләрдән булуын әдәби җәмәгатьчелек таныды инде. Үз тавышларын алтмышынчы еллар уртасында яңгырата башлаган интеллектуаль «ансамбль»дә Равил Фәйзуллин башлап җырлаучы булды һәм шагыйрь «лидерлык»ны бүген дә үз кулында тота. Аның иң яхшы шигырьләре нигезен кешелек һәм дөнья турындагы тирән һәм киң колачлы уй-фикерләр, халык җаны белән органик рәвештә тоташкан кичерешләр тәшкил итә. Шагыйрь халык акылы белән фикер йөртә:

**Тир тәмен тойган халыктан**
**хикмәтле сүзләр сөзәм,**
**күңелемдә кайнатам да**
**аларга тылсым өрәм...**

Шунысы игътибарга лаек: Равил Фәйзуллин киеренке үсештәге фикерне үз шигърияте җирлегендә табигый рәвештә яшәтә ала. Аның интеллектуальлеген философик трактатка хас салкын акыл түгел, ә йөрәк каны белән җылытылган, **матди һәм милли җирлеге булган фикер** билгели. Шагыйрь «шундый чама белү сәләтбәхетенә ия: аның әсәрләрендә фикер «кысып тутырылган» метафора һәм чагыштырулар белән томалап калдырылмый, тончыктырылмый» (М. Кәрим). Ул хакыйкать критерие — фикерне чын мәгънәсендә **«уйлый белүче» йөрәк** белән үзләштерергә омтыла. Бу уңайдан аның үз-үзе һәм каләмдәшләре алдына куйган таләбе дә катгый яңгырый: «Шигырь иң әүвәл хис аша акылга тәэсир итәргә тиеш... Халыкның гасырлар буенча яшь белән юылып, моң һәм акыл белән өртелеп килгән күңел авазы һәм ритмына сизгеррәк булырга...»

Интеллектуаль агым татар поэзиясен нинди сыйфатлар белән баетты соң? Табигый, яңа эстетик нормалар таләбе буенча поэзиянең, иң беренче чиратта, **фикерләү һәм гомумиләштерү масштабы** күзгә күренеп киңәйде. Бу тенденция үз чиратында поэтик чаралар арсеналына да үз төзәтмәләрен кертте. Ассоциатив фикерләүнең яңа формалары поэзиядәге тасвирчылыкны һәм натурализм элементларын, күп сүзлелекне, урынлы булмаган һәм очраклы образларны кысрыклап чыгарды. Поэзиянең шигъри күзәнәкләре тыгызланды, ә мәгънә сыйдырышлылыгы зурайды һәм ул философик гомумиләштерүне кристалл дәрәҗәсенә җиткерүгә иреште.

Фикер поэзиясе торган саен зур күләмле жанрларны, әйтик, поэманы да үзенең эстетик принципларына буйсындыра башлады. Мәсәлән, Равил Фәйзуллинның «Көрәшчеләр», «Гадиләргә гимн», Ренат Харисның «Рәссам», Рөстәм Мингалимовнең «Минем дәүләтем» исемле поэмалары яңа эстетик нормаларның гәүдәләнеше булып торалар. Бу әсәрләрне, һич икеләнмичә, фикер поэзиясенең яхшы үрнәкләре исәбенә кер-

тергә мөмкин һәм алар, әйтик, Андрей Вознесенскийның «Остазлар», Олжас Сөләйманoвның «Җир, кешегә табын!», Тасос Ливадитисның «Өч миллиард тавыш өчен кантата», Иржи Тауферның «Тема — хәтер» поэмалары кебек үк иҗтимагый-социаль идея белән сугарылган интеллектуаль диалог буларак кабул ителә.

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәктер: әдәбиятчылар арасында әлеге типтагы күләмле әсәрләрнең поэма булу-булмавына шикләнебрәк караучылар да бар. Дөрес, мондый тезмә әсәрләрне «шигырь формасы белән хикәяләп бирү» үзенчәлеген саклаучы классик билгеләмә калыбына берничек тә сыйдырып булмый. Әмма Вакыт кайчак фикерләрнең фикерен кристаллаштырган мәкальләргә дә төзәтмә кертә. Хәлбуки, поэма формасы да әдәбиятның күп гасырлык тарихы дәвамында сизелерлек үзгәреш кичерде һәм менә шуңа күрә ул тора-бара үзенең тотрыклылыгын югалтты. Мәсәлән, рус совет поэмасының тамырдан яңарыш кичерүе, белгәнебезчә, Владимир Маяковский иҗатыннан башлана. Татар поэзиясендәге мондый төр әсәрләрне дә «Нәрсә бу?» дип түгел, **ә жанр яңарышының бер казанышы** буларак кабул итәргә кирәктер. Аннары бу күренеш «татарныкы» гына түгел бит, мондый яңа формалар башка әдәбиятлар өчен дә хас.

Поэзия — мәңге ачылып бетмәслек серле дөнья. Анда яңадан-яңа күренешләр әледән-әле туып тора. Әйтик, танылган латыш шагыйре Имант Зиедонисның яшәеш, шәхеснең җәмгыятьтәге мораль-этик нормалары, кешенең кешелек алдындагы җаваплылыгы турындагы философик уйлануларны гәүдәләндергән «эпифания»ләрен яки шул ук Андрей Вознесенскийның «изоп» ларын, ягъни рәсем-шигырьләрен нинди жанрга кертергә? Яңа типтагы поэма яки әлеге «исемсез хисләр» турындагы бәхәсләрне, минемчә, аларның жанрын билгеләү максаты белән генә түгел, ә яңа форманың эстетик кыйммәтләрен, интеллектуаль сүзне шигърият сөючеләр күңеленә ирештерүгә хезмәт итүдәге потенциаль өстенлекләрен фикер поэзиясе принципларына таянып ачыклау юнәлешендә алып барырга кирәктер.

**Фикер,** сиңа ничек итеп шигъри яшәш бирергә?

Кулына ак кәгазь һәм каләм алгач, һәр шагыйрь эчке аваз белән әнә шундый сорауны кабатлый дип әйтергә җыену түгел бу. Ә менә шигырьгә чын мәгънәсендә шигъри җан өрергә омтылучы шагыйрь аңлы яки интуитив рәвештә шушы омтылыш белән эзләнергә һәм эзләнергә тиеш. Югыйсә, «акыл җимеше»нең кеше хиссиятенә берниндидә тәэсир ясамаучы силлогизм гына булып калуы бик ихтимал. Поэзия бакчасында фикер һәм хис дисгармониясе, фикернең матди җирлектән аерылуы, абстракт булып калуы нәтиҗәсендә эстетик кыйммәткә әверелә алмаган әсәрләр юкмыни? Кызганычка каршы, укучы аңында, әйтик, математик гамәлләр кебек үк, **ассоциацияләрсез** генә фикри хәрәкәт барлыкка китерүче әсәрләр очраштыргалап куя әле. Ничек кенә сәер яңгырамасын, «философия ташы» шигырьне кайчак «батыра» да. Әдәби тәнкыйтьтә һәм бер катлам укучылар телендә кайбер шигырьләрнең шартлы рәвештә «аңлаешсыз» дип йөртелүен дә, минемчә, шигъри фикернең табигый яшәешкә ирешмәве нәтиҗәсе итеп аңлатырга кирәктер.

Бүгенге поэзиягә кагылышлы кайбер күзәтү һәм уйлануларны чагылдырган бу язма «академик» нәтиҗәләр ясамыйча гына тәмамлана. Беренчедән, бәхәс һәм сөйләшү — асылда теге яки бу мәсьәләгә карата уй-фикерләр белән уртаклашу, аларны уртага салу дигән сүз бит ул. Ә гомуми нәтиҗә Вакыт белән бергәләп ясала. Икенчедән, мондый сөйләшүләр барышында, гадәттә, полемик характердагы фикерләр дә әйтелә һәм алар бу күзәтүләрдә дә бардыр дип уйлыйм. Әгәр шулай икән, ниндидер нәтиҗә ясарга иртәрәктер әле. Шулай да бер тенденцияне күрмичә мөмкин түгел: татар поэзиясе соңгы елларда дөньяны шагыйранә танып-белү коралы — фикергә аеруча ныграк таяна башлады.

# УКУЧЫЛАРДАН ХАТЛАР

*Поэзия турында сөйләшү уңаена укучыларыбыздан хатлар килү дәвам итә. Шулардан кайбер өзекләр тәкъдим итәбез.*

*РЕДАКЦИЯДӘН.*

ХӨРМӘТЛЕ РЕДАКЦИЯ

Байтак еллардан бирле инде мин «Казан утлары»н укып барам. Журналның һәр санын кулга алу белән, барыннан да элек, андагы тәнкыйть мәкаләләрен актара башлыйм. Нидән бу шулай? Бәлки Белинскийга, Добролюбовка булган ихтирамым бүгенге тәнкыйтьчеләргә дә күчәдер? Һәрхәлдә, әдәбиятка җитди эш дип карыйм һәм әдәбият галимнәренең хезмәтен хөрмәт итәм. Чыннан да, әдәбият дөньясында уңны сулдан, акны карадан аерырга кем безне өйрәтә? Әнә шул тәнкыйтьче дигән остазлар инде.

Минем аңлавымча, шагыйрь Равил иптәш Фәйзуллин тәнкыйтьне бик үк өнәп бетерми икән. Мәсәлән: «Кызык, нинди тәнкыйтьчеләрнең нинди шагыйрьләргә конкрет ярдәме турында сез нинди исемнәр китереп әйтә алырсыз икән?» — ди ул. Шулаймы соң? Безнең белүебезчә, бөек Тукайга телдәге чуп-чарлардан арынырга, ә Такташка символизм чиреннән котылырга нәкъ әнә шул тәнкыйтьнең ярдәме тигән дә инде.

Шагыйрь Равил Фәйзуллин иптәш моның белән генә дә тукталып калмый. «Мин үзем бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләренең фикри ярлылыкларына хәйран калам», — ди. Монысы инде һичнинди рамкага да сыймый торган сүз! Тәнкыйтьчене кимсетә торган тыйнаксызлык.

Әдәбиятның бер гиганты да мондый сүзләр ычкындырмаган бит.

1) «Призирать критику, значит — призирать публику, чего боже сохрани».

(А. С. Пушкин.)

2) «Тәнкыйть кирәкле шәйдер».

(Г. Тукай.)

3) «Критика высокого таланта имеет равное достоинство со всяким оригинальным творением».

(Н. В. Гоголь.)

... Нинди чаралар ярдәмендә кешенең рухына ныграк тәэсир итеп була? Шуны белмәгәндә нинди генә язучы да (шагыйрь дә) максатына ирешә алмаячак.

... Тасвирчылыкка корылганмы шигырь, әллә акыллылыккамы — анда укучының эше юк (ягъни аны ул мәсьәлә кызыксындырмый), сокланырлык булган юллар кызыксындыра.

Ниһаять, поэзиянең мөмкинлекләре турындагы мәсьәлә. «Пегас... Канатлы ат шул ул! Канат янына тартә куеп булмый», — ди Р. Фәйзуллин. Ягъни поэзия күп йөк тарта алмый булып чыга. Шулаймы соң? Моны белү өчен Пушкинга яки Маяковскийга мөрәҗәгать итсәк тә җитә — чиксез күп йөк тарта ала Пегас. Тик аңа ул йөкнетөйи генә белергә кирәк.

**РАФИКОВ А.,**

**Ульяновск өлкәсе, Зирекле авылы.**

*

* *

Поэзиябезнең бай тормышыбызга кыюрак һәм тирәнрәк үтеп керүе өчен файдалы этәргеч булачак бу сөйләшү.

Гомумән алганда, безнең поэзиябез үзенең сугышчанлыгын һич тә киметмәде, ул тормыш белән бергә атлый. Аны тагын да көчлерәк, сугышчанрак, тормышыбызга якынрак итәсе иде — бу сөйләшүнең төп максаты да нәкъ шулдыр, минемчә.

Журналның даими укучысы буларак, бу сөйләшүдән читтә каласым килми. Туган поэзиябезгә ихтирамым зур минем.

**Гайҗан бабай сөйли,**
**һаман сөйли.**
**Чәе суына, аны сизми ул.**
**Куанычы эченә сыймаганга,**
**һаман сөйли, һаман сөйли ул.**

Бу поэманың исеме, авторы турында төн уртасында йокыдан уятып сорасалар да, аны укыганыма утыз еллап вакыт үтүгә карамастан, авторы — күренекле шагыйребез Шәйхи Маннур, поэма «Гайҗан бабай» дип атала, «Кайнар йөрәкләр» дигән җыентыгында укыган идем дип, уйлап тормыйча, кырт кисеп әйтә алам. Чөнки шагыйрьнең нәкъ үзебезчә, гади һәм матур итеп язылган бу әсәре гомер буена онытылмаслык булып йөрәккә кереп урнашкан.

Халкыбыз тарихына караган һәр факт, һәр вакыйга искерүне белми, минемчә. Өлкән шагыйрь, яшь шагыйрь язамы, әгәр ул бу вакыйганы яңа төсмерләр, яңа образлар белән киңрәк ача алса, укучы шуңа канәгать. Мәсәлән, тынычлык өчен көрәш темасын шагыйрь Л. Ошанин үзенчә яктырта, ә аңардан күп яшьрәк Е. Евтушенко — үзенчә. Евтушенко сүзләренә язылган «Хотят ли русские войны?» дигән, халыклашып киткән җыр яшь татар шагыйрьләренә: тынычлык турында сез дә шулай языгыз(!) дип кычкырып тора кебек.

Минемчә, безнең татар шагыйрьләре соңгы елларда публицистик темага азрак язалар. Күбрәк лирика белән мавыгалар. Бүгенге героик эшләребез турындагы поэма һәм шигырьләрне күбрәк укыйсы килә.

Бүгенге поэзиябезне чын-чынлап әйдәп баручы Х. Туфан, С. Хәким кебек өлкән шагыйрьләребез белән беррәттән Ш. Галиев, Р. Гәрәй, Р. Харис, Роб. Әхмәтҗанов, Зөлфәт шикелле халык арасында танылырга өлгергән, яратып укырлык шагыйрьләребез бар.

Әгәр дә шагыйрьләребез зур эшләр белән тулы заманыбызны Такташ осталыгы белән җырлап бирсәләр, бүгенге укучы да, киләчәк буыннар да моның өчен аларга рәхмәт кенә әйтерләр иде. Такташ бай мирас калдырган шагыйрь. Аның һәр әсәре татар тормышын гына чагылдырып калмый, бөтен илебезгә хас күренешләрне һәм вакыйгаларны да тулы чагылдыра, барлык халыклар өчен дә уртак итә.

Тукайча, Такташча язу — алар әйткәнне кабатлау дигән сүз түгел, ә тормышны сизгер күрә белү, беренче карашка вак күренешләрне дә зур, актуаль итеп күрсәтә һәм аларны халыкның үз телендә, халык сөйләгәнчә үткен һәм матур итеп әйтә белү.

Тукай рус шагыйрьләре Пушкин һәм Лермонтовтан күп соң яшәсә дә, алар русча гына яңгырыйлар димәгән, һич тә тартынып тормыйча иҗатларын өйрәнгән. Тукайның:

**Пушкин белән Лермонтовтан үрнәк алам,**
**Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам,**

— дип язуы үзенең остазларына рәхмәт сүзләре булып ишетелә.

Әдәби тәнкыйтебезнең марксистик-ленинчыл позицияләрдән һәм заман интересларыннан чыгып фикер йөртә белүе мендә соклану тудыра. Тәнкыйтьтән башка үсеш юк дигән хакыйкатьне яшь шагыйрьләр беркайчан да онытмасыннар иде. Бу дискуссиядә И. Нуруллин һәм Х. Госман китергән дәлилләр мине ышандыра төшәләр.

Сүземне төгәлләп, шуны әйтмәкче булам: Кол Галидән башлап легендар Җәлилгә кадәр күп гасырлы зур юл үткән бай тарихлы поэзиябез вәкилләрен К. Кулиев, М. Кәрим, Д. Кугультинов, Р. Гамзатов, Ф. Алиева исемнәре белән янәшә күрәсем килә.

Туган телебез нормаларын читләтеп үткән күперенке шигырьләр ошамый миңа. Яшь шагыйрьләребез әйбәт әсәрләр өчен сөенеп яшәүче укучыларының Казанда да, Горькийда да, ерак Себердә дә барлыгын онытмасыннар һәм туасы шигырьләрен язганда борынгы бабаларыбызның «сүзең сүзгә ошамаса, сүз дип аны сөйләмә» дигән кисәтүләрен истә тотсыннар иде.

**ӘНВӘРБИК МӨХСИНОВ.**
**Горький шәһәре.**

*
* *

Сүз бүгенге поэзия турында барса да, Һ. Такташтан башлыйсы килә. Чөнки ул халкыбызның, сайрар сандугачлар шикелле, иң яраткан бөек шагыйре иде. Ул үзенең көчле таланты белән үзеннән-үзе үсеп чыккан шагыйрь иде. Әлбәттә, кайсы шигырьне ничек кабул итәргә йөрәккә приказ биреп булмый. Яхшы китаплар, шигырьләр алар үзеннән-үзе күңелгә якын булып урнашып калалар.

Хәзерге яшьләр — елларның тынычлыгына, тормышның муллыгына шатланып, өлкәннәр поэзиясеннән үрнәк алып (барыннан да элек Һ. Такташ һәм М. Җәлилләрдән), алар шикелле бирелеп эшләргә, киләчәктә үз иҗатларын халыкның уртак рухи хәзинәсе итәргә тырышсыннар иде.

**ЗАКИРОВА ХӘЛИМӘ,**
**Таҗикстан ССР, Яван шәһәре.**

*
* *

Шигырь яки җыр сайлаганда үткен сүзләрен сайларга тырышасың. Әйтерсең сүз түгел, ә корал сайлыйсың. Гомумән, шигырь укырга кечкенәдән яратам.

Үзем Х. Туфан, С. Сөләйманова, Р. Гәрәй, Р. Фәйзуллин, Р. Харис шигырьләрен яратып укыйм. Шигырьләрдән башка яши алырмын дип уйламыйм да. Шигырь җанга рәхәт, тәнгә сихәт бирә. Һәр шигырьнең сихри көче бар.

**МӘГЪМҮРӘ СӘЛИМҖАНОВА,**
**Азнакай районы, Актүбә поселогы, оператор.**

*
* *

Хөрмәтле Равил!

Шунысы куанычлы, Сез хәзерге поэзиябезне милли рамкалар белән генә чикләмичә, аны ил, дөнья күләме фонына куеп фикер йөртәсез. Аннан, шигърияттә яңалыкка кыю омтылуыгыз һәм бу юлда киртәләрнең булуын да истән чыгармавыгыз әйбәт тәэсир калдырды. В. Маяковский да бит «Сезнең шигырьләрегез аңлашылмый, дулкынландырмый, җылытмый» диючеләргә: «минем шигырьләрем су да түгел, мич тә түгел; ә инде аңлашылу-аңлашылмаулары турында мең елдан соң кабинетыма керерсез, сөйләшербез»,— дип җавап биргән. Мең ел түгел, бер буын кешеләре үк Маяковскийны аңлап кына калмады, ә үзенең иң бөек, иң сөекле шагыйре итте.

Хөрмәтле шагыйребез Хәсән Туфан да «аңлашылмый» белән башлап җибәрде. Чынында исә, поэзиядә үзенә генә хас гүзәллекнең тууы булган икән ул. Инде килеп, Равил, бүтән мәсьәләләргә күчик. «Бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләребезнең фикри ярлылыкларына хәйран калам», дип әйтүегез арттырыбрак җибәрүегез түгел микән, мәйтәм. Хәзергесе көндә поэзия тәнкыйте өлкәсендә эшләүче иптәшләрнең барысы да дип әйтерлек галимнәр. Такташлар чорында моның киресе иде — бу бер. Икенчедән, «поэзия тәнкыйтьчесе» дигән таҗлары булмаса да, шигырь турында тирән фикерләр әйткән мөхтәрәм язучыларыбыз бар (Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, мәсәлән).

Һ. Такташ адресына әйткән сүзләрегезне бер дә килештермәдем.

«Кыска шигырьләр»егезне укып чыккач туган тәэсир-тойгыларым турында әзрәк тукталам: мин, Равил, шигырьнең «Мәрьям анасы» булмаса, аны укудан ләззәт тапмыйм. Сезнең шигырьләрдә (барлыгы 19 исемдә 16 шигъри юл) «Мәрьям аналары» юк түгел. Мәсәлән:

**Ялкыныңмы минем янга төште**
**Мәк чәчәге булып, кызарып.**

**Сөешкәннәр күп,**
**кавышкан сирәк.**

**Чалкан йөзеп киттең ай юлыннан.**

Болай фәкать шагыйрь генә әйтә ала.
Ә болай исә:

**Китапханәгә кергәч бөрешеп калам...**
**Җиңел килгән рәхәтлектән саклан**

һ. б. шуның кебекләрне һәркем әйтә ала.
Ярый, Равил, шушының белән хуш иттек.
Сезгә иҗади уңышлар теләп, сәлам белән,

**АБДУЛЛА АБЯЗОВ**, Чүпрәле.

*
* *

Шагыйрьләребезнең күпчелеге бүгенге көн проблемалары белән дулкынлана, күңелгә ятырдай, югары бәягә лаек, ялкынлы шигырьләр язалар.

Шул ук вакытта, хис-фикер байлыкларын анализга алганда, кайбер әсәрләрдә сыеклык, идея эчтәлеге түбән, күңелгә ятмый торган (ни уму, ни к сердцу) тозсыз булган әсәрләр дә күренгәли.

Журналыбызның бишенче санында басылган Гамил Афзалның «Анкета»сы белән танышып чыктым. Мин аңлаганча, Гамил Афзал «Тарих тәгәрмәче»нә таяк тыкмаган, алга таба әйләндерергә дә уйламый. Бер сүз белән әйткәндә — ошамадылар.

Журналның бишенче саны Равил Фәйзуллинның «Кыска шигырьләр»е белән ачылуын күреп, кыска гына алар турында тукталасым килә: туры гына әйткәндә, бу «Кыска шигырьләр»дә йөрәккә ятырдай моң юк...

**ӘСХӘТ ХАЙРОВ**, Куйбышев өлкәсе.

# БУ — БЕЗНЕҢ ТУГАН ХАЛКЫБЫЗ...

Гомәр Бәширов — совет халкының рухи тормышында урын алган «Сиваш», «Намус», «Туган ягым — яшел бишек» кебек күренекле әсәрләр биргән язучыбыз. Әгәр бу китапларны, халык тормышының аларда тасвирланган дәверләренә карап, бер тәртипкә тезә калсак, Г. Бәширов иҗатының асылын, тирән мәгънәсен тәшкил иткән бер сыйфат калку булып күренәчәк: халыкның художестволы тарихын эзлекле тудыра бару сыйфаты ул.

«Туган ягым — яшел бишек»тә Бөек Октябрь революциясе өлгереп килгән чор татар авылы тарихчы һәм этнограф галим, хикәя остасы һәм сүз художнигы кодрәте белән ачылса, «Сиваш»та исә шул авыл кешеләренең революцион Кызыл Армия сафларында азатлык һәм бәхетле киләчәк яулап көрәше сәхифәләре сурәтләнә. Әлеге ике әсәр үткәннәргә мөрәҗәгать ителеп, инде тарихка тапшырылган вакыйгаларга сулыш өрелеп язылган булса, «Намус» романы үзендә сурәтләнгән тормыш барышында туды. Әсәрнең тематик җирлеге — халыкның тарихи үсешендә яңа этап, аның җиңүгә ирешкән социализм шартларында тормышы, төп герое — яңа дәвер кешеләре.

Шуннан соң Г. Бәширов яңа әсәр иҗат итәргә керешә. «Хәзер мин яңа китабымны тәмамлап киләм. Сугыштан соң узган утыз ел эчендә безнең республика тормышында гаҗәеп үзгәрешләр булды... Тормышка моңарчы күрелмәгән бик күп яңалык керде. Шуңа күрә, табигый ки, минем яңа китабымда безнең көннәргә хас омтылышлы кешеләр урын алды. Һәм мин сугыш чоры кешеләренең рухи өлгергәнлеге, аларның социалистик Ватан һәм халык алдында үз вазифаларын тирәнтен аңлау кебек сыйфатлары яңа әсәрем геройларының характер һәм язмышларында тормышның үзендә булганча чагылыш табуын бик теләр идем»,— дип язды ул.

Әсәр озак язылды. Вакытлы матбугаттан укып белгәнебезчә, аның нигезенә салынган тормыш материалы зур үзгәрешләр кичерде. Бу хәл, беренчедән, Гомәр Бәшировның художник буларак үзенчәлекле иҗади табигатенә хас төп сыйфатны — тормышның елъязмачысы булу, халыкның сәнгатьчә тарихын тудыручы булу сыйфатын ачыкларга мөмкинлек тудырса, икенчедән, язучының әнә шул сыйфатларына туктаусыз хәрәкәттәге тормыш тәэсирен өйрәнергә — шушы үзара тәэсир итешү нигезендә барган иҗат процессының диалектикасын аңлый төшәргә ярдәм итә.

Чынлап та, әлеге яңа китап «Җидегән чишмә» романы[1] язылган чорда тормышыбыз гаҗәеп зур үзгәрешләр кичерде. Алар сыйфат үзгәрешләре булды, һәм җәмгыятебез үзенең үсешендә яңа баскычка — социализмның өлгереп җитлеккән этабына күтәрелде. Бу — матди һәм рухи потенциалы мул, үсеш энергиясе гаять куәтле җәмгыять. Әсәр җитлегү про-

[1] Гомәр Бәширов. Җидегән чишмә. Роман. Татарстан китап нәшрияты. 1 нче китап, 1977 ел; 2 нче китап, 1978 ел.

цессының иң динамик чорында язылды. Бу — әдәбиятта идея-эстетик эзләнүләр активлашкан еллар иде. Эзләнүләрнең нигезендә үсеш диалектикасына хас каршылыклар ята. Үсеш табышлардан гына тормый, югалтулар да китереп чыгара. Иҗтимагый процессның баш әйләндерерлек кызулык белән алга барышы матди һәм рухи тормышта исрафчылык күренешләрен дә тудырмый калмады. Әдәбият рухи исрафчылыкка, гомумән дә югалтуларга битараф була алмады. Һәм совет әдәбиятында шул күренешләргә каршы пафослы байтак әсәрләр иҗат ителде. Ч. Айтматов, В. Астафьев, В. Распутин, Ә. Еники һәм башка әдипләр иҗатында бу тенденция ачык чагылыш тапты.

Гомәр Бәширов «Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә халыкның гасырлар буена тупланып килгән рухи-әхлакый тәҗрибәсен, югары гуманизм белән сугарылган тормыш фәлсәфәсен коммунизм төзүче җәмгыятьнең тарихи мирасы дәрәҗәсенә күтәргән иде. Бу фикерләре аның публицистик иҗатында да яңгырады.

«Җидегән чишмә» әсәре язучының актив рәвештә, үҗәтлек белән шундый тарихи-иҗтимагый-әхлакый мәсьәләләрнең чишелешен эзләгән елларында язылды. Бу, иң башлап, әсәрнең проблематикасында чагылыш таба. «Хәзерге заман кешесе, бүгенге авыл! Аның нечкә шигърияте, нәзберек табигате, шуның белән янәшә үк куәтле тракторлар, агрегатлар, комплекслар. Бу тыштан гына шулай ансат мәсьәлә кебек күренә. Ә уйлана башласаң, болар һәркайсы кеше язмышына барып тоташа. Алар хакында роман да, поэма да, докторлык диссертациясе дә язарга була. Үткәнне, хәзергене, киләчәкне бер фокуска җыеп күрсәтергә иде» — романның төп геройларыннан берсе, язучы Камил Дусаев әнә шундый максат белән йөри. Гомәр Бәширов еш кына аңа үз уйларын да тапшыра кебек.

Табигать һәм кеше! — сәнгатьнең беренчел һәм мәңгелек темасы. Безнең заманда яңа катлаулы мәгънәләр алган шушы тема әсәрнең проблематик арка сөяген тәшкил итә. Төп проблеманың колачлы куелышы һәм чишелеш перспективасы язучыга образлар системасын тәкъдим итә. Бар табигать язмышы, туган җир язмышы күтәрелгән икән, аны шул җирнең бердәнбер хуҗасы — халык кына хәл итә ала. Социализм җәмгыятен төзегән, коммунизм бинасын торгызучы совет халкы үз иле белән идарә итүче бердәнбер хуҗа. Әсәрнең образлар системасы иҗтимагый-политик казанышларның шул үрләре югарылыгында корылган. Икенчедән, Г. Бәширов — тарихи фикерле язучы. Марксизм-ленинизм методологиясен иҗади карашларына сеңдергән әдип буларак, ул бу әсәрендә дә хәлиткеч көч иттереп коллективны, халыкны алга чыгара. Әсәрдә проблеманың язмышын үз иңнәренә салган төп геройлар: Минһаҗ карт, халык депутаты Камил Дусаев, сыер савучы хатыннар Җәүһәрия, Язидә, яшь буын вәкилләре Гайнан, Фәйрүзә, Дилбәр, комсомоллар, пионерлар... — гади халык уллары-кызлары. Һәрберсенең үз шәхси язмышы бар. Әмма барысын да халыкның тормыш нигезенә — тарихка, табигатькә, җиргә, киләчәккә халыкчан мөнәсәбәт берләштерә. Мәңгелек һәм заманча актуаль проблематика күтәрелү һәм аны халыкчан тормыш фәлсәфәсе яктылыгында чишүгә ирешү «Җидегән чишмә» әсәрен яшәүчән итә.

Романның үзәк геройларыннан берсе — комсомол егет Гайнан образы язучы тарафыннан аеруча яратып гәүдәләндерелә. Ул аның тулы канлы шәхесен сурәтләүгә бөтен игътибарын бирә. Гайнан характеры романның беренче битеннән ахырына кадәр туктаусыз хәрәкәттә: ул җиңелә, юл таба, тагын хурга кала, алдана, тагын күтәрелә, мәхәббәт газабында яна, кыйнала, җиңә. Ул гел үсештә. Революция ветераны Минһаҗның, урта буын вәкиле Камил Дусаевның идеалларын алга илтүче өметле яшь буынның күркәм бер вәкиле булып җитлегә. Ул — ил хуҗасы... Бу тормышчан образны ача алу Гомәр Бәшировның әзлекле тарихи зирәклеген, һәр буынның халыкчан типларын бер үк тәрле дәрт, дәрман һәм ярату белән сурәтли алу куәтен раслый.

Романда безнең әдәбият өчен тагын бер үзенчәлекле тип — язучы Камил Дусаев. Гомәр Бәширов аның халык депутаты булуын гел искәртеп тора, һәм Дусаев әсәрдә халык хезмәтчесе сыйфатында сурәтләнә дә. Ул язучылыгын да шул эшенә ярдәмгә җигә һәм шул мәшәкатьләрендә «язарына азык та „таба», халыкның үз интеллигенты, үз язучысы тибы бу.

Камил Дусаев образы әсәрнең бөтен

тукымасына үзенчәлек алып керә. Сюжет линияләре аның кулында. Күбрәк ул уйхисләрендә, эчке монологларында ачыла, әсәр проблематикасының тарихи-әхлакый, фәнни-гамәли аспектларда чишелешенең заманга лаек дәрәҗәсен тәэмин итә. Тагын шунысы — ул әсәрнең күп төрле аһәңнәрдән хасил булган гомуми тонын билгели. Асылда ул тон йомшак, ягымлы, салмак, сабыр, әмма таләпчән. Менә Камил Дусаев романга ничек килеп керә: «Иген басуларын, тын утырган урманнарны, ак күгәрчен булып тау итәкләренә кунаклаган нефть чаннарын Камил рәхәтләнеп карап барды. Аңа инеш буйларындагы яшел тугайлар да, саргылт кояш нуры белән мөлдерәмә тулган урман аланнары да, аларга кереп баручы чүп-чуар балачага, хатын-кыз төркеме дә — һәммәсе дә якын, газиз, күңелдә җылы тойгы уяталар. Инеш буена тезелеп утырган җыйнак авыллар, алардагы калай һәм шифер түбәле яңа йортлар, болын буйлары, анда сибелгән каз-үрдәк — барчасы күңелен күтәрде. Болар һәммәсе дә аның туган иле, туган халкы иде. Ул үзе дә әнә шундый тугайларда печән чабып, басуларда иген игеп, шушындый ук авылда үскән кеше. Болар аның булачак китабының язылачак манзаралары. Аның каһарманнары әнә шунда яшәячәкләр — шушы сөйкемле якта, шушы матур елгалар буенда».

Камил Дусаев шушы тугайлардан, болын-басулардан, урман-бакчалардан бал җыючы бал корты шикелле үз халкының яшәү җирлегеннән, холык-фигыленнән, кылган гамәлләреннән бар гүзәллекне татып, ләззәтләнеп үзенә туплап йөри һәм күңелендәге китап битләренә күчерә бара. Ул чиста кәгазь битләренә туган иле, туган халкы тарихыннан сәхифәләр, аның асыл табигатен сурәтләгән бизәкләр чигә. Шул кояш-айдан, шул якның ел фасылларыннан, шул күк гөмбәзеннән, шул җир-судан алып чигә.

Әсәрдә аталган урын-җир исемнәре дә салават күпере төсләренең гүзәллеген хәтерләтә: Казан, Бөгелмә, Җидегән чишмә, Алтынбикә тугае, Әверлән инеше, Алыптау, Ык суы, Сандугач култыгы, Сөендек авылы... Шушы мәрхәмәтле, миһербанлы, шигъри табигать-ана кочагында яшәүче халык та рухи тәрбияле, сәламәт тәнле, таза акыллы булмый мөмкин түгел. Константин Паустовский бик хаклы рәвештә әйткәнчә, урын исемнәре — халыкның үз илен шигъри бизәве ул. Аларда — халыкның холкы, тарихы, һәвәслекләре һәм көнкүреш үзенчәлекләре. Баширов «Җидегән чишмә» романы белән К. Паустовский фикердәше булуын сәнгатьчә күрсәтте, раслады.

Минһаҗ, Камил, Җәүһәрия, Мәдәния, Идрис, Гайнан, Язидә, Рәмзи — дүрт буын вәкилләре. Алар бер үк күк-түбә астында, бер үк офыклар белән бүленгән җирдә яшәп ятучы бер үк тарихлы, бер үк язмышлы, бер үк халык балалары. Төрлетөрле булсалар да, үзара охшашлар. Һәм бу охшашлык — аларның уртак табигатендә, уртак омтылышларында, уртак тормыш фәлсәфәсендә. Алар туган җир-суларын, урман һәм болынлыкларны җәберләтә алмыйлар. Әсәрнең төп проблематикасы шул рәвешчә язучы ирке-теләге белән генә түгел, бәлки халыкның тирән табигатеннән, тормыш фәлсәфәсеннән органик рәвештә күтәрелә.

«Җидегән чишмә» — публицистик рухлы сәнгать әсәре. Аның күп кырлы тукымасында фольклор, тарихи тикшерену, газета, доклад, җыр, сәнгатьле хикәяләү стильләре шул кадәр тыгыз береккән ки, үзенә бер төрле язу стилен тоярга мөмкин. Әсәрнең бу үзенчәлеге дә әдәбиятчыларыбызның игътибарын үзенә тартыр әле.

Романда буйдан-буйга бәхәс бара, фикерләр, хисләр бәрелешә. Бәхәс вак-төяк тирәсендә кызмый. Гап-гади хезмәт ияләре, әмма рухи масштаблары белән дәү кешеләр зур проблеманы чишү — социализм җәмгыяте өстенлекләрен техника прогрессы мөмкинлекләре белән бергә кушу, туган илнең уртак гүзәллеген, аның матди һәм рухи байлыкларын ишәйтә бару белән мәшгульләр. Һәм алар бу көрәшне үзләренең интеллектуаль үсеш дәрәҗәсенә лаеклы тонда, шул югарылыкка хас ысуллар белән алып баралар. Әсәрнең проблемасы — коммунистик, интернациональ эчтәлекле булса, аның эчке рухы милли, төп герое, Максим Горький сүзләре белән әйткәндә, «айнык, саф күңелле, хезмәт сөючән һәм максатка ирешүдә рухи ягымлылыкны тырышлык белән бәйли алучы татар халкы».

«Җидегән чишмә» — туган илебез, туган халкыбызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында поэма булып яңгырый.

Миңа калса, әсәрне тагын да тыгызлыйсы, бөтен итәсе, түгәрәклисе урыннар бар. Аеруча мәхәббәт сәхифәләренең

кайберләре күңелдә канәгатьсезлек тудыра. Гомәр Бәширов мәхәббәт тарихларын халыкчан асылында: тыйнак, пакь, тирәндә яткан изге хис итеп сурәтли ала. Камил белән Мәдания, Җәүһәрия белән Харис, Минһаҗ белән Сөембикә, Язидә белән Гайнан арасындагы күңел җепләре романның йөзек кашы булган «Җидегән чишмә» җырындагыдай сузыла:

Җидегән чишмәләргә йөзек салдым,
Җидегән йолдыз күреп калсын дип.
Җанкай-җанаш алсын да куансын,
Вәгъдәләрем булып калсын дип.

Җидегән чишмәләргә чиләк куйдым,
Пар чиләгем тизрәк тулсынга.
Без сөябез, җаный, яр булсынга,
Без сөймибез вакыт узсынга.

Гайнан белән Шәүрә арасындагы мәхәббәт тарихы, бер ялганып, бер сүрелеп, романның буеннан-буена сузыла. Ул бик табигый башланып китә, баштарак укучы игътибарын рәшә кебек үзенә тартып тора, әсәрнең бай романтик рухында бер ялкын булып дөрли. Әмма тора-бара бу мәхәббәт качышлы уенын хәтерләтә башлый, ике күңел өчен дә бәйләнчек газапка әйләнә кебек. Табигыйлеген югалткач, ул геройларны ямьсезли.

Идрис белән Людмила мөнәсәбәтләре роман тукымасына бөтенләй дә чигелми. Өстәвенә, әдәбиятта шаблонга әверелеп бара торган күренешнең тагын бер чагылышы гына түгелме? Людмила хисләре самими итеп, табигый итеп бирелә. Идрис исә урланган торбалар белән булган вакыйгада пешмәгәнлеген бер күрсәтсә, Людмилага мөнәсәбәтендә холкының җитлекмәгәнлеген икенче тапкыр раслый. Ул әсәрнең халыкчан рухын, әхлагын, моңын, фәлсәфәсен, «Җидегән чишмә» җырын бер төрле җырлый, ә үзе «вакыт узсынга» йөри кебек. Автор аны «хәзерге яшьләрнең мәхәббәт мәсьәләсенә шулай җавапсыз караулары бик аяныч хәл иде», дип шелтәли дә, югыйсә, тик Идрис образының укытучы, авылда партия җитәкчесе образы булуын да һәм әсәрнең нигездә, яшьләргә юллануын да онытмаска кирәк. Хәер, Гомәр Бәширов кебек аксакал әдипкә нотык сөйләп торганчы, әлеге романнан язучы Камил Дусаев фикерләрен искә төшерү урынлырак булыр. Дусаев яңа әсәрен түгәрәкләп тә килә инде. Ике колхозны бергә кушып, кайсысының председателен калдырырга дигән мәсьәлә куелгач, Камил, күңеленә шик төшеп, язу өстәле янынннан тора. «Нәрсәдер борчый, нидер уйлап бетермичә, җиңелчәрәк, ансатлаштырып хәл ителә сыман тоела иде. Тормышның үзендә бу вакыйганың бүтән вариантлары, мәсәлән, бөтенләй киресе дә булырга мөмкин бит. Әйе, мәсәлән, колхозчылар яңа колхозга Һадиевны түгел, яңадан Чурмантаевны председатель итеп калдырсалар? Аны Камил ничек язар иде? Юк, алай булса да, китапка алай язмас иде. Чөнки Ризванны сайласалар, ул бит сәнгать хакыйкатенә каршы чыгу булып кына калмый, бәлки халык теләгенә, тормыш логикасына каршы куелган бер кирелек булачак».

Гомәр Бәширов китапларын басмаданбасмага тагын бер карап чыгып, камилләштерә килә торган әдип. Һәм ул яңа романындагы «тормыш логикасына, сәнгать хакыйкатенә каршы куелган» кайбер «кирелекләрне» игътибарына алыр, әлбәттә.

«Җидегән чишмә» күтәрелгән проблемаларның җитдилеге, халыкчан идеяләргә байлыгы, күрер күзгә гади кешеләрнең эре характерлары тасвирланган булуы белән татар совет әдәбиятының күренекле әсәрләреннән берсе булып әверелер.

**ХӘМЗӘ ЗАРИПОВ.**

# ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН...

*Нури Арслановның «Уйлар, сагышлар» китабы басылып чыгу уңае белән*

Шигърият һәм Вакыт... Бу ике олы төшенчә арасындагы үзара мөнәсәбәтләр, мәңгелек көрәш, тартыш хакында кайтып-кайтып уйлангалым, уйга калганым бар. Юк, кайсы көчлерәк яисә кайсы җиңәр дигән күзлектән чыгып түгел. Хәер, безгә — фактик гомере бер гасыр эчендәге санаулы елларга сыйган җир кешесенә — андый мөмкинлек бирелмәгән дә. Шуңа да карамастан, үз каланчабыз биеклегеннән генә булса да, күрергә мөмкин булган кадәрен күрәсе, аңлыйсы, фикер йөртәсе килү теләге бер генә минутка да ташламый. Шигърият һәм Вакыт... Вакыт һәм Шигърият... Йөрәгем, күңелем белән шигъриятнең, чын шигъри сүзнең көченә, мәңгелегенә инанган булсам да, салкын акыл бу дөньяда барыннан да көчлерәк Вакыт, «Вакыт галиҗәнабләре» булуын искәртеп тора. Вакыт — ул иң олы һәм мәрхәмәтсез хөкемдар, барын да үз урынына куя килә, тарихны һәм берочтан безне дә чикләнгәнлек һәм хаталардан арындыра бара.

Кеше гомере Вакыт алдында бары тик бер мизгел, ә шагыйрьләр Шигърият дип аталган мәһабәт олы дөньяның аерым атомнарын, кисәкчәсен тәшкил итә, һәм бу кисәкчәләр өзлексез сынауда. Вакыт сынавында! Шигърият сынавында! Берәүләрне көн сынаса, икенчеләрне еллар, ә кемнәрнедер гасыр сыный. Тик санаулы исемнәр генә мәңгелек сынауга узар. Дөнья шул бу — берәүләр сынала, берәүләр сыната... Сынау һәм сыналулар мәңге дәвам итә. Кичә дә, бүген дә, иртәгә дә...

Шигърият һәм Вакыт... Ә кулда тыйнак кына, пөхтә генә эшләнгән шигъри җыентык — олы төшенчәләр алдында нибарысы тузан бөртеге. Ләкин шулай да сүз шигырь турында барганда — салкын акыл җимеше — бу чагыштыру урынсыз булса кирәк. Тузан бөртегенә шигырь сыямыни? Һәм, гомумән, шигърият турында сүз барганда масштаблар белән эш итү, әй-һәй, мөмкинме икән?!

«Уйлар, сагышлар» җыентыгы (әле генә Г. Рәхимнең «Моңнарым» китабын укыган идем, кемгә ничектер, ошый миңа бу исемнәр)... Шигъриятттә һәм тормышта байтак кына еллар һәм юллар сынавын узган өлкән шагыйребез Нури Арслановның соңгы 3—5 ел эчендәге уйлары, сагышлары сыйган аңарга. Олы бер дөнья — шагыйрьнең планетада барган вакыйгаларга, илләр һәм халыклар язмышына, Ватанына һәм туган ягына, кешеләргә мөнәсәбәте чагылыш тапкан бу уйларда, бу сагышларда. Яшь һәм еллар исәбен онытып ялкынланып янган йөрәк җылылыгы, социалистик Ватаныбыз белән бергә данлы һәм озын юл үткән ир-егетнең күңел җимешләре бу уйларда, бу сагышларда...

Октябрьга алтмыш. Яшь ягыннан
Алты яшька гена олы мин,—
Унжидеда Кышкы Сарай алган
Батырларның, димәк, улы мин.

Җыентыкны шундый строфа ачып җибәрә. Һәм бер дә очраклы рәвештә түгел, бик табигый — шагыйрь үзенең тормыш юлы, үткәне, бүгенгесе белән чын-чынлап горурлана ала. Димәк, әйтер сүз — уйлар, сагышлар да җитәрлек. Октябрьда туып, Октябрьда кабынган утны безнең көннәргә кадәр сүндерми, сүрелдерми алып килгән буын вәкиле Нури Арсланов. Күңелләрне аның уйлары, сагышлары дулкынына көйләп без дә бераз уйланыйк, фикер йөртеп алыйк...

Шагыйрьләр аз түгел бездә. Чын шигъри талантка ия, сәнгатьле һәр сүзнең кадерен белеп, халык һәм җәмгыять каршында зур җаваплылык тоеп иҗат итүче олы күңелле җырчылар да бар. Әмма болары санаулы гына. 70 нче еллар татар совет поэзиясендә шундый җырчыларның берсе Нури Арсланов. Тормышка һәм шигъриятькә мөнәсәбәттә сокландыргыч бер матур сыйфат — киңлек хас бу шагыйрьгә. Дөньяга караш киңлеге, хыял офыклары киңлеге һәм күңел киңлеге... Болар исә, үз чиратында, тематик киңлеккә китерәләр.

Әйтик, Н. Арслановның политик темаларга язылган публицистик рухлы шигырьләре шигъриятебездә үзе бер күренеш, махсус игътибарга лаеклы вакыйга. Әмма шагыйрьнең үтә нечкә хисләр белән өртелгән лирик поэзиясен артык үз итүдәнме, җиңел агышлы, уйнаклап торган шаян, көяз һәм мут шигырьләре, җырларына алданыпмы, без аларны һәр очракта да күреп, ул гына да түгел, тиешле дәрәҗәдә бәяләп җиткермибез. Уйлана калсаң, Н. Арсланов иҗатының идея-эстетик югарылыгын, иҗтимагый яңгырашын нәкъ менә шул әсәрләр — сугышчан һәм актив публицистик шигырьләр билгели түгелме?.. Аларда бүгенге дөнья сулышы, пульсы аермачык сизелеп тора. Чилидагы вакыйгалар драматизмы, Австралиядә яшәүче кыргый кабиләләр язмышы тынгылык бирми шагыйрь җанына. Португалия, Испания һәм Мозамбиктагы демократик үзгәрешләр аның күңеленә язгы күкрәү булып килеп керә. Шигырьләрдә А. Куньял чыгышларындагы мәңгелек көрәш пафосы, Г. Лорка сүзләрендәге масштаблылык, В. Хара җырларындагы оптимистик моң хәрәкәткә килә, җанлы образлар булып яши башлый.

Җырчы Лорка тына, ә Хараның
Гитарасы сына зинданда,—
Тик чыңлый җыр, тавышы гитараның
Өзелмәгән — яңгырый җиһанда.

Ә Куньялның исәнлектә ирешә
Рәсемнәре дөнья күрмәгә;
Дауда туган сәнгать дауга дәшә,
Ябып булмый аны төрмәгә.

Н. Арслановның әһәмиятле политик вакыйгалар эзеннән язылган, халыклар дуслыгы һәм интернациональлек идеяләрен актив яклап чыккан, ялкынлы рәвештә пропагандалаган публицистик яңгырашка ия шигырьләре кайбер уйлануларга да этәрә: гомумән, сугышчанлык пафосы, политик яңгыраш безнең татар поэзиясенә элек-электән хас күренеш. Тукай, Такташ һәм М. Җәлил әсәрләре аның классик үрнәкләрен тәшкил итәләр. «Китмибез» һәм «Лорд Чемберленга СССР крестьяны Һади Такташтан җавап нотасы» шигырьләре, «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы, «Моабит дәфтәрләре» — болар һәркайсы шагыйрь исеменең дөньякүләм масштаблардан торып фикер йөртүче шәхес тәшенчәсе белән турыдан-туры элемтәдә булуы турында, ул гына да түгел, аларның үзара аерылгысызлыгы хакында сөйли. Безнең көннәрдә исә шигъриятнең илаһи олылыгын, дәрәҗәсен билгели торган әлеге сыйфат Нури Арсланов иҗатында — аның каләмдәшләре С. Хәким, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һәм Зөлфәт кебек төрле буын шагыйрьләре иҗатында — дәвам иттерелә, үстерелә. Әйе, үстерелә дә — конкрет исемнәр атап сөйләшкәндә, мөгаен, бу сүздән куркырга ярамый торгандыр.

Татар шагыйренең җир шарында барган политик вакыйгаларга мөнәсәбәте... Бу гадәти күренеш — безне социалистик Ватан үз мәнфәгатьләребез, үз бурычларыбыз белән генә чикләнеп яшәргә өйрәтмәгән. Һәр совет гражданины дөньядагы политик вакыйгаларны үз йөрәгеннән, күңеленнән үткәрә, кичерә бара. Ул гына да түгел, актив рәвештә көрәшә дә — тынычлык өчен, азатлык өчен, тигезлек һәм хакыйкать өчен. Үзебездә гражданлык, гуманизм һәм интернациональлек хисләре белән яшьли тәрбияләнгән, шундый гүзәл, олы сыйфатлар яшәвен үзебез дә кайчак белми йөрибез. Н. Арсланов шигырьләрендә мин ватандашларыбызга, туган халкыма хас иң матур сыйфатларның берсе булган — әлеге киң күңеллелек, кешелеклелек, олы масштаблы гамь, борчуларда яшәүнең үзенчәлекле чагылышын тоям.

Португалия бүген — давыл кичереп
Исән калган кораб,
Бара әкрен, төннән юлын күчереп,
Кояшына карап!

(«Кояшына карап».)

Көн китер, җил, Испан күкләренә,
Болытларны ку да,—
Ярларыннан ташый, күтәрелә
«Фуэнтеовехуна».

(«Фуэнтеовехуна».)

Шагыйрь Испания һәм Португалиядә дә, Чили, Мозамбик һәм Австралиядә дә булмаган. Шуңа да карамастан, бу илләрдә барган политик вакыйгалар, социаль яңарышлар уңаена язылган шигырьләре битараф калдырмый — тирәнтен дулкынландыра, борчый, уйлануларга этәрә. Ә бит төп чыганак безгә дә таныш булган, газета, радио һәм телевидение информацияләре генә... Дөрес, шагыйрь бу илләрнең тарихи үткәне белән дә кызыксына, халкының революцион һәм демократик традицияләрен өйрәнә, милли горурлыкка әверелгән батыр уллары, халыкның рухына ачкыч булган легендалар белән дә таныша. Нәтиҗәдә, шул характердагы төп һәм иярчен чыганаклар синтезы шагыйрь күңелендә — күңел күзендә — көтелмәгән һәм яңа офыклар киңлеге ачылуга китерә. Коры информация янсә политик кыяфәт алган буш куык сүзләр тезмәсе түгел, ә киң публицистик яңгырашка ия, күңелләргә юл табарга сәләтле уй-фикерле шигырь туа. (Дөрес,

шагыйрьләргә чит илләрдә булу, ерак сәяхәтләрдә йөрүнең кирәге дә юк икән дип аңлашылмас. Йөз тапкыр ишеткәнче бер тапкыр күргәнең хәерлерәк, ди рус халкы). Ләкин Н. Арсланов иҗаты белән танышканда, күңел сизгерлеге булса, тынгысыз рәвештә эзләнсә, өйрәнсә, шагыйрь шулай ук күпне күрә-кичерә һәм сөйли дулкынландыра ала дигән фикергә киленә.

Туган җир, Туган ил һәм Ватан. Н. Арсланов иҗатының үзәгендә әлеге темалар булу шулай ук табигый һәм һичкемне гаҗәпләндермәс. Шагыйрь генә түгел, һәр аерым шәхес тә иң элек үз-үзен шушы изге төшенчәләргә мөнәсәбәте — мәхәббәте, бирелгәнлеге һәм тугрылыгы белән билгели торган заманда яшибез.

Тугрылыклы улы булсам Идел-йортның,
Бөек Совет илендә бер ватандармын!

— дип җырлаган шагыйрь дә, әлбәттә, бер карашка зур яңалык ачмый. Ватандарлык, Туган илгә бирелгәнлек хисләре сабый чактан бишек җыры һәм ана сөте белән җаныбызга кергән, канга сеңгән. Шунда ук сорау туа: нигә соң әле шул темага язылган әсәрләр безне берөзлексез дулкынландыра тора һәм ни сәбәпле күңелләрдә бетмәс-төкәнмәс ихтыяҗ үзләренә? Югыйсә, аз яктыртылган тема дип әйтеп булмый бит. Ул гына да түгел, күңелләрне һәм фикерләрне кузгатып үзенә иярте, кузгата килгән һәр яңа күләмле әсәр теге яки бу дәрәҗәдә әлеге дә баягы шул ук темага багышланган була. Дөрес, укучы йөз чөерерлек язмалар да күренгәләп ала бу темага караган әдәбият арасында. Пародоксларммы? Ничек аңларга һәм аңлатырга боларны? Ничек?..

Туган җир, Туган ил һәм Ватан төшенчәләренең тирәнлеге, колач җитмәс киңлегеннән киләдер бу барыннан да элек. Чын художник таланты аның яңадан-яңа пластларына төшеп, көтелмәгән ачышлар ясарга мөмкин. Ә икенче берәү теманың «үтемлелеген» аңлап, ух-ах итәр, бирелгәнлеге һәм мәхәббәте турында канатлы сүзләр сибәр, нәтиҗәдә, укучының кәефен кырыр — әдәбиятка эстетик күзлектән генә түгел, идея күзлегеннән дә хыянәт итәр.

Чын художник, әдәби сүз остасы өчен әлеге тема — ул гомумән дөнья һәм әдәбият дигән сүз. Тормыш һәм яшәеш, мәхәббәт һәм сагыш дигән сүз. Юкка гына философлар һәм шагыйрьләр Ватанның кайда һәм нидән башлануы һәм кайда тәмамлануы, үзе эченә нәрсәләрне алуы турында элек-электән уйланмаган, баш ватмагандыр. Әмма төгәл җавап әлегәчә табылганы юк...

Туган җир һәм Ватанга мөнәсәбәттә шәхес билгеләнә дидек. Димәк, әдәбиятның кызыксыну предметы булган — кешене тулы һәм киң планда, сәнгать чаралары белән өйрәнү, тасвирлау процессында да иң элек аның әлеге изге төшенчәләргә мөнәсәбәтен ачыклау мәҗбүри. Кешенең гүзәллеге, рухи байлыгы һәм гомумән аның иң матур сыйфатлары да турыдан-туры туган җир һәм Туган илгә мәхәббәт, бирелгәнлек аша гына ачылырга мөмкин. Совет патриотизмы рухында һәм халыклар дуслыгы идеяләрендә тәрбияләнгән ватандашларыбызның эстетик зәвыгы һәм әдәбиятка карашы да шул ук җирлектә формалашкан. Димәк, туган җир һәм Туган илгә мөнәсәбәт шәхес һәм аның яшәешен генә түгел, әдәбиятыбыз һәм әдәбият алдында торган таләп, ихтыяҗларның да үсеш дәрәҗәсен, тирәнлеген билгеләүче төп үлчәм, төп критерий булып тора. Нури Арсланов поэзиясендә чынбарлыгыбыз һәм яшәү принципларыбыз белән билгеләнгән әлеге критерийны табигый сиземләү генә түгел, аңлы рәвештә күрсәтергә омтылу, ассызыклау бар. Һәм бу, һичшиксез, махсус игътибарга лаек һәм өйрәнелергә тиешле үзенчәлек.

Мисал өчен классик Көнчыгыш поэзиясенә аеруча хас формада иҗат ителгән «Ватандармын» шигыренә мөрәҗәгать итәргә була. Шагыйрь туган халкы язмышы һәм үзенең бөтен тормышы — үткәне, бүгенгесе, киләчәге ватандарлык хисе белән аерылгысыз бәйләнештә булуга игътибар итә. Һәм моның бары тик шулай булырга тиешлеген, ә башкача яшәү мәгънәсез икәнлекне ассызыклый.

Ир ирлеге — ил кайгысын кайгыртуда!
Илем-йортым өчен бөтен җан-арманым.

Сынатмадым Ватан сугышы кырларында,
Тапламадым яхшы атын бабамнарның.

Ләкин Н. Арсланов ватандарлыкны Туган ил бурычларын үзеңнеке итеп яшәү һәм аны яклап көрәшү белән генә дә чикләми, ул аны шәхеснең бөтен хыял-омтылышлары, мәхәббәте, рухи һәм физик тазалыгы, әхлакый камиллеге суммасы итеп карый. Туган илгә, Ватанга бирелгәнлекнең катлаулы һәм монолит күренеш булуын, замандашларыбызда нәкъ менә шундый рәвештә чагылуын, чагылырга тиешлелеген яклап чыга бай тормыш тәҗрибәсе булган өлкән шагыйрь.

Кисәүгә әйләнә янган барча әйбер,
Ә мин яндым да яктырдым — каралмадым!
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Олтан булсам булдым изге туфрагымда,
Чит җирләрдә солтан булып калалмадым.

Әлеге шигырьдән, шул рәвешчә, байтак строфалар китереп, иң яхшысы аны тулысынча күз алдында тотып, ныклап уйланырга, фикер йөртергә урын бар. Һәр юлы халкыбызның тарихи тәҗрибәсе, тапкырлыгы, яшәү мәгънәсе, әхлакый матурлыгы һәм рухи йөзен үтәдән чагылдырып килә. Шагыйрь өчен ватандарлык хисе элек-электән формалаша һәм туплана килгән әнә шул хәзинәләрнең берлеге, яңа шартларда яңача югарылыкта ачык чагылышы ул. Моңарга «Уйлар, сагышлар» җыентыгыннан күпләп, бик күпләп мисаллар табарга һәм китерергә мөмкин булыр иде.

...Мин табынам хакка — акка гына,
Тынычлыкның йөгерәм каршына:
Хәер — тынгысыз кирәк чакта гына,
Хәер, кирәк миңа барсы да:
Кирәк миңа Корваланнар иркe,
Азатлыгы испан халкының...

— дип җырлаган, туган җиренә һәм аның аша бөтен җиһанга гашыйк шагыйрь күкрәгендә уйлар һәм сагышларның чиге юк.

Туган җир — һәммәбезгә бер дәрәҗә якын һәм үз булган изге Ватан нәкъ менә шуннан башлана да... Туган җир, күңелләргә аеруча үз һәм якын төбәк — анда әле дә безнең тәүге тавышларның кайтавазы яңгырыйдыр күк, әкияти бала чак сәхифәләре, тәүге адымнар эзе саклана дыр, хыял, тәүге хисләр, омтылышлар кайнарлыгы суынмаган булса кирәк. Шуңа да гомер буе истән, хәтердән чыкмый сагындырып йөдәтә, берәзлексез үзенә тартып торадыр ул туган җир.

Туфраклары сөрмә, суы ширбәт,
Ризыклары бал да май икән;
Минем туган җирем кебек әйбәт,
Сайран яклар тагын бар микән?!

Шагыйрь Н. Арслановның лирик кичерешләре белән икәүдән-икәү генә калгач, тагы бер кат шул хакта уйга калдым. Инде ничә дистә еллар (мөгаен, ярты гасырга якынаеп киләдер) үзе Татарстан җирендә, Казанда, ә уйлары һич кенә дә туган төбәге Казагыстан киңлекләреннән читләшүне белми... Шагыйрь күкрәгендә мәхәббәт һәм хисләр ташый.

Туфрагында бала чагым таңнары атты:
Казакъ иле үз улыдай үстерде-бакты,
Акын бала дип атады, думбра бирде...
Шуңа артык якын күрәмдер шул казакъны.

Шагыйрьләрчә нечкәлек һәм ир-егетләрдәй тугрылык белән үз итә, әзгәләнеп ярата Н. Арсланов үзенә тормыш һәм яшәү суты биргән төбәкне. Татарстан җирендә туып-үскән укучыларын көнләштерерлек итеп ярата. Әлбәттә, вакыт-вакыт күңелдә эгоистик хисләр дә кузгалып ала, яраткан шагыйрең иҗатында сиңа аеруча якын булган Татарстан җире һәм аның кабатланмас гүзәллегенең дә шигъри гәүдәләнешен мулрак күрәсе, тоясы килеп куя. Күңелгә килә, әмма акыл хупламый — шигърият турында сөйләшкәндә мондый тарлык һәм җирле чикләнгәнлекләргә урын булырга тиеш түгел.

Казан, Казан! Сөеп баккан калам булдың,
Нәкъ җиреңдә тумасам да, анам булдың...

— дип язган шагыйрь иҗаты турында сүз барганда, бу хакта уйлану үзе үк артык булса кирәк.

Күз алдына яңадан татар шагыйре иҗатында гаять үз итеп, сөелеп җырланган Казагыстан далалары, мәһабәт Алатау һәм Кар-каралы, иксез-чиксез киңлекләргә сузылган Кәрәкәү кырлары, Иртеш суы буйлары килә. Күңелдә һәр вакыт киңлеккә, киң күңеллелеккә урынны түрдән биргән әдәбиятыбыз һәм шигъриятебез өчен зур горурлык, шатлык хисләре уяна, куаныч арта. Шагыйрь Акмулла, әдәбиятыбыз классигы Г. Ибраһимовлар иҗатында аеруча тирән чагылган тугандаш казакъ һәм татар халыклары арасындагы дуслык, теләктәшлек идеяләренең замандашыбыз Н. Арсланов иҗатында тагы да баетыла, үстерелә баруына чын күңелдән канәгать буласың.

Иртеш суы Идел төсле киң түгел,
Бер карасаң, **Иделләрдән ким түгел;**
Тоташтырыр идем үзен Иделгә,—
Әкияттәге тылсымчы карт мин түгел.

Ә миңа калса, әкияттәге тылсымчы карт белән бай тормыш тәҗрибәсе туплаган өлкән шагыйрь арасында аерма зур түгел. Белмим, беренчесе Иртеш суларын Иделгә куша алыр идеме икән, әмма шагыйрь Иртеш һәм Идел буйларын үзара гаять дәрәҗәдә якынайтуга, шул елга буйларында үскән күңелләрне дуслык, туганлык җепләре белән аерылгысыз итеп үзара берләштерүгә ирешә. Сәнгать һәм шигъриятгә дә тылсым көче аз түгел шул...

Н. Арсланов иҗатында Казагыстан табигате, тугандаш казакъ халкының рухи матурлыгы, гүзәллеге, чынлап та, киң һәм тирән чагыла. Ләкин бер казакъ халкы рухы белән генә чикләп карау бу шагыйрь иҗатын шактый тарайтуга да китерергә мөмкин. Н. Арсланов иҗатында, гомумән, Көнчыгыш поэзиясенең — бүгенге

һәм, беренче чиратта, классик Көнчыгыш поэзияләренең күп кенә специфик үзенчәлекләре характерлы чагылыш таба. Бу— шигырь төзелешендә, аларның рифмалашу, ритм системасында гына түгел, ә барыннан да элек, шигъри фикерләүдә, аның хикмәтлегендә, ачык һәм якты төсләр өстенлек иткән образларда, лирик геройның рухи активлыгы һәм романтик рухында аермачык күзгә ташлана, өскә калкып чыга.

Кашың Амур җәяседәй каш икән бер,
Каушавымны сиздереп ник фаш итәмдер?—
Тылсымыңнан исердем шул, әйләнде баш,
Гомерлеккә тынгы белмәс баш икән бер.

Хәер, шагыйрь үзе дә классик Көнчыгыш поэзиясе үрнәкләреннән өйрәнүен, шигърияттә шуларга йөз тотуын яшерми. Аерым алганда, «Ал син шәфәкъ болытларын» шигырендәге «Фирдәүсиләр, Ширазилар үрнәгендә язам мәңә бу мәхәббәт ярлыгымны»,— дигән юллар шуның характерлы бер мисалы булып тора.

Классик Көнчыгыш поэзиясе традицияләрен бүгенге шартларда дәвам иткән, аның күп гасырлар буе эшкәртелә, шомара, үсә килгән поэтик һәм идея-эстетик казанышларыннан татар совет шигырен, стиль төрлелеген баетуда киң файдаланган шагыйрь Н. Арсланов. һәм аның иҗаты бүгенге поэзиябездә, иң элек, шушы яклары белән үзенчәлекле дә. Бүгенге татар поэзиясендә Көнчыгыш әдәбиятларыннан килгән традицияләр һәм, аерым алганда, ул традицияләрнең Н. Арсланов иҗатында чагылышы, уйлавымча, махсус өйрәнү һәм кызыксыну объекты булып тора. Һәм бу якын киләчәк эшедер.

Сүз уңаеннан әлеге мөнәсәбәтләрнең тагын бер ягына игътибар итми китү ярамас. Н. Арслановның җиңел агышлы шигырьләрен укыганда еш кына үзебезгә мәгънәләре бик үк ачык булмаган сүзләргә, алынмаларга килеп төртеләсең. Табигате белән алар шәрки һәм күп очракта казакъ сүзләре: **тирмә, мәкян, асау, арман, томак, мәгъбүд, күрфәз, катарда...** Күп, артык күп бүгенге татар укучысына аңлаешлы булмаган сүзләр. Аларга еш мөрәҗәгать итүнең ихтыяҗы шул кадәр үк зурмы икәнни соң? Белмим, кемгә ничек, миңа калса, юк андый ихтыяҗ! Җирле колоритны бирүдә билгеле бер кадәр әһәмияткә ия булуларына да карамастан, алынма сүзләр шигырьнең саф татарча яңгырашын киметә, табигый агышына хилафлык китерә, әдәби телебезне чуарлыйлар... Хәер, бу турыда артык сөйләп тору кирәкме икән? Тик мәнә шундый тенденциянең татар телен бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән, укучылар тарафыннан яратып укылган өлкән һәм тәҗрибәле шагыйрь иҗатында чагылыш табуы бик тә аяныклы. Чиксез тирән хәзинәләре булган әдәби телебез һәммәбезгә дә бер, уртак ич.

Моннан элек язылган мәкаләләрнең берсендә шагыйрь Н. Арслановның шигърияттә елдан-ел яшәрә баруы, иҗатында яшьлеккә генә хас ашкыну, романтика, җете ачык төсләрнең өстенлек итүенә соклану белдергән идем. Бу чынлап та шулай, һәм шагыйрьнең соңгы еллар лирикасының яшьләр тарафыннан аеруча җылы кабул ителүе сере дә ерак яшерелмәгән — шушы үзенчәлек, шушы пафос белән аңлатыла. Юкка гына кайберәүләр: «Яшьләр Н. Арслановтан өйрәнәме, әллә өлкән шагыйрь үзе Зөлфәт һәм М. Әгъләмовлар кебек яшьләргә ияреме», дип шаяртмый, күрәмсең.

Менгән атым баткан ак күбеккә,
Белмим, һаман кая чабамдыр?!
Привал кирәк иде инде күптән,
Әйтерсең лә
Егет чагым белән чамам бер;

Уемда да юк җан суыклары,
Каян соң бу хәят шатлыгым?
И дивана!
Күргәч кенә үскән оныкларны,
Исләремә төшә картлыгым.

Чынлап та, яшьләрдән калышырга теләми, үзенә онык булырдай яшьләрне көнләштерерлек итеп иҗат итә — гашыйк була, ашкына, сагышларга чума, шигъриятнең символы канатлы ат «Пегас» кебек мәхәббәт ялларын җилфердәтеп, илаһи матурлык, мәңгелек гармониягә омтылып яши шагыйрь.

Аһ, романтик күңелем сыймый җиргә,
Гел талпына күккә ашарга!
Ачкычлары кайда икән, Җибрил,
Күк капусын ничек ачарга?

Шундый ярсу, романтик ашкынулы шигырьләр яңадан традицияләр хакында уйлануларга этәрә. Байрон һәм Лермонтовлардан киләме бу рух?.. Хәйям, Сәгъди һәм Хафизлар, фәлсәфи-романтик ашкынулы Көнчыгыш поэзиясе үрнәкләреннәнме?.. «Юк!» дип әйтү хата булыр, өздереп кенә «әйе» дисәң, күп гасырлык традицияләре булган татар шигъриятенең үз казанышларын — Г. Кандалый, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Һ. Такташларны кая куярга... Гомумән, вакыт-вакыт башка әдәбиятлар тәэсире һәм традицияләренә чамадан тыш зур өлеш чыгарып, телибезме-теләмибезме, үзебезне артык фәкыйрьләтеп калды-

рабыз түгелме икән без. Бу очракта да шулай аңлашылмасын: Нури Арсланов милли җирлектә формалашкан шагыйрь, татар шагыйре! Шуның белән бергә аның иҗатында, бөтен татар шигъриятендәге кебек үк, бөек рус әдәбияты традицияләре, Көнбатыш Европа һәм борынгы төрки, классик Көнчыгыш поэзияләренең тәэсире дә һәр даим чагылып килә. Болар исә, үз чиратында, лирик шагыйребез иҗатының форма һәм стиль байлыгына, сурәтләү чараларының күп төрлелеге һәм оригинальлегенә, тематик киңлеге һәм идея-эстетик әһәмиятлелегенә зур йогынты ясыйлар.

Әлбәттә, Н. Арсланов шигырьләре һәм бигрәк тә җырларында өстенлек иткән күтәренке романтик, оптимистик рухның табигате турында уйланганда, шагыйрь шәхесе формалашкан социаль шартларның хәлиткеч роль уйнавын да онытырга ярамас. Зур горурлык белән: «Октябрьның шагыйрь улы мин»,— дип яза ул һәм күңел көрлеге, хисләре кайнарлыгының үзе яшәгән, иҗат иткән еллар, бүгенге чынбарлыгыбыз белән турыдан-туры бәйләнештә булуын да яшерми.

Алышынып торды манзаралар,—
Нинди генә көннәр булмады...
Без мөкиббән идек — ватандарлар,
Яңа Республика уллары.
. . . . . . . . . . . .
Ил-оямда сакта мин торам —
Утлар-сулар кичкән чыдам солдат,—
Яшь күңелле карт бер ветеран.

...Н. Арслановның яшь бер каләмдәше «Тегә белсәң ияр тузмый ул, картаймасаң яшьлек узмый ул», дип язган иде шигырьләренең берсендә. Өлкән шагыйребезнең яңа җыентыгы белән танышканда кат-кат хәтергә төшеп, уйга кереп, теге, кем әйтмешли, «чистый йөдәтеп бетерде» шул халык мәкаленә тартым сүзләр. Һәм менә әлеге бу чыгышны йомгакларга җыенганда яңадан шул сүзләрнең мәгънәсе турында уйга калдым. Сүз тормышта һәм иҗатында тынгылык белмәс, һаман яшь шагыйрь Нури Арсланов хакында булгангадыр, күрәмсең. Кем белә, бәлки яшьлек һәм шигърият, гомумән, үзара аерылгысыз төшенчәләрдер... Вакыт сынауларын узган шигъриятнең дә төп хасиятләреннән берсе яшьлек түгелме?..

Шагыйрь иҗат итә. Димәк, әле яшьлек дәвам итә, дәвам итәргә тиеш дигән сүз. Еллар, дистәләгән еллар сынавын узып, янып-көеп, картаюны белми, иҗатында яшәргәннән-яшәрә барып җырлаган, моңланган шагыйрь Н. Арсланов. Вакыт һәм шигърият сынауларына алга таба да йөз белән каршы барырлык шагыйрь. Яшәү— көрәш, яшәү — иҗат. Яшьлек ялкыннарын шулай сүндерми-сүрелдерми көрәшергә, иҗат итәргә!.. Габделҗаббар Кандалый әйткәндәй: «Якутлар табыладыр вакыт белән, вакытлар табылмыйдыр якут белән»...

**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ.**

Шәүкәт Галиев

# ХИКМӘТЛЕ СҮЗЛӘР

*«Юмористның куен дәфтәрендәниләр бар икән?» — дип кызыксыналар. Кызыклар тулып ята инде анда — мәсәлән, язылмаган романнар, повестьлар, поэмалар дисеңме... Ә ник язып мәшәкатьләнергә ди, барыбер мисалга хикмәтле сүзләрен генә өзек итеп китерәләр ич! Укучыга эшне җиңеләйтеп, шактый вакытын янга калдыру нияте белән, мин турыдан-туры шул өзекләрне язарга булдым...*

*Бу жанрның мөстәкыйль яшәргә хакы бар дигән ышаныч белән, «Хикмәтле сүзләр»не укучыларга тәкъдим итәм.*

*АВТОР.*

### МАКТАНУ ДА ГАЕП ТҮГЕЛ — ТУГАН ҖИР БЕЛӘН МАКТАНСАҢ!

Күл — туган ягыннан аерылырга теләмичә бөгәрләнеп яткан инештер!

Күңелдәге сагыну бөресе туган җирдән киткәч ачыла...

Чыпчыкка да бер Ватан,
Лачынга да бер Ватан.

Бөек кешеләрне һәркем үзе сыйдыра алган чаклы күрә...

Байрак җилфердәгәндә матур, хәрәкәттә тере!

Туган җир йөзенә кызыллык китермә!

### ГАЛӘМ ГИЗГӘН БАТЫР ДА КӨЧ ҖЫЯРГА ТАБИГАТЬКӘ КАЙТЫР

Язның беренче карлыгачлары — кара каргалар килде!

Кара каргалар килгәч, күңелләр яктырып китте...

Язгы ташу яз ташый!

Килер язны үткәнен сагынганга көтәсең.

Язын бар йөрәкләр дә бер яшьтә!

Кәккүк — җәйнең кайтавазы...

Кайсы кош үзе матур, кайсысының сайравы матур.

Гомере бер көн булган күбәләкләр дә мәңге яши!

«Өй артында — шымытыр...» — ягъни чәчәк аткач та ботарлап бетергәннәр шомыртны.

«Кирәк тирәкне ега» — ләкин «кирәк»кә дә чик кирәк!

Җәй сәламәтлеге — кызуда, кыш тазалыгы — салкында...

Завод морҗасында кош сайрамый.

Аксак карга сак.

Кала кары кара...

Салкын чишмәләрдән җылы истәлекләр генә торып калмасын...



## СУГЫШНЫ СЕКУНДЛАР БАШЛЫЙ, ЕЛЛАР ГЫНА БЕТЕРӘ...

Җиңү көненең дә иң соңгысы булсын — сугышлар кабатланмасын!

Сагыш — сугыш сулышы...

Балаларны аналар тудыра, батырларны көрәш тудыра!

Кояшта яфрак матурлыгы күренә, давылда тамыр ныклыгы беленә!

Батыр — батмас,<br>Куркак — калыкмас!

Ю к л ы к т а сынатмаган т у к л ы к т а сынган...

## КАЛАЙ СӘГАТЬ ТӘ АЛТЫН ВАКЫТНЫ КҮРСӘТӘ

Сәгать — егерме дүрт ташлы вакыт тегермәне.

Сәгать теле — барлык милләтләргә дә аңлашыла торган тел.

Вакыт кадерен белмәүчегә сәгать телен күрсәтә.

Сәгатең алга китсә, үзең артка калырсың.

Һәркемдә сәгать, карап кына торабыз, алай да вакыт җитми!

Мәңгелек утны да мизгел кабыза!

Борын заман да заманында хәзерге заман булган.

Берзаман безнең заман да булыр борын заман...

Җинаятьле елларның бармак эзе гасырга төшеп кала...

Пәрәвез паровозны туктата алмый.

Үткән гомер әрәм түгел, әрәм үткән гомер әрәм!

Исәннәр үлгәннәр акылы белән яши...

Үткәннәрне үпкәләтмә, киләчәкне үртәмә!

## АШ ТӘМЕ — ЭШ ТӘМЕНДӘ!

Эшләп ару — тәнгә дару.

Яратмаган кеше белән яраткан эшне дә эшләп булмый..

Иң тиз туйдыра торган эш — ял...

Комсыз булсаң да ярый — эшкә комсыз булсаң!

Җир эшен авырсынмасаң,
Авыр җимешләрен җыярсың.

Кашык белән көй чыгарып та тамак туйдырып була...

Мич башындагы эш башында була алмый.

Базмаган — базда утырган.

Йокы мичкәсе кыяр тозларга да ярамый.

Яшәүне кушәүгә алыштырган.

Авыл хуҗалыгын авыз хуҗалыгы дип аңлый...

Ашауда ялкаулар юк.

Эш — эшкә, урын — ашка...

Әрәм тамакка
Әрәм табак та!

«Алма пеш, авызыма төш!» — дип ятканда, алма төшеп тешен сындырган.

Бер тиле бозганны ун акыллы төзәтә.

Уңмаса а ш л ы к,
Урнаша а ч л ы к...

Кара көндә кара икмәк күз алларын яктырта.

Пычракны яратмасаң — җиңеңне сызган!

## КЫЗЫКНЫ ТОРМЫШТАН ГЫНА КӨТМӘ, ҮЗЕҢ ДӘ ТОРМЫШНЫ КЫЗЫКЛЫ ИТ!

Менгән биеклектә тору ансат түгел. Төшкән түбәнлектән чыгуы тагын да читен.

Бүген шатлык киләсен белгән булсам, кичә кайгырмаган булыр идем.

Бүтәннәр белән тарткалашып, үзең белән көрәшергә вакыт та калмый...

Зарланганны яратмыйбыз, зарланырга яратабыз!

Кем — шатлыгын кайгырып уздыра,
Кем — кайгысын да көлеп үткәрә!

Кеше ошатмаса бер хәл, үзеңне-үзең ошатмый башласаң нишләрсең?

Без беркатлылардан көлгәндә, бездән кем көлә микән?

Борчылуыңның сәбәбен белсәң, тынычланып та була.

## СЫНАТМАГАННАРНЫ ТОРМЫШ КҮБРӘК СЫНЫЙ

Мәңгелек дөньяны мизгел гомерем белән үзгәртәм дип яшә!

Барын да гафу итү киң күңеллелек булмагандай, таләпчәнлек тә тар күңеллелек түгел.

Дөньяны төзәтә торгач, бөтен дөньясы белән бозылышып беттек!

Үзсүзлелек үзең хаклы булганда гына яхшы.

Кайчакта көчсезлегеңне күрсәтмәскә дә көч кирәк!

Көчсез көчленең көчсез көнен күреп көчәя.

Шапалакка кунган чебен исән кала...

Шәхесне ихтирам итсәң, хатасын да аңларсың.

Юл авыр булса да, юлчылар бетми.

Һәр сәфәр —
Фәлсәфә!

Тегәрмәч эчендә йөгергән тиен ташбаканы да уза алмый.

Борчалар гомер буе көрәшәбез дип инандылар...

Һәр таштан да ут чыкмый.

## ЯТЫП КАЛГАНЧЫ, ЯЗЫП КАЛ!

Сәнгатьтә тирәнлеккә төшү өчен биек күтәрелергә кирәк!

Халыкның шатлыгына — үз җырчысы, кайгысына — үз җырчысы...

Чорың нинди — җырың шундый!

Мәңгелек каләм белән гомерлек фикер язсаң да ярар иде...

Әдәбият тормышта фокус күрсәтү түгел, тормышны бер фокусҗыеп күрсәтү.

Тормыш чынлыгын ялангач күрсәтергә ярамый — берәр нәрсә кидерергә кирәк...

Өйрәнчек остазын уздырса, бу — остазның җиңүе!

Беренче булырга күнекте исә, кеше икенче урынга кала.

Дан үзе турында уйлаганнардан ерагая.

Суын алмаган кое тизрәк корый...

Тәнкыйтьче язучыны үз дәрәҗәсенә күтәрәм дип шактый төшергән.

Кем лирикка илһамчы, кем — сатирикка...

Көлке көлә килә, елатып китә.

Мәзәк аңламаган кешегә юморист тәртип бозучы булып күренә.

Сатира уты үт кебек — тормыш организмына бик кирәк!

Тормышта үз принцибы булмаган язучының әсәрендә нинди принципиальлек булсын?

Бер халтурщикка яхшылык эшләсәң, мең укучыга начарлык кылырсың!

«Кыскалык — талантның сеңелесе» булгач, озынлык — халтураның апасыдыр?

Тормышны артык шомартма — шома юл тайгак була...

Искергән м э т р дөрес үлчәми...

Үзенең яхшы атын оештыра-оештыра яман аты чыккан...

Кайсы анекд о т дошманның ут ноктасына әйләнә...

Әдәби хәрәкәткә хәкарәт иткән...

«Яшә!» дип язылган такта төшеп башын тишкән...

Мемориаль такта — кадер тактасы: кабер тактасыннан соң йөри...

## СҮЗ ЭЧЕНДӘ ХИКМӘТ БАР

Кем сүзгә тапкыр, кем сүзгә такыр...

Тапкыр сүз мәгънәне тапкырлый!

Тапкыр сүз ничә тапкыр кабатланса да тапкыр!

Күңел күзең булмаса, күңел сүзең юк инде!

Остаз барда телең тыйма — үзең дә остар!

Чын оста — гомер буе өйрәнчек.

Кайчакта сүзсез җыр әйбәт, ә кайчакта — җырсыз сүз...

Нокта — сүзләр таралмасын өчен җөмлә соңында кагылган кадак.

«Сүз йөри...» — диләр. Җәяүлеләре йөридер, канатлылары оча!

Юбилей китабына язылган кереш сүз — хуҗа исеменә әйтелгән озын тост!

Ялгыш телен тешләгән... туган телен...

Туган телгә тел тидергән — тилергән!

Ана телен оныткан — анасын да оныткан.

Серне, бергәләп саклауга караганда, ялгыз саклау ышанычлы.

Ачыктан-ачык сөйләшү ябык ишекләр артында була.

## ЧЫН ЯЛГАН БУЛА, ЯЛГАН ЧЫН БУЛМЫЙ

Эчтән янсаң да, төтенең туры чыксын!

Ялган сөйләп хаклыкны якламыйлар.

Мәгънәсезлекне белү дә мәгънәле эш.

Табу өчен нәрсә эзләгәнеңне белергә кирәк!

Акбур белән кара фикер дә язып була...

Дуга гомер буе тураерга омтылды — күбрәк файда китерермен дип уйлый торгандыр инде...

Сукырга ишарәләп, чукракка кычкырып ни мәгънә?

## НАДАНЛЫГЫҢНЫ ТАНУ ӨЧЕН ШАКТЫЙ ГЫЙЛЕМЛЕК КИРӘК!

Тизрәк алга бару өчен туктап бер уйлану да кирәк...

Акыллы киңәш — яртылаш кимегән эш.

Фикер — чая кош, әмма браконьерлар аңа да тидерә...

Табигатьтә уйлы уйсызны ашый да, тормышта төрлечә була...

Миеңне дә миең ирешкән дәрәҗәдә генә өйрәнә аласың...

Аллалар да кеше ирешкән акыл дәрәҗәсендә зирәк...

Акылга утыру әле ул тик утыру дигән сүз түгел...

Бик акыллы булып йөри-йөри дә, юләргә калуың бар...

Кем куенында таш йөртә,
Кем уенда таш йөртә...

Акыллы фикер әйтәм дип, ул шундый катлаулы фикер әйтте ки, хәтта үзе дә төшенә алмады...

Сәхнәдә аңгыра ролен уйнарга да акыл кирәк.

Техника заманында да энә белән кое казыйлар...

Югары белемне күпләр ала, тирән белемне кемнәр ала?

Коры галим — чи надан!...

Ул әзерләгән рухи азык эчкә тия...

Буйга җиткән, уйга җитмәгән...

Башыңны ташка орма — таш авыртыр!

Бер нәни генә кимчелеге бар — мие юк...

Башы буш булуга карамастан, фикер туарга урын юк...

Башы тулы цифр: гел нольләр дә нольләр...

Алфавит буенча карасаң, Ахмак та Акыллы белән бер тирәдә.

Акыл теше ахмакка да чыга.

Фәкыйрь фикерле факыр...

Надан сүзлек карамый, галим аны гомер буе укый!

Күләгә — яктылык юлдашы...

Ахмак акылдан язмый.

Мин сезгә шундый акыл бирәм: беркайчан да акыл бирергә ашыкмагыз!

## ЯШЬЛЕК — ИРЕННӘРГӘ КУНЫП САЙРАГАН САНДУГАЧ УЛ...

Күләгәң күләгәмә орынса да күңелем тетрәнә...

Гашыйклар ай яктысында кызына...

Йөрәккә ачкыч яратып булмый, яратып кына ачып була!

Иреннәр яратуны сүзсез дә аңлаша...

Дәртле тәндә чүпрәк тә рәтле!

Тойгыларның ымсынып кына калганнары тулырак...

Эзләребез — янәшә, юлларыбыз — төрле...

Кызлар матурлыгы — пропуск, ачылмас ишекләрне ачтыра!

Экияттәге сихерче карчык тикмәгә генә чибәр кыз сурәтенә керөп алдамый...

Җете кызлар тиз уңа...

«Йөрим синең белән мөлдерәмә тулып», — диде йөкле ханым иренә...

Язмышына җиңел караган кыз авырга кала...

Кызлар арасында яхшылыгы белән яманаты чыккан егет...

Мәхәббәтсез үткән көннәр — үлгән көннәр.

## БЕР БАЛАЛЫ — КҮП БӘЛАЛЕ.

Баласыз гаиләдә ир белән хатын бар, ата белән ана юк...

Баласызлар бакчага чәчәк утырта, балалы бәрәңге тутыра.

Балалар туу азая — проблема туа...

Бала чагың — баллы чагың.

«Малай актыгы!» — дип беренче балага да әйтәләр...

Кайсыбер ата-анага охшау баланы бәхетсез итә...

Бүтәннәрдән яхшырак итәргә теләсәң, үз балаңа кырысрак бул.

Балалар — тормыш чәчәкләре. Җимешләре нинди булыр?

Әти-әнине дә аңлый башладык, үзләре генә юк...

Кыргый алма яшел була,
Үги бала яшьле була...

Онык — бабасының киләчәктәге вәкаләтле илчесе.

Оныклар бабайларны яшәртә.

Хәзерге балалар күпне белә. Хәзерге бабалар да аз белми!

Гормоннар да, гармуннар сыман, үз көснә биетә...

## КАЙЧАК ПАРЛЫЛАР ДА ЯЛГЫЗ БУЛА...

Яратканыңа ярашканыңны сизми дә каласың...

Иң бәхетле чагың — бәхет турында уйламаган чак...

Бәхетле багучыга бармас.

Бәхетлеләр бәхетсез мәхәббәтен сагынучан...

Кайгыны адаштырып, шатлыкны иялэштереп булсачы!

Ир белән хатын бер-берсенең характер скульпторлары...

Ир белән хатынның холыклары я яраклаша, я яңаклаша...

Мәхәббәтләре булмаган ир белән хатын бала ягыннан туган тиешле кеше генә...

Мода — хатын-кызның кимчелеген уңыш итеп күрсәтә торган могҗизадыр.

Әби үз яшьлегендәге мода белән киенә...

Җанкисәгенең җан күсәгенә һәм җен кисәгенә әйләнгәнен абайламый калган...

Башына уклау төшкәч кенә хатыны искә төшкән...

Тиз танышкан — озак тынышмаган...

Кошелогыңны югалтсаң да, кешелегеңне югалтма!

Нәзакәтле тупас.

«Туа мөгез чыкмый, тора мөгез чыга», — дип башын кашыды бер ир...

Шик — шикәр түгел, тиз эреми...

## ИСКЕ ДУСЛАРНЫҢ ҮТКӘН ГОМЕРЕ УРТАК

Һәр кешегә дуска түзгәндәй түзсәк, бер дошманыбыз да булмас иде...

Бер дустым гына китте дә, тылым, фронтым ачык калды...

Яшең арта, гомерең кими, дошманнарың арта, дусларың кими...

Нигә миңа йөз ел гомер — якыннарым янымда булмаса!

Бер-берсен яхшы белгән дуслар, күз иялəшеп, бер-берсен белми башлый...

Кайсы кешене якыннан белгән саен ерагаясың...

Арада — дуслык иде,
Арада — бушлык инде...

Дус белән дус дусны бүлешә алмый дошманлашкан.

Кайсы д у с үзенең киресенә дә әйләнә — с у д...

Үзен генә яраткан кешенең дусты булмый — мәхәббәте үзенә китеп бетә...

Дустына хыянәт иткән — үзен югалткан,
Үзенә хыянәт иткән — намусын югалткан.

## КОЕЛГАН ЧӘЧЕҢНЕ УЙЛАП ЧӘЧ АГАРТМА!

Акыллы кеше картайгач та матур кала.

Кайсы картлар белән сөйләшү яшәртеп җибәрә.

Аксакал бул, аксак акыл булма!

Үткән көннәрнең төннәре дә якты...

Яшьлекнең ни икәнен аңласаң — картайдың дигән сүз...

Яшен яшәгән —
Яшене яшьнәгән...

Яшьләргә — романтизм,
Картларга — ревматизм...

Саулыкны сатып алып булмый, сырхауны бушлай да биреп булмый.

Карт йөрәккә шатлык та авыр...

Яшьлекнең грамматик хаталары картлыкта драматикка әйләнә...

«Сыер гомер буе диетада әле!» — дип әйтте ди бер булдыксыз.

Кысан киеп кыйналгач,
Иркененнән интеккән...

Авыру башта й о г а,
Аннары — е г а...

Сәламәтлек — шөкер, калганына — төкер!

Йортым озак яшәсен дисәң — таштан сал,
Үзем озак яшим дисәң — агачтан сал.

Сукыр кояшка туры карый дип көнләшмә.

## ТЕЛ ОЗАЙТКАН — ШТАТТАН КЫСКАРГАН...

Кыеклап әйтсәң дә, турысын әйт.

Кешегә үткәреп һәм үтереп әйтәсе килә, үзеңә киная дә җитә...

Мактауны халык алдында әйтсеннәр, тәнкыйтьне — колагыма...

Берәүнең тәнкыйтькә колак салырга борыны комачаулаган.

Телләр озая,
Штат кыскара...
Я, әйтеп кара!!!

Тәнкыйтьләргә маһир кешене президиумга утырт.

Бүкәнне үсмәүдә һәм алга бармауда гаепләделәр.

Шома багана агачның кытыршы якларын тәнкыйтьләде.

Бал кортының чагуы файдалы икәнне дә беләләр, шулай да ул килеп кунса, сугып төшерәләр...

Мөгез кисү эшендә мөгез чыгаручылар да булгалый...

## ТЕЛ ТЕГЕРМӘНЕ ГРАФИНДАГЫ СУ БЕЛӘН ӘЙЛӘНӘ

Берәүләр өчен җыелыш — чабып арган аякларга ял биреп, кул чабып ала торган урын.

Кайбер җыелышта утырмасак та, гомер үтәр иде, әмма әрәм үтмәс иде...

Кайбер җыелышларда эчелгән суны тегермәнгә койсаң, он суы да, тоз суы чыгар иде!

Графиндагы суны доклад укыган кеше эчеп бетерде, язган кеше сусап утырды.

Кат-кат җыелыш казанышы түгел, казна эшен калдырган каза эш...

Доклад — кемлегеңне күрсәтә торган лакмус кәгазе.

Куерта торгач, көн тәртибендәге мәсьәлә шактый сыеклана...

Көннең кадагы эшләпәле дә, ялан башлы да, башсыз да була...

Җыелышта күргән төш рас килә.

Ярты гомере җыелышта, яртысы өендә йоклап үтте. Калганын ул бик тырышып эшләде!

Берәүнең йөзендә борын хаким, икенченең йөзендә авыз баш!

Гәптәшләр арткан саен сүзнең мәгънәсе кими.

Информация ташкыны күмү бәла түгел, информациясез юшкын күмү бәла!

Су басудан котылган дөньяны сүз генә басмаса ярар иде!

Телдән алда йөрергә өйрәнгән аяк кайчакта телне куып җитә алмый!

Берәүдән сүзне штопор белән дә алыр хәл юк, берәүне бөке белән дә томалап булмый...

Әйтер сүзең юклыкны сиздермәс өчен озак сөйләргә туры килә...

Тыңласыннар дисәң, аз сөйлә,
Ишетсеннәр дисәң, кычкырма...

Сакау карга каты каркылдый.

Сүзләр микрофонның бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты.

Җыелыштан кайтканда теленә машина баскан...

Залдагы кешеләр төрле-төрле була, трибунага чыккач кына бертөрлегә әйләнә...

Бүтәннәрнең күп сөйләвен үзең туктагач кына күрәсең...

## ДӘРӘҖӘ — ЛИФТ СЫМАН: БЕР КҮТӘРЕЛӘ, БЕР ТӨШӘ...

Дәрәҗәле эштәге яшьтәшең дә олырак.

Яңа башлыклар яңабаштан яңа эш башлатып башны бутады.

Фикерле хезмәткәр фикерсез түрәгә бәла...

Бәләкәй буйлы казый — озыннарга да өстән карый!

Кешене түбәнсеткән — үзен кимсеткән!

Тупаслык — мин-минлек күләгәсе.

Казна эшендә казына-казына азынма!

Ашауны урынбасарга тапшырмыйлар.

Дуга белән Даганың аермасын белсә, ул әле дә җитәкчелек итәр иде.

Түрәнең төшкәнен генә сүгәләр.

Күтәрелүнең чиге бар, түбән тәгәрәүнең чиге юк...

Дүрт аяклы өстәл дә абына дип юанды.

## КЫЧКЫРЫП ТОРГАН ТЫЙНАКЛЫК

Сабын куыгы: «Миңа салават күпере сыя!» — дип кабарынды...

Үзен мактап кычкырды да, кайтавазын рәхәтләнеп тыңлады.

Юньсез мактаса хур итәр.

Бер генә уңай фикере бар — ул да булса үзе турында...

Үз тормышың җайлангач, бөтен дөнья көйләнгән кебек!

Җир үз күчәре тирәсендә, абзый үз күчәне тирәсендә әйләнә.

Үз чебененнән фил ясый, синең филне чебен итәргә күп сорамый...

Беркатлылыгы турында кат-кат әйткәненә ышанып беркатлы булма.

«Миңа яңа пальто тактылар!» — дип мактанды Иске Төймә.

«Мин Арысланны тешләдем!» — дип күкрәк какты Борча.

«Филләр бездән ясала!» — дип куйды Чебен.

«Сөяксез тел ни сөйләмәс!» — диде скелет эре генә...

Мактау — менә дигән йокы даруы...

Әй яратабыз да инде үзебезне яратканнарны!

Үземне генә яраткан чагым — үземне иң яратмаган чагым!

## АРАКЫ БАШКА КИТӘ, АННАРЫ БАШКА ҖИТӘ...

Шешәдәге авызыңа керсә, шешә авызына кергәнеңне сизми дә калырсың.

Эчкән кеше башы белән йөри, аяклары белән уйлый...

Аракы тутырган саен күңел бушый...

Ни эчсәң — шуны авырырсың!

Җиде кат үлчә, бер кат та... эчмә!

«Өч кешелек»тән эчкечелеккә өч адым...

Кыя кебек егетне дә кыяр кебек итә аракы...

Син аракыны эчәсең, аракы сине ашый...

Исерек аунаган җирдә акча калмый.

Кырык градуслыны капкан кешенең холкы йөз сиксән градуска борыла...

Бөке чыгара-чыгара бөкресе чыккан.

Аракыга батучы бөкегәябышыр.

Хәтта кеше акчасына эчкәндә дә үз сәламәтлегеңне эчәсең...

Кемнең «эш» дип кулы кычыта, кемнең «эч!» дип тамагы кычыта...

Өстәлде кунак,
Өстәлгә кун, ак!

Мәҗлес башында җырлаучы булмый,
Мәҗлес соңында тыңлаучы булмый...

Буш вакыттан буш, ватык шешәләр генә калган...

«Азмыштан узмыш юк!» — дип әйтте ди бер мут егет.

Башта ава шешәләр, аннан ава кешеләр...

Шешәләр шешенгәннәргә ишарәлиләр (эчүчегә тел һәм аяк көрмәкләндергеч).

«Саулыгым — байлыгым!» — диде дә, шул байлыгын аракыга туздырып бетерде...

Берәүгә өч метрлы һәйкәл тиеш, берәүгә — өч литрлы...

Эчеп үзен бетергән — үзен эчеп бетергән...

Аракы бик яхшы нәрсә ул... үзенә дошман кешегә!

## ӘЛӘК — БАШКА БӘЛӘК!

Ялган сөйләве дөрес, дөрес сөйлим дигәне — ялган!

Ялгыш та дөрес сүз ычкындырмый...

Төлке койрыгын ябынып йоклый, гайбәтче — телен...

Интриганнар — бик оста сюжет коручылар.

Телчән кеше — билчән кеше!

Ат кешнәшеп, адәм сөйләшеп талаша...

Гайрәт чәчә-чәчә гайбәт чәчә!

Этне кем кайда асрый — кем өй эчендә, кем үз эчендә.

Зур кешеләр гайбәтен сатудан бәләкәй кешеләр тәм таба...

Бүре тиресе ябынган сарык...

Имеш-мимеш ялган җимеш бирмеш.

Кеше ишетсен дисәң — пышылдап әйт!

Үтәли җилдәй сүз йөргән җирдә гайбәт-грипп тиз йога...

Гайбәт сөйлим, дими, информация әйтәм, ди — заманча!

«Этең миңа тел күрсәтте!» — дип хуҗасын эт итеп сүккән...

Еланның теленнән курыкма, тешеннән курык.
Гайбәтченең тешеннән курыкма, теленнән курык!

Ерткыч тырнагын кайрый, гайбәтче — телен...

Гайбәтне бушлай бирәләр, әмма кыйммәткә төшә...

## ЯЛАП ЯШӘГӘННЕҢ ТАМАГЫ ТУК БУЛА...

Начальникның күләгәсендәге мамыкны да чеметеп ала!

Боегучылар барда
Боеручылар була!

Икеле-микеле йөргән Өндәү билгесе, бөкрәеп, Сорауга әверелгән.

Ялгышмас өчен кешегә ияреп йөрде һәм... ялгышты.

Койрык та алдан бара... артка чигенгәндә...

Кеше сагая-сагая саегая...

Ун мең кешелек стадионда кул биреп күрешеп чыккан...

Усал эткә юаш кеше койрык болгый...

Кайбер мәгънәсезнең җирдә яшәвен күреп: «Регламент!» — дип кычкырасы килә.

## ТӘНӘФЕС БЕЛМИ НӘФЕС

Бал корты — кешеләргә җыя, мал корты — үзенә ташый...

Тормыш балына бер кашык дегет — шундый ул егет...

«Коега төкермә, үзең эчәрсең!» — диде бер кибетче, аракыга кушарга су алганда.

Тәүбә итә-итә
Сәүдә итә.

Акча беткәндә кесә авырая — вак акчалар арта...

Комсыз елан койрыгыннан кабып үзен-үзе йоткан!

Бер генә яхшылык эшлә, икенчесен йолкып алыр!

Кем үлгәннәрдән дә тартына, кем исәннәрдән дә оялмый...

Бүре баласын бүреккә салсаң да у р л а р г а карый...

Юлдан язганнар да бүтәннәр белән бер юлдан йөри.

Йом күзеңне, ачкүз!

Угры тугрыны сөймәс, тугры угрыны сөймәс тә сөймәс!

Бүре сарык мәсьәләсен кабыргасы белән куйды...

Хәйләләп намусын яшереп куйган да, соңыннан табалмаган...

Бердәнбер яхшы ягы шул — начарлыгын яшерми.

Йөз суыңны түкмә, йөз сумыңны түлә!

Кешелек дәрәҗәңне саклый белү — иң югары дәрәҗә.

Тозсыз кешене бергәләп бер пот тоз ашамыйча да белеп була.

Этенә була йортыннан бизәсең.

Дуңгызның мөгезе борынында!

Дуңгызның этлегенә эт дуңгызлык белән җавап бирде...

Кара төндә дә белемеп тора йөзе кара!

«Кулым җиңел булсын!» — диде дружинник, хулиганны култыклап.

Законга бармак аша карау — тимер рәшәткә аша карау белән бер.

Явызлыкка — авызлык!

## Роберт Миңнуллин

### Мияулый торган ишек

Тавышлары
Әй әче,
Кычкыруы
Нәкъ мәче.
Ачкан саен
Мияу, ди.
Мин һәр вакыт
Уяу, ди.
Май бирмиләр
Миңа-у, ди.
Мияулый да
Мияулый,
Хуҗалардан
Май даулый...

Ачканда да
Мияу, ди.
Япканда да
Мияу, ди.
Мияулап ул
Туялмый,
Мияулавын
Тыялмый,
Нәрсә соң бу?
Кем аңлый?

...Алмазларның
Ишекләре
Бертуктаусыз
Мияулый.

### Кирәкне бирде әби

Әби әйтә: өлкәннәрне,
Улым, тыңлап өйрән, ди.
Тыңламаган өчен менә
Кирәгеңне бирәм, ди.

Әллә әби миңа ниләр
Кирәкне белә микән?
Пәрәмәч пешерә микән?
Чикләвек бирә микән?

Әбием белми икән лә
Миңа ниләр кирәкне —
Кирәк әйбер урынына
Кирәкмәгән эләкте...

Нәрсә эләккәнен сезгә
Әйтмим инде — уңайсыз.
Әйтмәсәм дә, үзегез дә
Чамалыйсыз бугай сез?!

## Менә сиңа кечкенә!

Бөтереләнәни колын
Гел әнисе янында.
Әнисенә сыенасы
Киләдер шул аның да.
Әле бигрәк бәләкәй шул —
Чаба-чаба йөрисе
Бик килсә дә, үз яныннан
Җибәрмидер әнисе...
Кечкенә дә, усал үзе:
Тешли,
Кешни,
Тибешә.
Әти көлә:
— Колынга, — ди, —
Тибешсә дә килешә...
Мин беркөнне шул колынга
Атланам дип мактандым.
Һәм сизми дә калды колын —
Сикердем дә атландым:
Атландым да, очтым гына...
Яшел чирәм өстенә!
... Менә сиңа нәни колын,
Менә сиңа кечкенә.

## Кем нәрсә тарта?

*Сүз уйнату*

Тегермәнче минем әти —
Тегермәндә ул он **тарта**.
Абыйны да шунда кыстый —
Көн дә аның кылын **тарта**.

Ләкин абый гел баш **тарта**:
— «КамАЗ»ым бик кызганыч,— ди,—
Әле эшли торган эшем
Күңел **тарта** торган эш, — ди.

Клуб идәне дер селкенә
Минем абый биегәндә.
Ул бит Алып батыр кебек —
Ун пот **тарта** ким дигәндә.

Клубка китте ул бүген дә.
Тышта бераү гармун **тарта**.
Шул гармунны тыңлый-тыңлый
Апам тиз-тиз сөрмә **тарта**.

Ә мине кич чыгармыйлар.
Җәйгән әни урынымны.
Чыгармыйлар, шуңа күрә
**Тартып** ятам... борынымны.

# ЛАФОНТЕН МӘСӘЛЛӘРЕ

*Лафонтен (1621—1695) — француз шагыйре, француз академиясе члены. 1657 елда Парижга килеп, поэмалар («Адонис» һ. б.), драматик эклогалар («Климена»), мадригаллар, балладалар, багышлаулар яза башлый. Нахак бәла тагып төрмәгә ябылган остазына теләктәшлек белдереп әсәр язганы өчен 1663 елда сөргенгә куыла. Шуннан соң классицизм стилендә поэма да, повесть та язып карый. Шигырь белән язылган күңелле, шук әкиятләре, хикәятләр китабы һәм атаклы «Мәсәлләр» җыентыгы белән исә үзен иректе фикер иясе һәм күренекле сатирик итеп таныта.*

## Ишәк һәм караклар

Бер ишәкне урлый да ике карак:
«Ул минеке!» диеп берсе дәгъва итә.
Икенчесе «юк, минеке» диеп раслый...
Эш кыйнашка кадәр барып җитә:
Берсен берсе әүмәкләп шаулаша алар.
Берсен берсе рәхимсез тукмаклый.
Шул чакны исә өченче бур килеп
Ишәкне ала да урманга атлый.

Көчле дәүләтләр дә бит, нәкъ шуның кебек,
Көчсез илләр өстенә ташлана —
Үтереш һәм кырыш башлана.
Дөнья шаулатып кычкырышалар...
Кыскасы, бер дә юкка тырышалар,
Һәм алар коры кул белән кала:
Өченче берәү, һич көч куймыйча,
Малны үзенә ала.

## Тау тудыру

Бала тудырып азаплана зур тау,
Тирә-юньдә хәтта җирләр тетрәп тора.
Сыкрана бичара, иелә... Ниһаять,
Тау хәтле биек тау... бер тычкан тудыра.

Бу хикмәт, әлбәттә, гадәти бер мәзәк.
Мин менә язамын булган хәл турында:

Бер шагыйрь, ай буе көчәнеп, үзенә
«Яз син! Яз!» дигән мораль сүзе тукый,
Аннары күпләгән дусларын җыя да
Шәп-шәрә, мәгънәсез бер шарада[1] укый.

## Төлке һәм бюст

Бөеклек дигәнең кайчак гади шәхес кенә була.
Сәбәбе шул: ул бик тә вак, бик кечкенә була.
Лаеклыны олыларга кайчак тик коры сүз кала.
Тик, бәхеткә каршы, белгеч затлар да сүз ала.
Төлкене әйтик, мәсәлән. Ул, идолны[2] күрми торып,
Күңел карашлары белән җаннарына керми торып,
Тыңламый торып сулуын, әйтмәс аның кем булуын.
Данлымы ул, дансызмы ул, санлымы ул, сансызмы ул —
Һич әйтмәс, түзәр, ашыкмас,
Сүзләр кәсасен ташытмас.

... Бер чакны бакчада төлке бер батырның бюстын күрә,
Бөтен яктан иснәп чыгып, аңа гүя сәлам бирә.
Аннары уйланып кала һәм сүзен ярып сала ул:
«Чырайларың әйбәт бик тә!
Матурлыгың салмый шиккә!
Күрдем, рәхмәт! Ярый, хуш! — ди.
— Тик, кызганыч, башың буш!» — ди.
Бу уңайдан әйтеп була шуңа күрә:
Ошбу бюстка охшый әле бик күп түрә.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәсе

[1] Шарада — французча — сөйләү, лыгырдау мәгънәсендәге сүз.
[2] Идол — сын, пот, кешеләр табынырга тиешле тораташ.

# ЭШЧӘН ҺӘМ ТУРЫЛЫКЛЫ ДУСТЫБЫЗ



Безнең яшьлек авыр чакка туры килде. Мин аның кайчан башланганын белмим, ләкин ничек булганын беләм. Без тугызынчы классны тәмамлаган елны сугыш бетте. Сугыш тагын берәр елга сузылган булса, ихтимал, без дә шинель киеп, мылтык асып ут эченә китеп барган булыр идек. Безнең белән бер урамда, бер тузанда уйнап үскән, бездән тик бер-ике яшькә өлкәнрәк булган күп малайлар шулай китеп бардылар да күбесе кире кайтмады...

Без торып калдык. Без исән калдык.

Бүген шәһәрләрдә, авылларда урам тутырып йөргән кешеләрнең күбесе — безнең энеләр, сеңелләр һәм безнең балалар алар. Ә бит моннан утыз еллар элек без дә кемнәрнеңдер энеләре, сеңелләре һәм балалары идек! Шулай итеп, сездермичә генә җирдә буыннар алышына бара.

Гомернең инде яртысыннан артыграгын узгач, әледән-әле артка борылып карыйсы килә. Караган саен мин узган елларны һәм чордашларны, юлдашларны яңадан күргән кебек, яңача күргән кебек булам.

Ниндирәк идек соң без элек һәм хәзер нинди? Ярты гасыр яшәп, энеләргә-сеңелләргә һәм балаларга нәрсә калдыра алдык без — сугыш дәһшәтеннән исән калган бәхетле кордашлар? Еш кына шундыйрак сораулар борчый.

Көндәлек тормышта, үз шәхесеңә кагылган һәр мәсьәләдә — тыйнаклык һәм ни бары белән канәгать булу. Шул ук вакытта туктаусыз тырышлык һәм алга, югарыга омтылыш. Аннан соң, ил һәм халык язмышы өчен җаваплылык тойгысы, гражданлык тойгысы. Сугыш китергән бик күп кайгы-хәсрәтләрне, әйтеп бетергесез мохтаҗлыкны үз җилкәсендә татыган безнең буын кешеләренең төп сыйфатлары менә шундый иде.

1946 елның көзендә без — авыл малайлары, авыл кызлары — Казанга укырга килдек. Университетка, татар әдәбият-тел бүлегенә. Хыялларыбыз, күңел омтылышларыбыз белән без теләсә нинди байлардан да баерак идек. Һәркайсыбыз, үзе генә белеп, әлбәттә, язучы, шагыйрь яисә галим булу турында хыяллангандыр дип уйлыйм. Мин үзем, мәсәлән, университетта укыганда, чынлап та, каләм остасы булырга теләп хыяллана идем. Ләкин университетны тәмамлаганда беркем дә син — язучы, син — шагыйрь, син — галим дип исем биреп чыгармады. Тормыш юлында университет безнең өчен бер биеклек, бер баскыч кына булды. Аны тәмамлагач, безнең кайберләребез мәктәпләргә укытучы булып китте, кайберләребез редакцияләргә эшкә керде, кайберебез исә аспирантурада яңадан укырга калды.

Берничә елдан соң минем сабакташлар арасыннан татар әдәбияты, татар культурасы һәм мәгарифенең күренекле кешеләре үсеп чыкты. Шундыйлардан Казан дәүләт педагогия институты ректоры, татар тел белгече профессор Мирфатих Закиевне, «Социалистик Татарстан» газетасының өлкән журналисты, редактор урынбасары Рафак Тимергалинны, Казан университетында татар теле, әдәбияты укытучылары — фән кандидатлары Сәгадәт Ибраһимов белән Зәет Мәҗитовны, «Ялкын» журналы редакторы Роза Хафизованы, Татарстан китап нәшрияты редакторлары Фәния Гайнанова белән Фатих Хәсәновны, Алабуга педагогия институты укытучысы Саимә Газизованы, РСФСРның атказанган укытучысы Әлфия Абдрахимованы күрсәтергә була. Минем шулай ук башка сабакташларымны — Гыйззениса Гарифуллинаны, Һаҗәр Шәйдуллинаны, Анастасия Бояровалы, Миңнурый Вәлиеваны, Галимә Хәлимова һәм мәрхүмә Әминә Салихованы яхшы яктан искә төшереп үтәсем килә.

Шулар арасында безнең тагын хөрмәтле бер кордашыбыз, сабакташыбыз бар. Аныcы — Гараф Низаметдин улы Шәрәфетдинов.

Студент чакларда без биш ел аның белән бер бүлмәдә тордык. Менә быел февраль аенда аңа да илле яшь тулды. Шул түгәрәк дата уңае белән мин аның турында бераз җылы сүз әйтмәкче булдым.

Укуын бетергәч, Гарафны «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясенә эшкә җибәрделәр. Шулай итеп, аның мөстәкыйль тормыш юлы журналистикадан башланды. Эшендә ул тырыш һәм карусыз булды. Яшь кеше өчен бу, барыннан да элек, әлбәттә, өлкәннәрнең сүзенә колак салу һәм үз эшеңне җиренә җиткереп үтәү дигән сүз. Ләкин шулай да бу әле «тырыш һәм карусыз» журналистны күз алдына китереп бастыра алмый.

Журналист та, язучы да сүз белән эш итә. Алар икесе дә — каләм осталары. Тик шулай да журналистның эше авыррак һәм катлаулырак. Газета көн саен диярлек чыга, һәм журналист үзенең мәкаләсен, әйтик, язучы кебек айлар, атналар буе түгел, ә көне-сәгате белән язып бирергә тиеш. Ул әле язучы кебек үз өендә, кабинетта гына утырмый, бик еш кына аңа завод-фабрикаларга, авылларга чыгып китәргә туры килә. Җәйге матур көннәрдә генә түгел, көзге пычракта да, кышкы кар-буранда да ул берниндн каршылыксыз каядыр «ил читенә» юл тота. Һәм ул редакциягә кирәкле материалны һичшиксез алып кайтырга, я булмаса берәр четрекле мәсьәләне хәл итеп кайтырга тиеш. Кыскасы, журналистның эше һәрчак тынгысыз һәм вакытны бик күп ала. Гараф Шәрәфетдиновлар, Рафак Тимергалиннар редакцияләрдә эшли башлаган елларда исә бу бигрәк тә шулай иде. Кайчагында алар иртәннән башлап кичкә кадәр баш калкытмый «кара эш» эшләп утыралар, кайчагында исә әле ашыгыч материал әзерләп, әле полоса күзәтүче «саф баш» булып төннәрен дә кайтмый калгалыйлар иде.

Яшь чагында Гараф хикәяләр язарга, прозаик булырга хыяллана иде. Ләкин менә шундый тынгысыз шартларда ул бу эшкә артык бирелә алмады.

Хәер, кешенең кеше булуы, ил өчен, халык өчен файдалы булуы аның журналист яисә язучы булуына гына кайтып калмый, билгеле. Һәркемнең тормыштагы урыны кешеләр өчен, гомуми максатлар өчен эшли һәм яши белүенә кайтып кала. Нәкъ менә шул тойгы — ил һәм халык язмышы өчен борчылу тойгысы Гарафта аеруча көчле булган дисәк, һич ялгышмабыз.

Әйтергә кирәк, сугыштан соңгы елларда авыл хуҗалыгы шактый артта өстерәлә иде. Авылда һәр төрле җитешсезлекләр, кимчелекләр тулып ята. Барыннан да бигрәк колхозларда, совхозларда кирәкле техника, тәҗрибәле, белемле кадрлар җитешми иде. Менә шундый шартларда, партия чакыруы буенча, утыз меңчеләр хәрәкәте башланды. Шәһәрдән авылга җитәкче кадрлар китте. 1955 елда минем сабакташым Гараф Шәрәфетдинов та иң артта калган берәр колхозга эшкә китү теләге белдерде.

Бу вакытта аңа егерме биш яшь иде. Шуның өстәвенә, зур белеме һәм туган халкына чиксез мәхәббәте бар. Ләкин шул ук вакытта җитәкчелек эшендә әле берниндн тәҗрибәсе юк. Шулай да аңа ышаныч белдерделәр. Өйрәнелгән, яраткан эшен, иплe-җайлы квартирасын калдырып, бөтен семьясы белән авылга күченеп китте безнең сабакташ.

Менә ул — Азнакай районының Сәпәй авылында колхоз председателе. Иң артта калган колхоз. Дәүләткә 125 мең сум бурычы бар. Һәркайда таркаулык, җимереклек. Авылда яшьләр калмаган диярлек...

Гараф чын тормыш белән очраша. Бу инде сиңа кимчелекләрне фаш иткән хикәя яки мәкалә язу гына түгел. Кимчелекләрне, җитешсезлекләрне хәзер үзең төзәтергә тиешсең! Һәм Гараф муеннан эшкә чума. Яңа эштә, яңа кешеләр белән баштарак бик авырга туры килә. Яшь, тынгысыз председательне кайберәүләр дошман күрәләр, хәтта... үлем белән яныйлар. Гараф чигенми дә, каушап та калмый. Ул бит монда шәһәрдән качып, үз эшләрен җайлау нияте белән килмәгән! Авылга ул үзенең дөрес һәм изге эш эшләвенә инанып, үз халкына әзме-күпме конкрет ярдәм күрсәтәчәгенә ышанып килде.

Озакламый нәтиҗәләр дә күренә башлый. Колхоз дәүләткә булган бурычын тулысынча түләп бетерә. Хуҗалык аякка баса, яңа төзелешләр күренә башлый. Иң мөһиме шул — инде яшьләр туган авылларын ташлап каядыр «бәхет» эзләп китмиләр. Булдыклы, эшлекле колхоз председателе Гараф Шәрәфетдиновне партиянең Азнакай район комитеты бюросына член итеп сайлыйлар.

Шунысы кызык, журналистикадан аерылып торган арада, авылда, эш шартларының бик авыр булуына да карамастан, Гараф беренче мәртәбә иркенләп иҗат эше белән шөгыльләнергә мөмкинлек таба. 1957 елда «Совет әдәбияты» журналының бишенче санында аның «Беренче танышу» дигән күләмле очеркы басыла. Бу очеркны хикәя дисәң дә урынлы булыр иде — чөнки шундый җанлы һәм әдәби яктан оста язылган. Әйтергә кирәк, ул елларда Гараф үзе дә искәрмәстән әдәби әсәр герое булып китә. «Хазбулатның яңа гадәтләре» хикәясен Гариф Ахунов нәкъ менә Гарафның Сәпәйдәге эшләренә нигезләнеп яза.

«Беренче танышу»дан соң Гараф хикәя сыман җиңел укыла һәм җырлап тора торган тагын берничә очерк иҗат итә. 1964 елда исә шуларның барысын бергә туплап «Мастер» исемле аерым җыентык бастырып чыгара. Шул ук вакытта ул әдәби тәрҗемә белән дә шөгыльләнә. Аның тәрҗемәсендә төрек әдәбияты классигы Сабахетдин Алиның «Бәләкәй Хәсән» дигән китабы, «Корея хикәяләре», Польша хикәяләре («Безнең юл») һәм шулай ук Семен Новиковның «Чәчәк атсын тюльпаннар» дип аталган китаплары дөнья күрә.

Бүгенге көндә ул Татарстан китап нәшрияты директоры. Эше җаваплы, эше мактаулы. Татар әдәбияты, татар культурасы үсешенә ул күзгә күренми торган, мактау такталарында күрсәтелми торган көндәлек, даими хезмәте белән өлеш кертә. Бүгенге татар китапларының язмышы турыдан-туры аның тырышлыгы, аның ихтыяр көче һәм җитәкчелек сәләте белән хәл ителә.

Кыскасы, Гараф Шәрәфетдинов татар әдәбияты, татар культурасы һәм мәгарифенә бәйле эшне төпкә җигелеп, чын күңелдән бирелеп тартучыларның берсе. Без аның киләчәктә дә Бурыч, Намус һәм Иҗат алдында һәркайчан турылыклы булып калачагына ышанабыз.

**ФӘТТАХ.**

## ИҖАТ СОЮЗЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

12 декабрьда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында республикабыз иҗат союзларының берләштерелгән пленумы булды. Ул КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежневның «Кече җир», «Яңару», «Чирәм җир» әсәрләрен тикшерүгә һәм хезмәт ияләрен идея-политик тәрбияләүдә иҗат интеллигенциясенең бурычларына багышланды.

Пленумны ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе Мирсәет Яруллин ачты, ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов доклад белән чыкты. Фикер алышуларда М. Горький исемендәге РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким, композитор Л. З. Любовский, СССР Архитекторлар союзының Татарстан оешмасы председателе, РСФСРның атказанган архитекторы С. С. Айдаров, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Р. А. Җиһаншина, язучылар Мөхәммәт Мәһдиев һәм Ләбибә Ихсанова, Казан кинохроника студиясе режиссеры, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Х. Ф. Фәхретдинов, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе художник В. П. Игнатьев катнашты.

Пленум эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, партия һәм совет оешмалары җитәкчеләре катнашты.

Пленум республиканың иҗат интеллигенциясен совет халкының героик эшләренә лаеклы әсәрләр иҗат итәргә чакырган резолюция кабул итте.

## РАЙОНДА БӘЙРӘМ

Казан шәһәренең Бауман районы иҗат коллективлары промышленность предприятиеләре белән элемтәдә торалар. Качалов исемендәге Зур драма театры һәм елга порты коллективы, Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театры, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе һәм Казан тегүчеләре, Г. Камал исемендәге татар академия театры һәм мех берләшмәсе коллективларының иҗади дуслыгы матур традициягә әйләнде.

Икенче ел инде районда, шул дуслыкның чагылышы булып, «Хезмәт һәм сәнгать союзы» дип исемләнгән бәйрәм үткәрелә.

Бу елгы бәйрәм партиянең Бауман район комитетында башланды. КПСС райкомының беренче секретаре А. В. Сафьянов культура әһелләренә, производство алдынгыларына, фән эшлеклеләренә, инженер-техник һәм иҗат интеллигенциясе вәкилләренә район хезмәт ияләренең уңышлары турында сөйләде. Очрашуда язучы М. Мәһдиев, Ленин комсомолы исемендәге яшь тамашачылар театрының баш режиссеры Л. И. Верзуб, РСФСРның халык артисткасы В. Шәрипова чыгыш ясады.

Районның промышленность предприятиеләрендә, төзелеш мәйданнарында, культура сарайлары һәм хезмәт учреждениеләрендә өч көн дәвам иткән бу бәйрәмдә Г. Тукай исемендәге премия лауреаты Равил Фәйзуллин, М. Җәлил исемендәге премия лауреаты Туфан Миңнуллин, шагыйрьләрдән Зәки Нури, Нәби Дәүли, Роберт Миңнуллин, Марк Зарецкий, прозаик Сафа Сабиров һ. б. катнашты.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Азнакай районында нефть ягы яшь язучыларының зона конференциясе булды. Анда Азнакай, Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә, Сарман, Баулы районнарында яшәүче авторлар катнашты. Конференцияне Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев ачты. КПСС-ның Азнакай райкомы секретаре Ф. М. Әминова котлау сүзе белән чыкты, районның экономика һәм культура үсеше белән таныштырды. Аннары Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе язучы Гариф Ахунов докладлы тыңланды. Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге секретаре, язучы Әдип Маликов докладлы нефть ягы районнарындагы әдәби берләшмәләр эшчәнлегенә багышланды. Конференциядә катнашучылар алдында шагыйрь Сибгат Хәким һәм язучы Шамил Бикчурин чыгыш ясады. Әдипләрдән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары, тәнкыйтьче Фарваз Миңнуллин, шагыйрьләр Нәби Дәүли, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, Роберт Миңнуллин, Шамил Маннапов, Хәкимҗан Халиков, Клара Булатова, язучылар Аяз Гыйләҗев, Шамил Рәкыйпов, Мәхмүт

Хәсәнов, Кояш Тимбикова, Җәмит Рәхимов, Ринат Мөхәммәдиев, Мансур Вәлиев, Габделхәй Сабитов конференциядә семинар җитәкчеләре булып катнаштылар.

Конференциядә бик күп яшь авторларның кулъязмалары тикшерелде. Алар арасыннан Марсель Галиев, Әхмәт Гадел һәм Фәрит Гыйльметдинов СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителде. Ямаш Игәнәй һәм Нур Әхмәдиевнең шигырь җыентыклары китап нәшриятына тәкъдим итәрлек дип табылды.

Конференциядә мәктәп укучылары иҗаты да тикшерелде, район авылларында, мәктәпләрдә әдәби очрашулар, кичәләр уздырылды.

## ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫНДА

Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы җыелышында «КПСС Үзәк Комитетының ноябрь пленумы йомгаклары һәм язучыларның бурычлары» дигән темага зур сөйләшү булды.

Партия оешмасы секретаре Туфан Миңнуллин докладыннан соң фикер алышуларда «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури, шагыйрьләрдән Мөхәммәт Садри һәм Нәби Дәүли, «Азат хатын» журналы редакторы Венера Ихсанова, прозаиклардан Самат Шакир һәм Рәфкать Кәрамиевләр катнашты.

Җыелыш конкрет бурычлардан торган карар кабул итте.

## ХЕЗМӘТ ТАНТАНАСЫ

ВЛКСМ өлкә комитетында 1978 ел уңышын җыеп алуда тырышып эшләгән яшь механизаторларны хөрмәтләү тантанасы булды. Кыр батырлары белән очрашуга драматург Рәйсә Ишморатова һәм шагыйрь Роберт Миңнуллин чакырылган иде. Алар хезмәт алдынгыларын кайнар котладылар, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

## ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, язучы, журналист Шәһит Әхмәдиевнең тууына 90 ел тулу унае белән утырыш булды.

Шәһит Әхмәдиевнең иҗтимагый-политик һәм дәүләт эшчәнлеге, язучы һәм журналист буларак калдырган мирасы, халык мәгарифе өлкәсендәге хезмәтләре турында профессор М. К. Мөхәррәмов, өлкән фәнни хезмәткәр М. А. Сәйдәшева, язучы Сафа Сабиров, кече фәнни хезмәткәр Х. Н. Зарипов сөйләде.

Утырышта галимнәр, язучылар, журналистлар катнашты.

## КАЗАН ПРЕМЬЕРАЛАРЫ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры Аяз Гыйләҗевнең «Китмәгез, тургайлар» исемле әсәрен сәхнәләштерде. Спектакльдә СССРның халык артистлары Фоат Халитов һәм Шәүкәт Биктимеров кебек сәхнә осталары белән бергә Д. Нуруллина, А. Гайнуллина, Р. Мотыйгуллина кебек яшь артистлар да катнашты. Спектакльнең режиссеры — РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Марсель Сәлимҗанов.

*
* *

В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» пьесасын сәхнәләштерде. Ул рус телендә «Әниемнең ак күлмәге» исеме белән бара. Әни образын артистка Л. Маклакова башкара. Әсәрне сәхнәгә режиссер Марсель Сәлимҗанов куйды.

*
* *

Республика күчмә театры М. Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты Илдар Юзеевның «Командировка» исемле моңсу комедиясен куйды. Спектакльдә төп рольне артист Наил Шәйхетдинов башкара. Спектакльнең режиссеры — Г. Тукай премиясе лауреаты режиссер Равил Тумашев.

## ЯЗУЧЫЛАР КЛУБЫНДА

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында башкорт халык шагыйре Сәйфи Кудаш белән очрашу булды. Күренекле шагыйрь Л. И. Брежневның «Чирәм җир» әсәре турындагы фикерләре белән уртаклашты, үзенең иҗат планнарын сөйләде һәм шигырьләр укыды. Очрашуда өлкән буын шагыйрьләрдән Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким һ. б. катнашты.

Кичәнең икенче бүлегендә «Чаян» журналы авторлары үзләренең юмористик шигырьләрен укыдылар.

## ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВКА — 50 ЯШЬ

Республикабыз җәмәгатьчелеге Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеровка 50 яшь тулган көнне билгеләп үтте. Драматург Туфан Миңнуллин юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләде. Республикабызның партия һәм җәмәгать оешмалары, иҗат коллективлары вәкилләре Шәүкәт Биктимеровны кайнар котладылар. Академия театры директоры Ә. Хөсәенов КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеевның, Бөтенроссия театр җәмгыятенең, күп кенә театр коллективлары, артистлар һ. б. котлау телеграммаларын укыды.

Тантананың икенче өлешендә тамашачылар Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен карадылар. Әлмәндәр ролен Шәүкәт Биктимеров башкарды.

Юбилей кичәсендә КПССның өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, Татар-

стан Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Консерваториянең Концерт залында ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Мирсәет Яруллинның иҗат кичәсе булды. Анда композиторның иң яхшы әсәрләре — шагыйрь Ренат Харис сүзләренә язган «Кеше» ораториясе, симфоник оркестр өчен язылган «Балалар сюитасы», М. Яруллин тарафыннан эшкәртелгән татар халык җырлары һ. б. тыңланды.

Әсәрләрне Татар дәүләт филармониясе симфоник оркестры (дирижер А. Монасыйпов), Башкорт дәүләт хор капелласы (художество җитәкчесе РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Т. Сәйфуллин), М. Җәлил исемендәге опера һәм балет, Г. Тукай исемендәге филармония артистлары башкарды.

Кичәне Йолдыз Исәнбәт алып барды.

*

* *

Республикабыз сәхнәләрендә тугандаш Башкортстан үзешчәннәре — Бөтенсоюз, Бөтенроссия смотрлары лауреаты исемен алган башкорт халык хор капелласы һәм халык бию ансамбле чыгышлары булды. Моннан 40 ел элек Ленин орденлы һәм Кызыл Байрак орденлы Уфа мотор төзү берләшмәсенең Культура сарае каршында оешкан бу коллектив республикабыздагы чыгышларын Башкортстан АССРның 60 еллыгына багышлады.

Аның җитәкчесе БАССРның атказанган культура работнигы Асаф Даушев.

## КИТАП СӘНГАТЕНӘ КОНКУРС

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсе, Татарстан культура работниклары профсоюзы өлкә комитеты һәм фәнни-техник җәмгыятьләрнең өлкә правлениесе ел саен китап сәнгатенә конкурс үткәрә.

Бу елгы ярышта Һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар», авторлар коллективының «Есть КамАЗ», С. Айдаровның «Казанның архитектура мирасы», А. Нуриева һәм Л. Галиеваның 2—3 класслар өчен «Туган тел» дәреслеге, К. Чуковскийның «Телефон» һәм С. Маршакның «Угомон» дигән китаплары эшләнеше иң яхшы дип табылды.

## КамАЗ ТАРИХЫ

Чаллының «Батыр» кинотеатрында «Коммунизм байрагы» газетасының фотокорреспонденты Николай Тугановның фоторәсемнәр күргәзмәсе ачылды. КамАЗ автомашиналар комплексын төзүгә багышланган бу рәсемнәр гигант төзелеш тарихын яңадан күз алдына китерә.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры артистлары **Гөлшат Ибраһим кызы Сәйфуллинага, Идеал Дәүләт улы Ишбүләковка РСФСРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Совет театр сәнгатендәге зур уңышлары өчен һәм 50 яшь тулу уңае белән Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры артисты, СССРның халык артисты **Шәүкәт Хәсән улы Биктимеровка**, театр сәнгате өлкәсендәге уңышлары һәм 60 яшь тулуын искә алып, шул ук театр артисткасы, РСФСРның халык артисткасы **Вера Егоровна Минкинага КПСС өлкә комитеты** һәм **ТАССР Министрлар Советының Почет грамоталары** бирелде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

*

* *

Әлмәт шәһәренең 25 еллыгы уңае белән, бүлек язучылары Татарстан радиосыннан чыгыш ясадылар. Бүлек җитәкчесе Әдип Маликов нефть ягы авторлары иҗат иткән әсәрләргә тукталды, шагыйрьләр Г. Афзал, С. Сөләйманова, К. Булатова үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар, язучы Рафаил Төхфәтуллинның яңа әсәреннән өзек башкарылды.

*

* *

Әлмәт районының үзешчән җыр һәм бию коллективлары Болгария шәһәрләрендә һәм авылларында булып кайттылар. Аларның София, Плевен, Тырнова шәһәрләрендә, күп кенә авыл клубларында ясаган чыгышларын тамашачылар алкышлап каршы алды. Россия смотры дипломанты Валентина Исламова һәм Халидә Старшинина татар халык җырларын оста башкарулары белән Болгария тамашачылары алдында аерчa ихтирам казандылар. Биючеләр коллективы чыгышлары да зур уңыш белән узды.

Әлмәт үзешчәннәр коллективы белән бергә Болгариядә шагыйрә Сажидә Сөләйманова да булды.

# ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ



Әдәбиятыбыз зур югалтуга дучар булды: шушы елның 7 нче февралендә озакка сузылган каты авырудан соң күренекле, бөтен илгә танылган язучы Габдрахман Әпсәләмов дөнья куйды.

Габдрахман Сафи улы Әпсәләмов 1911 нче елның 28 нче декабрендә Мордва АССРның Рыбкин районы, Иске Аллагол авылында туа. Мәскәүгә килеп, токарь һөнәренә өйрәнә, җиде ел буе заводта эшли. Техникумда һәм М. Горький исемендәге әдәбият институтында укый.

Аның беренче әдәби язмалары Мәскәүнең Муса Җәлил җитәкчелегендәге иҗади яшьләр түгәрәгендә тикшерелә, матбугатка шуннан юл ала. Язучының «Бәхет кояшы» исемле беренче китабы 1941 нче елда басыла. Газета-журналларда күренгән мәкалә-очерклары да, хикәяләре дә, повестьлары да аның күп кырлы сәләтен раслыйлар. Әмма Габдрахман Әпсәләмов укучы күз алдына барыннан да бигрәк күп санлы романнар авторы буларак килеп баса. Аның «Алтын Йолдыз», «Газинур», «Сүнмәс утлар», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр», «Күк күкрәр», «Яшел яр» кебек романнары күп милләтле совет әдәбиятында лаеклы урын алды.

Әдип үз әсәрләрендә төрледән-төрле һөнәр ияләре язмышына мөрәҗәгать итә. Образларның эчке дөньясын ачуда тормышчан детальләрдән юмарт файдалана. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки язучы үзе һәрчак актив булды. Ул бик яшьли эшчеләр арасына килеп керә. Бөек Ватан сугышы елларында, кулына корал тотып, дошманга каршы көрәшә. Инде тулаем әдәбиятка бирелгәч, язучы кабат хезмәт кешеләре арасында кайный, язылачак әсәр геройларының язмышын өйрәнә, укучыларына берсеннән-берсе кыйммәтлерәк әсәрләр бүләк итә.

Габдрахман Әпсәләмов әсәрләрендә совет кешесенең иң күркәм сыйфатлары өстенлек ала, намус, сафлык, тугрылык җиңеп чыга. Иҗатындагы бу юнәлеш тә язучының үз холкындагы тынгысызлыкка, эшчәнлеккә, илгә һәм партиягә бирелгәнлеккә, интернациональлеккә, иҗтимагый активлыкка барып тоташа. Ул күп еллар буе РСФСР һәм ТАССР Язучылар союзы идарәләрендә член булды. «Дружба народов» журналының редколлегиясендә эшләде. Әдәби хәрәкәтнең үзәгендә кайнады. Республикабыз коммунистлары аны КПССның XXII съездына делегат итеп сайладылар. СССР Верховный Советының алтынчы чакырылышында депутат буларак та әдип бик күп җаваплы эшләр башкарды.

Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте Габдрахман Әпсәләмовның хезмәтен һәрчак олы бәяләп торды. Аңа ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Язучы Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнде.

Габдрахман Әпсәләмов «Казан утлары» журналының якын дусты иде. Аның барлык әсәрләре диярлек иң элек шул журнал битләрендә басылып килде. Язучы үзе дә шактый еллар буе журнал редакциясендә һәм редколлегиясендә эшләде, авторларның да, укучыларның да акыллы киңәшчесе, ярдәмчесе булды.


Әйтканебезчә, әдип соңгы елларда каты авырудан җәфаланды. Әмма шул хәлендә дә аның кулыннан калəм төшмәде, яңа әсәрләре туа торды: «Күк күкрәр», «Агыла болыт» романнары, берничә повесте, уннарча хикәяләре һәм публицистик мәкаләләре дөнья күрде.

Күп еллар үтәр, Габдрахман Әпсәләмовның якты хатирәсе, фидакарьлек, партиягә һәм халыкка тугры хезмәт итү үрнәге буларак, безнең күңелләрдә озак сакланыр.

# ӘЙ, КАЗАН

ӘГЪЗАМ ФӘТТАХ музыкасы

СИБГАТ ХӘКИМ шигыре.




Әй, Казан, бабамнар йорты,
Тарихым узган синдә,
Данлы һәм шанлы булып син
Яшәрсең бездән соң да.

Әй, Казан, яшьлегем йорты,
Иң якты эзләр синдә,
Данлы һәм шанлы булып син
Яшәрсең бездән соң да.

Әй, Казан, киләчәк йорты,
Нур чәчеп йөз гасырга,
Данлы һәм шанлы булып син
Яшәрсең бездән соң да.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналның киләсе айда чыгачак 4 нче санында сез язучы Вакыйф Нуруллинның «Аккан су юлын табар» исемле яңа повесты белән таныша башлаячаксыз. Авыл кешеләре, колхоз җитәкчесе язмышына багышланган бу әсәр журналның алдагы ике санына бүлеп бирелә.

Билгеле булганча, бездә, апрель аенда, кадерле шагыйребез Габдулла Тукай туган көнне искә алып, шигырь бәйрәмнәре үткәрелә. Журналның бу санындагы шигырьләр бәйләме дә шул тантанага аваздаш яңгырый. Гәрәй Рәхим, Гамил Афзал, Галимҗан Латыйп, Рашат Низамиев шигырьләре төрледән-төрле зәвыклы укучыларыбызның теләген истә тотып тәкъдим ителә.

Очерклар бүлегендә язучы Марсель Зариповның «Ут бригадиры» исемле очеркы урнаштырылган.

Бу айларда Татарстан язучылары үзләренең IX съездларына әзерләнәләр. Журналның әдәби тәнкыйтькә караган материаллары, шул вакыйгага багышланып, «Татарстан язучылар съездын каршылап» дигән гомуми рубрика астында бирелә. Монда филология фәннәре докторы М. Хәсәнов, тарих фәннәре кандидаты Ш. Хамматов мәкаләләре бар. Шагыйрьләр Сибгат Хәким, Роберт Әхмәтҗанов һәм Казан дәүләт университеты хезмәткәре Ләлә Хәйдәрова «Бүгенге көн поэзиясе турында сөйләшү»не дәвам иттерәләр.

Л. Җамалетдинов һәм И. Кадыйровның сәнгатькә караган мәкаләләрен дә, кечкенә күләмле юмористик әсәрләрне дә, «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары»н да кызыксынып укырсыз дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210